ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

5.2008



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ

**“Татарстан Республикасының Халык язучысы” дигән мактаулы исем бирү турында**



Татар әдәбиятын үстерүдәге зур казанышлары өчен: язучы **Батуллин Роберт Мөхлис улы**на (Рабит Батуллага); язучы **Хәбибуллин Мөсәгыйт Мөдәррис улы**на **“Татарстан Республикасының Халык язучысы”** дигән мактаулы исем бирергә.



**Татарстан Республикасы Президенты** — **М. Ш. ШӘЙМИЕВ**

Казан, Кремль.
2008 ел, 21 Март.

---



Татарстан Президентының 2008 ел 25 апрельдәге Указы белән 2008 елда дүрт Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Лауреатлар арасында шагыйрь **Рәдиф Гаташ** та (Гатауллин Рәдиф Кәшфулла улы) бар. Бу югары бүләккә ул “Газәлләр” (“Мәгариф” нәшрияты, 2001 ел) һәм “Мәңгелек сусау” (“Рухият” нәшрияты, 2005 ел) китаплары өчен лаек булды.

***Каләмдәшебез, хезмәттәшебез—“Казан утлары” журналының поэзия бүлеге мөхәррирен ихластан котлыйбыз!***

*(Указ тексты журналыбызның 188 битендә бирелә.)*

# Казан утлары
# Qazan utları

2008

5
(1027)

*Гамәлгә куючы:*
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
Факс—(843) 541-38-77.
E-mail: kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Айдар ХӘЛИМ. Хунвейбин. *Роман-эпопея* ........ 5
Рәниф ШӘРИПОВ. Соңгы сәлам. *Өч монолог* ........ 44
Марат ӘМИРХАНОВ. Үрбәт ханәкә гыйшкы. *Роман* ........ 50
Айрат СУФИЯНОВ. Киеренке кылы күңелнең. *Шигырьләр* ........ 88
Мәгъсум ХУҖИН. Ипи. Колын. Без. *Хикәя* ........ 91
Рашат НИЗАМИ. Төнге яңгыр. *Хикәя* ........ 105
Лилия СӘГЫЙДУЛЛИНА. Мизгелләр йолдызлыгында. *Шигырьләр* ........ 110

**ТЕЛ ДӘРЬЯСЫ**

Халисә ШИРМӘН. Кул язганны колак ишетсен ........ 113

**СӘНГАТЬ**

Шамил МОНАСЫЙПОВ. Тәрәзәгә язмыш чирткәндә ........ 116
Кадим ҖӘМИТЕВ. Кайттым герман җиреннән. *Скульптор язмалары* ........ 120

**ХӘТЕР**

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Остаз кайгысы ........ 132
Хәнисә АЛИШИНА. "Без үзебез – Себер татары" ........ 161
Булат СӨЛӘЙМАНОВ. Чал Иртышның үзе кебек... *Шигырьләр* ........ 163

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Тарих сабаклары ........ 150

**ФӘН**

Фаяз ХУҖИН. Күпкырлы галим ........ 157
"Татар энциклопедиясе" битләреннән ........ 169
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ........ 172

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Фирдәвес ГӘРӘЕВА. Кәче Барый ........ 166

Зөфәр ФӘТХЕТДИНОВ. Хикмәтле җөмләләр ........ 178

**АК ҖИЛКӘН**

Рәйсә ЮСУПОВА. Тэтчер мажаралары ........ 179

Гаилә елы уңаеннан ........ 86
Берлекнең яңа әгъзалары ........ 185
"Казан утлары" архивыннан ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман-эпопея А. ХАЛИМА "Хунвейбин" (начало), роман М. АМИРХАНОВА "Любовь Урбат-ханакэ" (продолжение), рассказы М. ХУЗИНА "Хлеб. Жеребенок. Мы.", Р. НИЗАМИ "Ночной дождь", Ф. ГАРАЕВОЙ "Незабываемый Бари"; монологи Р. ШАРИПОВА, стихи А. СУФИЯНОВА, Л. САГИДУЛЛИНОЙ.
"Лингвистика": Х. ШИРМАН. "Пусть руками написанное будет услышено".
"Искусство": статья Ш. МОНАСЫПОВА о творчестве композитора Р. ЕНИКЕЕВА; автобиографический рассказ К. ЗАМИТОВА.
"Память": М. УСМАНОВ. "Боль наставника", статья Х. АЛИШИНОЙ к 70-летию Б. Сулейманова "Мы—сибирские татары", стихи Б. СУЛЕЙМАНОВА.
"Литературная критика": Т. ГАЛИУЛЛИН. "Уроки истории".
"Наука": Ф. ХУЗИН. "Многогранный ученый", Ф. ГАРИПОВА. "История наших деревень" (продолжение); страницы из "Татарской энциклопедии".
З. ФАТХУТДИНОВ. Крылатые слова.
"Белый парус". Р. ЮСУПОВА. "Приключения Тэтчера" (продолжение).
Новые члены Союза писателей.
Из фотоархива журнала.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Казанский вокзал. Писатель Габдулла Галиев.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

"Prose and poetry": novel-epopee by A. HALIM "Hunveybin" (beginning), novel by M. AMIRHANOV "Love of urbat-hanaka" (continuation), stories by M. HUZIN "Bread. Foal. We.", R. NIZAMI "Night rain", F. GARAEVA "Unforgettable Bari"; monologues by R. SHARIPOV, verses by A. SUFIYANOV, L. SAGIDULLINA.
"Linguistics": H. SHIRMAN. "Written by hands will be heard".
"Art": article by SH. MONASYPOV about creativity of composer R. ENIKEEV; autobiographical story by K. ZAMITOV.
"Memory": M. USMANOV. "Pain of instructor", article by H. ALISHINA to 70th anniversary of B. Sulejmanov "We are Siberian Tatars", verses by B. SULEYMANOV.
"Literary criticism": T. GALIULLIN. " History lessons".
"Science": F. HUZIN. "Outstanding scientist", F. GARIPOVA. "History of our villages" (continuation);
Pages from "Tatar encyclopedia".
Z. FATHUTDINOV. Catchwords.
"White sail". R. YUSUPOVA. "Thatcher's adventures" (continuation). New members of Union of writers.
From photoarchive of magazine.
Our calendar.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Kazan station. Writer Gabdulla Galiev.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 29.04.2008 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Т–515 Тираж 5302.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-н шрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2008 ел.



Айдар Хәлим

# ХУНВЕЙБИН

РОМАН-ЭПОПЕЯ

*Дөнья буйлап таралган татар мөһаҗирләренә багышлана*

## БЕРЕНЧЕ КИТАП*

### Автордан

*Соңгы ун ел гомеремнең мәгънәви нәтиҗәсе булган ошбу романым басыла башлардан алда мондый мөмкинлек биргәне өчен журнал мөхәрририятенә рәхмәт белдерәм. Әсәр белән танышу укучылар өчен бәйрәмгә әверелер дигән өметем зур. Әсәрем басылу уңаеннан аларга шушы кечкенә эндәш сүз белән мөрәҗәгать итү урынлы булыр дип уйладым.*

*Исеме ят яңгыраса да, "Хунвейбин"—бүгенге татар милләтенең хәл-әхвален сурәтләгән саф милли-психологик роман. Хунвейбин, кемнәрдер уйлаганча, ниндидер милләт яки сыйныф түгел; ул, дөресрәге, хунвейбинчылык—милли затсызлану; ул хәтта ки образ, символ да түгел: ул—халәт, күренеш.*

*Әсәрнең сюжеты да, яратылыш, тәенләнеш, үсеш, чишелеш юллары гаять катлаулы. Мондый катлаулылык автор тарафыннан куелган ихтыяри үзмаксат түгел. Ул әсәр каһарманнары—беренче чиратта соңгы йөз елда татар халкының бер тере кузәнәген тәшкил иткән мөһаҗир Сәлахиләр нәселе кичергән милли-тарихи тетрәнүләрнең безгә хас булмаган, гадәттән тыш, молекуляр дәрәҗәдәге катлы-катлы катаклизмнар аша үтүенә бәйле. Вакыйгалар төрле кыйтгалар, илләр, төрле телләрдә төйнәлә һәм коллизиягә керә. Ил эчендәге һәм ил тышындагы татар җәмгыятенең һәммә катламнары тормышының социаль, тарихи-иҗтимагый, әдәби-нәфис, урыны белән кискен публицистик, урыны белән кискен сатирик яссылыкта сурәтләнүе, тел-стиль чараларының күп тармаклы булуы, конфликтларның еш кына*

---

* Журнал варианты.

Айдар ХӘЛИМ (1942)—*шагыйрь, прозаик, публицист, җәмәгать эшлеклесе; татар, башкорт, рус телендәге күпсанлы китаплар ("Тилергән сирень", "Татар вакыты", "Талант. Шәхес. Шагыйрь") авторы. Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясе лауреаты. Чаллыда яши.*

*символлар аша чишелеше—болар барысы да яшәеш һәм сәнгати дөреслек таләпләреннән туган чынбарлыклар.*

*Шуңа күрә "Хунвейбин" без күреп-укып өйрәнгән "йөгрек беллетристика" түгел. Укучыдан түземлек һәм сабырлык сорала. Бирегә гасыр (роман) башында куелган сорауга җавапның гасыр азагында гына табылуы, ә бәлки әлегә бөтенләй табылмыйча калуы да мөмкин. Романның беренче китабы "Сәлахиләр сагышы"нда татар милләтен борчыган глобаль проблемаларның "маяклары" гына кагыла. Икенче Меңъеллыктан чыкканда хәл ителгәндәй булып күренгән гомуммилли бурычларның Өченче меңъеллык башында да хәл ителмичә, алай гынамы, Рәсәйгә бүгенге кыргый демократия килгәннән соң, милләтебезнең, киресенчә, патша, совет хакимиятләре заманнарына караганда да кискенрәк, көтелмәгәнрәк сынаулар алдында калуы шушы татар түземенең, бара торгач, аркабызга оры булып калкып чыгуын раслый кебек. Автор һәм әсәрнең төп каһарманнары Сәлахиләр токымы шул "тарихи оры"дан дәүләти арыну юлларын эзли.*

*Хәерле сәгатьтә!*

*9 февраль 2008*

# БЕРЕНЧЕ КИСӘК

## Сәлахиләр сагышы

### I

Бар галәмне тетрәтеп күк күкрәде. Гүя меңләгән атлар табыры үтте. Җир кабыгы кузгалып куйды.

Күк йөзе актарылып һәм болытлар ташкынында кайнап яшәрде.

Тыгыз, каты куллы җил агачларны чайкалдырды, мал капкаларын гына түгел, җан капкаларын да ачып җибәргәндәй булды.

Һавада койма яңгыр алдыннан була торган дымлы иркенлек яралды.

Туган Ил һавасы. Аһ, Туган Ил һавасы—Ватан кәгъбәсе!

Башы әйләнеп киткәндәй тоелды.

Кайдадыр бала елый иде.

Юктыр ла! Барган унаеннан туктап, Иркен ага бер мизгелгә күзләрен йомды: ул ихластан да баш әйләндерерлек ләззәт шаукымында йөзә иде. Ул дала гөлгеле кебек колакларын шомрайтты. Бала еламый, гүя шушы гөлгел, әле яңа гына ана карыныннан яшь үләнгә сикереп төшеп, дүрт аякланган колын, кыңгырау аһәңнәре таратып кешни һәм бу көмеш кешнәү... (шунысы сәер... гомерендә беренче мәртәбә!..) аның шикәрдәй ак тешләре арасыннан чыга да, шигырь булып яңгырый:

Ни газизрәк—бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!
Ул мөкатдәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!
Сөт калыр, Ватан китәр!
Сөт калыр, Ватан китәр!..

Зиһененнән томырылып чыккан колын, уйгыр даласының колыны, монда, Чаллы урамында кыңгыраулар зеңгелдәтеп, шигырь укый!.. Кеше ышанырлык хәлме?!

Моннан нәкъ алтмыш ел элек ерак Уйгырстанның, ягъни борынгыча Кашгария, тагын да аныграк итеп әйтсәк, Шәркый Төркестан дип аталган төбәкнең, Кизләү дигән авыл мәктәбендә ятланган бу шигъри сәхифә

тәэсирендә күзләренә бөртек яшь тә шытып чыккан иде. Ошбу беренче язгы күкрәүләрне тарихи Ватанында беренче тапкыр үз колагы белән ишетә алсын өчен аны бирегә нәкъ әнә шул изге сөт—Ана сөте алып кайткан иде!..

Ул йомылган күз кабакларына шифалы ягмур тамуын көтте. Туган ил ягмурлары астында бер генә тапкыр булса да бәгърене кадәр чыланасы килде. Әмма бу сафландыргыч шәфагать шылт та итмәде. "Явар-явар, һич кенә дә яумый калмас,—дип юатты ул үзен.—Әнә, җирнең кабыгын ничегрәк кенә җилтерәтеп алды? Күк-Ата шулай тетрәткәч кенә уяна бит ул Җир-Ана кышкы йокысыннан. Күк-Ата тәнен шулай җилтерәтеп кенә туфрактагы тамырларны, андагы ачыккан күзәнәкләрне кузгата да, тире астындагы кан тамыры сыман күзгә күренмәс юлыклар аша аларга язның татлы һавасын һәм сихәтле дымын сеңдерә..."

Уенга түгел, шәһәр мәхкәмәсенә—хөкемгә бара ятса да, агабызның кәефе ярыйсы иде. Үзенә каршы агылган халкының да кәефе һәйбәт кебек. Ул юлдашына күз ташлады. "Юлдаш" дигәне—менә ошбу кул таягы болады. Ана буеннан буена гарәп имлясында зурайткыч пыяла аша кояш утын юнәлтеп "Иркен Сәлах-Кизләви" дип язылган. Бары тик Һималай тауларында гына үсә торган хуш исле, нindидер йомшак сынлы, йөрәккә шифалы артыш агачыннан ясалган ул таяк. Кришна тәгълиматындагы һиндуслар артышның бу төрендә яшрен вә яшәрткеч көч, мөселманнар исә анарда Йәэҗүҗ-Мәэҗүҗ кавеменнән саклый торган илаһи дәрман бар, диләр. Серле таяк ул. Көчле таяк. Дару төенчеге кебек шифалы. Ходайга шөкер, дөнья буйлап бихисап мөһаҗирлек кылып, аның бу таякны әлегә кадәр беркемгә дә күтәргәне юк. Кискен мизгелләрдә киңәшеп кенә ала...

Башка вакытлардагыча үҗәтләнеп тыкылдамый бүген аның "тык-тык бабае". Иркен ага, әлхәмдү-лиллаһ, артык чайкалып аксаган аксак түгел. Бераз чатанлагандай итә. Уң аягы сулыннан ун миллиметрга кыскарак. Ун миллиметр хирургиядә бик күп икән ул. Адәм баласының очлыклары арасындагы аерма ике генә миллиметр булса да, ул, үрдәк сыман як-якка янтаеп, озынрак аягын читкә ыргытыбрак атлый, юк-юк, дөресрәге, давылдагы көймә кебек чөнкәебрәк "йөзә" башлый икән. Теге чакта, Тәкла-Мәкан чүлләренең хезмәт лагерьләрендә "сәяси тәрбия" үткәндә, хунвейбиннар[1] уң аягының үкчәсен эрзин таяк белән төеп, шул хәлгә төшерделәр. Еллар буе ташкапчыкта тотып, гаебен ачыклау өчен бер тапкыр сорау алмадылар, эттән талаттылар да, уң аягының үкчәсен генә төйделәр...

"Хунвейбин... Хунвейбин...—дип пышылдады ул.—Башыбозыклар... Кытай башыбозыклары..."

Шул сөргендәге заманнардан ук балтыр сөягенең җелеге кибә башлады. Гомерлеккә гарип калдыру өчен төйгәннәр икән хунвейбиннар үкчәләрен. Аһ, аякларының сызлаулары! Кырмыска иләвенә түгел, утка тыгасы килгән көннәре вә төннәре күп болады. Менә шулай, хунвейбиннар аны асмадылар да, атмадылар да—аксак ясадылар. Табиблар аягын бөтенләй кисеп ташларга дигәннәр иде, югыйсә. Әлхәмделиллаһ, Голҗадан Тозмөхәммәд атлы уйгыр кардәшемез бу бәладән коткарды. Ул үзе бик ишетеп тә бармый.

[1] Хунвейбин—кытайчадан сүзгә-сүз "хун"—кызыл,"вей"—сак,саклау,"бин"—солдат,гвардияче. Ягъни "кызыл сакчы","кызыл солдат","кызыл гвардияче" дип тәрҗемә ителә. Мао Цзе-дун җитәкчелегендә "Мәдәни инкыйлап" ны (1966-1974) тормышка ашырган бу анархист яшьләр хәрәкатенең төп көче булып талиблар—укучы яшьләр, халык армиясендә хезмәт итүче яшь гыйсъянчылар—цзаофаньнәр торды. "Мәдәни инкыйлап" фаҗигасы Кытайга тарихта булмаган зыян китерде. Ун елга якын чор эчендә мәйданнарда мәсхәрә ителеп,акылдан язган,төрмәләрдә җәзалап үтерелгән,хезмәт концлагерьләрендә "тәрбия" үткәндә имгәтелгән корбаннарның саны йөз миллионга җитте. (Биредә һәм ары таба автор искәрмәләре.)

Колакка каты. Төрекләр әйтмешли, колагын капкач белән каплаган. Ничек итеп, диеңез. Иркен-ага кичә үлгән булса, бүген ишетмәгән булыр иде: Һималай-Һиндекыш тауларының ылыслы урманнарында гына үрчи торган кыргый бал кортлары бар икән. Аларны икенче төрле "кар кортлары" дип тә атыйлар, ди. "Һималай"—һиндидән "кар йорты" дигәнне аңлата. "Һиндекыш"ының бары тик Һиндостан тауларында гына була торган "Һинд кышы" икәнлеге инде әллә кайлардан кычкырып тора. Аллаһуның кодрәте киң, менә шул кар кортлары үрчи торган биектән-биек тауларда нәкъ менә шул кортларны ашый торган "корт бүресе" дигән зур башлы кортлар була, имеш. Тозмөхәммәд кардәшемез Иркен-аганың аягын шул "корт бүреләре" башыннан алынган алтынсу сыгынты белән уды. Көнгә күрсәтергә ярамаган дәрәҗәдә якты, көнгә күрсәтсәң, шундук кара төскә керә торган үтә күренмәле сәлсәбил—нектар иде ул. Үзенә исә шушы кортларның балыннан куылган аракы эчерде. Көненә өч уймак. Берәр уймак. Бер тапкыр, мавыгып китеп, бер юлы ике уймак та эчте. Ике уймак бал балыннан башына шаукым сугып, җырлап җибәргәне дә хәтерендә калган:

Сәнең беләзегең лә ике пар,
Берүсе инлү улса, берүсе тар.
Матур жегет улсан, сөй ике жар,
Берүсе сырхау улса, берүсе бар...

Тозмөхәммәд, тукмак борын, "Менә сиңа сырхау!" дип тәгәрәпләр көлә иде андый чакларда.Рәхмәт төшкере, желеге кибүдән туктаса да, уң аягы барыбер кыскарып калды. Онытмаң, уң аягының үкчәсе сулыныкына караганда, дингез өсте тигезлегеннән ун миллиметрга югарырак йөридер.

Иркен ага дәвасы өчен Тозмөхәммәдкә инде дә рәхмәтле. Менә шул көннәрдә аңлады ул бал корты дигән илаһи җанның шифалы мәртәбәсен. Менә шул көннәрдә әйтте инде ул үзенә нәзер итеп: кайда яшәвенә карамастан, бал кортлары асрарга, умарталар тотарга, кая гына барса да, умартачылык кәсебе буенча дөнья әдәбиятын тупларга тиеш. Жир йөзендә ничә төрле кавем булса, корт нәселләре дә шулкадәр төрле була икән. Кем әйтмешли, үзең ач торсаң да, бал кортларын ач тотмаң. Нәзеренә тугъры калды: Әмрикәнең төньягында урнашкан Висконсин штатының оҗмахтай бер төпкелендә менә утыз ел инде ул умарталык асрый. Егерме баш умарта!.. Монда, Олы Күлләр тарафларына агылган тигезлекләрдә, кайчандыр ерып чыга алмаслык кара урманнар шаулаган. Кайчандыр бу урманнар жирле һинди кабиләләренә, татарга хезмәт иткән Тау Ягы урманнары кебек, баскынчыларга каршы кальга бурычын үтәгән. Кырылудан чак калган һиндиләр хәзер ары-бире сакланган урман эчләрендәге биләмә-резервацияләрдә гомер кичерә. Аларның гасырлар буена вәхшиләрчә киселгән, төпләнгән, яндырылган урманнарының тамыр көлләрендә—черемәле кара тупракта хәзер солы, бодай, клевер, кукуруз басулары, шалкан, бәрәңге, шикәр чөгендере плантацияләре—һи-и-и, нәрсә генә үсмәйде анда! Бар дөньядан агылган колонистлар һиндиләрне резервациягә—коллыкка куып кертеп, малны һәм алар күшәячәк клеверны иреккә чыгарганнар. Шуна күрә урман-болыннарда һәр һинди кешесен күргән саен Иркен ага үз татарын күргән, Илһам Шакир башкаруында үзенең атаклы "Кара урман"ын тыңлаган кебек була. Алар аңа бертуганнары кебек якын. Каян килгән бу якынлык? Гүя Олы Күлләр тирәсендәге калын кара урманнар, Миссисипи, Сент-Круа, Висконсин елгалары ярлары,

Әмрикәне сөйрәп килгән атлы олаулар сыман, Канаданың урманлы үрләренә менгәндә "Кара урман"ны җырлый!..

Шәркый Төркестанның Элә буйлары, туган Кизләү табигате бер җәннәт булган булса, монда, Висконсин елгасы буйларында үзе нигезләгән Кизләү икенче җәннәт болады! Элә буйларын Әмрикәнең Олы Күлләр тирәсенең табигате белән чагыштырганда, алар бер-берсенә кискен капма-каршы кебекләр. Тегендә зәңгәр чыршылар булса, биредә каеннар һәм өрәңге-чаганнар. Тегендә көндезен кояш тәнне пешерсә, төне исә салкыны белән тәнеңне өтсә, бирелә, Олы Күлләр тарафында, салкын котып та, эссе мунча ләүкәсе дә юк—һаваның тын алышы тигез, адәмзат салкыннан да, эсседән дә бәргәләнми—нәкъ Тукай әйтмешли, Татарстандагы кебек, "җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява". Әмма табигатьнең, көн-төннең нинди дер фасылларында вә гамәлләрендә алар берсенә охшашып та, хәтта бер-берсен кабатлап та куялар. Нәкъ адәм балалары кебек: тәннәренең төсе төрле, телләре, диннәре төрле—әмма катыкны барысы да эчәләр, барысы да яратышып, бала тәрбияләләр!.. Кайнар һәм салкын муссоннар үтеп кермәгән үзәнлекләрдә мәңге яшел субтропик табигать чәчкә атып утырса, бераз гына тауларга күтәрелсәң, анда, нәкъ Татарстандагы кебек, яфракларын коя торган агачларга тап буласың. Ә бит аларның берсе Үзәк Азиядә, икенчесе Төньяк Әмрикәдә урнашса, өченчесе—Азия-Европа чигендә!.. Агачлар төрле, әмма яфраклар шул ук—коелалар!..

Шушы каршылыклар бердәмлеген тәшкил иткән табигать кебек табигатьләр җир йөзендә сирәктер!.. Табигатьләр арасындагы кискен континенталь аерымлык һәм кискен континенталь охшашлык мәҗбүр итмәде микән Сәлахиләр нәселен өч континентта—башта Европа, аннан Азия, аннан инде Әмрикәдә дә бер үк Кизләү исемен йөрткән өч авылны нигезләргә? Төркестанның Элә буйларында, үзәндә һәм тауларда, Татарстандагы кебек, җәен-кышын җылылар-суыклар плюс-минус утыз, хәтта кырык градус дәрәҗәсенә җитеп тирбәлә. Ә менә Әмрикәнең ул яшәгән Олы Күлләре районында һава бик йомшак, континенталь, температура кышын минус алты-унөчтән, җәен плюс унсигез-егерме биш градусны тәшкил итә. Әмма Төркестанда да кышын, җәйге ком бураннары белән бергә, елына карап, Татарстандагы һәм Висконсиндагы кебек, күз ачкысыз кар бураннары була. Висконсин калкулыкларының биеклеге 500-600 метрдан артмаса, Төркестанның Элә буйларын уратып алган тауларның биеклеге алтышар-җидешәр чакрымга җитә. Әмма, ни гаҗәп, кайсыбер елларда Миссисипи һәм Элә үзәнлекләренең икесендә дә, алдан сөйләшеп куелган кебек, койма яңгырлар ява. Никадәр киң, серле вә төрле бердәм Аллаһының рәхмәте!..

Шәркый Төркестандагы туган авылы Кизләүгә охшасын дип, Иркен ага анда әремнә кадәр үстерә хәтта. Иркен ага Сент-Льюис янында үзе нигезләгән авылын Кизләү дигән атама белән йөртү өчен департаменттан махсус лицензия алды. Аның авылына кергән төштә тактага ук белән күрсәтеп, "Q I S L A U-TATAR" дип язып та куелган...

Бал корты, умартачылык, дигәннән. Ул туган татарын да тырышлыгы белән бал кортларына охшата. Үзе дә соң, бал корты сыман тырыша торгач, Бөтендөнья татарларының Икенче Конгрессына хәтта ки өч көн алдан килергә насыйп итте. "Татарстан" кунакханәсенә урнашып, бераз әл-хәл тапкач та, беренче эш итеп Казан урамнарына чыкты. Тукай шигырьләре, татар әдәбиятыннан борынга кергән кайнар пәрәмәчле чәйханәләр эзләде. Исләрен дә таба алмады. Чәй эчәргә чәйханә, тамак туйдырырга ашханә юк иде. Билхаккый, кызык, Проломный урамы татар мөстәкыйльлегенең җиденче елында да Казан, татар тарихына берниди катнашы булмаган

Бауман исемен йөретеп ята икән. Бауманның кем булганлыгын ачык кына итеп беркем дә әйтә алмады. Террорист диме шунда. Казан Керимеленең Нургали капкасына да шул адәмчекнең реклама белән ялт-йолт килеп торган урамы алып чыга. Казан халкы урам исемен һаман да алыштыра алмыймы? Казанда милләттәш кемсәләрнең туган телен, аның исә милләттәш кемсәләренең телен анламавы аптыратты гына түгел, шаклар катырды.

Ул Казан урамнарыннан шан эзләде. Ул Казан урамнарыннан дан эзләде. Ул Казан урамнарыннан җан эзләде.

Казан белән Чаллы арасында, Алабуга ягыннан Түбән Кама сусаклагычына житәрәк, чук гүзәл нарат урманнарын күреп куанды. Әмрикәнең Олы Күлләр тирәсендә дә нәкъ шундый урманнар. Тик тарихта бу мең ел билгеле Кама буе урманнарын "Шишкин урманнары" дип йөртәләр икән. "Аларны Шишкин дигән урманчы үстергән мәллә?" дигән сорауга : "Ю-у-ук,—диделәр кардәшләре.—Алабугада моннан йөз ел элек Иван Шишкин дигән алпавыт-рәссам яшәгән. Урман, аюларны яратып төшергәнгә күрә, халык урманнарыбызны аның исеме белән атый".

Кандай[2] да эчкерсез вә беркатлы безнең кавем!..

Менә шулай, Чаллының Чаллысында үз аяклары белән йөреп ята әле Иркен агаңыз. Таң атып, иртәнге намазын укыгач, сәгать жиде тулыр-тулмаста, үзенә каршы агылган ватандашларын ерып, Рубаненко урамыннан килә ята әле ул. Кызык, кем икән ул Рубаненко? Рәсәйдә урамнарга нигә исем бирәләр икән? Мәсьәлә ниндидер Рубаненко дигән әфәнденең берәр килмешәк булуында түгел. Тәүбә-тәүбә, әгәр тарихчы Михаил Худяков, композитор Александр Ключарев, дирижер Натан Рахлин кебек, татар алдында хезмәтләре зур урыс, ябрәй кешесе икән, бирә күрсеннәр! Тиеш!.. Юк, боларга бирмәгәннәр бит. Ә менә ниндидер Рубаненкога биргәннәр. Әгәр тегеләргә "урыс" дип карасалар, Рубаненко кем? Нигә ул чакта татар жирендәге шәһәр урамына шул ук татарлардан физик-академик Роальд Сәгъдиев, йә булмаса, бөек татар химигы Гыйлем Камай, башта СССР коралды көчләре генераль штабы житәкчесе урынбасары, аннан житәкчесе сыйфатында фашизмны тар-мар итүгә зур өлеш керткән армия генералы Иннокентий Антонов исемен бирмәгәннәр? Бу Рәсәйнең миллионлаган урамнарына миллионлаган чит-ят исемнәрне каян табып, аларны хат, телеграмма, пушты аша жибәрелгән башка хат-хәбәр, низамнамәләргә ничегрәк итеп язып өлгерәләр? Моны язу өчен күпме вакыт, күпме язу карасы, күпме чыгым кирәк?! Урамга кемнендер исемен бирү өчен күпме сәясәт уены уйнарга, ничә миллион кешене атка атландырып, ничә миллионын аттан аударып төшерергә кирәк? "Нигә бу исемне бирдегез, нигә тегесен бирмәдегез?"—дип чәкәләшеп тә алалар, ди, монда, дөрес булса. Шунысы кызык, урам исемнәреннән чыгып, "Биредә татар дигән өммәт бөтенләй яшәми мәллә?" дип сорыйсылар килеп китә...

Штатларда бу мәсьәлә бик жиңел хәл ителгән. Буйга сузылган, озын, гадәттә, агачлар утыртылган проспектларны хәтерләткән урамнарны авеню, диләр. Алар агачларның кәүсәләрен хәтерләтәләр. Аркылыга сузылган кыска урамнарны стрит, диләр. Аларны кәүсәләрдән чыккан ботаклар белән чагыштырырга мөмкин. Әгәр сез 3-нче, йә булмаса конкрет исем йөреткән авенюда басып торасыз икән, ниндидер Рубаненко урамын сорашып, баш кангыртып торасы юк, алу-кушу гамәлен аз гына да үзләштергән булсагыз, дүртенче, дүрткә берне кушып, бишенче авенюны һәм тиешле стритны шунда ук таба аласыз. Бик сирәк, зур урам-авенюлар гына конкрет

[2] Кандай (үзбәк) — нинди, ничек, никадәр.

исем йортә, әйтик, Вашингтондагы Ак Йорт белән Конгресс арасындагы Пенсильвания-авеню...

Иркен ага туктап күккә төбәлде. Күкрәүләр күкнең бушка барабан кагуы гына булып чыкты. Карт уч төпләренә төкереп, угалаштырды—их, ничекләр генә коргаксып, ничекләр генә ягмур шифасына сусап, ынгыраша иде аның уч төпләре, ничекләр генә иске арба кебек шыңгырдый иде аның тән шәрифләре! Юк, яумады бу ягмур. Баш очыннан яшеннәр чәчрәтеп кенә китеп барды. Яумаска булган икән. Куе кара болытлар эһ дигәнче күк йөзенең көнбатыш тарафын тиз генә боексытып алдылар да, юк булдылар. Әлегә чыгып өлгермәгән булса да, көнчыгыш тарафтан сыек болыт катламнары артыннан күтәрелеп килгән галиҗәнап Кояшның бүген җир өстендә башкарачак олуг хезмәте инде күзаллана иде...

Их, күрсәгез, күз алдына китерә алсагыз иде сез Иркен агабызның никадәр сөйкемле кеше икәнлеген! Мондый илһамлы кыяфәт алдында үземнең көчсезлегемне яшермим. Аның тышкы портретын сурәтләр өчен тел күәсем житмәсен беләм. Шуңа да, укучыма әйтеп куям: житмәгән буяуларны күңел каләмегез белән үзегез өстәп, тулыландырсагыз иде!..

Иркен—болгар бабаларыбыздан килеп житкән исем. Әйе, кайчандыр ошбу Кама-Идел сәхраләреннән куылган татар-мөселман бабалары аңа, соңгы елларда Кытай Шинҗәне дип аталган Шәркый Төркестан сәхраларында туган сабыйга, борынгы болгар бабалары хөрмәтенә Иркен дип исем кушканнар. Әйе, җаны белән иркен, золымнан азат ул. Читтән караганда, төпле баганага, юан алтын кадакка, әйткәч, анысын да әйтим, чутсыз алышларда җиңеп чыккан арена гладиаторына охшаган. Сыны туры, төз, адымнары хуҗаларча ышанычлы һәм үлчәмле, урында басып торганда уң аягының үкчәсе кәгазь калынлыгында гына җирдән күтәрелеп тора; уртача буйлы, гәүдәсе таманча гына—таза да, арык та түгел, анда эскәк белән чүпләрлек тә май, "жир" дигән нәрсәне тапмассың; киң, текә итеп күтәрелгән якты маңгайлы, спартан, Сәлахиләр нәселендә була торган бөркет борынлы, чыпчык чәчәге кебек жете зәңгәр күзле; мөселманча җыйнак, аклы-кара булып чаларган сакал-мыеклы, инде агара-агара саламга әйләнгән ак чәчле; йөзенең төсендә Үзәк Азияларда, гомумән, кайнар кояшларының нуры тәнгә туры төшкән мәмләкәтләрдә генә куна ала торган өрек туты саклана...

Кием ифрат та килешә аңа. Өстендәге иске киемнәре дә нурланып вә аның үзен нурлап, янара да куя.

Астагы теш казнасында җыйнак кына утыртылган алтын теше бар. Елмайганда нииндидер мөлаемлек биреп, ошбу алтын теш тә елмая. Башында шул ук өрек төсендәге, бераз гына уңга янтаеп торган кәпәч. Европада аны берет, диләр. Күргән-белгән кеше Иркен аганы, сурәтләреннән чамалап, мажаралы романнар остасы Жорж Сименонга охшатуы мөмкин...

Кайчандыр чем-кара чәчләре хәзер инде, әйткәнемчә, агарганнар һәм сирәгәя төшкәннәр. Яшь чагында шомырт кара чәчләренә таң калып, "Әллә буяттыңмы?" дип сорасалар, хәзер инде шуның киресе—саламдай агарган чәчләрен күрәләр дә, "Әллә буяттыңмы?" дип сорыйлар.Таралып сибелергә генә торган чәчләре, кәпәчен салганда, учмаланып, маңгай агына ишелеп төшкән чакта ул, бер караганда, мәшһүр шагыйрь Һади Такташ, икенче караганда—мәшһүр композитор Заһид Хәбибуллинны да хәтерләтеп куя...

Ул—ифрат моңлы кеше. Сабыр кеше. Моңлы кеше сабыр була бит ул. Тота-каба очынып бармый. Җырчы булмаса да, кайчакларда көннәр буе бер көйне көйләп, бер шигырьне сөйләп йөри. Әгәр иртән тору белән теленә Сәгыйть Рәминең "Яшәгез каһарманнар аты берлән!" дигән гыйбарәсе

килгән икән, димәк, ул анын телендә көне буе талпыначак; әгәр икенче көнне, күзен ачу белән, аңа Хисам Кятибнын "Бар таланган жиргә ит үсеп тора, үскәнен жылан-чаян өзеп тора" дигән юллары килгән икән, димәк, ул көне буе шул юлларны кабатлаячак.

Шигырь уку белән хәтерендә кала. Ник шулай? Бу хакта уйланганы бар. Очраклымы бу? Юктыр. Каян килгән төрки-татарга бу кадәр шигъри мәхәббәт? Казанда үзе күреп иманды: анда хәзер, күз-колак—цензура дигән нәрсә дә беткәч, шигырь, мөнәҗәт китабы чыгармаган инсан калмаган. Һәр әби-бабай китап чыгарам дип, сыерын сата. Ислам диненең кире кайтуы белән бәйледер дип уйлый ул бу шигъри адарынуны. Чөнки, хәтерләсәгез, ислам дине аякка баскач, YIII-XIII гасырларда, гарәпләр бар дөнья өчен үрнәк шигърият мәктәбе тудырып кала алдылар. Коръән кешелекне шигырь белән яулады. Коръән кешелек тарихында иң бөек шигырь болады һәм бу шигырь исламны үз канатында бар дөньяга таратты.

Иркен ага инануынча, һәр халык мәдәниятенең авыз иҗаты, шигъри эпос-дастаннардан башлануында илаһи сер бар. Халык даһилыгы милли мәдәният тукымасын мөмкин кадәр мул, мөмкин кадәр иркен, мөмкин кадәр күбрәк күләмдә шигърият вә әкият берлә дыңгычларга тырышкан. Милләт никадәр шигъри җанлы, шигърияткә никадәр якын булса, шулкадәр үлемсез, озын гомерле була. Шигърияттән ераклашкан саен милләт тә мәңгелектән ераклаша, гомере дә кыскара бара. Баласыннан әкияте киткән милләт үлемгә юл ала...

Шигъриятнең үз язмышындагы урыны турында уйланганда ул анын адәмзатта тел белән бергә яратылган һәм Аллаһы Тәгалә тарафыннан беренче итеп бирелгән һәдия икәнлегенә ышана. Бер караганда, Иркен ага әдәбиятчы да түгел. Хәтта әдәби белеме дә юк анын. Гади бер инсан. Укытучы-биолог. Тагын да дөресрәге, биология фәннәре магистры. Әмма ул, биолог булса да, татар шигъриятенең илаһи ярдәменнән башка беркайчан бернинди җаваплы адым ясый алмаганлыгын белә. Аңа башка инсаннар да шундый булып күренә. Чөнки шигърият—ана сөтеннән яратылган бүләк. Ул адәмзатның кендеген кискәндә типченә торган кан күзләве. Аны тамызмыйча туып, аны сөймичә, тормышны сөеп болмайды. Менә шуңа күрә, гомере мөһаҗирлектә үтсә дә, ул беркайчан да татар матбугатыннан аерылмады. "Совет әдәбияты", аннан "Казан утлары" дип атала башлаган журналны "салкын сугыш"ның иң кызган чорларында да алдырырга тырышты. Алдыра алмаган елларда Конгресс китапханәсенең абонент челтәре аша соратып укыды. Конгресс китапханәсендә борынгы һәм бүгенге татар әдәбияты буенча шактый бай тупланма бар. Иркен ага аларны өйрәнеп, татар шигърияте буенча картотека төзи башлады. Тора-бара бу картотекада тормышның һәр борылышын чагылдырган меңнән артык асыл күчермәләр тупланды...

Иркен аганың йөзеннән хәтта карадан киенгәнендә дә яктылык тарала. Гаҗәеп хәл, мин сезгә әйтим! Анын теле турында аерым әйтергә кирәктер. Тел дә шул шигърияттән киләде. Инанган: тел культурасы—ил культурасы; адәм заты туган телен никадәр нечкә белсә, башка телләрне дә шундый нечкәлек белән үзләштерә. Шунысы кызык, анын теле үзенең һәм әңгәмәдәшенең кәефенә, сәгать-вакытына, хәтта көненә, һава торышына карап үзгәрә. Иркен аганың сүзлегендә төрки телләрнең тулы байлыгы сакланган диярлек. Шуңа күрә аны төрки телләрнең аяклы академиясе дип булыр иде. Җөмлә төзелеше, сүз байлыгы Урта, Үзәк Азиядәге төрки-татар, үзбәк, казакъ, уйгыр сөйләшен хәтерләтә, алар шул кавемнәр теленнән алынган җәүһәрләр белән җәүһәрләнгән. Шул ук вакытта ул туган татар, аеруча Казан татарлары телен дә ифрат яхшы, бар нечкәлеге белән белә.

Казан артындагы Арча татар мәктәбен тәмамлаган диярсең. Татарның борынгы гарәби сөйләшендә язылган әдәбиятны, гарәп әдәбиятын күп укыгач, нииндидер күләмдә бу телнен үзен дә белгәч, сөйләмендә гарәби тәгъбирләр дә еш очрый. Кайчакларда аның тел куәсенең кинәт үзгәреп куя алуына башкалар гына түгел, үзе дә аптырый: әле генә саф "казанча" сөйләшеп торган кеше, вәзгыятьтә, халәттә, тирә-юньдә нииндидер үзгәреш сизенеп, "сезденез"дән "сездегез"гә, "бармыйм"нан "бармаем"га күчә, шундук төркиләшә, гарәбиләшә, үзбәкләшә, казакълаша, уйгырлаша иде...

Алтмыш сигез яшь өстендә булган бу адәмзат күзгә күренеп картая белми, картайганын абайлап булмый сыман. Күзләре (әйткән идем бугай), асаба төркиләрнеке шикелле, жете зәңгәр. Яхшы күрә, күзлекне сирәк, күзләре арыган, йә булмаса хәрефләр гадәттән тыш кечкенә булган очракларда гына кигәләштерә. Бит алмаларын мөселман затларында, аеруча мөселман аксакалларында гына була торган алсулык алсулый, тәне-тиресе җыерчыксыз, шома, затлы һәм яшь. Гүя ул, тарихи ватанына нәсел шәҗәрәсен вә туганнарын эзләп кайткан мөһаҗир, бары тик матурлыктан вә сагынудан яратылган иде. Аның атлавында да сагыну, сөйләвендә дә сагыну, хәтта ки саф һавадагы тын алышында да сагыну иде. Ул һәр нәрсәне, һәр матдәне, һәр фикерне магнит кебек үзенә тартып ала, ана бәя бирә; кирәк икән, олылый, иркәли, аның өчен яшь түгә, юата, иңләштерә; кирәк икән, бәхәскә керә, инкарь итә, читкә этәргәндәй этәрә; әмма минут та үтми, айнып киткәндәй була, һәм аны, хәтта үзенә жан зыяны салган кемсәне һәм нәрсәне, яңадан үзенә тартып ала, коча, иркәли, юата, бары тик туган жир, туган һава, туган кавем булганы өчен генә гафу итә һәм беркайчан да, беркемнән дә рәнжеттерми...

Әнә, ул "Курчак театры" тукталышына якынлашып та килә. Менә ул, баскычтан-баскычка йомшак кына тирбәлә-тирбәлә, аргы якка чыгу өчен жир асты юлына төшә дә башлады. Борынына аврсу дым, бетон-тупракса астында төне буе басылып, катламланып куерган исләр бәрелде.

Жир астындагы һава, вак сәүдәгәрләр, кырыктартмачы алыпсатарлар, эшкә баручылар, бихисап дөнья мәшәкате артыннан куып, үткенче-сүткенчеләр, эшсез, тегендә-монда сугылып, күз майландыруны да кәсеп иткән бәндәләр, айлар, хәтта еллар буена шушындагы шакшы бетон идәнне түшәк итеп, юынмыйча, тәннәре әчегән сукбайлар барлыкка китергән шау-гөр, жир өстеннән саркылып төшкән машиналар гөрелтесе белән кушылып, бер тәмам доңгырдык хәлгә килгән иде. Иркен ага бер мөлаем ханымны туктатып, сорады:

—"Проспект Мира"ның... татарчасы кандай?..

—Я не татарка,—диде хатын аңа караш та ташламыйча.—Спросите у них[3]...

Шушы ук сорауны ул икенче, төсе-башы коеп каплаган татар хатынына бирде.

—Сумасшедший что ли?—диде тегесе.—А сам—в берете[4]!

Иркен ага шунда себеренеп маташкан ханымга мөрәҗәгать итте. Рәхмәт. "Мир" урысчадан "тынычлык" була икән. Кызык, Татарстанда, урам исемнәре тәрҗемә ителә!.. Әйтик, урысча "Голубиная улица" булса, рәттән "Күгәрчен урамы" дип язып куялар да, гамәлдә урысча гына атап йөртәләр икән. Шуңа күрә, татарча "Кояшлы урам" шундук "Солнечная"га әйләнә дә куя. Урам ике исемле булалмый һәм исемнәр беркайда да тәрҗемә ителми дә бит югыйсә!..

[3] Мин татар түгел. Башкалардан сорагыз.

[4] Акылдан язган инде әллә? Үзе берет кигән тагын!

—Нинди гауга монда?—диде бер хатын-кыз.—Исәнмесез, Иркен ага!..

Мөһажир кисәк кенә борылды. Алдында борынгы дусларча елмаеп торган ханымны төсмерләп таныса да, исемен исенә төшерә алмады.

—Э-э-э, исәнмесез, исәнмесез...—диде ул, ниһаять, исемен хәтерләп.—Сәгыйдә сылуым... исәнмесез...

Игътибарлырак итеп караса, хатын һич кенә дә "сылу" түгел, ә кырык яшьләр өстендәге ханым икән. Ул аның белән Чаллының Татар Иҗтимагый Үзәге җыенында соң танышкан, дөресрәге, бу хатын аңа Әмрикәдә яшәгән кызларын илгә кайтару буенча ярдәм сорап сарышкан иде. Була бит ул шулай тормышта—исемнәрен дә белмәгән кешеләр янәшәдә басып торалар һәм шуннан башлап үзләрен якын таныш санап, җан ата башлыйлар. Баскан урынында очкын чыгара торган бу хатынкай, ни сәбәпледер, аңа күргәне саен якынаерга тырышты. Юк, аның Иркен агага бернинди дәгъвасы да юк кебек. Моннан сигез ай элек, Иркен ага көтелмәгән фаҗигага тарып, хастаханәгә яткач, бөтенләй дә таныш булмаган ярты миллионлы шәһәр халкы арасыннан аны беренчеләрдән булып нәкъ менә шушы Сәгыйдә-хан эзләп тапты, рәхмәтләр төшкере. Рәтләнә төшкәч, аңа тәмле-тәмле шулпалар, вак бәлешләр, пәрәмәчләр китерде. Иркен аганы тизрәк аякка бастырырга тырышты. Аның бу кадәр якын итүен Иркен ага бары шул татарлык, кауми бердәмлек тойгысы белән генә аңлатты—башкача монда тагын нинди дәгъва ятуы мөмкин? Мөселман хатыннарына ят ир-ат катына болай килеп йөрү гөнаһ санала да инде ул саналуын.

Хәер, сиксән ел мөселманлыктан дүндерелгән адәм баласыннан ислам канунын таләп итеп буламы? Юктыр кү. Ничек кенә булмасын, теләктәшлек күрсәткән бу киң күңелле хупъямалга бик тә рәхмәт әйтергә кирәк. Көтмәгәндә теленә калыккан "хупъямал" дигән сүздән көлемсерәп куйды. Уйгырстан татарлары "хупъямал" дип ир-ат күзенә кереп, аралашып барган хатын-кызга әйтәләр. Мәхкәмә мәшәкатьләре үтеп кенә китсен, Алла боерса, ул Сәгыйдәгә үз һәдиясен дә тапшырыр.

—Бик иртәләгәнсез, Иркен ага? Кызлар яныннан түгелдер лә?—Сәгыйдә сәгатенә карый-карый күзләрен уйнаклатты.—Җиде тулып кына килә, ә сез шулай таң тишегеннән белән аякта!..Каяндыр кайтып киләсез булыр?—Ул җир астын яңгыратып көлде.—Нарсудка барасыз, дисәк, бик иртә?

"Нарсуд" дигәнне ишеткәч, мөһаҗир сискәнеп куйды. Әйе, ул шунда дип чыккан иде.

—Сез бу хакта каян, кемнән ишетмеш?

—Лотфрахманнан ишетмеш!—Ханым "ишетмеш" дигән ят гыйбарәдә авыз читен ерды.—Нәрсә, ярамас идемеш?

—Бу хакта артык таратмаска дигән идем дә... Мәхкәмә—халык җыйнап, шау-шу куптара торган тәшкилат имәс[5]...

—Мин генә килим инде, Иркен ага... Рөхсәт итегез, яме?—Сәгыйдә, кыланып, иркәләнгәндәй итте.—Парктагы митингтан соң сез чын милли каһарманга әйләндегез. Без сезне бөтенләй белмибез икән. Кем сез, нинди сез? Иҗтимагый Үзәк җыенына чакырып сөйләттерәсебез бар!.. Әллә... кунакка үземә генә чакырыйммы? Сез бит беләсез, минем кызларым... Флора-Фауна Америкадалар! Кайтмасалар, сезгә ябышам да, үзем Америкага барам! Юнион стайтс оф Америко[6]!—Сәгыйдә тагын да кеткелдәп көлде, йомшак бармаклары белән аның беләген каты кысты һәм күзләренә керердәй итеп текәлде.—Сезнең судта безнең кебек чын милли патриотлар утырырга тиештер бит?

---

[5] Имәс (үзбәк)—түгел,булмас.

Рэкэт (инглиз.)—куркытып талау.

[6] (инглиз) Америка Кушма Штатлары.

Иркен ага буйга-сынга ифрат та җыйнак, ике бөдрә чәч алкасы маңгай агында алкаланып торган, әле генә энәдән төшкәндәй купшы киеме өстендә бик тә килешеп утырган бу утыз биш-кырык яшьләр тирәсендәге ханымны янадан күзеннән кичерде. Сүз дә юк, ипле һәм тигез мәхәббәттән яратылган сылу иде ул.

—Мәхкәмәгә керү иректе...—диде ул чак ишетелерлек итеп.—Махсус чакыру кирәк имәс. Килсәгез, шат булырмын...

—Рәхмәт, Иркен ага!—Сәгыйдә бер мизгелгә аның инбашына сыенып алды.—Билгеләнгән сәгатьтәдер бит?

—Күчергәннәр. Көндезге үндүрт сәгатьтә башланачак икән.

—Нигә?—диде Сәгыйдә, күңелсезләнеп.

—Аларның низам[7]нары үзләре белән... Ә сез күңелсезләнмәгез. Күңелсезгә көлмәк кидермиләр.

—Ничек күңелсезләнмисең!..—Ул тагын сәгатенә карады.—Сезнең вакытыгыз бар, ә миңа—эшкә!.. Нишләмәкчесез, сер булмаса?

—Нишләмәкче дип...—Иркен ага югалып калды.—Бераз саф һавада булам да..."Татар ашлары"на барып, тәгам җыярга иде. Аннан, уйгырлар әйтмешли, кояш көзгә көзлек кидерер...

—Судта җиңеп чыгуыгызны телим!..—диде ханым, урынында дәрте ташып.—Очрашуга кадәр—хушыгыз!..

—Исән-аман булыгыз, Сәгыйдә ханым!..

Хатын китеп тә барды.

...Көтмәгәндә үзен чит-ят мәмләкәтләрдә чит-ят мәнфәгатьләр хакына гариплэнгән горәбә итеп тойды һәм, хәлен җуйгандай, туктап, диварга сөялде. Гүя ниндидер галәми телескоп аша, туганыннан нәкъ алтмыш сигез ел үткәннән соң, тарихи Ватанындагы замандаш милләттәшләренең йөзләрен, күзләрен, йөрәкләрен тикшерә, капшый, тән белән җан бердәмлегенең ул гына белгән-аңлаган серләрен барлый башлагандай булды ул. Йөзләр... күзләр... сүзләр... карашлар... Йөзләр... күзләр... сүзләр... карашлар... Болар нәрсә: Ватанның ана сөтеннән калган барлык байлык шушымы? Ул алардан заман, милләт, кешелек өчен ниндидер гомуми кануннар чыгарырга теләде. Теләде генә түгел, мотлак чыгарырга тиеш иде!.. Бер минут... Аның зиһенне гүя экранга әверелде. Хәлиткеч мизгелдә аның белән шулай булады: баш мие яктыра, анда, экранда, ниндидер утлы хәрефләр йөгерешә... Монда нәрсәдер бар иде!.. Бәлки ике-өч минут та үтмәгәндер, Иркен ага беренче тапкыр үзе гомер буе эзләгән сергә, ачышка якын, хәтта бик якын булуын тойды.

Ул, ниһаять, дымсу җир асты базыннан җир өстендә барган яз тантанасына күтәрелде.

Анда чынлап та чалт аяз һәм яз иде!. Һава кояшлы, саф һәм татлы иде.

Бер генә мизгелгә тынып калган колакларының куышын җир өстендәге шау-шу биләп алды. Монда ашыгалар, утырып тормыйлар икән. Бары тик баралар. Алгамы-арткамы, анысы мөһим түгел—баралар. Яшеренер өчен күләгә дә юк. Әллә чын, ихлас тормыш җир астында гынамы? Анда—күләгә. Андагы кояш, җир өстендәге кебек, оптик аймылыш тудырмый. Анда эшлеклесе дә, эшлексезе дә ашыкмый—әҗер сәгатьләрен көтеп утыра. Ә менә җир өстендә ашыгалар. Бигрәк тә кешеләрне алып китәргә ашыгып та, илтеп җиткерергә өлгермәгән автобуслар. Оҗмахка, әллә мәхшәргә ашыгалармы? Халык ташкыны эшкә ашыга. Эшли белгәнгә, әллә эшли белмәгәнгә ашыгамы? Табышын тапканга, әллә тапмагангамы? Гадәттә, эшли белгәннәр һәм табышлылар ашыкмый.

[7] Низам (гарәп)–кагыйдә, тәртип, канун

Иркен ага күкрәгенә сыйдыра алганчы язның исерткеч һавасын сулады. Каймак кебек тәмле иде ул. Их, ягмур да яуган булса! Утырырга теләп, тукталыштагы бердәнбер эскәмияне абайлады. Әмма ул башмаклардан төшеп калган карасу-кызыл мәтедән шакшы иде. Яшьләр эскәмияләрнең аркаларына атланып утырып, утыргычларны шулай нәҗесли икән. Аларның төнге “утырышларыннан” соң, карт-коры, бала-чагалы ата-ана эскәмияләргә утырып, ял да итә алмый. Кибеттән берәр җыелмалы урындык сатып алып, урамга чыкканда үзең белән рюкзакта йөртми булмастыр кү. Ул кулъяулык чыгарып, эскәмиянең почмагына җәйде һәм, бөршәеп кенә шунда чүмәлеп утыргандай итте...

Җир астындагы манзаралар теңкәсен кузгатып җибәргән иде шул. Әмма, зыян юк. Күңел дигәне күтәрелеп тә куйды әле. Ни өчен дигәндә, җир асты юлы бер үк вакытта аңа теге гомере буе эзләгән “ачышны” ача биреп куйды түгелме?!.. “Теңкә” дигәннән. Аны мондагы татарлар латинчалатып “нервы” диләр. Шәркый Төркестан татарлары аны бик гади генә “тенкә”, “тенкә чире” дип йөртә. Уйлап торсаң, тел дигән байлыкта кызыклар күп очрый ул. Безнең “күшәү”не урыслар “кушать” дип үзләштергәннәр икән. Шул ук “кушать”не “жыррать” дип тә сөйлиләр, имеш. “Жыррать”ның тәрҗемәсе “тыгыну” була ди. “Ты пожрал?”—дигән сорау аларча “Син тыгындыңмы әле?”—дип сорау була, имеш. Никадәр нечкәлек!..

Әйе, тенкәсе тынычлана төште. Гүя әле генә кичергәннәр реаль чынбарлык түгел, ә тарихи ватанында күргән бер татлы өлге, сагынычлы бер төш һәм ул үзе дә шушы ватанның бер күзәнәге—адәм заты түгел, ә бәлки аның үз шәүләсен үзе генә үлчи ала торган бер тере баганасы иде...

Тукталышта—мәхшәрнең мәхшәре. Автобуслар килә-китә, килә-китә. Һәр киткән автобус иске, һәр килгән кеше яңа иде аңа. Һәм—киресе. Бу агымның, бу ташкынның азагы булмас кебек: КамАЗның меңләгән эшчесе, гүя берсе өстенә берсе менеп атланып, берсен-берсе таптап, изеп, этешеп һәм төртешеп, кырмыска кебек астан һәм өстән кайнашып, суырылып, этәрешеп һәм түнтәрешеп, үтәргә—эшкә өлгерергә тырыша...

—Задний прахуд аткривай!

Эчкә үтә алганнары бу бәхеткә куанып, икенчеләре, үтә алмаганнары, тышка сәленгән аяклары, ярты гәүдәләре белән галәмдә йөзеп, ярым-йорты асылынган хәлдә, янгырларда-җилләрдә сөякләрен сызгыра-сызгыра эшкә баралар. “Донбасс” җырындагы киек казлар, диярсең!..

Иркен ага чаллылар өчен бик тә гади булган бихисап әйберләрне аңламыйча, юк кына нәрсәләргә аптырый, таң кала, гаҗәпләнә. Мәсәлән, ул менә шушы кечкенә хакыйкатьне аңламый: әгәр бу инсаннар хезмәткә баралар икән, нигә аларны эшләтүче хуҗа, капиталист, автобусларны житәрлек бүлми? Нигә адәм баласы эшкә мондый газаплар белән барырга тиеш?

Янында басып торган бер Сызык Мыек, аның фикерләрен укыган сымак, үз алдына сөйләнә башлады:

—Өченче автобусым да үтте, бядь!.. Соңга калдыралар, нәгъләтләр!..

—Ә син эшкә барма да куй!—диде аңа икенче бер Ак Керфеклесе, урынында җинелчә чайкалып.—Син бүген кеше дә, эшче дә түгел, син прусты исерек!.. Җитмәсә, эш-ш-ш хакын да түләмиләр, чушь сабачий!..

—Ничек, бармыйм?! Әллә син дә... жиденче кумпликстәнме?

—Нигә жиденче?

—Патаму шты, җыен тиле-миле җиденчедә яш-ши!.. Андагылар җитмеш сантиметрга кадәр үскәннәр дә туктап калганнар!.. Карлик!..—Йөзе-ние чалшаеп ватылган Сызык Мыек үзе дә шактый салмыш иде.

—Без барыбыз да карлик инде хәзер,—диде Ак Керфек тыныч кына.—

Житмеш сантиметрдан артмыйбыз, бядь.

—Мин карлик түгел. Титан,—диде Сызык Мыек.—Син генә белмисен...

—Беләм, ник белмәскә?—диде Ак Керфек сирәк тешләрен ыржайтып.—Минзәләдән, Бакчасарай[a]дан бит син!.. Сез барыгыз мин куйган титаннан чәй эчеп үскән титаннар.

—Әйе, тач шуннан!.. Үткән ялда инәкәйгә коесын тазартып бирдем... Күнел болганганчы тазарттым, н-х! Кибеткә киттем, анда барсам, милитсия—ат б...ннан да күбрәк. Уратып алганнар. Кибеттән прдависы првалис... Бульнистә күзенә дару урынына йоды салганнар ди... Сукыр килеш растрат ясап, чыгып качкан ди, малайкаем!..

—Менә сина сукыр, бядь!..

—Авылда хәзер сатучы булып эшкә керәсен дә, киткәндә, сыерынны сатып, эштән китәсен!..

—Чушь сабачий!.. Ха-ха-ха!..

—Мин эшкә киткәндә дә бер литр эчеп китәм ул. Эчә торам, симәнке ашый торам. Эчә торам, лабравай лис ашый торам. Аннан—жылыйм, н-х! Эчкән аракым яшь белән чыга да бетә... Исертми!.. Йөрәк шалить итә башласа, Бакчасарайдан... авылдаш брачым бар. Ул мина биллетиен ясап бирә, ну и өйдә ятам, н-х!..Эчми торам. Үземә үзем пырырып ясыйм, ызначит. Кирәк чагында гел генә шулай иттертеп биллетиен ала торам. Кичә Тәүхитләрнен независный прафсаюзыннан забастовкага чакырып килгәннәр. Бармыйм мин Тәүхидләрнен сартирный независтный профсаюзларына. Үмәр Нуретдиннәрнен гүре-гүретдин прафсаюзларына да бармыйм. Нигә кирәк мина гурлы драти, митингауати?

—Безме? Без шундый инде ул...—дип дәвам итте тегесе.—Хезмәт хакын күтәрүне сорап забастовка игълан ит, бер татар чыкмаячак. Ябрәйләр булсамы?...

—Диафрагманны чамалап ач. Алар үзләре турында начар сөйләгәннәрнен башына тиз житәләр...КамАЗ-нын теге түгәрәк йөзле директоры Бехны әйтәм!.. Шундый матур кеше дә урлаша диген, ә? Әйткән ди бит ул КамАЗ беркайчан да банкротка чыкмаячак, дип. Ни өчен, дигәннәр. Татарлар хезмәт ярата, иртәгә эшкә килмәгез, түләмәячәкбез дип язып элсән дә, чыгачаклар, дигән ди...

Таралып китәрдәй булып, як-якка ишелеп, автобус килеп туктады. Әнгәмәдәшләр, этешә-төртешә, эчкә үттеләр. Утырышкан арада эчтән нинди дер эт баласы йөрәккә төшәрлек итеп чыйнап жибәрде. Аягына бастылар, күрәсен.

Шәһәр хәлләрен беләсен килсә, көн дә чыгып утыр да, тынла икән. "Курчак театры" тукталышында фәлсәфәгә бирелгән Иркен ага тирә-ягына каранды. Бирелә ул бернинди театр бинасы күрмәде. Анын уйлавынча, мондый бинанын алдында Камыр батыр кебек курчак сыны булырга тиеш иде. Шушы сынны эзләп күк белән жир кушылган араларны—офыкны күздән кичерде. Шынгырдап кипкән һавалардан коры дары исе килгәндәй булды.

Үзенен мен елында сала булып, сонгы чирек гасырда гына сәяси ихтыяр нәтижәсендә генә ярты миллионлы калага әйләнгән, кем әйтмешли, саладан чыккан, калага килеп житмәгән сәер, бик тә сәер бу Чаллы дигән авыл-шәһәр—телләр һәм диннәр, милләтләр һәм кавемнәр, тарафлар һәм карашлар казаны үзенен барча үзенчәлекләре белән бытырдап кайный иде. "Шәһәрнен ярты халкы татар-мөселман, яртысы урыс-кяфер кавеменнән тора дип әйтәләр,—дип уйлап куйды Иркен ага.—Каян, нинди чикләрдән

[a]Тукай районындагы авыл исеме.

үтә икән татар-мөселманлык белән урыс-кяферлек арасы?" Урыстагы татарлыкны, татардагы урыслыкның берәр төрле асаси бүленеше вә билгесе бар микән? Татар дигәненең асылында исламмы? Урыс дигәненең асылында носари-христианлык рухиятымы? Әллә икесе дә ярым-йорты мәҗүси халәттәме?"

"Кем уйната бу галәми театрда миллионлаган, хәтта миллиардлаган адәм балаларын?—дип дәвам итте ул.—Нинди глобаль режиссер? Нинди язмышның нинди артыш таягы?"

## II

...Күз алдында егерменче гасыр азагы адәмзатлары кырмыска кебек кайнаша. Монда олуг ханнарның һәм кенәзләрнең, бәкләрнең һәм "бай ир"—боярларның, вәзирләрнең һәм карач-стольничийләрнең, морзаларның һәм дворяннарның, аксөякләрнең һәм зәңгәр канлы аристократларның, алпавыт һәм помещикларның, ишан, мулла һәм изге атакай-попларның, коллар, хезмәтчеләр һәм башка, ничек атасаң да атарга мөмкин булган дистәләгән катлам вәкилләре балаларының балалары иртәнге сәгатьләрдә КамАЗда эшли алу хокугын яулау өчен көрәшә.

Монда кайчандыр югары катламнар тарафыннан авыр хезмәттә көчләнгән, сукага җигеп җир сөрдергән, изелгән, кирәк икән, кылычтан үткәрелгән түбән катламнар һәм, киресенчә, гасырлардан гасырларга кабатланган кызыл инкыйлаплар, түнтәрелешләр чорында инде хакимияткә килгән түбән "прлетар" катламнарның үзләре тарафыннан көчләнгән, изелгән, аккоштай муеннарына ат камыты кидереп, тәртә арасына кертелгән югары катламнар—барысы бергә буталышкан һәм бер автобуска утырырга тырышып ята. Ул, Иркен ага, кешелек, раса, нәсел, зат—адәмзат биологиясе, ягъни генетика фәне буенча белгеч, укытучы,—Кытайда дөньяга килеп, үсеп, ярты гомерен шунда яшәп, аннан Мао хунвейбиннары кузгаткан "бөек мәдәни инкыйлап" аркасында "халык дошманы" дигән ямانат алып, аннан битәр, куылып, качып ук китеп, инде гомеренең соңгы чорын Әмрикәдә яшәп яткан татар, әле, Чаллының "Курчак театры" тукталышында, һәр кемгә, һәр асаба, татарына, урысына, башкасына туганнарча укталa, текәлеп тикшерә, төрләргә, гаиләләргә, милләтләргә, шивә-кабиләләргә, нәсел-ыругларга бүлә, аера, берәмлекләрдән гомумиләштерә, гомумилектән берәмлекләп, үзенчә кыйтгалардан-кыйтгаларга чаба, кайчандыр Скандиния вәрәгләре, викингеләренең славян-сакләб нәселенә нигез салуының, кайчандыр Алтынай-тау үзәнлекләреннән һау-һаулап чыккан бөек болгар-төрки бабаларыбызны Азия белән Әләскенең Чукыт бугазы аша Әмрикәгә, соңыннан Йеллестоун дип аталачак Җиләс-Тауларга (йеллес—җиләс!) барып җитеп, мая, истәк, сиу, дакота мәдәниятләренә нигез салуларының, ниһаять, кечкенә бер мәсьәлә—Колумбның Әмрикәне түгел, ә Һиндстанны ачтым дип уйлап, Әмрикәнең җирле кабиләләрен "һинди" дип атавы аркасында гына аларның бүгенге көнгә кадәр үзләренә чит-ят булган һинди исеме астында йөреп ятуларының серләренә төшенәсе килә...

Тупас көч, физик, рухи, рухани һәм икътисади золымның милләт, кеше язмышындагы урыны һәм роле турында китап язар иде ул әгәр кулыннан килсә. Юк, Иркен аганың татар-урыс мөнәсәбәтләренә ниндидер сәяси, милли кысым, үзара конфронтация күзлегеннән чыгып кына бәя бирәсе килми, ә бәлки аларның—бу ике глобаль нәсел—славян һәм төрки-татарларның еллар, гасырлар буе нинди этносоциаль үзгәреш, әгәр мөмкин икән, нинди фаҗигаи кыйралышлар кичереп камилләшүләре кызыксындыра, йә булмаса, аларның артка чигенү, таудан түбән тәгәрәүләренең эчке, күзгә ташланып бармаган сәбәпләре борчый. Бигрәк

тә, беренче чиратта, туган төрки-татар кавеме, аның киләчәк язмышы тыңгы бирми аңа. Гүя тере телескоп булып, милләте канының, аның сыек тукымасының сүрүенә—плазмасына үтеп керәсе, барлык кызыл һәм ак тәнчекләрен, исәпкә алынган һәм алынмаган эритроцит, лейкоцит, тагын да әллә нинди тромбоцитларын янадан тикшереп, киләчәк тормышка яраклы, йәки яраклы булмавы турында үз фикерен туплыйсы килә...

Кеше дигәннән. Инсан дигәннән. Инсаният, кешелек тәрәккъыятенең, Чарльз Дарвин әйткәнчә, маймылдан яратылуына беркайчан да ышанмады ул. Аның бу хакта үз фикере булды. Дөрес, бу фикер, тәгълимат буларак, әлегә биология фәнендә ныгынган гипотеза түгел. Нинди маймылдан ди, гади судан, диңгездән чыккан ул адәм зат. Киресенчә, авыр кол хезмәте адәмзатны маймыл хәленә төшергән. Адәмзатны Аллаһы Тәгалә хлорофиллдан—балчыктан, ә хлорофиллны—яшәешнең яшел төген исә диңгез суындагы витаминнардан яраткан. Балык булган ул адәм заты әүвале. Кешенең куллары—канат, аяклары исә балыкның ян һәм оча сөякләрендәге ишкәкләре болады. Бу хакта мәшһүр Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф"ында да бар бит:

Йосыф шунда, кул күтәреп, дога кыйлды,
Ул догасы Хакъ алдында кабул булды,
Ул балыкның соңра ике угълы туды,
Алар да дәүләт иясе булды, имди...

Никадәр бөек хаклыктыр бу юлларда! Татар "Бай Күл"дән чыккан. Татарның ватаны—Бай Күл. Тик нигә ул һаман бозылган ят исем—"Байкал" дип йөртелә? Татар Азия белән Европа арасына ор белән буразна орган, ике арага гүя тимерне эретеп ике кыйтганы ябештергән һәм шул олы орыш—яраны хәтерләткән Орал таулары аша Көнбатыштан Көнчыгышка, Көнчыгыштан Көнбатышка сикергән. Тик нигә татарның бу атаклы Орал таулары Урал дип атала? Уралып-уралып, тау- кыялар белән кайнап Каспийга таба ашыкканга күрә генәме?

Кеше—су баласы. Шуңа да сусыз тора алмый. Ни сәбәпле ул аз гына да юынмыйча, эчәр сусыз торса, коргаксый һәм чирли башлый? Чөнки ул—диңгез улы, диңгез кызы!.. Жир Шарында су дәрьясының житмеш бер, коры жирнең нибары егерме тугыз процентын биләп торганын онытмыйк. Шунысы кызык, биологлар кеше тәнендәге су микъдары белән аксым микъдарының да шул су (житмеш бер) белән коры жир (егерме тугыз) күләмендә булуын расладылар. Кеше канындагы тоз микъдары да нәкъ шул нисбәттә бит!..

Һи-һи-һи, уйлый китсәңме!.. Ничек кенә хәбәрдар булмасын, Иркен ага үз милләтенең бер зур өлеше булган Кама-Ык-Агыйдел буйларында яшәгән милләттәшләренең егерменче гасырның икенче яртысында гына да Татарстанның нәфт байлыкларын үзләштерү, КамАЗ, Түбән Кама нәфт-химиясе комбинаты, Түбән Кама сусаклагычы төзелешләре дигән мәхшәрләр аша үтеп, беренче, икенче, өченче, хәтта дүртенче Явыз Иван яуларына торырлык сират күперләреннән кичүен, шул сынаулардан зур югалтулар аша исән чыга алуын әлегә белеп бетерми һәм хәтта моны искәрми дә иде...

Әнә, каршында, кадак кебек очлы, нокта зурлык кына үкчәле аяк киемнәрендә, буяткан ап-ак чәчле, почык борынлы, итәген оят жиренә кадәр күтәреп кигән зәп-зәңгәр күзле кызкай басып тора. Кем була ул? Мөслимәме? Нәсрани[9]мы? Әллә гыйбрәни[10]ме? Болай киенүне һәр өч дин

[9] Нәсрани (гарәп) – христиан.
[10] Гыйбрәни (гарәп) – яһүди, еврей.

дә гаепли бит. Милләте кем? Наташамы, Нәфисәме? Әллә Саррамы? Әллә Нәфисә атлы маржа-сәкләбияме, әллә Наташа атлы төрки-татармы? Әллә Сара атлы гыйбрәнияме? Төрки-татар булса, нигә бу кадәр "сәкләбия"гә әйләнгән? Ә менә бу чем-кара күзле, озынча туры борынлы, әллә каян "мин—төрки!" дип кычкырып торган икенче бер чибәр—төрки-татармы ул, әллә... Сәкләбия, гыйбрәния булса, нигә бу кадәре үзгәргән, үзләренекен ташлап, башкадан төс алган? Юк, мәсьәлә аларның үзләрен бүген нинди милләт итеп тоюларында түгел, ә затларында, күрәсең.

Ул шулай иркен итеп, туган җирендә, тарихи ватанына кайтып, нәселендә үз нәселен, ыруында үз ыруын, затында үз затын эзләү бурычын куйды. Бу бурыч Җир шары буйлап Милләтне генә түгел, Җир шары буйлап Камил Матурлык, Камил Гармония эзләүгә тиң иде. Моның өчен аңа күп нәрсә, беренче чиратта—тазалык-саулык, ягъни нык йөрәк кирәк иде. Җир асты юлында аның күз аллары киңәеп, дөньялары яктырып киткәндәй булды. Аңлата алырмы ул үзенә язгы гөренде кебек җимерелеп килгән ачышның сәбәпләрен? Аны чишмәләрнең башкалар белән кушылып, елгага әверелү, йәисә корып, комга сеңеп, бетүгә бару, аннан бигрәк, беренче сафлыкларын югалта, болганганнан-болгана барып, үзләрен-үзләре танымас дәрәҗәгә җитеп, затсызланып, юкка чыгу сәбәпләре кызыксындырды...

Әйе, былтыр Икенче Бөтендөнья Татар Конгрессы тәмамланып, Болак ярларында Мөстәкыйльлек бәйрәмен үткәргәннән соң, аларга, бер төркем чит ил татарларына, Бөгелмә тарафларына махсус экскурсион оештырдылар. Юл уңаенда, туктап, һаман да урылмыйча кыштыр-кыштыр килеп утырган бодай басуы буйлап килеп, Ыкның текә яр-кыясыннан борынгы елгага карап торганнары хәтерендә.

Кемнәрдер мондагы ихлас киңлек, саф һава, шәмдәй төз нарат урманы белән әсәрләнде. Иркен ага исә зәңгәрсу нәфт түгәрәкләре алкаланып аккан елгага ярдан йөгереп төшкән чишмәләрнең язмышын күреп тетрәнде. Алар, гәлсәр суларын таудан ашыга-ашыга зур елгага ташыган чишмәләр, якты агым булып агып баралар-баралар да, бераздан...елганың соргылт-пычрак алкымнары белән кушылып болганалар һәм, юкка чыгып, күз алдында үләләр иде...Гаҗәп!.. Алар ашыга-ашыга юкка чыга иде. Әйе, ышанасызмы, таудан ургылып төшкән чишмә күпмедер гомер үзенең аклыгын, пакьлеген ак тастымал, аналарыбызның ак чәч толымы кебек саклап бара-бара да, күпмедер ара үткәч, талана-талана, як-ягына карана-карана һәм, әлбәттә, каргана-каргана төссезләнеп, юкка чыга да куя... Сау бул, чишмә! Кеше заты, кеше нәселе белән дә шулай түгелме? Ярый, чишмәгә кеше акылы бирелмәгән, ул табигый зат—яшәеш, ризык чыганагы. Адәмзатның алай тиз генә югалырга акылы, зиһене бар бит!.. Адәмзатта, чишмәләрдән аермалы буларак, Акылның Ихтыяр Көче—нәселлек инстинкты бар. Тик моны аңлау-күрү өчен һәркайда мондый чишмәне, мондый текә тауны, мондый юлдашларны ничек табарга?! Сафлыкны ничекләр сакларга? Сафлык болганчыклыктан яхшырактыр ләбаса? Чишмәләр сафлыгыннан, нәселләр төрлелегеннән дөнья тәрәккъыятенә зыян юктыр бит, биллаһи газыйм?!

Чук гүзәл! Асыл кыйбланәмә! Камил мантыйк! Камил хиссият!..

Мондый юкка чыгуның гаҗәеп манзарасын Иркен ага үзенең юлдашларына күрсәтеп маташты. Ләкин алар, озатып йөрүчеләр, күпчелеге җирле татарлар, әллә яшь булулары, әллә илтифатсызлыклары аркасында, тыңлап та тормадылар. Дөресрәге, алар, үз ояларында гына көн күреп, мондый халәтне абайлау, бәяләү өчен өлгереп җитеп, ояларыннан борын чыгарырга өлгермәгәннәр иде әле. Ләкин күзләре башка нәрсәгә, әйтик, матур-матур кызларга-ханымнарга очлы иде очлылыкка...

Чаллы үзе шушы болганунын үзәге, чирли-чирли, талана-талана, әрни-әрни юкка чыгунын "тере күзәнәге" түгелме? Җир асты юлындагы баягы сискәнү анарда тагын да кабатланды. Хәерлегә булсын. Карт эченнән генә "Әльмәгун" сурәсен укыды. Туган телдә генә аңлашкан газиз күзләр һәм сүзләр, авызлар һәм авазлар, гәүдәләр һәм шәүләләр, колаклар һәм чишмә-болаклар аның өчен инде бары тик аһәңнәр яңгырашыннан гына торган очраклы тәнгәллек түгел иде. Алар арасында, һаман да шул үлемсез Дәрдмәнд әйтмешли, бары тик бер милләт балалары өчен генә билгеле булган "күз кысулар" һәм "чыш-пышлар" бар иде. Әйе, тәндәге төс, килеш-килбәт, ниндидер миң, сипкел, караш, борын, маңгай, күзләрнең кабатланмас милли чалымы, әгәр шулай әйтергә яраса, бары тик милләт сәхифәсе генә тотып ала торган эчке сизем нәтиҗәсендә Иркен агага татарларны Пекин, Нью-Йорк, Истанбул вокзалларында, хәтта ки Гарвард университетында һәм Майями курортларында да танып алырга туры килгәләгәне булды. Әйе, "Аһ, туган каумем газиз!" дип әйтерлек дәрәҗәдә үз кавемеңне тоемлау һәм яд итү өчен һич кенә дә Гарвардта докторлык якларга да, мәктәптә биология укытырга да кирәкмидер, шәт. Кайдадыр Копенгаген аэропортында меңләгән үткенче арасыннан бер татарны шәйләп алу өчен, генетика фәненә нигез салган бөек Грегор Мендельгә тиң галим булу да, бу фән харитәсендәге ниндидер "дискрет кисәкчәләр"не, "геном" йәки эчпошыргыч "аллель"ләрне белү дә зарур түгелдер.

Һәр килгән автобус ихластан да иске машиналар каберлегенә илтеп ташланыр дәрәҗәдә таушалган, и с к е булып, аларга тозлы балык кебек дыңгычланып төялгән кешеләре генә я ң а иде. Бу автобуслар бушаган тимер-томырлары белән әллә кайлардан шыңгырдап килеп чыгалар, килеп туктыйлар да, йәнәдән кузгалып киткәндә, шактый ютәлләп, төчкереп, туктаган урыннарында бензин, соляр төтененнән кара арканнар ишеп, күңелләрне болгатып торалар-торалар да, дыңгырдый-дыңгырдый, ыңгыраша-ыңгыраша янадан кузгалып китеп баралар. Бу хәл Иркен агага кәеф өстәми, әлбәттә. Ул һава агуланмаган төшкәрәк күчеп утырырга теләп урыныннан күтәрелде. Әмма арыда мондый эскәмия күренмәгәч, "лып" итеп кире урынына утырды.

Шәһәр урамнарында утырып ял итү мөмкин түгел эш, эскәмияләр гүя стратегик мөлкәт итеп җыеп алынган иде. "Татар ашлары"на барырга иртәрәк иде әле. Аны тагын да уйлар биләп алды. Уйлар, уйлар!.. Ярата ул уйланырга!.. Шушы яшенә житкәч кенә аңлады: тирә-як табигать кузгаткан камил уй—камил кешенең иң камил байлыгы икән. Агачлар гүя әле җәйгә таба кузгалырга өлгермичә ярымшәрә халдәләр. Ул хәтерләми: быел яз ләйсән ягмуры да булмады шикелле. Шуңа күрә агачлар, үләннәр әлегә яшеллеккә, яфрак-сабакка бай түгел. Ләйсән яумый торып, җәйнең киләчәк холкын чамалавы авыр. Җәйнең холкы исә, үз чиратында, кешеләрнең холкын билгели. Ул әле Уйгырстанда атасы авызыннан ишетеп һәм үзе күреп белә—җәй холкы агач сарысының вакытында саркып чыгуыннан килә. Беренче суыклар җирне туңдырган мәлдә агач кәүсәләрендәге җәйге сутның сыгыласы сыгылып өлгерми кала. Суыклардан соң, көннәр җепшенгәч, җир җылынып тын алгач, агач төпләренә игътибар итсәгез, анда соргылт су ишарәтен күрерсез. Бу соргылт пычкылдык нәкъ әнә шул агач сарысы була да инде. Киләчәк җәйдә агачларның, барча үсемлекләрнең яфракка вә сабак-кыякка бай йәки ярлы булачагы менә ошбу агач сарысының кайчан саркылып чыгуы белән билгеләнә дә инде...

Иркен ага халык ташкынын күзеннән кичерә башлады. Милләтнең аңы беренче чиратта кием-салымында чагыла. Чаллыдагы күпчелек халык милли түгел, яхшы, хәтта купшы киенә. Ул бар тапканын киемгә

генә тотмый микән, дигән уй да туа. Кайберәүләрнең май таплары белән тапланып беткән бәйләм башлыклар, спорт курткалары киеп, әрсез хәләттә кешелеккә чыгуларына да игътибар итми калмады. Кемгәдер кешелеккә кия торган көндәлек кием, кайсыдыр яхшы киенүчегә зәвекъ житешми. Эш вә кешелек киемнәре арасында әлләни аерма күренмәйде. Ә менә Әмрикәдә купшылыкны бер дә яратмыйлар. Гади, мәнфәгатьтән һәм моменттан чыгып киенүне унайлырак күрәләр. Биредә кием—һавалылык, үзеңне күрсәтүнең беренчел чарасы булып алгы планга чыга кебек. Мондый тәкәллеф, төтен кебек, әчетеп күзгә керә. Кием аша фикер бүләк итү түгел, өстенлек хиссияте тәрбияләнә. Әмрикә исә кием статусын яшереп, шәхес статусын алга чыгара. Анда кунакка, эшкә бару, бигрәк тә кич белән урамда болганырга чыгу өчен аерым кием тотыла.

Башларына берет, кәпәч, эшләпә киючеләр бөтенләй диярлек күзгә чалынмый. Эшләпә—аристократия, аксөякләр киеме. Яратмый эшләпәне Чаллы, җен дошманы күреп сөймәйде. Егетләрнең яратып кигән баш киеме—бәйләм башлык. Җәен дә, көзен дә, кышын да, язын да шул бәйләнгән, юылуның нәрсә икәнен белмәгән башлыкларда алар. "Вязанка" диләр. Шуны киеп алсалар, читтән караганда, елгыр молекулага охшыйлар да куялар. Биш яшь кешене бергә күрәсең икән, аларның берсенең дә йөзен хәтердә алдырып булмый. Нәкъ балык уылдыгы кебек бу "вязанкалар". Маймыч та маймыч, алар да маймыч. Егетләр аны йоклаганда да салмыйлардыр сыман. Кайчакта барлык Чаллыны шундый "молекула"лар басып ала: кашларына кадәр батырып киелгән башлыклар, тәгәрәп торган күзләр... Алар матур итеп бәхәсләшми, җырламый, бер-берсенә шигырь укымый, онытылып, башларын артка ташлап көлми. Аларның йолдызларга, Айга карап илһамланган чакларын күреп булмый, алар сүгенә генә белә. Сүгенү дигәннән. Иркен ага укыган Голжада һәм Уремчедә урыслар—кытайлар аларны "сулян" диләр—байтак иде. Сабый чагында урамнарда шул суляннарның авызыннан чыгып, кальбен хурлаган бу әшәке сүзләр аны менә бүген, Кытайдан күчеп китүенең егерменче елы дигәндә, биредә, Чаллыда, яңадан эзләп тапты. Ул мондый ганимәтнең жир йөзендә барлыгын тәмам оныткан да иде, шөкер. Мәгънәләрен аңламаса да, авазлар яңгырашыннан мотлак сүгенү сүзләре икәнлеге хәтердә!..

Иркен ага, дөньяга беренче тапкыр чыккан кебек, күп нәрсәгә ихлас гаҗәпләнә. Мәсәлән, хатын-кыз атламын гына ал. Чалбар кию аларның атламы белән бергә холык-фигыльләрен дә үзгәртә икән. Алар Әмрикәдә дә чалбар кия!.. Әмма анда бу күренешкә игътибар иткәне юк иде. Мөселман хатыннарының чалбар кия башлавы бөтенләй икенче! Моңа кадәр гасырлар буе алар, матур, нәфис, гүзәлләр, үзләрен итәк тыемында тыеп, шундый ук гүзәл жир өстеннән чеметеп кенә атлаган булсалар, хәзер алар чеметеп атламый. Хәзер алар гвардия майорлары кебек жимереп атлый. Ферма атлары кебек янтаеп, чайкалып атлый. Чаба. Йөгерә. Йөзендә—мәшәкать. Кулында төенчек. Күпләрнең икенче кулында шешәсе белән сыра, авызларында тәмәке. Әмрикәдә җәмәгать урыннарында эчү-тарту тыелган.

Житмешенә житеп барганда гына тарихи ватанына кайта алган Иркен ага, чынлап та куанып һәм сокланып, аптырап һәм гаҗәпләнеп, сәерсенеп вә жаны илә кайнап, кайгырып һәм үкенеп таң кала белә. Тик таң калуы безнеке ише түгел. Безнең күнел каткан жирдә гаҗәпләнеп шакката ул. Гүя туган ягына кайткан да, яңадан туган. Ә без гажиз булып гаҗәпләнә дә белмибез. Гаҗәпләнә белмәгәнебез өчен куанабыз хәтта. Даими гаҗәпләнү өчен арымас йөрәкләр кирәк. Гаҗәпләнү, таң калу—адәм баласының мәңгелек сыйфаты бит. Әгәр кеше гаҗәпләнүдән туктый икән, димәк, аның

тирә-юне киләчәктә болай кала алмый, аны үзгәртергә кирәк булачак...

Тукталышта, менә күпме вакыт инде, күкрәгеп орден-медаль, тимер билгеләр белән бизәп, кәчтүн якаларын итәк очларына кадәр металл базасына әйләндергән сугыш ветераны басып тора. Утырыр иде—урыны юк. Автобус килгән саен ул кулын каш өстенә куеп карый. Иркен ага ана үз урынын тәкъдим итте. Карт утырмады. Менә тагын бер түбәтәйле абзый. Аллы-гөлле түбәтәе чәчкә түтәлен хәтерләтә. Түбәтәй татарның тукмачы, бәлеше белән бергә йөргән милли казанышы. Яһүдине "Тәүрат" китабы яһүди итсә, бүгенге татарны "Коръән" түгел, түбәтәй татар итә, әмма, кызганычка каршы, мөселман итми. Бу аллы-гөлле түбәтәй исә Иркен ага яратмаган түбәтәй. Ир-ат, анын уйлавынча, мондый чәчкәле түбәтәй кияргә тиеш түгел. Мондый түбәтәйнең чәчкәләренә, ана клумба сыман, су сибәсе килә башлый. Аннан, ир затынаниндидер хатын-кыз чалымы да кертә әле ул. Түбәтәй ул бит калфак түгел. Ир-ат кырыс кара, йә булмаса шундыйрак кер күтәрә торган төстәге түбәтәй кияргә тиеш. Бар Иркен аганың андый түбәтәе. Хәтта икәү. Карасу-яшькелт бәрхеттән тегелгән Арча түбәтәе. Һәм кара сырылган түбәтәй. Конгресс корылтаенда Президент исеменнән бүләк иткән иделәр. Ул аны һава торышына карап, бик тә җаваплы визитлары вакытында гына кия.

Ул шушы ташкында, иртәнге кысыкта, үзе дә сизмәстән, м а т у р и н с а н н а р эзләде. Анын өчен матур инсан, матур кешенең милләте юк иде. Барынан да элек иманлы, төзек тәнле, буй-сынлы, матур телле, йөзеннән алсулык китмәгән, кыяфәтендә, карашында, атламында эчке бер куәт сизелеп, дәрте ташып торган кеше. Ул—тәрәккыйпәрвәр, күзләрендә нур, өмет, илһам, хәтта ки илаһилык шаукымы да бар. ..

Шулай да һәр милләт, һәр дингә ихтирамлы Иркен аганың зиһенендә борынгыдан килгән, ортодоксаль, чын матур кеше булып мотлак ислам тәрбиясендәге мөселман кешесе генә кала ала иде. Ни өчен дигәндә, анын уйлавынча, бозыклык, зина, хәмер һәм сихер тыелган исламда кеше тән белән дә, җан белән дә бозыла алмый иде. Анда аларга юл бикле. Бер караганда, мөселман төшенчәсе әхлак төшенчәсенә тигез һәм шул таләпкә тигез җавап бирә кебек. Анысы шулай, әмма анын бу рухи, кануный мөселманлыкны тагын да кинәйтәсе килә иде: анын уйлавынча, әгәр адәм баласы башка дин, башка тәгълиматны алга сөргән хәлдә дә, көндәлек тормышында мөселман кануннары белән яши икән, барыбер "матур кеше" була ала иде. Ул монын билхаккый шулай булуына биш ел элек Мәккәи-Мәдинәгә кылынган Хаҗ гамәлләре вакытында да инанган иде. Хаҗдан сон Әмрикәгә кайткач, ул берничә ай буена Әмрикәдәге, әле кичә генә үзе өчен гадәти булган тәртипләргә, кануннарга аптырап йөдәде. Гүя ул тегендә яна кешегә әверелгән дә, монда үзен-үзе танымый тора, имеш... Ул монын сәбәбен эзләде. Соныннан килеп аңлады: бер айга якын Мәккәдә чын мөселманлык халәтендә яшәп, биш вакыт намаз, хәләл аш-ризык, хәләл су-эчемлек эчеп, хәләл сүз сөйләп, хәләл гамәлдә хаҗ кылып, сафланган вә үзе дә хәләлгә әверелеп кайткан булган икән...

Һава, сүзнең нинди телдә яңгыравына карамастан, берүк авазлар белән кайнашты. Гүя тел культурасы дигән төшенчә биредә әлифбаның утыз биш-утыз сигез авазыннан үзен бары тик б, н, х, п, ч, з, д кебек кискен авазлар белән чикләнгән аралыкта яши иде. Ул йөзен җыерды. Гүя ир-ат халкы монда бары тик ямьсез гыйбарәләр аша гына аңлаша иделәр. Алар гүя иртән, күзләрен тырнап ачканнан сон, беренче һәм махсус эш итеп, әле күңелләре көн шакшысы белән пычранмаган, бер гаепсез, садә җанлы адәмнәрне шакшыларга, пычратырга, кальб көзгесен тапларга ашыгалар һәм монын өчен берниндә җәза күрми ләззәтләнәләр, алай гынамы,

калган халык, гүя үз күнелләрен шулай шакшылаган өчен авызларын ерып, теге оятсызларга рәхмәт әйтәләр иде. Иркен ага тагын аптырады: ничек шулай? Бу аның ватанымы? Шушында ук фәрештә валчыгыдай чиста җанлы сабыйлар да басып тора бит!.. Бу хәшәрәтләрнең ата-инәсе бөтенләй дә булмады һәм алар ата-инәдән бернинди тәрбия-әдәп алмады микәнни? Тагын да шунысы гаҗәп: бая җир астында симәнке саткан әби-сәбиләрне чыркылдаткан милисиләр, тун багана кебек, басып тора һәм эһ дип тә эндәшми. Әмрикә полисмены булган булса, таңнан торып бар дөньяны шакшы сүз белән коендыручы яманавызларга штраф салып өлгерә алмаган булыр иде. Иркен ага аңлады: биредә саф татар теленә түгел, урыс теленә дә көн юк, күрәсең, алар гүя өчәр-дүртәр катлы катнаш никах белән буталышкан кебек, үзара буталышкан, ямьсез сүз-сүгенү белән сыны катырылып, тел дигән тере табигать тагын да әллә-нинди ык-мык, йотык чүп-чар, котсыз, урынсыз кулланылган латыйни, инглизи алынмалар белән мыжлап торадыр.

Ул бу иртәнге, әйе, иртәнге агымда матур кешеләр, матур телле инсаннар табып, куанырга тырышты. Аһ, сирәк иде бу матур телле м а т у р к е ш е л ә р!..

Әнә, алар, беренче карашка, бик тә төрлеләр. Матурлар һәм ямьсезләр. Бәлки алар ямьсез түгел, гамьсездер? Кашлылар һәм хәтта кайнар цехта кашын көйдергән кашсызлар. Кашлылары башлымы? Күзлеләр һәм шул ук цехта кайнар пыяла чәчрәп сукырайган күзсезләр.Күзлеләре сүзлеме? Әйе, йөзләре булып та йөзсез, чәчләре булып та чәчсез, нindидер тимрәүдән иелгән башлы, күзләре булып та күзсез, танаулары булып та танаусызлар... Иякләрен йорт куяны шикелле алга сузып, баш төзәтергә йөз грамм гына эзләгән сәрхүшләр, тәгәрәп торган күзле кесә караклары, хәлсез куллары кашык та тота алмас дәрәҗәгә җитеп калтыранган, шешенке күзле, калын, бүселгән битле сукбайлар... Кадерсез, типтереп яшәп, тәннәре төс ташлаган, майланган, чуерташ хәленә килеп шомарган, ахыр чиктә татармы, урысмы икәнен белеп тә булмаган кызлар вә егетләр. Ир-егетнең бармак кагуын гына көткән ястыклы вә ястыксыз Наташкалар. Нәрсә ул төс? Төс—ул төнлә дә үз төсен югалтмый торган байлык. Мондыйлар Әмрикәнең теләсә кайсы шәһәрендә, Манхэттендә дә, Брайтон-Бичта да бихисап. Әмма биредә алар гүя конвейердан сүтелеп, нindидер бер төссез, мәгънәсез, даими тукылган тукыма кебек, туктау белми агыла... Таушалган милләт!..

Әнә, алар, сары-сорылар. Симезләр. Арыклар. Юкагач кебек кипкән “корылар”. Җепшекләр. Хатын-кыз килбәтле ирләр, ир-ат килбәтле хатын-кызлар. Җирдән карашын күтәрми, сөйрәлеп атлаучылар. Күкнең барлыгын да онытучылар. Күзгә-йөзгә карамаучылар. Карасалар, йөздә күз, күктә бер генә йолдыз да күрмәүчеләр. Галәмдә, илһам галәмендә очучылар, җаннары белән күкне гизүчеләр кая булган? Таушалган милләт!..

Менә алар—өлкәннәр һәм сабыйлар. Сәламәтләр, чирлеләр. Киңәйгәннәр. Тарайганнар. Сузылганнар. Тартылганнар. Суырылганнар... Ничек кенә гарипләми бу тормыш безнең халыкны!.. Гүя почмакта кемдер, нindидер Җен, махсусән тәнне изеп, сөякләрне чүкеп, имгәтеп утыра. Тукта, әнә, нинди гүзәл ханым! Ничек сакланган?! Үтеп киткәндә затлы шоколад тәмәйткән җил килеп бәрелде. Әнә—аяксыз. Әнә—ике аяксыз, кулларындагы калаклары белән җирдән этенеп, тәгәрмәчле тактасы өстендә тәгәрәп килә ята... Әнә—ярымшәрә кызкай. Кендек чокыры сукыр күз сыман бәбәкле, күзе исә кендек сыман сукыр. Әнә—чәчләре тарактан таралмаганнар.Таралып каралмаганнар. Таралмый торып, киезләнгәннәр. Уянмаганнар. Уянганнар. Янганнар. Көйгәннәр. Бетерешкәннәр. Сенешкәннәр. Әнә, бер гүзәл хатын. Әнә—тагын бер садә сабый!.. Тагын

бер чалшайган йөз... Таушалган милләт!..

Кинәт Иркен ага тынсыз калды. Алдында—тал чыбыгы кебек нәфис буйлы шәрыкъ гүзәле. Кулларына игътибар итте. Бармаклары озын җимшәнле "Ханбикәләр йөземе"н, бармакларының буыннары ак чәкчәкне хәтерләтте. Төшемдә түгелме бу, күземә күренмиме, дип яңадан күзеннән кичерде. Аганың кызга якынрак киләсе, тарих өчен генә исемен-атын, аны тудырган ата-анасының исемен-атын беләсе, елмайтасы, ирен араларыннан ап-ак энҗе тешләре белән җир йөзен тагын да яктыртасы килә де. Шушы түгелме ул эзләгән Милләт Анасы булырлык Милләт Гүзәле? Аһ, кая аның янында Милләт Атасы булырлык ЕГЕТ? Аларны таныштырырга, кавыштырырга, никах укырга иде!.. Их, кая икән аның үз яшьлеге?! Әллә чынлап та ул, картаюның үзеннән чыккан карт аю, гашыйкъ булды инде? Әйдә, "солдат, сал да ат!"—дип шаяртты ул үзен. Нечкә билле, кара кашлы, түм-түгәрәк йөзле, бит алмалары очыннан нурлар, керфекләре астыннан шулай ук нурлы дәрт ургылып чыккан, ап-ак күлмәктә, биек үкчәле аяк савытларында һаваларга үрелеп үскән бу чибәр, билхаккый, шәрекъ гүзәле, бар булмышы белән милли табылдык вә милли казаныш, бер сүз белән, милли байлыгыбыз болады.

Татар кызы өстенә кигән киемнәре белән дә, биллаһи, кошлар нәселеннән икән. Шушы очраклы гына очраган, әле бер минут кына элек кенә ташландык күренгән шушы тукталышта калкып чыгып, бар дөньяны яктырткан кыз бу илаһи көчне кемнән, каян ала? Ул үзен бәхетле тойды. Ул үзен барлык вак дөнья нәҗәсәтеннән арынган, тазарынгандай итеп күрде. Юк, мондый хатын-кыз булган вакытта милләт үләме?! Мондый кызлары булган Чаллының киләчәге булмый диме?! Йә, Хода, кем бәхетенә үсә бу?—дип уйланды ул. Кемнәр аны гүзәл гөл итеп күккә күтәрер? Әллә ниндидер бер тупас кемсә аны, чүп урынына, таптап кына китәрме? Йә Раббым, алай була күрмәсен иде!

Ул кызны күзәтте. Кыз горур сын булып басып, карашын вакламыйча, автобусын көтә. Автобус әрҗәсе—аның язмыш сәхнәсе. Башкалар, ир-ат халкы арасында тәнгә-тән кыршылып бару—шушы илаһи гүзәлнең язмышымы?! Иркен ага күңеленнән бу гүзәлгә лаек шигъри җәүһәрләр эзләде. Алар сиңа кирәктә күңелгә дә килмиләр иде. Ниһаять, ул Мәҗит Гафуридән мисалы зар-интизарын тапты:

> Айлы кичләрдә әгәр чыксаң, йөзеңне нык яшер,
> Юкса бу матур йөзеңне күреп ай көнләшер;
> Ул чыдый алмас, сине күргәч, ачудан чайкалыр,
> Ул китәр башка галәмгә, Җир йөзе айсыз калыр...

Менә килде ул буяулары кыршылып беткән КамАЗ автобусы. Менә дыңгырдап вә сайраган калай тавышлары чыгарып, котсыз ишекләрен ачты һәм кызкай башкалар арасында күренеп-күренмичә эчкә үтте. Кайсы Таһирның Зөһрәсе, кайсы Йосыфның Зөләйхасы китеп барды? Бер ялгызы, шушы сасы, нәҗес арбада, башкалар арасында буталап вә ешынып китеп барды ул. Милләт Анасы булырга тиешле Милләт Гүзәле. Кая китте? Кем белән? "Казанның киләчәк ханбикәсе, Чаллы морзасының бүгенге Ак Бикәсе бер ялгызы!..—дип пышылдады Иркен ага.—Кая китте? Нигә берүзе китте?"

Бар-тирә моңсыз, затсыз калды.

Шушы буламы нәтиҗәләр? Бүген иртәдән бирле Иркен аганы мөһаҗир язучыбыз Гаяз Исхакый һәм аның мәшһүр "Ике йөз елдан соң инкыйраз" дигән романы эзәрлекли. Инкыйраз—татарны юкка чыгуга алып барган

куркыныч, димәк. Моннан йөз елга якын элек язылган һәм кайчандыр әле 1905-нче елгы инкыйлапка кадәр гарәп имлясында басылган бу китапның беренче басмасы Иркен аганың шәхси китапханәсендә саклана. Ул аны еш кына кулына ала. Монда, советлар арбасыннан төшеп калган Рәсәйдә, татар тормышы белән таныша башласаң, Исхакый һәм аның романының төп каһарманы язучы Җәгъфәр белән килешүдән бигрәк, алар белән бәхәсләшүдән туймыйсың. Хәтерли, күнеленнән, яттан хәтерли Исхакыйның оранын: "...Алардан качмаска кирәк! Барыбер качып котыла алмыйбыз! Милләтемезне инкыйраздан коткарасымыз килсә, мотлакан, урыс мәктәпләрендә уку тиеш!" Бу хакмы? Хак булса, татарның бүгенге хәле аның шул урыска якынаю нәтиҗәсеме? Һәйбәт нәтиҗәме?.. Ай-һай, ай-һай... Нәрсә, Исхакый татарларны урыслар белән катнаш никах корып туганлашырга, балаларны бары тик урысча гына укытырга чакырган, авыз сулырын корытып, маржаларны мактаган Исхакый шулай җинел генә, үзе теләп... алданганмы? Нәрсә, без Исхакыйның ул заманда фикерен бары тик үз каланчасыннан торып кына йөретеп, татарны гына түгел, урысның үзен дә төп башына утырткан яһүди интернационализм афәтен алдан күрә алмавы белән акларга тиешбезме?..

Гүя гомерен мөһаҗирлектә үткәреп, җәсәде дә Төркия тупрагында ятып калган Исхакыйның шәүләсе аны, Әмрикәдән килгән мөһаҗир энекәшен, таң белән урыныннан күтәреп алып чыккан иде Чаллы урамнарына. Гүя язучы Җәгъфәр ул үзе икән ләбаса... Менә ул, әле үзе шаһит булган 1997 елдан торып түгел, ә бәлки Исхакый сурәтләгән ике йөз елдан соң—2097 елдан торып, Чаллы бусагасына, кызыл Мавзолей эчендә яткан Кызыл Мәйдан даһие кебек, менеп баскан да, моннан ике гасыр элек, ягъни 1897 елда Рәсәйдә үткән халык санын алуны, Исхакый язуынча, үзенең "ангыралыгы, наданлыгы, караңгылыгы аркасында урыслаштыру, христианлаштыру дип аңлап, аңардан качабыз дип Төркия солтанатына, башка мәмләкәтләргә качып китеп, юлда вә читтә үлеп, кырылып бетеп, унбиш миллион татардан нибары 3800 аксак, чулак, сукыр, күзсез, гарип болгарга калган татар кавеме" кабул итеп, күкрәк каршысыннан үткәрә...

Унбиш миллион мәгърур җанлы, горур бәдәнле татардан калган матур инсаннарны эзләгәндәй, ул тирә-ягына каранды. Һәм тирә-ягы чынлап та моңсыз, затсыз күренде. Беркем беркемгә шаярып эндәшмәс. Беркем беркемне котламас. Беркем урамнарны яңгыратып көлмәс. Беркем дөньясын онытып гашыйк булмас. Баягы Сызык Мыекның җитмеш сантиметрлыларының берсе дә илһамга әсир төшмәс һәм шигырь укымас. Әнә, алар—нәтиҗәләр. Йомгаклар. Агайлар, тәгәри китте йомгагым, күрмәдеңезме? Күрдек, менә алар. Сезнең күз алдыгызда! Кабул итеп алыгыз! Кайчандыр мәгърур җанлы, гаярь халыктан капчык төбендә калган өлеше. Алар белән теге Шүрәле шаярмаганмы, кытыклап, тәннәрен гарип-гораба ясамаганмы?

"Курчак театры" тукталышының җир асты юлында башына килгән ачыш һәм җир өстенә чыккач күргән бу фаҗигаи манзаралардан башы сызлап куйды. Җан гына түгел, тән дә изелгән, таушалган, чамасыз авыр хезмәт, өметсез көнкүреш, хәләл булмаган ризыктан чит-ят рәвеш кабул итеп, тәннең төсе дә үзгәргән иде...

Исхакый язган фараз һәм ул үз күзләре белән күргән хакыйкать.

Бу куркыныч тәнгәллектән йөрәге дөпелдәп типте. Аны, хак мөселманны, нииндидер рух, нәселнең Күзәнәк Иясе сыман кемсә эзәрлекли иде. Кем ул? Бичурамы? Шүрәлеме? Әллә Аллаһы Тәгаләдә фәрештәләр мөгаллиме булып хезмәт иткән Шайтан үзе гариплиме татарның җанын-тәнен?

Иманын сыга? Гүя кемдер, ниндидер бер Козгын, татар Прометеенын бавырын Кафтау-Оралтауларда һәм КамАЗларда чукуын дәвам итә. Кафтауда—туп тавышлары, Оралтауда татарны күрәлмәү һау-һавы. Гүя ниндидер милләтсез Шүрәле, милләтне чираттан үткәреп, кытыклый, ипи шүрлекләренә Татнефть, КамАЗ талоннары өләшеп көлдерә, ә милләт, нигә көлгәнен аңламыйча, аңына килә алмыйча юкка чыгып бара. Бу Шүрәледән исән-имин үткән бер генә инсан да юк. Барысы да, тиле кебек, көләләр-көләләр, шырды-бырды җырлыйлар-җырлыйлар да—үләләр...

Иркен агала рух белән фән, динилек белән матдилек каршылыкта түгелләр иде. Биология фәненең умырткасын тәшкил итәчәк генетиканың атасы чех Грегор Иоганн Мендель дә рухани кеше—пастор булган бит. Күзәнәк яратылу кебек серле рухиятнын никадәр матди булуын руханилар ача!.. Унсигезенче гасыр азагында ул гыйбадәтханәсе бакчасында борчакларның нәселен яхшыртуга утыз биш ел гомерен бирә. Һәм... генетика фәненең асылын—женси күзәнәк, аның яшәү-яшәтү серләрен ача һәм бу үлемсезлек күзәнәген гамета дип атый."Гамета" латинчадан "хатын" дигән сүз. Нәрсә, безнең милләтнең ир заты үзенең "хатын " дигән гомерлек яртысын кулыннан ычкындырып, югалтты мәллә? Әллә югалган "хатын-күзәнәк" Ирдә Зат тәрбияләүче "ир-күзәнәк"не тәрбияләүдән туктадымы?

Рәсми-мәдәни тарихы ике мең ел булган татар өммәте шулай йөз елда юкка чыгармы? Әле Исхакый фаразлаган ике йөз елның йөз елы гына үткән бит?! Ике гасыр эчендә унбиш миллион татар-мөселманнан исән торып калган болгар-мөселман..." Язучының кичәге фаразы бүгенге ачы хакыйкатьме, әллә уйдырма гынамы? Юк, милләттәшләр, диндәшләр—ышаныгыз, ул беркемне дә рәнжетергә теләми. Ул хәтта үзен язмыш бүкәненә салып, бары тик гаҗәп төгәллек, камиллек, яптәш симметрияләр генә эзли, шуларны гына билгелисе килә!

Ишетәсезме сез?!

Татарны Бөтендөнья Татарлары Конгрессы җиде миллион дип тамгалады. Ике Израиль халкы. Әмма җиде миллионнан ничәсе мөселман икән? Аның җиде миллион татарның барысын берьюлы галәми телескоп аша күрәсе, кан тамырының тибешен тотып карыйсы, күпмесе мөселман икәнлеген белү өчен намазлыкка бастырып карыйсы килде...

Тора-бара бу чагыштырулар аны туйдырды. Үзенә дә ачуы килеп куйды: кешеләргә, җәмгыятькә, системага бәя биреп утырырга аның ни хакы бар? Үзең кем? Үзеңне кара!.. Чатан!.. Тере гарип!..Житмәсә, килмешәк!.. Тормышы кандай—кешеләре шундай. Бераздан ул үзен яклый-аклый башлады: юк, ул бит берниндидә бәя бирми. Ул реаль чынбарлыкны күзәтә генә. Чөнки ана Аллаһтан күз бирелгән. Бәлки ул үзе дә башкаларга сарыдан суырылган суган башы булып күренәдер? Бәлки аның кәпәче дә кемнәргәдер ошамый, гафу әйләнез, сыер ләпәшкәсе булып күренәдер? Атлаганда, буыннары бәлки кораб арканы сыман шыгырдаган авазлар чыгарадыр? Әйе, ул үзе күзәткән манзараларга ниндидер гасабилык, мин-минлек тойгысы илә өстән карап түгел, киресенчә, шушы ташкынның исән калган бер тере тамчысы буларак, читтән тыш гарьлекле үкенү белән үз итеп, астан, тирәннән карый иде. Нигә, әгәр дә бу кешеләрне җирле хунвейбиннар кыйнаган һәм гариплегән булса, аны икенче кыйтгада башка, икенче, әмма шундый ук молекула-хунвейбиннар гарипләмәдемени?

Юк, кардәшләр, милләттәшләр, ватандашлар, диндәшләр—ышаныгыз, ул беркемне дә рәнжетергә теләми. Ул үзен язмыш бүкәненә салып булса да, бары тик тормышта гаҗәп төгәллек, камиллек, япьтәш симметрияләр эзли, шуларны ачасы һәм башкаларга бүләк итәсе генә килә.

“Шулай да, нинди матур булган икән безнең халык!”—диде ул үз-үзенә.

Телче булмаса да, тел нечкәлекләрен ифрат та нечкә аңлаган Иркен ага үз авызыннан кинәттән генә очып чыккан “булган икән” дигән сүзбәйләнештән көлемсерәп куйды. Нәрсә, “Инде без дә бетәбез” дигән сүзләр чынбарлык булып алга килеп басты да мени? Әллә әлеге дә баягы Гаяз абзыйның “Ике йөз елдан инкыйраз”ы шулай йөз ел да үтмәстән хакка чыктымы?

Күзләрен челт-челт йомып, бу төшенкелек баткагыннан чыгарга тырышты. Юк, бетмәдек әле! Ни сөйлисең син, татар баласы! Тьфу-тьфу, әллә ни әйттерерсең тагын! Әгәр милләт беткән булса, адәмнәрнең әлеге ташкынында шулкадәр гариби манзара белән бергә шулкадәр матурлык вә зифалык күрә алган булыр идеме? Юк-юк, биредә кирәклесе ничектер житешми, житешмәскә тиешлесе ничектер артык түгелме? Менә әле генә үз милләтендә үз милли тегермәне он итеп тарткан нинди генә милләт һәм кавемнәр чагылышын күрмәде ул! Әгәр аның милләте беткән булса, ул, тарихи Ватанына кайта алган, аның саф һавалы тупсасын тәшкил иткән Чаллы каласында, “матур булган булганбыз икән” дип тора алган булыр идеме? Мондый фикер килсен өчен агымдагы ташкын, агымдагы куерымда туа, яши һәм үз акылы белән үлә белүче милләтең булуы зарури бит!?

Ә, чынлап та, никадәр зур, киң, күп нәселле, бихисап күзәнәкле, күп төрле, күп милләтле, күп кавемле һәм юнәлешле безнең милләт! Аның эчендә нинди генә милләттән булган милләт балалары юк?! Без моны файдалана беләбезме? Бу хәл милләтебезнең борынгыдан үз кабыгына бикләнеп, мич башына менеп, аягын салындырып утырып кына яшәмәгәнлеге, юрган астында әкәм-төкәмгә әйләнмәгәнлеге, киресенчә, кыйтгалардан кыйтгаларга, дәрьялардан дәрьяларга, даругалардан даругаларга кул сузып, сикереп, сәлам илтүе, катнашуы, катнашышуы, үз җырын, үз байлыгын башкаларга мул өләшеп һәм үзе дә башкалардан алып, күп, бик күп алып, ни кызганыч, буш калуы, беркайчан да күршесенә янгын уты җибәрмәве һәм иманын сатмавы турында сөйләмиме? Ул, Ватанын кулыннан җибәрсә дә, сөтенең тәмен теленнән җуймаган!..

Әйе, менә әле генә, шушы иртәнге кысыкта ташкын булып аккан милләте көзгесендә Иркен ага нинди генә кавемнәр чагылышын күрмәде! Алар арасында озын буйлы, таза карынлы, зәңгәр күзле, тыннары белән тирә-юньне кайнарлатып килгән аксыл йөзле гайяр угыз-төркиләр, кыска буйлы, бөтерчек кебек хәрәкәтчән, каракучкыл йөзле, коңгырт күзле, йомшак борынлы, тамырдай бармаклары белән тимер сындырган кыпчак-төркиләр, аксыл-сары йөзле, аксыл-сары чәчле, күп эчеп, талымсыз яшәп тазарган, хәтта агач кайрысы ашап та, яхшы йокыда тәннәренә май һәм сумит утырткан урыс-славян, тактадай яссы аркалы, озын буйлы, итләч битле, шалкан кебек ак, көпшәк тәнле, җитен чәчле урман угры-финнәре, үркәч борынлы, киң, эре сөякле рум-византлар, почмак иякле, башлары муеннарына казан кебек капланып утырган борынгы шумерлар һәм урартлар, йөгерек күзле, бөдрә чәчле, кабак күзле арийлар, гарәпләр һәм гыйбрәниләр, кысык күзле, кечкәнтәй буйлы, кырмыска сыман йөгрек кытай-чин һәм мангуллар... Аларның һәркайсы үткән гасырлар, үткән эралар, үткән чорлардан үз заманының “комсомол юлламасы” белән безгә килеп юлыккан, безнең канга килеп кушылып, безнең тамырларда аккан бөек татар каны ташкыны иде...

Дөнья буйлап күп юллар кыдырды ул. Күрмәгәне аз калгандыр. Чагыштырырга хакы бардыр, шәт. Әгәр расаларны, милләтләрне чагыштыра икән, ул моны ниндидер милләтне кимсетү, аларның берсен икенчесенән

югары яки түбән кую өчен эшләми. Әгәр Аллаһы Тәгалә милләтләрне аеры яраткан икән, моның сәбәбе бар. Алар табигатьнең бик салкын һәм бик кайнар, уртача һәм түзәрлек булган параллельләрендә бар ителмешләр икән, димәк, яшәешнең төп мәгънәсе—үзенчәлек. Үзенчәлек—яшәү ысулы. Үзенчәлекнең алдынгысы һәм артка калганы булмый. Аларның үзенчәлекләрен, тигезлек вә тигезсезлек дигән сәяси уеннар белән бутап, милли психологияны шул үзенчәлекләрдән чистарту һәм юкка чыгару бара. Менә төркиләрне алыйк. Ул—иң карт милләтләрнең берсе. Ике мең еллык ташка язылган тарихы бар. Әмма төркиләрнең тәне яшь. Җаны яшь. Алар картаймый. Бит алмаларын, тән тиреләрен астан, эчтән ниндидер кояш алсулыгы яктырткан кебек. Шул ук вакытта әрмән, грузин, гарәп, гыйбрәни кавемнәрнең, бигрәк тә аларның хатын-кызларының, чамадан тыш иртә картаюына игътибар иткәне бар Иркен аганың. Утыз-утыз биш яшьлек арий хатыннары ни өчен алтмыш-җитмеш яшьлек әбиләрне хәтерләтә?

...Бер караганда, кавемебез бетүгә, юкка чыгуга бара. Икенче караганда, тәне-җаны яшь милләт ни өчен күз алдында юкка чыгарга тиеш? Исхаки ике йөз елдан соң дип фараз иткән инкыйраз ни өчен йөз ел үтмәстән үк килде? Бәлки төркиләрнең үлем сәгатен икенче кара көчләр көчләп суктырадыр? Күтәрелергә бирмидер? Бәлки төркиләр, бердәм булалмыйча, берсен-берсе ашап, юкка чыгарадыр? Кистереп кенә әйтүе дә читен. Нәрсә, милләт сүрү-протоплазмасында шартлап, шундый революцион юл белән ярала да, шундый сызлавык, эволюцион юл белән юкка чыгамы? Нәрсә, "Бу әфәнде милләтнең соңгы шагыйре", "Бу ханым милләтнең соңгы җырчысы" дип әйтер көннәребез килдеме? Бәлки милләт тә, инсан кебек, гомер чиген белеп, үләргә әзерләнергә, кәфенен, үлемтеген алдан хәстәрләп куярга тиештер?

Юк, Иркен аганың милләтнең бетүгә бару тенденциясе белән һич тә килешәсе килми. Шулай да... сизенә. Сизенми буламы? Бәлки миллиятебез чынлап та картайгандыр? Таушалгандыр? Ир-атларыбыз орлыксызланган, нәселсезләнгәндер? Ул, шулай катып калып, үләлмичә газапланган атавистик тамырдыр?

Аның баш миендә нәрсәдер гүелдәп яктырды.

Кинәт "затсызланган!"—дип кычкырып җибәрүен сизми дә калды.

Дулкынланудан, үзенә урын табалмыйча, кайсыдыр тарафка бара башлаганын тойды.

Тапты!.. Җир асты юлында килгән ачыш нәкъ менә шушы иде!

Ул өнсез килеш үксеп куйды.

Ул елый иде.

Менә тапты ул үзенең эзләгәнен! Шушы нәрсә яктырткан иде аның баш миен ж и р   а с т ы   к и ч ү е н д ә. Шушы атылчак йолдыз, метеорит кебек зиһенне яктырткан сүз хәзер аның язмыш гөмбәзендә утлы хәрефләр булып яна, ялкынлана иде. Ул сүз "затсызланган" дигән бик гади сүз иде. М и л л ә т   з а т с ы з л а н г а н. З а т—с ы з—л а н—г а н.

Дөньяда иң бөек һәм бердәнбер Заты пакь—ул Аллаһы Тәгалә. Бу Иляһи Зат адәм галәйһиссәламне дә Затлы итеп яраткан. Заты гали. Димәк, акылы-фигыле, тәне камил шәхес, асаба, асыл. Димәк, безнең бүгенге затсызлыгыбыз алласызлыктан, д и н с е з л е к т ә н киләдер?!

Матурлыгыбыз да затсызланган бит!..

Мәккәи-Мәдинәдә үз кавемен йөзләгән, меңләгән кавем белән чагыштырып, үзе дә белми-аешмыйча эзли башлаган "сер" аны, затсызлык төшенчәсе булып, Чаллының "Курчак театры" тукталышында килеп тапты бит!..

Күз алдына Шәркый Төркестандагы туган авылы Кизләү аша үткән

хунвейбиннар ташкыны, шул хунвейбиннарның мәктәп ихатасында ясаган сабантуй күренешләре килеп басты. Бу ташкында шул хунвейбиннар ташкыны, шул хунвейбиннар сабантуе белән ниндидер охшашлык бар иде. Мондагы хунвейбинлык гүя тегендәге сәяси хунвейбинлыкның гади көнкүрештәге чагылышы, автобус тукталышындагы иң беркатлы нәтиҗәсе иде...

Агымдагылар үзләре моны күрә алмый иде. Моның өчен яна күз, яңа караш кирәк иде. Ай-һай, бик зур вакыйга бит ул затыңны югалту. Затсызлану. Үлемнең башы, фаҗиганың чыганагы бит ул!.. Зат. Бу шаукымлы сүз кинәт кенә Һиндостан суфилары мәзһәбе җырчысы, бөек магулларның атаклы баласы Хәзрәт Инәят Ханны хәтеренә төшерде. Әмрикәдән киткәндә үзе белән алган иде ул аның мәшһүр "Аваз шаукымы" дигән китабының инглизидәге басмасын. Бу китапны бары тик шушы көннәрдә, сәфәргә кузгалганыннан сигез айдан соң гына укый алачак дип кем уйлаган. Китапның азагында мәшһүр җырчы кулланган сүзләр сүзлеге бар. "Зат" дигән төшенчәгә тап булды анда Иркен-ага. Бихисап мәгънәләргә ия икән ул без еш кына уйлап та тормыйча кулланган тәгъбир. Гарәпчәдән әйбер, бер нәрсә, шәхес, аерым кеше, табигать, асыл, аслы табигать, чыганак, аслы чыганак, яратылыш, нигез, үзлеклелек мәгънәләрендә тәрҗемә ителә, суфиларда исә Бер Аллаһы, Абсолют итеп йөретелә. Мәҗит Гафуриның сабый чагында ятлаган "Мәхәббәт орлыгын чүпли әтәч кебек усал затлар", дигән юлын хәтергә төшереп елмаеп куйды.

Тукта, кая бара әле ул? Кәефе яхшы иде. "Кая барамыз?"—дип сорады артыш таягыннан. "Татар ашлары"на барамыз, тәкъсир",—дип җавап бирде җолдасы[11].

Шулай, кайчагында таягы белән сөйләшеп-киңәшеп ала Иркен ага. Гүя гади таяк түгел, ә бәлки атланып йөри торган аты-аргамагы ул аның. Шулай, егерменче гасыр азагында унтугызынчы гасыр азагындагы мөкаммәл тел һәм мәкам берлән сөйли белә ул таяк. Таякның "Татар ашлары" йорты белән дуслыгы зур. Җылы каршылыйлар, дөресрәге, Зөһрә-сылу аны үзе каршылый. Шелтә алган малай актыгы кебек почмакка сөяп куймый, ә түрдәге шәхсән чөйгә элә. Таяк кебек почмак иясенең түргә куна торган шәхси чөе булгач, начар түгел бит инде, җегетләр.

Ул бүген азык җыймаган иде. Ага көненә бер тапкыр булса да шушы асыл ашханәдә тукланырга форсат таба. Монда кызлар аның өчен өзелеп торалар, аш-суларын әйтәсе дә юк, телеңне йотарлык. Бик кыйммәт тә түгел. Дөрес, биредә затлы фасоль борчагы сирәк була. Иркен агалары чуен чүлмәктә томалап пешерелгәннән соң суытылган бозау итен, аңа бераз гына керән тамызып, шундый ук салкын фасоль белән бергә ашарга ярата.

Тукланган саен түләп азапланмас өчен ул әҗерен алдан ук түләп куя. Болай уңайлырак та, мәшәкате дә азрак.

"Татар ашлары" бинасы менә монда, уң кулда, "Тынычлык-Мир" проспектының эчке култыгында урнашкан. Ул сукмактан унга борылды. "Милләтләрнең юкка чыгуы, дөнья харитәсенең төссезләнүе, тере табигатый чәчкәләрнең кимүе кем файдасына?—дип уйланды ул.—Кемгә нәрсә, җирдә урын җитмиме? Аерым милләтләргә, аеруча төрки милләтләргә, мөселман өммәтенә каршы алып барылган идән асты көрәшен кем оештыра? Мазасын кем түли?"

Татар гына мондый авыр хәлдә түгел бит?! Димәк, сүз милләтләр болынлыгының дөньяви масштабтагы иминлеге турында бара! Татар гына диме?! Милли мәсьәлә буенча даими кызыксынып, бу тема буенча бар дөнья әдәбиятын җыештырып баргач, ул белә: Рәсәйдә дистәләрчә

[11] Җолдас (казакъ)—юлдаш.

милләт һәм кавем—чуашлар, чирмеш, калмык, коми, инде үзләрен "урыс" дип атый башлап, бер мәктәпсез дә калган эрьзә, мукшылар да бар... Газ, нәфт, асылташлар, җәнлек тиресе исәбенә Рәсәй бюджетының йөздән туксан керемен биргән, инде бүген ярты аракыга хатынын, кызын сатып җибәрергә әзер нинәс, хантыйлар, мансыйлар һәм юкак-ирләр дә бар... Ерак Африканың юкка чыгып барган гишу, рунди, сога, Үзәк Азиянең әрәмгә чыгу алдында торган нииндидер палаун, секун һәм шан кавемнәре бар. Азмы мондыйлар?!

Дөньясын басып—коя төшкән!..

Дөньяның галәми табигате, кешелек табигате келәменә коя төшкән—һәм бу хәл беркемне дә борчымый!..

Дөньяда бер миллиард инсан бүген туйганчы ашый алмый. Аның каравы Җир шарын талап баеган Европада уч төбе кадәр Швейцария—акча империясе бар дөнья буйлап процентка акча суга. Мәйданы ике квадрат километр булган Монако кенәзлеге казиносында рулетка артына утыру өчен биш кыйтганың миллиардерлары чират тора...

Иркен ага ачуыннан исән аягы белән ниндидер таш кисәгеи тибеп очырды.

Коя̈ләр исән-сау—яши бирәләр!

Берләшкән Милләтләр Оешмасы милләтләрне талаучы, милләтләрне талаштырып яшәүче "бөек державалар" мафиясенә әйләнде. Кырыгынчы еллар азагында Иркен аганың күз алдында оешкан бу оешма коры җирдә менә шул коя̈ләрнең, дәрья-суларда исә менә шул ерткыч акулаларның мәнфәгатьләре өчен барлыкка китерелде. БМОның Куркынычсызлык шурасы кешелек белән идарә итү тәшкиләте буларак рәсмиләштерелде. Террорчы-дәүләт күршесендәге берәр мескен, хәлсез дәүләт, дәүләтсез милләтне басып ала да, әгәр дә басып алынган мәзлүм басып алучыга бер генә "ярамаган" сүз әйтә икән, ана шундук "экстремист" ләкабе тагыла, танкларына каршы таш белән атса, шундук "террорист" исеме алып, БМО көн тәртибенә тикшерүгә куела. Алтмышынчы еллар уртасында колонизатор дәүләтләр кайчандыр үзләре басып алган, каннарын эчеп туйган, шул аркада җитлекми картайган сабый милләтләргә "азатлык бирәбез" дигән булып, аларны биләүләре-ниләре белән бишекләреннән төртеп төшерделәр. Азатлык өчен көрәшкән милләтләр мөстәкыйльлекне кайда үзләре, сугыш юлы белән яулап алдылар, кайда колбиләүче державалар бу мөстәкыйльлекне аларга дипломатия юлы белән "биргән" булдылар да, шундук аларны "артта калган дәүләтләр", "өченче дөнья" дип атап, инвестицияләр тараткан булып, шул ук милләтләрне имеп ятуларын дәвам итәләр...

Кан имүчеләргә тегеләрнең " аякка басуы, савыгуы" кирәкми, әгәр, савыккан хәлдә, алар бит каннарын суырттырудан туктаячаклар!..

Дөнья буйлап—яшел хлорофиллны көйдерүче коя̈ләр сабантуе!

Яңа Татарстан, яңа Рәсәй кайсы юлдан китәр? Рәсәй, чынлап та, янамы соң әле ул? Әллә тагын да хәтәррәк, тагын да айныйрак төшкән яңа империя генәме? Рәсәй үзенә янаган кыйралышны ничегрәк үтәр? Моның өчен ул үзендәге милләтара таушалу, затсызлану, ямьсезләнү сәбәпләрен ачыкларга, милләтләре белән корылтай җыеп, киңәшергә, бу чиргә иҗтимагый дару табып, инсаннарның, милләтләрнең ак төшкән күзләренә (аны катаракта диләр шикелле), сукыр айтмыйча, шул даруны, кальбләренә яңа өмет салырга тиеш. Их, нигә элегрәк килмәде икән ана мондый уй-теләкләр? Күрәсең, хунвейбиннар аны "азрак" кыйнаганнар. Күрәсең, мондый ачыш татарга кыйналганда түгел, мәгәр кыйналганнан соң... "Татар ашлары"на (ул көлемсерәп куйды) тамак туйдырырга килгәндә

килә икән...

Менә кайларга барып тоташты уйлары Чаллының "Курчак театры" тукталышында! Чынлап та, курчак театры булып чыкты түгелме соң әле бу тормыш?

Ул әсәрләнеп күккә карады.

Күк йөзе һаман да үтә коры, башны инрәтә торган ниндидер магнитлы коры иде.

Әле үзе китеп барган һәм аның күз алдында үтәчәк мәхкәмә дә шул курчак уенының бер чагылышы булмасмы? Анда сөйләнәчәк сүзләрдәге мәгънә, очрашачак күзләрдә укылган фикерләр—барысы да, ул телиме аны, әллә бөтенләй теләмиме—әле генә ул ясаган ачыш, ул уйлаган уйлар, ул кичергән хисләргә барып тоташмасмы?..

Иртәнге сигез сәгать булып килә икән. Тагын алты сәгатьтән соң мәхкәмәнең көн тәртибенә аның белән, ягъни мәсәлән, чит мәмләкәттән кайткан мөһаҗир—тән ярасыннан каза күрүче Иркен Сәлах белән шушы тарафларда туып үскән инсан—аңа бу тән ярасы салучы якын кардәше, туганнан туган борәдәре Салют Сәлахов арасында хөкем эше карала башлаячактыр. Сизенә: мәхкәмәдә каза күрүче һәм каза салучыдан сорау алу барышында ул кичерәчәк газаплар бәлки аның тормышында, язмышында моңа кадәр кичергән газапларының иң авыры, иң җәфалысы булыр, бәлки. Барысына да әзер, тик бу кичерешләр бая гына җир асты юлын аша чыкканда зиһенендә яктырып куйган яңа фикер учагына бер янар чыраг булып өстәлсен иде, илаһым!..

### III

—Көтәбез, Иркен ага.

Ак калпагын башына чөйгән, баскан җирендә очкыннар уйнаткан Зөһрә, аны бусагадан ук каршылап, өерелтә-өерелтә, залга алып кереп китте.

Сылуның үзеннән дә алдарак, алсу бит алмалары белән бар тирәне алсуга манып һәм артыннан һаваны сафландырып, нәзакәтле иннеккершән исләре бара.

Күзе тышта калган Иркен ага, берәзгә күзләрен табалмый, инке-минке килеп торды. Ниһаять, күзләре өйрәнә төшкәч, күрде: залда кәефләнеп утырган ике-өч сәрхүштән һәм ак калпакларын башларына тәпән итеп сикерткән хатыннардан башка беркем дә юк икән.

—Исәнмесез, Иркен ага!—Хатыннар боерыкка буйсынгандай, урыннарыннан күтәрелделәр.—Ярый әле Чаллыда сез бар!.. Кем безне күрер иде?

Кыргый базарчылык котырган Рәсәйдә тормыш шартлары чынлап та җинелдән түгел кебек. Тамак туйдырырга йөрүчеләрнең булмавыннан, аларны көтеп утырудан ялыккан пешекчеләр телләрен чарлый башладылар.

—Сез күренү белән доллар тотып карагандай булабыз!..—диде кыелган кара кашлысы.

—Тәмләп карагандай булабыз, диген!—дип икенчесе колакларындагы ат дагасыдай алтын алкаларын тирбәтеп.

—Ашханәбезгә керүче дә, безне күрүче дә юк! Аптырагач, үзебез залга чыгып утырабыз...—диде каш уртасында кара миңе яктырып торганы.

—Безне майлап ташласаң да алмыйлар шул!.. Аласы килгәннең артыннан баласы килә!..

—Ир-атның гайрәте бетте бит хәзер!..—дип күкрәгең киерде йомырка кебек тулы хатын.—Ичмасам, капшап та карамыйлар. Ха-ха-ха!..

—Әнә тегеләр ир-ат булмый кем соң алар?—Иркен ага залда сыра артында чебенләп утырган ирләргә ымлады.

—Кем белгән инде. Бәлки ирләрдер дә... Тотып караганыбыз юк.

Хатыннар тагын да дәррәү көлеште.

—Туктагыз, оятсызлар!—димичә Зөһрә сылуга чара калмады.

—Алар бит ирләр түгел, акчасыз клиент кына!..

Ул арада жимерек йөзле бер иркәй урыныннан күтәрелде һәм Иркен аганың каршына килеп кәмит күрсәтә башлады:

—За доллар! Всего лишь за доллар!—Урынында чегән чечеткасын шапылдатып алды.—Качалов театрының элеккеге атказанган артисты Максимилиан Клотовский булабыз!—Ул Иркен агага килеп текәлде.—Үлемсез төрмә жырчысы Михаил Круг репертуарыннан!..—Актер бармакларын гитарада уйнаган сыман итеп, күкрәгендә чирткәләп торды.—Махсус сезнең өчен!..

Песня вольная!
Дальнобойная!
Жизнь нежирная!
Хочешь волком вой!
Хочешь песню пой!...

—Житте сиңа, Макс!—Зөһрә, арага кереп, аны иптәшләренә таба этәрә башлады.—Кызлар, сезгә дә житәр! Кунагымны бозып бетерәсез. Әйдәгез, Иркен агай!..

—Болай булгач, кызлар,—диде алкалы хатын.—Зөһрәбез бу абзый белән Америкага тү-тү инде!..

—Әйдә, китсен!—Америкада "Татар ашлары"н ачып, безне дә эшкә чакырыр!..

—Чакырды ди, алъяпкычыңны киереп тот!..

Зөһрә белән янәшәдә, айсберг сыман агарып, таш идәндә атлаган саен таяк шакылдаган авазлар чыгарып, мөһажир эчтәге аерым кунаклар өчен банкет бүлмәсенә килеп керде.

Иркен ага көлемсерәп куйды. Мәдинәсе күрсә, көнләшер иде микән? Хәер, көнләшү түгелдер ул. Бер женеснең икенче женескә хакы булуын белгертеп кенә куюдыр, шулай бит? Шулай гына да көнләшмәгән хатын-кызны табып кара син. Мәдинәсенең сиздермичә сискәнеп куячагы анарда канәгатьлек тойгысын янарта. Хемингуэй әйткән "эгоизм кәнфите"нең ачы ширбәте шулдыр ул. Мәдинәсен ярата дип кенә әйтү бик аз. Кырык ел бергә яшәп, ул аны күреп тә туймаган кебек. Сөекле шагыйре Дәрдемәнд шигырендәгечә:

Сезне, милләт кызлары, аһ!
И өмид йолдызлары!
Таң-сәхәрләр эзләп-эзләп,
Бер күреп каналмадым!..
И өмид йолдызлары!..
Бер күреп каналмадым!..

Бүлмәдәге һава ябылып ятып тынчыган иде. Иркен ага кулыннан тавыш-тынсыз гына Зөһрә кулына күчкән таяк горур кыяфәттә чөйгә менеп кунаклады. Зөһрә сылу барып, жилтәрзәне кысты һәм, Иркен ага өстәл артындагы урындыкка утырырга өлгермәде, мәгъдән суы һәм бәллүр китереп куйды.

—Рәхмәт. Чарчаган идем. Бик тә.

Ул йотлыга-йотлыга Ижау суын эчте.

Зөһрә аның алдына аш-су исемлеген этәрде дә, җавабын да көтмичә, бүлмә почмагында пөхтә итеп җыештырылган урын-җиргә ымлады:

—Аш китергәнче ятып хәл җыйсагыз да була. Нимә китерәем?

—Минекен... беләсез инде. Тукмачлы аш. Булса, катык та. Кыздырылган бәрәңге белән салкын ит. Керән булса, керән. Аннан тагын... кара җимеш, өрек салып ике җамаяк чәй...

—Бүген, гафу итәсез, салкын итебез юк иде шул. Пешерергә итебез бар, тик ике холодильникның берсе эшләми. "Татэнерго"га түләргә акчабыз юк икән...—Зөһрәнең елардай булып тавышы өзлекте.—Әгәр, каршы булмасагыз, Ырымбур татарларынча әзерләнгән бишбармак бар. Бик тә тәмле! Китерәемме? Чәй янына бер элпә как та, чеметем генә бавырсак та китерәемме? Бераз гына бал да тамызаеммы?

—Ихтыярыгыз.

Ниндәен дә гүзәл тел! Китерәемме? Тамызаеммы?

—Берәй йөз грамм коньяк, аракы да китерәемме?

—Юк. Егерме ел капканым юк.

—Егерме ел дип. Капмасагыз, кабарсыз.Сез—кунак. Ир-ат. Ир-егеткә бераз гына чеметмәйчә ярамай...

Чеметмәйчә ярамай!.. Үтерде бу сүз Иркен аганы. Ул Зөһрәгә сөйкемле караш ташлады.Алдында биеп торган бу сабыйның йөзе яктысыннан бар тирә-як яктырган кебек. Иркен ага белән сөйләшә-сөйләшә, хатын-кызларга хас пөхтәлек белән һәрнәрсәне урынына куеп, җыештырынган чагында колак йомшакларындагы алтын ярымай алкалары кузгалып-кузгалып ала. Иркен аганың хәтта һәр көйсезлегән үтәргә әзер булган Зөһрә сылу вакыт-вакыт гүя җәядә тартылган укны хәтерләтә иде.

—Ырымбур татарларының бишбармагы чаллыларныкыннан аерыламыни?

—Бу якта бишбармак дигән ашны бөтенләй белмиләр. Боларның бар белгәне бәлеш..—дип аңлата башлады һөнәренең нечкәлекләрен Казан пешекчеләр училищесендә шактый яхшы үзләштергән Зөһрә сылу.— Казанда бишбармакка охшаганрак аш "өлеш" дип атала. Юныс агай Әхмәтҗанов безне шулай дип өйрәтте...

—Кем ул?

—Сез... Сез Юныс Әхмәтҗановны белмәйсез?

—Юк.—Ә сез Сәгыйть Рәмине беләсезме?—дип каршы сорау бирде Иркен ага.

—Юк. Бөтен кешене дә белеп бетереп булмай бит инде. Ә менә... Юныс агайны да белмәү... Татарның атаклы пешекчесе бит ул!

—Һы! Ә тегесе татарның атаклы шагыйре!..

—Әй, шагыйрьләр күп бит алар. Хәзер инде хәтерләмәем, татар шагыйрьләреннән кемдер... Мәхмүт Хөсәен микән шунда... Юныс агай Әхмәтҗановны татар ашларының Тукае дип атагайны.

—Кит әле!..

—Чын!.. Дөрестерме, аны Ленин ордены алган аш-су остасы диләр иде. Безне укытты ул...

—Кит әле!—Бу хәбәрләрдән бихәбәр Иркен ага, мөкиббән тыңлый иде.—Йә, хуш. Ә теге Ырымбур бишбармагы... ничегрәк була сон?—диде ул, ашыйсы килүен сиздереп.—Тәмле болады?

—Ул бишбармакта камыр кулланылмый.—Чыгып барган җиреннән кире килеп, Зөһрә аңлата башлады.—Башта ит пешерелә. Сарык ите яхшырак була. Ите сосыла. Өреле шулпасында бәрәңге пешерелә. Аннан ит белән бәрәңге эре итеп турала. Аннан алар шул үзләре пешкән шулпага салына

һәм янадан кайнатып чыгарыла. Тәлинкәгә салгач, өстенә божра-божра итеп туралган ак суган, кара борыч сибелә... Бераз гына корыт[12] катсаң да ярый.

—Булса!..—диде ачыгудан түземе калмаган Иркен ага.—Корыт, дисең инде?

—Корыт.

—Бик тә тәмле була, дисең инде?

—Бик тә тәмле була, Иркен агай.

—Бар, йөгертә күр!..

—Хәзер! Әллә касан шулай диләр аны!..

Зөһрәнең сөйләше кызык тоелды. Залда чип-чиста итеп татарча сөйләшкән кызкай, монда, аерым бүлмәгә үткәч, үзгәрде дә куйды. "Бармаем-кайтмаем" дип сөйләшүче бу кавем... Ырымбур, Агыйдел-Урал буе татарлары түгелме соң?

Мизгел дә үтмәде, бүлмәгә өреле шулпа, кара борыч, суган исләре аңкыткан арбасын тәгәрәтеп, Зөһрә килеп тә керде.

—Сорарга онытканмын. Ите хәләлдер бит?

—Сорап торасыз. Кайнар килеш кенә ашагыз әле. Корыт юк. Катык кына. Сезнең өчен үзем оеттым...—Ул сөйләнә-сөйләнә тәлинкәләрен өстәлгә куйды.—Чаллы халкы катыкның нимә икәнен дә белмәй. Авыл халкы да оетып маташмай. Корыт хакында инде әйтеп торасы да юк...

—Бездә, Төркестанда, татарлар корытны ясапмы ясыйлар! Бездә аны "ак болыт" дип тә атыйлар. Әйрән ясап эчсәң, торганы белән кымыз болады!..

—Бездә дә шулай. Ә бында—юк!.. Гомумән, мал агыннан азык ясарга дигәндә, халык ялкау бында. Сөт белән майдан башка нәрсәне белмиләр. Кымыз хакында ишеткәннәре дә юк. Мин сезгә катык кирәклеген беләм! Шуңа да үзем оетам. Суытмыйча ашый күрегез, яме. Ашыгыз тәмле булсын!

Кара әле, яшь булуына карамастан, нинди акыллы хатын!..

Ашаган унайга ул аңа беренче тапкыр шулай текәлеп карады. Чыклы карагат кебек кара күзле, кара тут йөзле икән. "Чибәр, житмәсә, үткер...— дип уйлап алды Иркен ага.—Кешесе туры килсә, милләткә ун бала үстерәчәк бит бу".

—Үзегез бу яктанмы?

—Юк. Башкортстандан. Хәйбулла районыннан. Юлдыбай кызы.

—Шундый вилаять тә бармыни?

—Вилаяте ни була тагын?

—Штат. Сезнеңчә префектура. Кантон. Юк, район болады.

—Әйе, район! Хәй-бул-ла! Биегән кеше бай була. Бар андый район.

—Татарлар яшиме?

—Ашым тозлыгы кадәр генә. Калгандары—башкорттар.

—Әллә син дә башкортмы?

—Әйе. Башкорт. Саллыга комсомол путевкасы белән килгән идек...

Иркен аганың йөзенә елмаю таралып эреде. Ул чын башкортны беренче тапкыр күрә иде.

—Сылуым!—Иркен ага беразга куанычыннан сүзен әйтә алмый торды. Аның, урыныннан кутәрелеп, ошбу төрки сеңелкәшен бертуганы сыман кысып кочасы килде.—Сылуым!.. Бирегә килмәгән булсам, мин чын башкорт кызын күрмәй-белмәй үлгән булыр идем!..

—Һы, күрмәй-белмәй!..—дип көлде Зөһрә.—Сез дә башкортча сөйлисез

[12] Корыт—әчегән катыкны эркеткә әйләнгәнче кайнатып, суын агызып, киптереп ясалган коры сөт азыгы.

бит!..

—"Күрмәй-белмәй" дип сөйләү безнен төрки-татарга бигрәк тә хас, Зөһрә сылу,—диде Иркен ага аны-моны уйламыйча.—Аны Тукай да куллана.

—Юк, ул башкортка гына хас!.. Бездә дә "сылу", тизәр. Әмма мин—сылу гына түгел, мин—асаба башкорт сылуы,—Зөһрә күзләрен җете чекрәйтте.

—"Асаба" ны ничек анларга? Төшендерең.

—Асаба—"особый"дан инде. Урыслар килгәннән сон, җирләребезне үзебездә калдырганнар. Салым да түләтмәгәннәр, көчләп әрмегә дә алып китмәгәннәр. Шуна да без "особый". Башка халыклардан җирне талап алсалар, башкортлардан сатып кына алганнар. Башкорттан башкалар—килмешәктәр. Припущенниктәр.

—Һы. "Саф башкорт" дигәне ни нәрсә болады?

—Татар белән бер грамм да кушылмаган,—диде Зөһрә, керфеген дә какмыйча.—Каны бозылмаган, димәк...

Иркен ага ашавыннан туктады. Капкан азыгы гүя тамагына аркылы торгандай итте.

—Соң татар белән башкорт... бертуган халык түгелсән? Татар белән кушылганда башкортның каны бозылады? Башкортлар шулай татарларны... яратмыймени?

Авыр тынлык урнашты. Иркен аганың кулындагы сәгатенең йөргәне ишетелә иде. Үзенең тирән уйга сабуын сизенмәсен дип, Иркен ага мөкиббән китеп ашап азапланган булды. "Әгәр син татар белән урысның катнаш никахларына лаф орасың икән, нигә әле ул, Зөһрә сылу, татар белән башкортның катнашуын алкышларга тиеш?—дип уйлады.—Анысы шулай... Ярар, урыс белән татар икесе ике фәлсәфә, ике дин нигезендә яшәп яткан ике аерым галактика ди. Ә менә башкорт белән татар исә—бер үк төркиләр... бер үк дингә инанган игезәкләр бит... Асылда икесе бер милләт... Бәлки шушы бер төрки милләт булуы аларны аерадыр да?"

Ниһаять, Зөһрә тынлыкны бозды:

—Яратмасам... Яратмасам, монда яшәгән булыр идем микән? Яратмасам, мин кайбер башкортлар кебек, Чаллыны ташлап кайтып киткән булыр идем.—Анын аһәңе тирәннәрдән килеп калтыранды. Илтифат иткән кеше анын сөрмәле керфекләренең дымлануын абайлар иде.—Сагындыра бит... Татар теле—матур тел, сирәк тел... Әмма һедден менән туган телемдә лә һөйләшкем килә, агай!.. Сөнки һез—сит кеше!..

—Бәй, сөйләш!.. Башкортча да... белгәч?

—Белмәй тиме! Тыуган телен әзәм балаһы онота тиме?!—Ул тулаем башкортчага күчте һәм бәбәй бишеге өстендәге кыңгырау кебек чәңгелдәп көлеп җибәрде.—Мәрәкә кеше һез! Телен оноторга, мин бит... татар түгел!..

—Татарлар... онытамы?

—Онытмай гынамы? Бар тип тә белмәйдәр!..

Бик тә кәефе кырылды Иркен аганың. Сиздермәскә тырышты.

—Миңа калса, башкорт теле—шул ук татар теленең бер җирле сөйләше түгелме? Анда берничә сакау аваз гына...

—Башкорт теленең көсе—шул һед әйткән һакау авазларда!..—диде Зөһрә, аны бүлдереп.—Татар теленә нәкъ шул һакау ауаздар етмәй!..

—Ә нигә сез башкортча гына сөйләшмисез?

—Татарстан җирендә башкортча сөйләшеп азаплануны мин тугандаш татар телен дә, үз телемне дә ихтирам итмәү кебек анлаем. Гамәлдә, алар чынлап та икесе бер тел...

—Шулай да, үзегез башкортча сөйләшергә теләйсез?..

—Телдәрде ходай аерган бит!.. Аергас, һөйләшке килә шул, агай!.. Был—һедден өсөн генә!.. Һедден менән генә!..

Иркен ага, югалып калып, аңа нәрсәләрдер сөйләп маташты, әмма артына борылып караса—Зөһрә-сылуы шым гына чыгып та киткән икән. Мөһаҗирнең яшь хатынкайга "Зөһрә-балам" дип эндәшәсе, бу башкорт баласының күңелен арбыйсы килде. Аның өчен хатын-кызның күңелен китү, рәнҗетү—зур гөнаһ. Хатын-кыз—җир белән күк арасында яши торган илаһи җан иясе. Миллиятне бар иткән ошбу ил аналарына күңел тойгылары ташып чыккан мәлләрдә ул керсез, риясыз, бертуган сеңлесе кебек якын күргән сылуларына "балам" диясе килә башлый...

Ул бишбармакны бик тә яратты. Катыгы да кәттә булды. Уйгырстанда да күп татар гаиләләре ашны катыксыз ашамыйлар. "Катык-сөт ашаган кешенең эче кортламый, карынына бабасыр да иялә шми,—ди торган иде аның картинәсе Бибикамал карчык.—Ашказанына яман шешләр дә калыкмый". Катыкны көчләп сабыйларның ашына салдыра, әйрән итеп сыеклап, көчли-көчли, көрәгәсе белән эчерә торган иде. Житмәсә, "Эч тизрәк, картатаң күрмәсен!"—дип хәйләләштергән булып, ашыктырып эчерә торган иде. Әйтерсең, мал-туар арасында мең мәшәкатьтә йөргән картаталарының шул ачы катыкка калган көне булган инде, ходаем. Әй, бу әби-бабайларның халык дипломатиясе!..

Азык җыйганда аны кемдер күзәтеп торгандай тоелды. Ашавыннан туктап, карашы белән диварларга күз йөртеп чыкты. Аңа кургашын күзләре белән оеп, югарыдан сурәт карап тора икән. Йотасы азык һаман тамакта иде. Таяксыз-нисез, як-якка янтая-янтая, сурәт янына килде. Ельцин икән. Бу сурәт әле кичә генә биредә юк иде бит!.. Рәсәйдә падишаһлык иткән кыргый демократия атасының чит-чите елтыр калай белән каелган кечкенә сурәтен ялт итеп арты белән әйләндерде дә куйды. Титаклый-титаклый кире урынына килеп утырды.

Гамәлдә исә аны шымчылардан башка да күзәтәләр иде. Пешекче хатыннар алмашлап килеп, ишектәге үзләре генә белгән тишек аша караштырып китәләр. Америкадан килгән татарның нәрсә ашавыннан тыш, ничек ашавы, калакны кайсы кулга тотуы да кызык иде аларга. Яшермик, Рәсәй ФСБсы өчен мәртәбәле кеше иде Иркен ага. Аның кемнәр белән очрашуы, нәрсә хакында сөйләшүе, ничек уйлавы да кызыклы иде. Иркен ага, төрмәләр, сөргеннәр аша үткән тәҗрибәле тоткын буларак, аңа бары тик әмрикәле булганы өчен генә дә үзенә игътибарның зур булуын белә һәм бер үк вакытта, үзенең "беркемгә дә кирәкмәгән карт мөһаҗир икәнлеген" исләп тә, ул чишенгән гардероб, ул утырган урындык, ул азык җыйган өстәл астында кырмыска кебек кечкенә, тынлый, яза, кирәк икән, сурәткә дә төшереп ала алган кулайламаларның, каршыдагы йортның тәрәзәсеннән мондагы һәр хәрәкәтне таш дивар аша да кинога теркәп бара торган аппаратларның булуына һич тә шикләнми иде...

Ә менә Әмрикәдән килгән татарга, үз чиратында, мондагы татарларның ни-нәрсә һәм ничек азыклануы кызык иде. Чаллының байтак ашханә-рестораннарында булганы бар аның. Күпчелегендә бик начар тукландыралар. Акчаны алуын мулдан алалар, әмма азыкларына килгәндә, әллә чүбек, әллә кояшта пешенгән салам чәйнисең. Әллә ит, әллә агач тешлисең. Карының тулса да, тамагың туймый. Соныннан, билләһи, ниндидер химикалий кикереп йөрисең. Ә менә бирелдәге аш белән яратып ризыклана ул. Биредәге ашның тозы-татыры, токмачының үзле катылыгы, тешләрдә сизелеп чәйнәлүе, катыгының әчкелтем тәме аңа Шинҗәнендә ашаган токмачларны хәтерләтә. Нидән шулай? Араларда—кем исәплəп

караган?—кимендә ун мең чакрым юл ята; җир-туфрак, тир-талым—икенче; агым су, искән җилләр, бу азыкларны әзерләгән затлар башка... Иркен ага разыйдан елмаеп куйды: сер азыкның хәләллегендә болады. Хәләл ризыкны хәләл хатын әзерләп биргәнгә һәм бисмилла аша хәләл ир-егет ашаганга күрә туя ул хәләл тамак. Әйе, беренче булып шушында, Чаллының "Татар ашлары" йортында килде Иркен аганың тынгысыз зиһененә теге уй: Сталин исеме белән тарихка кергән милләт билгеләмәсендәге биш сыйфат—җир-су, икътисад, тел, тарих, мәдәният берлегенә, алтынчы сыйфат буларак, аш-су өстәлергә тиеш. Әйе, аш-су!.. Милләтне башка милләтләрдән, киемгә караганда да, аш-су аермасы ныграк саклый бит. Иркен агага билгеле булуынча, татарның аш-суы, төрлелеге ягыннан, җир йөзендә иң байлардан саналырга хаклы. Кытайлардан... ниппуннардан кала, әлбәттә. Уйлабрак торсаң, аның, милләтнең, Аллаһы Тәгаләгә генә билгеле җиденче, сигезенче, хәтта йөзенче сыйфатлары да бардыр әле...

Иркен ага, тамак туклык итеп, каклы чәен дә эчкәч, ашыкмыйча гына догасын кылды. Зөһрә кереп, җыештырына башлаган икән.

—Ашыгыз тәмле булды, Зөһрә сылуым. Бик тәшәккүрмен.

—Тәшәккүр...—Ул кеткелдәп алды.—Тәшәккүр... Монысы нәмәрсә тагын?

—Гарәпчәдән рәхмәт дигән сүз. Үктәбер түнкәрелешенә кадәр телдә даими кулланылган.

—Түнкәрелеше нәмәрсә?

—Революция, ягъни дөньяның асты өскә килү дигән сүз.

—Асты өскә килүе нәмәрсә?

—Йөзтүбәннең чалкан, чалканның йөзтүбән әйләнүе.

—Сезнең белән никадәр кызык!—Зөһрә тагын да бала кыңгыравы кебек зеңгелдәп көлде.—Шушы яшемә җитеп, тәүге тапкыр ишетәм...

—Шушы яшемә җитеп, дияргә...сез шулай картмыни инде?—Иркен ага да көлемсерәп куйды.—Сер булмаса, сезгә ничә яшь?

—Егерме сигез.

—Тормыштамы?

—Булып алдым. Киявем дә, үзем кеүек, Хәйбулла башкорты ине...—диде Зөһрә моңсуланып.—Якташым ине...

—Аерылыштыгызмы? Һаман да шул гашрәтме? Эчтеме, диюем?

—Юк, агай!.. Сәбәп эчүдә булган булса, бала хакына, бәлки, түзгән дә булыр инем... Аерылышуыбызның сәбәбен сез күз алдыгызга да китерә алмассыз бәлки... Быны аңлатуы да авыр...—Зөһрәнең йөзенә кара күләгә ятты, япь-яшь йөзен җыерчыклар биләп алып, аны гүя шундук ун елга картайтты.—Ул татар халкын... ул татар милләтен... татар кешесен... татарның атын... этен... ашын-суын.. бер нимәһен дә яратмай ине!..—Ул кирәкле сүзне җаныннан сытып чыгара алмыйча җәфаланды.—Аны, агай... Уфа милләтселәре... әйтергә оят!.. татарны күрә алмау чире белән агуладылар!..—Зөһрә лып утырды һәм йөзен каплады. Кинәттән ул җанының тирәненнән "их!" дигән кебек авазлар чыгарып, үксү катыш сөйли башлады. Ул, хезмәттәш хатыннары арасында татарча гына сөйләшеп, көтмәгәндә, Иркен ага иркенендә "иркенгә" чыккач, үзе дә сизмәстән, татар-башкорттан үзе кораштырган телдә гәперә[13] иде.—Мин уны дөрес юлга бастырырга тырыштым, агай!... Шуның аркасында сыккан гауга-тавыштарны күрсәгез-ишетсәгез сез!.. Мин аптырашка кала инем: без бер су эсеп, бер һава һулап, бер тупракта үскәнбез—әмма без икебез ике кеше инек!.. Ә бит татар менән башкорт икесе бер милләт, ырыудары гына башка!.. Каян, кемдән килгән уга татарны был кадәр яратмау, күрә алмау,

[13] Гәперү (төрки-үзбәк.)—сөйләшү.

дошмандык тойгоһо?! Тимәк, кандан, нәселдән килгән!.. "Татар ултырган урындыкка кырып йыумайынса ултырма!" "Татар менән көрешкәндән һун улынды кер һабыны менән йыу!", "Татар—атаһын һатар!" "Татар—ашар да касар!" Иртәһен дә—"татар!", кисен дә—"татар!", хәтта... йокларга яткас та "татар" ине унын телендә... Ул татар турында бары тик мәкаль менән генә һөйләшә ине! Сирләне шул сир менән, сирләне, агай! Тыуган төяккә кайтып китү уе менән котырып, эсә башланы... Эсә лә татарды һүгә, эсә лә татарды һүгә!..

—Аты кандай иде?

—Анын аты юк иде шул. Ул атсыз иде... Шунын аркасында кайтып китте лә инде...

—Исемен сораган идем...—диде Иркен ага Зөһрәнең анлап житкермәвен төшенеп.

—Ә-ә, исемен әйтәсезмени? Исеме унын, исеме...—Зөһрә сылу, көлемсерәп, теләр-теләмәс кенә телен әйләндерде.—Исеме заманса унын. Револь... Ишморатов. Ишмораттар Револьверы, тимәк. Татар былай йоктаһа, был Револьвердәр әле Саллыны басып аласак!..

Иркен аганы шаукым суккандай булды. Иртәнге ягмурнын яумый калуы бәлки шушы Револь калдырып киткән шаукымга бәйле булгандыр? Иркен ага өчен Зөһрәнең һәр сүзенә мәгънәле мөһер сугылган иде. Ул—тәне вә жаны белән татар, чит илләрдә дә татар-башкорт өчен жан атып, ватанын күрергә кайткач, борәдәре тарафыннан баш сөяге ярылган милләтпәрвәр, ике ут арасында калды. Бәлки ул, чынлап та, хаклы рәвештә кыйналырга тиешле "начар инсан, бозык кеше"дер? Бәлки милләте дә, бары тик... кыйналырга тиешле милләттер?

—Ул хәзер кайда, Чаллыдамы?

—Юк. Уфада.

—Башлы-күзлеме? Эшлиме?

—Юк әле. Өйләнмәгән. Мине Уфага кайтмасын, күземә чалынса, татарга сатылганы өсөн башын сабып өдәм, дип әйтә ти...

—Шулай укмы? Балагыз да... бармы?

Зөһрә сылу дертләп куйды.

—Бар. Ике яшьлек улым. Нәркәс.

Очлары күлмәген төртеп торган күкрәкле, май йомарлагыдай түгәрәк, куен иркәсе булырдай бер жыйнак-гүзәл хатын иде ул. Көч-хәл белән генә эш тапкан, гомумторакнын бер бүлмәсендә өченче өйдәш булып яшәгән, баласын әле күптән түгел генә бакчага урнаштыра алган бу яшь ана ата кадереннән мәхрүм сабыен һаман да имезә һәм, уйлавынча, дүрт яшенә кадәр имезеп утырачак. Иркен ага карашын идәнгә күчереп, уйга калды. Анын үз әнисенең исеме дә, Төркиядәге яраткан онычкасынын исеме дә Нәркәс иде. Биредә аны ир балага кушканнар.

—Бер ялгызын читендер?

—Енел түгел. Хәер, без күмәк бит... Ашханәлә утыз ике хатын-кыз эшләй, шуларнын егерме икесе ялгызак... Бәхетсезлек, күмәк булганда, күзгә салынмай бит ул. Чаллы, гомумән, ирсез хатыннар, холостячкалар калаһы. Бында һәр ир-ат ашау-эчү хакына хатын-кызны көн саен алыштыра ала... Кайберәүләр шулай яшәй дә...

Авыр уйларыннан тизрәк арынырга теләп булса кирәк, Зөһрә сылу радионы тоташтырды.

—Сез "Күнел" радиосын тынлыйсыз!..—Бүлмәне нечкә дискант белән сөйләгән егеткәй тавышы тутырды.—Туган көннәр уңаеннан без туры эфирдан концертыбызны башлыйбыз!..

—Райнур үзе алып бара... Мин анын кызлар тавышын яратам!..

—Әлү-әлү!.. Исәнмесез!—Эфирда икенче бер чебек тавыш ишетелде.—Райнур, сезме бу?

—Әйе, мин,—диделәр эфирдан.—Сөйләгез, сөйлә!

Чебек тавыш дәвам итте:

—Сезне егерме җиденче күмпликстән Икестрә Җәмлиханова беспоколит итә... Без, бертуган апалар һәм энекәшләр, туганнар һәм кардәшләр, папы-мамыларыбызны безне иҗат иткәннәре өчен рәхмәт әйтеп, туган көннәре белән кайнар котлыйбыз. Шушы randomнан... Шушы ыслучайдан чыгып, Хәмдүнә Тимергалиева башкаруында "Тары җире, киндер җире" җырын... юк, ул түгел икән... (эфирда нәрсәдер шытырдады) келәссикәбезнең тары...әй, тәре, әй, гафу итегез, тере фондыннан "Галигә барам әле" дигән җырны тапшыруыгызны үтенәм...

—Экстра, сезгә ничек эндәшергә? Сез туташмы, әллә ханыммы?—диде Райнур.

—Бәй, икесен дә әйтегез. Туташ-ханым диегез. Мин, әтним ысловом, Икестра,—диде эфирдагы тавыш.—Әй, эрәзве ите имет эзнәчинне?

—Ярар, туташ диик алай булгач. Икестра туташ, әти-әниләрегез кайсы районда яши? Радиобыз Мамадыштан да ары янгырамый.

—Зәчим әдрис? Бергә яшибез! Әле бергә сезне тынлап утырабыз!..

Пырхылдап көлеп алгач, бер мизгелгә тынсыз торган эфир телгә килде:

—Сезнең өчен Хәмдүнә башкаруында милли эшләгиребез "Галигә барам әле" башкарыла...

—Чаллының Сидоровка поселогында яшәгән сөеклебез, яратканыбыз, кадерлебез, бердәнберебез, сагынычлыбыз, түр башындагыбыз, өф итмәгән җиргә утыртмаганыбыз, идәннәрен кыргычлап-кыргычлап юган әниебез, сине туган көнең белән өзелепләр котлыйбыз,—дип дәвам итте Райнур.—Әтиебез белән кырык ел бергә яшәп, яшьлектә черек бәрәңге витаминнары ашап, чабаталар киеп, ике дә уйламыйча, рәхәтләнеп, безне үстергәнсез. Сезнең берегез—ай, сезнең икенчегез—кояш! Сезгә музыкаль сәлам итеп композитор Чуртакаевның местный шагыйрь Күнелуйнин сүзләренә җырчы Чәмчеттин Җепшеттинов башкаруында җыр тапшыруыгызны үтенәбез. Сезнең Чаллыда яшәүче балаларыгыз Зенит, Зәрнис, Әнис, Дәнис, оныкларыгыз Мәрмәр, Алмаз, Гранит, Солнцедар, Изолента!..

—Сылуым, баса күр...—диде күзләре маңгайга менгән Иркен ага. Ул бу кадәресен үк башына сыйдыра алмый иде.—Бүген башны аудара торган магнитлы көн, күрәсең...

—Магнит безнең кызлардан түгел микән?

—Кая ди ул миңа? Мин карт кеше...

—Һи-и, Чаллы өчен Америкадан кайткан карт—иң яхшы шарт!.. Безнең хатыннар, акчасы булса, җитмеш яшьлеккә генә түгел, йөз яшьлеккә дә ияреpгә әзер! Доллар! Доллар!! Доллар!!! Бүген сез миңа ошап җитмисез әле!.. Башка көннәрдәгечә, берәр мәзәк тә сөйләмисез!..

—Сөйлим!—диде Иркен ага, нәрсә сөйләрен дә белмичә.

—Сөйләгез!..—Зәһрә-сылу чүпрәген өстәлгә ташлап, утырды.

—Һм... Бу мәзәкне былтыр татар конгрессы барган вакытта кунакханәдә ишеткән идем. Паравызлар чыккан заманнан калган, диделәр. Паравыз күрмәгән татар паравыз күргәненнән сорый, имеш: "Абзый кеше, сөйлә әле, ничегрәк йөри соң ул шул паравыз дигәннәре?" Тегесе аңлата икән: "Паравыз кузгалып китәр алдыннан "Удды-мыррт! Удды-мыррт!" дип көчәнә. Аннан "Чув-ваш! Чув-ваш!" дип пар борхытып кузгала. Станцадан чыгар алдыннан, "Мук-шы-у! Мук-шы-у!" дип җиз торбадан бакырта да, ачык яланга чыгып алгач, "Та-та-рин! Та-та-рин!" дип җилдерә башлый,

ди, имеш...

Икесе дә кинәнеп көлделәр. Зөһрә сылунын жыештырыласы жыештырылган, сөртеләсе сөртелгән булса да, бүлмәдән чыгасы килми иде. Иркен ага сәгатенә күз салды. Мәхкәмә башланганчы әле тагын биш сәгать вакыты бар икән. Зөһрә сылу кинәшен тотып, әнә теге диванда бераз хәл жыеп, фикер туплап алганда да яхшы булыр иде, югыйсә...

—Безнен монда... телевизорны ачсан да—атыш-үлтереш, урамга чыксан да—атыш-үлтереш... Тормыш түгел, караңгы баз, агай...—Зөһрәнен күкрәк төбеннән күтәрелгән тавышы калтырана иде. Ул тагын башкортчасына күчте.—Мин бит йөрәгем ярһыузарына урын таба алмаганга гына шулай маһаеп һөйләшкән булам, агай!.. Шушы яшьтән... ир кадере күрмәйенсә...

Ул, башын учларына салып, өстәл өстенә бөгелеп төште.

—Сез ул кадәр бетеренмәгез, балам,—диде Иркен ага нәрсә әйтергә дә белмичә.—Сезнен әле барысы да алда...—Ул Зөһрәнен чәчләреннән сыйпый, юата башлады.—Ышаныгыз, сез әле үзегезгә менә дигән юлдаш табачаксыз, биш-алты бала үстерәчәксез...

—Алдамагыз мине! Ышанмаем!—Зөһрә сылу үксеп елый иде.—Алты бала атаһы булырлык татар-башкортны табып кара!.. Ышанмаем!.. Урыска сыккым килмәй!.. Ятар урынын уртак булып, йөрәгеңдән һурылып сыккан балаң урыстыкы булгас, яшәүзен ни мәгәнәһе бар?! Юк!.. Киткем килә!.. Алып китегез мине бынан!..

Зөһрә сылу, нәрсә әйткәнен сизми дә калып, авызын каплады. Ул ап-ак булды. Аннан, тора-бара, менә шушы бүлмәдә, әнә, тегендә, югарыда, түшәмдә эленеп торып, яктысын тирә-якка тарата-тарата, инде үзе саргаеп калган шәмдәл пыяласы сыман саргайды. Башын кискен күтәреп, артка таба какты, күз керфекләре очындагы яшь бөртекләрен һавага сипкәндәй итте дә, көлеп жибәрде:

—Сез нәрсә, Иркен ага? Тормыштан зарланган һәр Рәсәй бичәсен Америкага ташый башласагыз, аннан үзегезне куып чыгармасыннар!... Алып барма син безне анда, ку син безне аннан, Ходай бәндәсе! Барабыз дисәк тә алмагыз, самолетларга бәйләнгән бауларыбызны кисеп, жирдә калдырыгыз!..—Чак кына ишетелерлек итеп ул тагын үкси башлады.—Юк, бернинди Америкага да китмим мин! Мин анда корып кибәсәкмен! Мин унда һуласакмын, агай! Онотмагыз, башкорт сит-ят якта үлмәй! Башкорт ситтә үлә башлап, барыбер туган еренә кайтып ерләнергә өлгерә... Башкорттын атаклы йыры "Илсе Гайсә"лә "Исән генәләй йөреп илгә кайтһам, тарих язып инем ташына" тиелә, аңлайһыгызмы? Минең бөтә хыялым—кире Хәйбуллама, таузарыма, далаларыма кире кайту! Бында минә тын етмәй! Әрәмәлектәре бар—коштары һайрамай!.. Зур елга буе—һыуы юк! Һауалары бейек—тын етмәй!.. Ә бына һедден эшегед—тарих языу!

—Нинди тарих?—диде Иркен ага сискәнеп.—Кандай тарих?

Бүлмәдә әллә Зөһрә баланың, әллә Иркен аганың йөрәк тибеше сәгать йөрешедәй текелдәп янгырый иде.

—Тынычлан, сылуым... Мондый вакытта, сабырлык эзләп, уч төпләренә кара...

Зөһрә уч төпләренә карады.

—Тынычлан. Тыныч-лан. Ты-ныч-лан. Син нинди тарих турында сөйлисең?

—Үзегезнен тарихны!..Сезгә үзегез турында китап язарга кирәк. Сез сирәк кеше, агай.—Тынычланган Зөһрә сылу инде таң каршылаган кызбала кебек шат иде.—Әгәр мин сезнең кебек Америкалардан кайткан булсам, әллә нинди китаплар язган булыр идем!.. Әйе!.. Бездә хәзер күрше

авылдан күчеп килгәннәр дә мемуар яза...

Иркен ага тирән хыялларга батканын сизми дә калды.

—Чынлап та!.. Язсагыз сез ул китапны!.. Аны сез генә яза аласыз!..—Ул өстәл тартмасын ачты, аннан кәгазь һәм каләм чыгарды.—Тотыгыз да яза башлагыз... Бездә, "Татар ашлары"нда... Менә шушында, агай!..

Һәм ул агасының җавабын да көтми чыгып йөгерде.

Үз җиренең мәгърур йөрәкле бер баласы иде бу Зөһрә сылу. Аның карлыгандай юеш күз каралары идәнгә төшеп челпәрәмә чәчрәгәндәй тоелды. Иркен аганың йөрәге кысып, күзләре идәнгә текәлде. Идән хәзер Зөһрәнең меңләгән күзләре белән карый иде кебек. Юк, алар Мәдинә-иркәгенең күзләре икән бит. Ул күз кабакларын йомды һәм, бисмилласын әйтеп, идәндәге шушы меңләгән күзләрне йомдырырга тырышты... Күзләрен ачты. Хәзер аңа бу күзләр дивардардан һәм түшәмнәрдән дә карыйлар иде. "Яз!—диеп ялвара иде алар Иркен агага.—Китап яз!"

Карар бар иде. Ният ителгән иде. Җинелрәк булып китте. Ул урынга барып ауды. Яңадан күзен йомды.

Сөт калыр, Ватан китәр!
Сөт калыр, Ватан китәр!..

Гүя бу юлларны аның колагына Дәрдемәнд булып хәзер Мәдинәсе пышылдый иде...

Ул яңадан күзләрен ачты. Идәндә, диварларда, түшәмнәрдә чекрәеп янган күзләр хәзер инде югалганнар иде. Кара әле бу Зөһрәне, ә? Китап язарга кирәк, диме? Кайда, диген. "Татар ашлары" йортында!.. Нишләп моңа кадәр бер генә кешенең дә аңа мондый киңәш биргәне булмады? Яшерми, үзенә килгәне бар иде мондый фикернең. Тик ул китап яза ала диме? Дөрес, сабый чагында, Тукай шигырьләре белән сихерләнгәч, шигырь сырлап маташкан иде. Дәрдемәнд шигыренең кыска, кайнар сулышы тын юлына капканнан соң, бүтән язып азапланмады. Зөһрә сылу дөрес әйтә әйтүен: күргәне-кичергәне бихисап. Язарга тотыну түгел, бу хакта уйларга да курка. Бәлки Аллаһы Тәгалә аңа ошбу китапны нәкъ менә бүген—Чаллы каласында, туганнан туган борадәре белән икесенең арасында булачак мәхкәмә алдыннан уйлый башларга боергандыр?!

Әгәр, аңа тотынырга җөрьәт итсә, нәселе, үзе шаһит булган тарихи вакыйгалар турында публицистик бәян-белешмә генә язган булыр иде, әлбәттә. Шуннан артыгын булдыра алмаячак. Их, язарга иде дә бит борынгы татар нәселләре, ырулары турында каһарманый әсәрләр!.. Борынгы скандинав халыклары әдәбиятындагы "сага" (saga), татар әдәбиятына жанр ягыннан тәңгәлләштергәндә, нәсел турында героик дастанга туры килми микән? Норвег, исландларның "Ньяле турында сага", "Эгиль турында сага" дигән атаклы риваятьләре бар. Шулар үрнәгендә язган бит инде бөек инглиз язучысы Джон Голсуорси үзенең "Форсайтлар турында сага"сын. Теодор Драйзерның "Әмрикән фаҗига"сы да миллионер Каупервудлар нәселе турында сага түгелме? Их, язарга иде татарның "Сәлахиләр сагышы" дигән сага-дастанын. Чук гүзәл болады!..

Әгәр ул, борын-борынгыдан Шәркый Төркестан дип йөртелгән, соңгы чорда кытайларның "Голҗа солтанлыгы" дигән соңгы уйгыр дәүләтен җимергәннән һәм 1874-1884 елларда уйгыр халкын тәмам басып алганнан соң, Шенҗаң провинциясе дип үзгәртелгән, хәзер исә Шенҗаң-Уйгыр автономияле вилаяте дип исемләнгән тупракның Кизләү авылында 1930 елның 29 августында туып, шунда үскән, хәзерге көндә Әмрикә Кушма Штатларының гражданины сыйфатында Висконсин штатының Сент-Люис

калачыгы янындагы утарында гомер сөреп яткан Иркен ага, үзе турында китап язарга утырса, сүзен нидән башлап киткән булыр иде икән?

Әйе, ихластан да!..Кызык бит бу!.. Уйлап карасаң!..

Ул баш очындагы мендәрен рәтләп куйды, башын кушырылган учлары өстенә салды.

Фикер килми иде.

Мендәрен янадан төзәткәндәй итте.

Фикер һаман да килми иде әле.

Ниһаять!

Ул китабын, мөгаен, шулай башлаган булыр иде:

"...Мин, чыгышым белән россияле татар Иркен Фәррәхетдин угылы Сәлахи, американ паспортым буенча Иркен Сало, 1997 елның 26 августында татарларның Икенче Бөтендөнья Татар Конгрессы мәҗлесендә вә җөмһүриятебезнең Мөстәкыйльлек бәйрәмендә катнашып, милли тәрәккыятебез юлларын бергәләп эзләү ниятендә, Казанга килгән идем...

...Менә бүген 1998 елның 27 мае. Минем Рәсәйгә унбиш көнгә дип фаразланган визитым тугызынчы ае белән бара. Яшәп яткан ватаныма әле булса кайта алганым юк...( "Ни өчен?"—дигән уйда аны курку басты. "Ни өчен кайталмыйсән?")

Бу сорауга җавап бирү өчен "Ни нәрсә ул Ватан?" дигән сорауга җавап бирергә тиеш булады.

Ватан, дигәннән...

Язмышыннан чыгып, кешенең өч ватаны булмакта икән: туып-үскән ватаны; гомер иткән ватаны; тарихи ватаны. Аның, мәсәлән, нәкъ шулай килеп чыкты: туып-үскән ватаны—Уйгырстан. Аны уйгырлар һәм барча төрки дөнья Шәркый Төркестан дип тә атый. Кытай коммунистларының бу атаманы женнәре сөйми. Шуңа күрә алар ана Шенҗән (Шинҗән)-Уйгыр автоном вилаяте дигән рәсми исем тактылар. Уйгырстанны канга батырган кытай биләмәчесе Зу Зон-тан калдырган бу мәкерле исем ике мәгънәгә ия. "Шин"—Цин, чин империясе, "җәнг—өлкә". Төрки уйгырлар түгел, чин, ягъни кытайлар өлкәсе, жире, тупрагы, имеш. Икенчесе: шен—"яңа", "җәң"—"чик". Ягъни кытайлар билгеләгән "Яңа чик"...

Әйе, туган ватаны—Шәркый Төркестан. Гомер кичергән ватаны—Әмрикә Кушма Штатлары. Тарихи ватаны—Татарстан. Ул "Тарихи ватаным—Рәсәй" дип әйтергә тиеш иде. Әйтә алмады. Йөрәгендә нидер чәнечте. Күзләренә яшь типте. Ул карашын түшәмдә асылынып торган бер чынаяклы соргылт шәмдәлгә юнәлтте. Керфекләре йомылганнан-йомыла, шәмдәл исә кечерәйгәннән кечерәя барып, караңгылыкка чумды...

*Дәвамы киләсе саннарда*



Рәниф Шәрипов

# СОҢГЫ СӘЛАМ

ӨЧ МОНОЛОГ

## 1. Зәйтүнә монологы

*"Без Чистайга китәчәгебезне, бары күрешү өчен генә килүебезне әйткәч, Тукай: "Бик кызганыч",—диде.*

Зәйтүнә Мәүлүдова истәлегеннән.

*Очты дөнья читлегеннән, тарсынып күңлем кошы.*
*Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы.*

Габдулла Тукай.

**Кара төстә дөнья,**
**Кара төстә һава,**
**Барлык тирә-ягым кап-кара.**
**Җаным сизә, тоя:**
**Мәңгелеккә каршы**
**Ак пароход суда эз яра.**
**Артта Казан балкый,**
**Ләкин миңа түгел,**
**Ерагая һаман, тик, ара.**
**Эз югала суда,**
**Күздә хәсрәт төсе—**
**Ул һаман да кара... кап-кара...**
**Юкса, җәй бит әле,**
**Якты Кояш чагы.**
**Унбиш яшьлек мин яшь кыз бала.**
**Күңлемнең үз хәле:**
**Артта Казан түгел,**
**Бик әйтәсем килгән сүз кала.**
**Борылам да карыйм,**
**Борылам да карыйм,**
**Казан инде күздән югала.**
**Өзгәләнә күңел,**
**Кыска гомер булып**
**Артта моңлы, моңсу җыр кала.**

Рәниф ШӘРИПОВ (1950)*—шагыйрь; "Тәрәзәдә ут", "Ян, учагым", "Йорт иясе" һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Ходай язган язмыш,
Аны узып булмый,
Күз алдымда дөнья чайкала.
Ишетелә тавыш,
Әллә киләчәктән?—
Артта тарих кала, чор кала.
Киләчәкне сизәм,
Тик, аңламыйм әле—
Унбиш яшьлек бик яшь кыз бала...
Авыртса да түзәм,
Телеп—телеп, уелып,
Йөрәгемдә тирән эз кала.
Гомер башы әле,
Барысы да алда,
Тик узарлык түгел бу ара.
Күңелемнең хәле—
Бу эз генә түгел,
Төзәлмәслек мәңгелек яра.
Мин күтәрмен хәбәр,
Юкка өметләнеп.
Мин кыюсыз. Мин бит кыз бала.
Тормыш җәе кадәр
Артта кыска гомер—
Яшәлмәгән алтын көз кала.
Әле кыз бала мин,
Ул бит егет кеше,
Нигә соңгы өмет югала?
Үтмәслек арамы?
Ә ул дәшми һаман...
Артта упкын кала, чор кала.
Еллар булса исән,
Егермедән узган
Мәхәббәтле бер яшь егет бит.
Өзгәләнгән үзәк,
Телгәләнгән йөрәк,
Җитмеш яшьтән узган кебек бит...
Башындагы гамьне,
Җанындагы хәлне
Йөрәгенә якын ул ала.
Сүнеп барган шәмне,
Ташып торган ямьне
Өзеп, артта кара су кала.
Дөрес юлдыр, дөрес,
Шуңа да ул—язмыш,
Язмаганы аның югала.
Миңа—минем өлеш,
Ә калганы—ялгыш,
Ләкин артта моңлы җыр кала.
Ходай шулай язган,
Әллә эсседәнме
Күз алдымда дөнья чайкала.
Шундый өлеш калган
Безгә бу еллардан,
Артта моңсу, моңлы җыр кала.

**Борылам да карыйм,**
**Борылам да карыйм,**
**Артта инде Казан югала.**
**Тик шул моңым–зарым –**
**Артта Казан түгел,**
**Ишетәсем килгән сүз кала.**
**Барысы да алда,**
**Гомер башы гына,**
**Тик, узарлык түгел бу ара.**
**Гасырларны ялгап,**
**Йөрәкләрне уеп,**
**Артта кала мәңгелек яра.**
**Ямьле көй ишетәм**
**Җаным–тәнем белән,**
**Артта моңлы, моңсу җыр кала.**
**Китәм, ләкин китәм**
**Өметсезлек белән,—**
**Артта Тарих кала, Чор кала.**

## 2. Габдулла монологы

*Тукай пристаньгә безне озатырга килергә вәгъдә бирсә дә, без аны яңадан күрә алмадык.*
Зәйтүнә Мәүлүдова истәлегеннән.

*Әй мөкатдәс моңлы сазым! Үйнадың син ник бик аз?*
*Син сынасың, мин сүнәмен—аерылабыз ахрысы!*
Габдулла Тукай.

**Синең әле чәчәк атасың бар,**
**Син әле тик тулган бер бөре.**
**Мин сүнәрмен:**
**Тынымны чир йота.**
**Чарасы юк, каһәр төшкере.**
**Бердәнберем минем, тулган бөрем,**
**Үпкәләмә.**
**Көтмә.**
**Елама.**
**Ник качасың диеп газаплама,**
**Ник килмисең диеп сорама.**
**Әйтер идем, күзләреңә багып,**
**Сине генә, бәгърем, сөям дип.**
**Тыштан гына салкын, битараф мин,**
**Ә эчемнән янам–көям бит.**
**Сөяр идем, кулларыңнан тотып,**
**Гомерләрнең әле бит башы.**
**Синең әле чәчәк атасың бар,**
**Мине эчтән яман чир ашый.**
**Юләр бала–чага булыр идем,**
**Күңелеңдә өмет уятсам.**
**Беркемем юк.**
**Бернәрсәм юк минем.**
**Өем дә юк.**
**Хәтта юк акчам.**
**Йортны салып була.**
**Акча табып була.**
**Тормышның бит әле тик башы.**

Ләкин, вакыт җитмәс...
Мин сүнәрмен...
Эчтән мине яман чир ашый.
Моңсуланма бер дә.
Тормыш бара бит ул.
Күзләреңдә өмет нуры бар.
Бормалы бу яшьлек юлларыңны
Язмыш беркөн үзе турылар.
Аяк астың якты булсын диеп,
Баш өстеңнән агар яктылык.
Курыкмыйча атла.
Бүтән абынмассың,
Бүгенгедәй, миңа атылып.
Син эзләмә мине.
Сакчы фәрештәсен
Бу дөньяда күрми беркем дә.
Юлларыңа якты моңнар салган
Мин булырмын—башың өстендә.
Мин сүнәрмен тиздән, күзләремдә
Синнән балкып калган ямь белән.
Син китәсең бүген.
Мин сынармын.
Аерылабыз бүген мәңгегә.
Кичер мине.
Озатырга кил дип,
Булган иде синнән үтенеч.
Килалмадым...
Юк, килмәдем юри,
Шунсы гына бераз үкенеч.
Һәр күрешү якынайта бит ул,
Һәр күрешү тик буш мәшәкать.
Тамырында калсын газаплары,
Бөресендә калсын мәхәббәт.
Кичер мине.
Бик киләсем килде.
Күзләреңә килде багасым.
Чишеләсе түгел серләрнең бу—
Үтеләсе түгел арасы.
Син китәсең.
Мин сүнәрмен тиздән.
Аерылабыз бүген гомергә.
Сүнсен өмет:
Идел яры буйлап,
Мин түгел, ул елап йөгергән.
Мин сынармын тиздән.
Син—яшисе...
Сүнеп калсын өмет очкыны.
Сүндерүе җиңел түгел аны,
Дөрләп китсә, кулдан ычкынып.
Болай да бит инде, сиздермичә,
Күрсәтмичә янам-көям мин.
Зәйтүнәкәй бәгърем, Мәҗнүн кебек,
Сине генә бары сөям мин.
Эх, булмады инде.
Эчемдә чир.

**Чарасы юк, каһәр төшкере.
Синең әле чәчәк атасың бар,
Син әле тик тулган бер бөре.
Ник качасың диеп газапланма,
Ник килмисең диеп сорама.
Бердәнберем минем, тулган бөрем,
Үпкәләмә, көтмә, елама.
Мин сүнәрмен тиздән.
Син китәсең.
Аерылабыз бүген мәңгегә.
Тик, сүнсәм дә, китәм, күзләремдә
Синнән балкып калган ямь белән.**

## 3. Ил (Автор монологы)

*Мин кабер янында Коръән укып,
бик озак елап утырдым.*
Зәйтүнә Мәүлүдова истәлегеннән.

*Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы.*
Габдулла Тукай.

**Кич... Зират... Ямьсез... Караңгы...
Агачлары чайкала.
Бер кабердә, елый-елый,
Коръән укый кыз бала.
Аз булганмы елаучылар
Бу кабернең читендә?
Бу елаган кыз баланың
Ил сагышы—битендә.
Бу кыз бала биш ел йөрткән
Йөрәгендә истәлек,
Китапларга сыймас сүзләр,
Озын-озын киштәлек.
Җир кайгысы, Ил кайгысы
Аның моңлы йөзендә,—
Бөек сагыш, мәңгелек сер
Кыска гомер эзендә.
Агачларны сыгып җиргә,
Аның белән җил елый.
Җил түгел ул—җимерелгән,
Бетерелгән Ил елый.
Бу кабердә үтерелгән
Илнең җаны, җәсады.
Казансуда кан болгатып,
Тәкъдир сурәт ясады.
Бетте халык, калды сурәт,
Кояш баткан төс кебек.
Югалды ил, көймәләрдән
Суда калган эз кебек.
Җан сорады беркөн сурәт—
Күмелмәгән шәһитләр,
Юл табалмый Мәңгелеккә,
Мәхрүм тыныч бәхеттән.**

**Мең тискәре язмышка да**
**Килеп чыга бер уңай—**
**Үле милләт җаны булып,**
**Дөньяга килде Тукай.**
**Очкын кебек кыска гомер,**
**Хәнҗәрдәй үткен каләм—**
**Үлеп барган халык өчен**
**Хушлашу, соңгы сәлам.**
**Уйнап-көлеп, "эшем кырып",**
**Гомер итәргә иде.**
**Ләкин, язмыш аңа күптән**
**Әҗәл җибәргән инде.**
**Без инде милләт түгелдер,**
**Бу—милләтнең җәсаде.**
**Зур казанда җан болгатып,**
**Патша сурәт ясады.**
**Тәнең генә җитми, ахры,**
**Көн дә җан сорый сурәт.**
**Илең генә җитми аңа,**
**Тагын халкың да кирәк.**
**Күрмибез генә без аны—**
**Көн саен бара сугыш.**
**Сурәткә җан кирә, ләкин**
**Өзелә безнең сулыш.**
**Кич... Караңгы... Ямьсез... Зират.**
**Агачлары чайкала.**
**Бер кырыйда, елый-елый,**
**Коръән укый кыз бала.**
**Агачларны сыгып җиргә,**
**Аның белән җил елый.**
**Җил түгел ул, җимерелгән,**
**Бетерелгән Ил елый.**
**Бу кабердә үтерелгән**
**Илнең җаны, җәсады.**
**Патша бездән денсез, гамьсез,**
**Ямьсез сурәт ясады.,.**
**Китапларга сыймас җәбер,**
**Озын-озын киштәлек.**
**Онытылган, югалтылган,**
**һәм сатылган истәлек.**
**Күзгә төн. Мин йоклый алмыйм.**
**Тәрәзәдә җил елый.**
**Җил хәбәр ул. Җан табалмый,**
**Үтерелгән Ил елый.**

Марат
Әмирханов

# ҮРБӘТ ХАНӘКӘ ГЫЙШКЫ[1]

РОМАН

***

Хан күтәрмәк йоласы белән бәйләнешле тантаналар шактый озак дәвам итте. Үрбәтнең шушындый да мул, шушындый да купшы, шушындый да зиннәтле тамашаны беренче күрүе иде. Булса да булыр икән байлык, үлчәп-санап кына бетерермен димә. Илһамны болай олыламаганнар иде. Һәрхәлдә, ул вакыттагы мәжлес-тантана сәхифәләре күңелендә сакланмаган. Бәлкем, Илһам үзе теләмәгәндер? Ә Мөхәммәдәмин бөтенләй башка чут. Үзен күрсәтә белә, кешеләр белән аралашудан тәм таба белә. Туганда ук хан булып туган. Аның белән аралашу үзе бер рәхәт.

Шул ук вакытта, Үрбәт әлеге күптин-күп мәжлесләрнең тизрәк тәгәлләнүен дә тели иде. Көнләшә ул бу мәжлесләрдән. Чөнки Мөхәммәдәмин алардан арына алмый.

Бүген, ниһаять, бәхете елмаячак, Мөхәммәдәмин үзе дә сагынган икән, көт, киләм, диде. Көне буе үзен тәртипкә китерде Үрбәт. Түшәкчесенә дә, юындыручысына да тынгы бирмәде. Беренчесен, урын-җирне йомшак җәймәгәнсең дип битәрләде, икенчесен, суың каты, ислемайларың искергән, дип дәгъваләде. Аш-су тутасына да эләкте. Тутырган тавыгын табынга бөтенләй куйдырмады, артык кызарган, ә ул алтынсу төстә булырга тиеш, имеш. Патраш үләненнән ясалган онны да охшатмады, шулпаны болганчыкландыра бу, дип читкә этеп куйды.

Ә күлмәк сайлау үзе бер тамаша иде. Алдында бер тау күлмәк, кайсын сайларга белмичә иза чикте. Күлмәкче тәкъдим иткәннәр аңа ошамый, ул якын иткәннәрне күлмәкче кабул итми. Әйткәләшеп беттеләр. Ахырдан, күлмәкчене бүлмәсеннән куып чыгарды да кытай ефәгеннән тегелгән ак күлмәген кияргә булды. Ак төс аның гәүдәсен тагын да нәфисрәк күрсәтә иде. Аккошка охшап китә.

Иң соңыннан кабалын көйләде. Моны берәүгә дә ышанып тапшырмый ул. Хәер, Казан җирендә кабал сукмыйлар, монда гөслә, кубыз ише уен кораллары таралган. Кабалы һәрвакыт үзе янында. Тоткынлыкта да кулыннан төшермәде. Нугайда чакта кызлар белән ярыша-ярыша кабал сугалар иде. Көйләрне һәр бормасына туры китереп ул гына уйный белә иде. Берәү дә аңа житә алмады. Үз уйнавына үзе кушылып җырлый да. Тавышы моңлы Үрбәтнең, мамыктай йомшак нәфис тавыш.

Мөхәммәдәмин Үрбәт катында дөньясын онытып, тугарылып ял итә.

---

[1] *Дәвамы. Башы узган санда.*

Гыйшкы да көннән-көн арта гына барган кебек. Хатынының йөзе-бите дә, буй-сыны да, тавышы да, үз-үзен тотышы да бик якын иде ана.

Зөфаф кичендә Үрбәт иренә кулъяулык бүләк итте. Үзе чикте, сурәтләрен дә, бизәкләрен дә үзе сайлады. Аларның һәрберсенә тирән мәгънә багышлады. Мәхәббәте сонарып килсә дә әнә шулай уты-ялкыны ашкынулы хисләр белән килде. Һич көтмәгәндә алдына бәхет кошы сайрап кунды ич.

—Төсем итеп сакла, бу кулъяулыкка минем бөтен хисләрем салынган,—диде Үрбәт.—Сурәтләренә игътибар ит, менә бу ике һома кошы синен белән мин. Бер-берсенә турылыклы, изге оҗмах кошлары. Ходай безне дә нәкъ шулар сыман яраткан, беребезне-беребезгә насыйп иткән.

—Мина әле берәүнен дә кулъяулык бүләк иткәне юк иде,—диде Мөхәммәдәмин.—Рәхмәт. Мин аны һәрвакыт үзем белән йөртермен.

Мөхәммәдәмин бүләкне бик кадерләп эчке кесәсенә салып куйды. Ә үзе Үрбәткә затлы асылташлар белән бизәлгән көмеш беләзек бүләк итте. Хатыны аны бик яратты, йоклаганда да салмый.

Мөхәммәдәмин килеп керүгә, Үрбәт хезмәтчеләрен чыгарып җибәрде. Ул ирен үзе сыйларга ярата, үз куллары белән. Тик бүген эчке бер тоем белән иренен күнелендә борчуга охшаш ят нәрсә барын абайлап алды. Беренче карашка, һичнинди үзгәреш тә юк сыман. Мөхәммәдәмин элеккечә үк ихлас та, шат та, аз-аз гына вәкарльле дә, тәкәббер дә иде.

Үрбәт нинди борчуын бар дип, иренен өстеннән тормады. Кирәк тапса, үзе әйтер әле, дип уйлады. Дөрестән дә, бер-ике чәркә шәраб эчкәч, Мөхәммәдәминнен күнел төене дә чишелеп китте.

—Гафу ит, аппагым, мине бүген чыгырдан чыгардылар,—диде.

—Мәшәкатьләренне онытып тор, җанашым, ял ит, күнел ач,—диде Үрбәт ирен назлый-назлый.—Телисенме, кабал сугып алам, җыру җырлыйм.

Ул кабалын кулына алып, нәфис бармакларын кыл өстендә биетеп алды. Бүлмә эче колакка ятышлы аһән белән тулды. Ана җыр өсталде.

Агач башы әкрен җилгә тәсбих әйткән кеби,
Минем җаным омтыладыр сина, гүя һома кошы имди.

Бу ашкынулы гыйшык җырын тыныч кына тынлап булмый иде. Ул бөтереп ала да, әле күкләргә ашыра, әле ярсу дингез дулкыннарында тибрәтә, әле эссе кояш нурларыдай өттерә башлый. Җырда Үрбәтнен үз хисләре, шуна күрә ихлас вә табигый янгырый, тынлаучыны да битараф калдырмый.

Бу җиһанга килдек без ялгыз кошлар кеби,
Мәрхәмәтле ходай пар канатлар насыйп итте имди.

Мөхәммәдәмин хатынының алдына килеп тезләнде. Үрбәтнен кулыннан кабалы төшеп китте.

—Җанашым, акылына кил, хан тез чүкми,—дип иренен аякларына егылды.

—Мин сине бик яратам, бикә,—диде Мөхәммәдәмин.

—Ә минем яратуымның чиге юк...

Яратышып-сөешеп янә табынга утыргач, Мөхәммәдәмин өзелгән сүзен ялгап җибәрәсе итте. Күрәсен, йөрәгенә тигән иде.

—Гаскәренне яртысын тарат дип бәйләнә Кляпик,—диде бик битәрләнеп.—Бу юлы Мәскәүдән бик үзгәреп килде ул, ни сөйләгәнен үзе белми.

Үрбәт каш астыннан гына иренә карап куйды. Урысларга кагылышлы сүзләре күп иде аның. Иң нык борчыганы, Мәскәү кешеләренең Казан-йортка баш булып йөрүләре. Сарайда да алар бихисап. Юньлегә түгел ич бу. Тыкшыналар, күрәсең. Хан булып ханга күрсәтмә бирсен инде ниндидер килмешәк.

—Ул Келәпик белән Теләшне Мәскәүләренә куып җибәрергә кирәк,— диде Үрбәт иренең сүзен куәтләп.—Гаскәреңне тарат, имеш. Бәлкем, ханлыкны да таратыргадыр? Үзе тагын иренә карап алды, җимне йоттымы, янәсе, йөзен чытмадымы? Тыгылма, бу синең эшең түгел, дип орышып ташламасмы?

—Аларны җибәреп булмый, илчеләр бит,—диде Мөхәммәдәмин сүрән генә,—гаскәр мәсьәләсендә мин синең белән тулысынча килешәм.

—Казан-йортны элекке хәленә кайтармый торып, бу бәлаләрдән арынып булмас, Мөхәммәдәмин,—диде Үрбәт.—Синең ханлыгың вакытында аны урыс үз пәрәвезенә чорнаган, син үк ул пәрәвезне өзгәләргә бурычлысың. Югыйсә, үз халкың алдында каһәрле булуың ихтимал.

Үрбәт сүзләрнең юри кискенрәкләрен сайлады. Чын дөреслекне белеп тору ханның үзенә дә, халкына да файда гына, дип уйлады.

Мөхәммәдәмин ни гаҗәп, сырт йоннарын кабартмады.

Үрбәт янә үсенеп китте.

—Җә, нигә авызыңа су каптың?—дип көлә-көлә иренә тустаган тоттырды. Мөхәммәдәмин аны тиз генә бушатып куйды да әйтте:

—Син тәкрарлаганны эшләү өчен, бикә, Рәсәй белән төзелгән Килешүне гамәлдән чыгарырга кирәк. Ә минем Иван Васильевич каршында антын орган аты аласым килми,—диде.

—Мөхәммәдәмин, мин сине кыю, тәвәккәл, булдыклы, зирәк хан дип беләм,—диде хатын,—һәм ышанам, Казан-йортның элекке данын кайтарачаксың әле син. Кайтарачаксың!

Үрбәт әлеге әңгәмәдән бик канәгать калды. Чөнки Мөхәммәдәмин аның сүзләрен җитдигә санап тыңлады. Җае туры килүгә, фикерләшүне дәвам итәргә дә була лабаса. Әле бу башы гына.

—Җанашым, хатыныңны назлар идең ичмасам, бетмәс ул Мәскәү хәлләре,—дип, үпкәләгәндәй иренә елышты.—Мин сине бик сагындым...

***

Көн артыннан көн үтте, тормыш арбасы үз көенә тәгәрәвен белде. Мөхәммәдәмин шул арбаның төбенә җигелде. Ханның мәшәкатьләре бихисап бит аның, башы түбәтәйгә сыймаган чаклары да еш була. Ә бервакыт колагына: “Арча даругасында баш күтәрергә җыеналар икән”, дигән хәбәр килеп иреште.

Арча гомер бакыйга ханлыкның сызлавыгы иде. Кәҗәләре һаман сөзешергә генә тора. Мөхәммәдәминнең үз язмышында да кылычын болгап алды Арча. Гаделлекне табарга булышты, диярга дә ярыйдыр әле бәлки.

1496 елның май аенда Мәскәүнең олуг кенәзе Иван өченчегә Мөхәммәдәмин өстенә Шәйбан ыруыннан булган Мамык исемле Себер ханының яу чабуы мәгълүм булды. Иван өчен Казанга һөҗүм кылу, Мәскәүгә һөҗүм кылу белән бер иде. Ник дисәң, Мөхәммәдәмин хан аның кешесе.

Казанның Кәлимәт, Урак, Садыр, Агыш кебек дәрәҗәле кешеләре дә Мамык хан тарафын куәтләмәктә, имеш. Болары да олуг кенәзнең таянычы иде. Күрәсең, Мөхәммәдәмин белән аралары бозылышкан.

Озын-озак уйлап тормастан, ул ярдәмгә гаскәр тәгаенләде. Мамык чигенергә мәҗбүр булды.

Мөхәммәдәминнең эченә җан керде. Хәтта кирәге юк, дип, ярдәмгә

килгән урыс гаскәрен кайтарып ук җибәрде.

Мамык исә хәйләкәррәк булып чыкты, гаскәрен янә Казан тарафына борды. Ана нугайлар кушылды. Әлеге бәкләр дә Мамык ханга тугрылыкларын белдерделәр. Мөхәммәдәмин электән казанлыларны шактый рәнҗетүе сәбәпле, халыкта яклау тапмады. Бердәнбер юлы качып китү иде, шулай эшләде дә.

Шөкер, Иван хәлен анлады, элеккеге җирләренә, Каширага башлык итеп билгеләде.

Мамык хан, һич уйламаганда, үзенә Казанны яулап алырга булышлык иткән шул ук Кәлимәт бәкләрне тотып зинданга яптырды. Аннан китереп, сәүдәгәрләрнең малына кул салды. Шул рәвешле катгый тәртип урнаштырырга омтылды.

Арча гына баш иярга теләмәде. Яна хан аны яу чабып тезләндерергә ниятләде. Ә орыш арчалылар файдасына төгәлләнде.

Мамык Казанга кайтып, калага керергә маташып караса да, керә алмады. "Бәкләребезне зинданга яптырдын, сатучыларыбызны таладын", дип якын да китермәделәр.

Шул рәвешле, теләпме, теләмичәме, Мөхәммәдәминнең үчен арчалылар кайтарды. Дөрес, Иван тәхеткә аны түгел, туганы Габделләтыйфны утыртты. Тик барыбер Арча анын күңеленә яхшылык белән кереп калды.

Бу бунтарь һәм дәгъвале кала янә үзе хакында белгертте.

—Гаскәр җибәрергә, канга батырырга!—дип хәл итте илче Кляпик.— Башкаларга сабак булыр.

Телешев борынын җыерды.

—Тәкъдимегез монголларныкыча тупас, кенәз. Нәзбереклек таләп ителә әлеге шартларда,—диде ул ярымшаяру, ярыммыскыллау рәвешендә.

—Үзегез нәрсә тәкъдим итәсез сон?

—Арча даругасы Хуҗаш бәкне чакыртып бик шәпләп борычларга кирәк. Нишләргә икәнен үзе белер. Нигә дип әле без ул эшлисе эшне эшләргә тиеш?

Телешев кәнәфигә җәелеп утырып, касәсенә шәраб агызды.

—Бәлки, бәлки,—дип икеләнгәндәй кыланды илче.

Мөхәммәдәминнең бу тамашадан чигә тамырлары бүртеп чыкты. Күр, тын алырга да бирмиләр. Чистый киртәбаш хайван булдылар.

Очлы күз Телешев Мөхәммәдәминнең эчендә буран купканын бик тиз сизеп алды.

—Хан галиҗәнаплары, бу эшне без баш карачыга гына тапшырыйк. Кәлимәтнең турыдан-туры вазифасы лабаса даругаларда тәртип урнаштыру,—дип сүзнең юнәлешен үзгәртеп җибәрде.

—Әйе, әйе,—диде Кляпик.—Хан һәр ярыкка чөй була алмый.

Сез ул монда чөй булып утырасыз, дип тешләрен кысты Мөхәммәдәмин.

Мәскәүлеләр чыгып киткәч тә ул Арча хәлләре турында уйланып утырды. Борчый иде бу мәсьәлә аны. Бу хакта Үрбәт белән дә киңәште.

Бичәсе аны дикъкать белән тынлады.

—Арчага синең үзенә барырга кирәктер Мөхәммәдәмин,—диде.—Бүрек ташлап кына бүредән котылып булмас, күзгә-күз очрашып анлашуга ни житә?

Бу фикер Мөхәммәдәмингә дә ошады. Тагын ике көннән ул Арчада иде инде. Хуҗаш бәк аны бик зурлап каршы алды. Янында мари бәге Турай да бар иде.

—Борынгы Арча җирендә Барча Казан җиренең синең шикелле мәртәбәле вә олуг ханын сәламләү бәхетенә ирешүебез белән без чиксез

куанычлы хисләр кичерәбез,—диде Хуҗаш бәк билен бөгеп.—Арча ягы һәрвакыт ханлыкның терәге булды. Киләчәктә дә шулай булып калыр, иншаллаһ. Вәләкин кем дә кем кылычын кынысыннан чыгара икән, үзенә үпкәләсен.

Соңгы сүзләрен олпат бәк шундый катгый итеп әйтте ки, сөңгеләр чәкелдәшкәндәй булды.—Мамык хан, әнә, Арча сабагыннан соң әле булса игә килә алмый, ди.

Мөхәммәдәминнең, билгеле, үзен хан тәхетен ташлап качарга мәҗбүр иткән Себер шаһзадәсе турында ишетәсе килеп тормый иде. Сизелер-сизелмәс кенә иреннәре кысылып куйды. Бәк моны бик яхшы белә. Шулай да тәрттерәп кую зыян итмәс, дип санады, ахры.

Чират Турайга җитте.

—Бес тә үсебесне Касан йорты адәмнәре дип саныйбыс, хан, ярдәмгә өмет итәбес,—диде ул куе җирән сакалы аша ургылып чыккан көр тавышы белән.—Мари урман кешесе, сугыш-орышка маһир түгел. Ә менә агач эшендә бесгә тиңнәр юк. Урман нигъмәтләребес дә җитәрлек.

Турай кулын болгап алды. Шунда ук озын итәкле чикмәннәренең алгы чабуын билбауга кыстырган, бәкләре шикелле үк җирән чәчле көчле егетләр өч зур мичкәне тәгәрәтеп тә китерделәр.

—Балыбыстан авыс итегес,—диде Турай,—сүс бирәм, сарайны балдан өсмәбес.

—Янә бер тамаша,—диде Хуҗаш бәк. Сызгырып җибәргән иде, җир астыннан гына калкып чыккандай бер чирү җайдак пәйда булды. Атларын биетеп кенә бастырып киләләр. Иң алда ак атка атланган углан. Ияр өстендә төзгә катып утыра, әйтерсең лә, анадан аты белән туган.

—Угланны кем дип белик?—дип сорады хан.

Бәкнең авызы ерылды, бу сорау аны чын-чынлап бәхетле итте.

—Минем үз улым ул, хан, Уйгын атлы,—диде. Аннан соң олы бер канәгатьләнү белән ниятен белдерде:—Углан Уйгын житәкчелегендәге бу чирүне сиңа бүләк итәм, кабул итеп ал.

—Чынлапмы?

—Вәгъдә—иман, хан, арчалыларның сүзе бер булыр!

Очрашу менә шулай күтәренке рухта башланып китте. Нахак хәбәр таратканнар икән Арча кешеләре турында, ару суны гына куерткannar икән, дигән нәтиҗә чыгарды Мөхәммәдәмин. Тик бу ашыгыч нәтиҗә иде. Әңгәмә моны бик ачык күрсәтте.

—Казан-йортыбыз кайчан урыс кубызына биюдән туктар икән, хан?—дип капланды аңа Хуҗаш бәк табынга утыргач.

—Без дустанә ике дәүләт, бәк...

—Казан үзенчә яшәргә, үзе теләгән ханны тәхеткә утыртырга, үзенең мөстәкыйль эчке һәм тышкы сәясәтен алып барырга тиеш,—диде йорт хуҗасы канәгатьсезрәк рәвештә.—Син бөек ыру варисы. Бурычың ыруыңа лаек дәүләт кору. Олуг Мөхәммәд, Ибраһим ханнарның рухы рәнҗеп ятмасын. Кулыңа ныклап ал хакимият дилбегәсен. Оят бит, Казан урыс белән тулган, аяк атларга ирек юк. Белеп-сизеп торабыз ич, сиңа урыс илчеләре, урыс дьяклары үзләренекен тукыйлар. Тукыйлар гынамы, үзләренчә эшләтәләр дә. Себереп түгәргә кирәк аларны. Татар үз өендә үзе хуҗа булсын!

Хуҗаш бәк кипшенгән иреннәрен касә читенә тигезеп алды, әмма эчмәде, кире өстәлгә куйды. Мөхәммәдәмин дә шәрабка кагылмады.

Кызык, бәк Үрбәт бикә сүзләрен сөйли ич, дип уйлап куйды Мөхәммәдәмин. Ләкин ул Хуҗашның дәгъваларына карата турыдан-туры ярып бер сүз дә әйтмәде. Әмма шуны ачыклады, арчалылар ханлыкның

бүгенге хәленнән риза түгелләр.

—Кәлимәт куштанның бүресе улый Казан-йортта,—дип, ташка баскандай сүзен өздереп дәвам итте бәк,—мин белгәндә генә өч ханның башын ашады ул. Карачылар белән дә шул хаин идарә итә, диваны да аның кубызына бии. Иван патша, билгеле инде, бик риза-бәхилдер ялмавызының гамәлләреннән. Йөрәк сыкрый.

Хужаш, һичшиксез, хаклы. Ханлык Мәскәү сүзе белән яши. Кәлимәт тә баштан-аяк олуг кенәз кешесе. Бу вазгыять Мөхәммәдәминнен үзенә дә ошамый. Тик ни хәл итмәк кирәк, ике арадагы Килешү шуны таләп итә бит. Килешүгә тугрылык хакында ул Иванга кат-кат ант итте. Шунын белән бергә, Хужаш бәк кебекләрне дә узындырырга ярамый.

—Ханның тәпәләве үтергеч булырга тиеш,—диде ул эчке бер киная белән Иван патшаның яраткан гыйбарәсен кабатлап.—Әгәренки аның тәпәләүләре көчле күренеп тә, үтергеч булудан туктый икән, чарасызлыкның башлануы шушы була инде. Ә минем тәпәләүләрем үтергеч булыр!

Бу кинаяны һәрберсе үзенчә гөманлады. Кәлимәтләрнең койрыгына басар бу, дип сөенде Хужаш бәк. Турай исә аны урысларга карата һөҗүмне көчәйтүгә өндәү дип кабул итте.

—Монахлар мариларны христиан диненә күчәргә өндиләр, чиркәү салдырыгыз, диләр. Беснең мөселман кардәшләребесне мәсхәрә итәләр,—дип урыслар бакчасына бер олау таш ыргытты.

Әңгәмә озынгарак сузылды. Сүз бозау имезә, башка тояк тигезә, житәрдер, мөгаен, югыйсә үтергеч тукмаклар эләгүе дә бик ихтимал, дип уйлап куйды бәк һәм җинелчә генә кулларын чәбәкләп алды. Бүлмәгә ябырылып яшь туташлар килеп керде. Кием-салымнары җиңел, үтә күренмәле, бөтен матурлыклары уч төбендәгедәй: менә мин дип ярылып ята. Ашкынулы көй яңгырады. Кәнизәкләр боргаланып-сыргаланып биергә тотындылар.

Мәҗлес соңында Хужаш ханны улы белән таныштырды.

—Казан-йортның олуг ханына хезмәт итү минем өчен зур дәрәҗә,—диде Уйгын ханның күзләренә туп-туры карап.

Йөзе-күзе, килеш-килбәте, бөтен торышы нур чәчеп тора иде угланның. Үзе дегет арбасыннан төшеп калган диярсең, чәче кара, каш-керфекләре кара, сакал-мыегы кара. Шул кара тут йөздә асыл таш сыман шомырттай ике кара күз елтырый. Энәдән-жептән киенгән. Ат бәйләрлеге бар бу егетнең, дип уйлап куйды Мөхәммәдәмин.

—Хан байрагы астында җанымны фида кылырга да әзер,—дип тәгалләде углан сүзен.

—Җиһан исәннәр кулында, углан, яшәү хакында уйларга кирәк,—диде Мөхәммәдәмин,—башлы-күзле булырга ниятлисең дип ишеттем, Ходай хәерле тормыш насыйп итсен.

Уйгынның нурлы йөзе тагын да балкып китте.

—Бусагана йөземне сөрәм, и, мөхтәрәм Мөхәммәдәмин хан,—диде ул шундый ук тәвәккәллек белән,—үтенечемне кире какма, зинһар, никахыма фатиханы бир!

—Сөбханалла, углан,—дип, хан Уйгынның юлпычтай кин аркасыннан сыйпап алды. Охшатты ул Арчаның яшь бәген.

Кәләш киенеп-ясанып күрше бүлмәдә генә көтеп торган икән. Турай бәк аны житәкләп, хан каршысына китереп бастырды.

—Минем кысым Тутыя сина баш ия, хан җәнапләре.

Мөхәммәдәмин кызны башыннан аягына кадәр күзәтеп чыкты. Ул аптыраштa, чөнки сылукай ике тамчы су шикелле Серафимага охшаган иде. Тутыя да аның элекке мәгъшукасы кебек тау кыгланыдай аксыл чәчле, аксыл кашлы, аксыл йөзле иде. Шундый ук чибәр, зифа. Ни хикмәт, бу чибәрлек

ханны дулкынландырмады. Серафима узган заманда калган иде шул инде. Үрбәт аны Мөхәммәдәминнен күңеленнән тәмам кысып чыгарды.

—Бик гүзәл кызың бар икән, бәк, котлыйм,—диде ул Турайга. Ә кызга карап өстәде: "Ышанам, Казан бикәләре арасында да үзеңнен лаеклы урыныңны табарсың".

Аннан соң ул Уйгын белән Тутыяны янәшә бастырып, аларга ханның абруйлы фатихасын юллады:

—Мин, Барча Казан җиренең бөек ханы Мөхәммәдәмин, сезнең никахка үземнең дәрәҗәле фатихамны бирәм. Шуның белән Ходай каршында үз өстемә зур җаваплылык алам. Фатихамны гомерегез буе саф-пакъ килеш саклагыз. Бер-берегезнең кадерен белеп яшәгез. Уйгын бәк, син ирлек вазифаңны, Тутыя бикә, син хатынлык вазифаңны Корьән-каримдә тәгаенләнгәнчә намус белән үтәгез. Мәмләкәтебезгә лаеклы ул-кызлар үстерегез. Ошбу теләкләрне Аллаһы рәхмәте белән житкерәм. Амин!

Яшьләр тезләнеп, ханның чабуын үптеләр. Турай ирексездән бәреп чыккан күз яшьләрен сөртергә дә онытты. Хуҗаш бәк тә бик дулкынланган иде, ханга әйтергә сүз таба алмыйча тотлыгып торды.

***

Арча Мөхәммәдәмингә ниндидер дуамал тәвәккәллек индерде. Ул аннан читлектән чыгарылган җанвар шикелле иркен сулыш тойгысына уралып кайтты.

Шул кызу белән ул икенче көнне үк Карачылар шурасын җыйды. Диван әһелләре дә чакырулы иде.

Ханның итәгенә ут капкан кешедәй үрсәләнүен Кәлимәт ошатмады. Хуҗаш бәк коткысына бирелгән димәк ки, ә ул гомер бакый Мәскәүгә каршы булды. Җыенга Кляпик белән Телешевның чакырылмавы аның шиген тагын да көчәйтеп җибәрде. Бу ычкыну Иванга ошамаячак, билгеле, нигә карамадың, нигә юл куйдың, диячәк. Мөхәммәдәмин үзе дә башы-аягы белән олуг кенәз кешесе. Шуның өчен аны тәхеткә утырттылар да. Бәлки, энәдән дөя ясамаска кирәктер? Яңа хан бит, ихтимал, бераз гына кети-мети уйныйсы да киләдер? Шаяргалап алсын, әйдә, аннан ни зыян, мал да үз утарына кайта, адашып әллә кая олага алмас, дилбегә барыбер Кәлимәт белән Иван кулында.

Кәлимәт суны болгата да, үзе су өстендә кала да белә иде. Сизгер, хәйләкәр, зирәк. Хакимлек хакына ул бернинди хилафлыклардан да йөз чөерми. Борыны сак, җилнең кай тарафтан искәнен шундук тоеп ала. Мәскәү кенәзе Иван Васильевичтан Казан ханлыгын вассал дәүләт итүгә, дәрәҗәлерәк урын өмет итеп, теге чакта урыслар башкаласына элдертте Кәлимәт. Олуг кенәзнең аю ише ерткыч җанварларга мөкиббән икәнен күптән белә иде инде ул. Былтыр Себергә кешеләр җибәреп, кара аю баласы кайтарткан иде. Кулга ияләштерделәр, бер елда биниһая зур булып үсте. Ушлы да иде.

Кәлимәт Мәскәүдә сарай ишеген тәгәл бер атна саклады. Иртүк килеп баса, ут алгач кына китә. Кабул итми генә бит Иван. Дьяк аша "көтсен", дип әйттерә үзе, ә һаман чакырмый. Кылыч борынлы, юка иренле дьякның кесәсенә алтын тәңкә дә шудырып карады, файдасы гына тимәде. Әйтерсең лә, кизү тора, сарай йомышчылары кебек нәкъ эш башлануга килеп җитә дә, ишек катындагы аулак кәнәфигә сеңә. Кешеләр патша катына керәчыга, ду киләләр, тормыш кайный. Кәлимәт исә утыра-утыра йокымсырап та китә. Аннан соң бер-бер ят тавыш чыгармадыммы икән дип куркынып тирә-якка күз ата. Янына дьяк килеп басканда да йокылы-уяулы хәлдә иде. "Олуг кенәз Иван Васильевич сине көтә", дигән сүзләрнең асылын

төшенмичә берара ангыраланып торды.

—Ә... нәрсә... кайда,—дип мыгырданды.

—Олуг кенәз Иван Васильевич көтә, тиз бул!—дип кычкырды дьяк, ә үзалдына: "И, поганый татарин", дип сүгенеп тә алды.

Патша янына кергәндә Кәлимәт үз акылында иде инде.

—Хөрмәтле галиҗәнап, атабыз олуг кенәз Иван Васильевич,—дип тәхет хуҗасының аягына егылды—Казан-йорттан сезләргә күп сәламнәр алып килдем. Без сезләрне үзебезнең бердәнбер һәм алыштыргысыз хакимебез дип саныйбыз. Ходай озын гомер, патшалык куәте бирсен. Эчкерсез хөрмәтемнең билгесе итеп сезләргә бүләк алып килгән идем, кабул итеп алсагыз, бик шат булыр идем...

—Бүләген кая?—дип сорады Иван битараф кына.

—Тышта,—дип орынган башын идәннән күтәрде Кәлимәт,—сезләр кайда кушса, шунда илтәбез.

—Ни-нәрсә соң ул?

—Аю, Иван Васильевич җәнаплары, Мишка...

—Мишка?!

Иван гаҗәпләнеп, бәккә текәлеп катты.

—Тор әле, поганец, тор. Татарлар гадәттә чапкын бүләк итә торганнар иде, син аю дисең, Мишка... ха-ха-ха...

Ул буыла-буыла көләргә тотынды. Аңа ияреп боярлар, дьяклар, жан сакчылары шыркылдый башлады.

—Өйрәтелгән аю,—диде Кәлимәт патша көлеп туйгач,—берәүдә дә юк андый аю. Корымга буягандай чем-кара.

—Ниемә дип алайса утырасың соң, күтәр үкчәңне, бар, тиз бул, Михалычны алып кер.

Кәлимәт атна буе тыныч кына үзенең язмышын көтеп утырган алпамша тәпине житәкләп диярдәй патша янына алып керде. Аюны баһадир гәүдәле дүрт кеше чылбырда тота. Кулларында озын саплы балта. Алай-болай тузынырга керешсә, хәзер маңгаена балта төтәсе төшәчәк.

Бүләк аю гайрәтен күрсәтергә ашыкмады. Киресенчә, үзен иркә мәче шикелле тотты, дәрәҗәле урынга килеп эләгүен сизенә иде булса кирәк. Дәрәҗәле урын бер үк вакытта иң куркыныч урын да әле ул. Шулай да яңа хуҗасын ошатты, ахры, сәлам биргәндәй калын тавышын чыгарып, үкереп алды.

—У-у-у...

Иван яшь бала сыман сөенде. Аюның бер алдына, биш артына төште, маңгаеннан сыйпады, сөйде, яратты. Ул яшьтән шушы ерткычны үз итте. Башкалар эт дип хыялланганда, ул атасыннан аю баласы бүләк итүен үтенде. Шуннан китте инде. Көч-куәтләре, житезлекләре, килеш-килбәтләре белән ихтирамын яулады Михалычлар Мәскәү тәхетенә дәгъва кылучы малайның. Баш бирмәүчеләренең маңгаена үзе үк кистән белән тондыра иде. Бер сугуга ега иде. Үзе дә аюдай гайрәтле иде Иван.

—Каян эләктердең син, поганец, мондый нөсхәне, беренче күрү-ү-үем,—дип сузды олуг кенәз.—Шаккатмалы бит, ә? Гәүдәсе дисәң гәүдәсе, төсе дисәң төсе...

Шул арада Михалычның сырт йонына кызыл төстәге тукыма да бәйләп куйдылар. Ул инде бозымнардан азат иде.

—Кеш тиресеннән тегелгән бер тунымны китерегез!—дип әмер бирде олуг кенәз.

Иван әлеге зиннәтле тунны бәхетеннән ике-өч җәя буе каләр үсеп киткән Кәлимәтнең җилкәсенә элде.

—Бәйрәм ашы—кара-каршы, бәк. Бу тун сиңа күп җиңеллекләр алып

килер. Чөнки дә син бүгеннән Казан йортындагы минем яшерен шымчым буласың. Колакларым. Күзләрем. Ышанычым. Әгәр дә мәгәр хыянәт юлына басасың икән, үзеңә үпкәлә, үз аюыннан ботарлатачакмын.

Кәлимәт олуг кенәзнең ышанычын аклады. Хәтсез генә бәкләрне үз ягына аударды. Хөкүмәттә дә, диванда да аның кешеләре утыра. Карачылар, угланнар арасында да сүзе үтә. Иван шымчысының гамәлләреннән канәгать. Бүләк турында да онытмый. Алар инде тун ише генә түгел. Баш карачы вазифасы ул бүләкләрнең иң кыйммәтлесе. Бу вазифа аңа мал-мөлкәтен дә, дәрәҗә-абруен да олаулап-олаулап китерә.

***

Мөхәммәдәмин кымыз кертергә кушты. Әңгәмә тагын да җанланыбрак китте. Тик әлегә бәкләр, морзалар үзара сүз куерталар. Бәгъзеләре ат көтүләре белән мактана, бәгъзеләре ау хәлләрен сөйли. Яшь кәләшләр дә телгә кереп-кереп ала. Кыскасы, төп сүзгә керешкәнче була торган гадәти гайбәтләр.

Төп сүзне йә хан үзе башлый, йә аның фатихасы белән баш карачы тәкърарлый. Яңа хан үзен ничек тотар, әлегә билгесез. Әгәр авыз хәбәрләре раска килсә, ул баш карачыны өнәп җиткерми, имеш.

Кәлимәтнең башында кырыкмаса кырык уй. Үз сүзенең сүз буласына ышанычы зур булса да, нигәдер күнеле тыныч түгел. Эче поша. Илчеләр белән киңәш-табыш итешер иде, алар чакырмаган. Ни сәбәпледер, дөньясы кирегә китәргә тора кебек.

Хан тамагын кырып куйды. Бу, игътибар, хәзер мине тыңлагыз дигәнне аңлата иде. Ләкин авызыннан сүз чыкмады, йомышчы морза гына нидер ишарә итте. Бүлмәгә төз гәүдәле, ыспай киемле бер чибәр углан килеп керде. Тын калдылар. Һәммәсе карашы белән угланны капшый, янәсе, нинди тутый кош бу?

—Таныш булыгыз, баш углан Уйгын бәк,—дип тантаналы төстә тәкъдим итте аны хан.

Уйгын хан каршысына килеп тезләнде.

—Күз карашларыннан күреп торам, монда җыелган мөхтәрәм җәмагать синең белән бик кызыксына, углан, кыскача гына тәрҗемәи хәлеңне сөйләп уз,—диде Мөхәммәдәмин.

—Мин Арча бәге Хуҗаш морзаның төпчек улы,—диде Уйгын,—атам хан галиҗәнапларына гаскәри хезмәткә җибәрде. Үзем белән бер чиру сугышчы алып килдем. Ханга турылыклы булырга ант эчәм. Аның өчен башымны салырга да әзер.

—Бәрәкалла, бәрәкалла,—дип хуплады Әхмәт бәк баш угланның сүзләрен. Кәлимәт аңа күзенең агы белән карап куйды. Чөнки, беренчедән, хан баш угланны алыштыру хакында ләм-мим әйтмәде. Бу аны, баш карачы буларак, танымау лабаса. Ә баш углан турыдан-туры баш карачыга буйсына. Икенчедән, ул Хуҗаш бәк улын баш углан итеп куюга теше-тырнагы белән каршы.

Мөхәммәдәмин баш карачының эчендә нинди ялкын дөрләгәнен белми һәм белергә дә теләми иде.

—Салым түләү, аны дәүләт мәнфәгатьләрендә файдалану мәсьәләсе мине бик тә борчый,—дип, ул җыен табынына яңа жим сипте.—Күп кенә дәүләтләрдә, әйтик, Литвада салымны җан башыннан түлиләр. Бездә төп бәрәмлек итеп хуҗалык алынган. Эре җир биләүчеләр исемлектән бөтенләй төшеп калган.

—Эре җир биләүче бәкләр гаскәр тота,—диде Сардар морза.

—Бу хакта да сүз булыр,—диде Мөхәммәдәмин,—гаскәрнең хәле бик

мөшкел, мин салымның яртысын хәрби мәнфәгатьләргә тотарга кирәк дип саныйм. Баш углан да бу фикерне хуп күрә. Сез дә унай карарсыз, дип ышанам.

—Белүемчә, Казан-йорт бер дәүләт белән дә орыш ачарга җыенмый. Хәзерге вазгыять шартларында андый хаҗәт гомумән юк,—дип, ниһаять, Кәлимәт тә сүзгә кушыласы итте.

—Сүз яу чабу, орыш ачу турында бармый,—диде Мөхәммәдәмин сабыр гына,—сүз Барча Казан җиренең иминлеге, шул иминлекне тәэмин итү турында бара.

—Салым тәртибен үзгәртү ханлыкның эчке хәленә тискәре йогынты ясаячак,—диде Кәлимәт. Ул теләктәшләр эзләп, күзләре белән бүлмәне сөзеп алды. Ләкин аны хупларга атлыгып торучылар юк иде. Һәрхәлдә, хан белән бәхәскә керергә ашыкмадылар.

—Үзен-үзе саклый алмаган дәүләтнең эчке халәте дә була алмый,—диде хан өздереп,—Казан элекке бөеклеген кайтарырга бурычлы. Шул чакта гына эчке халәтебез дә мантып китәр.

Сардар бәк ялгышын төзәтергә ашыкты.

—Мин,—диде ул иреннәрен чуп-чуп китереп,—хәрби мәнфәгатьләргә акча арттыруны ифрат та мәслихәт эш дип саныйм. Гаскәр бит бәкләрдә. Шулай булгач, әлеге үсеш үзебезгә файда лабаса. Хан галиҗәнапларын моның өчен күккә чөяргә кирәк, җәмәгать. Ә түгел, кайсыдырки, сүз көрәштереп утырырга.

—Инде үземнең дәрәҗәле карарымны житкерәм, тынлагыз,—диде Мөхәммәдәмин сүзен төгәлләп,—Арча, Мамадыш, тагын берничә даругада сынап карау нияте белән салымны җан башыннан түләүгә күчәбез. Җыелган салымның яртысын хәрби максатларда файдаланачакбыз.

—Афәрин!—диде Әхмәт бәк.

—Гаскәр тулысы белән хан карамагына күчә,—дип дәвам итте Мөхәммәдәмин,—бәкләр, угланнар сыйфатында, баш угланга буйсына. Шул ук вакытта алар үз карамакларындагы гаскәрләрен тулысы белән үзләре асрый. Хан эчкеләре генә казна акчасы исәбенә тотыла. Амин. Инде аш-судан рәхим итегез.

***

Бөек княгиня Софья Палеологны Мөхәммәдәмин якыннан торып белә иде. Сөйләшеп утырганнары да булды. Укымышлы, акыллы, горур патшабикә иде. Аны бик чибәр дип тә булмый, әмма буй-сыны исткиткеч күркәм иде. Кием-салымга бик таләпчән. Җәмәгать алдына бер күлмәктән ике мәртәбә чыкмады. Аз сүзле. Шуңа күрә башкаларга ниндидер тылсым иясе булып күренә иде. Ул урыс княгиняларыннан бөтен ягы белән дә аерылып торды. Нурсолтан ханбикә белән уртак тел табып, дустанә рәвештә бүләкләр алышып яшәделәр. Үз кадерен белеп кенә көн итте. Ана бервакытта да үлем тимәс кебек иде. Тигән бит әнә. Кайгысыннан Иван Васильевич та бик бирешкән, имеш.

Үрбәт Мөхәммәдәминнең урыс патшабикәсен күккә чөюен килештереп бетермәде. Хәер, хатын-кыз үз затын мактап сөйләгәнне өнәп бетерми бит ул. Һәрберсе үзен генә бердәнбер дип саный. Гашыйк хатын-кыз аеруча көнчел була.

—Ай-һай, бер дә харап икән, чит тәтәләр турында авыз суын корытканчы, янындагысының күңелен күрер идең,—диде Үрбәт.

—Ахирәт күлмәге кигән княгиняга мөнәсәбәтле бу үпкәләүләрең һич тә урынлы түгел, бикәм,—диде Мөхәммәдәмин житди генә.

—Мин шундый көнчел инде, нигә шулайдыр, үзем дә аңламыйм...

—Мин сине генә яратам бикәм...

—Юк, Мөхәммәдәмин, ханны беренче нәүбәттә мәмләкәтенең хәле борчырга тиеш,—дип бармак янады Үрбәт.—Казан-йорт барыбызның да гомер бишеге.

—Бу сүзләрнең төбендә ниндидер яшерен мәгънә ята кебек, бикә,—диде Мөхәммәдәмин уйчанланып,—бер башлагач, йомгагыңны сүтеп бетер инде, яшермә.

—Софьяның бакый дөньяга күчүе олуг кенәзне чарасыз иткәндер, мөгаен,—диде Үрбәт киная белән,—сизенәсеңме, ташларны санар вакыт килеп җитте бит, Мөхәммәдәмин.

Мөхәммәдәмин хатынының изүеннән умырып тотты да, күзләренә чәнчеп бакты. Озак кына керфекләрен дә какмыйча карап торды. Усал, башбирмәс, дуамал караш иде бу.

—Син, чыннан да, Аллаһының бу көне килеп җитте дип саныйсыңмы?—диде ул, ниһаять.

—Җитте, Мөхәммәдәмин!

Ирен озаткач, ханбикә җиңел киемнәрен генә элеп бакчага чыкты. Бакча искиткеч матур иде. Алмагачлар ап-ак чәчәктә. Тирә-якка хуш ис сибеп утыралар. Иснәп туймалы түгел. Ара-тирә, яфракларны селкеткәләп, шаян җил исеп куя. Шушы хозурлыкны сәламләгәндәй эреле-ваклы кошлар сайраша. Бу аңа кабал сугу булып ишетелә.

Кабал сугу дигәннән, кичә генә Нугайдан мәкуп китерделәр. Алгай морзадан.

Алгай Үрбәтнең төпчек энесе. Аталары бер, аналары башка. Мөселманнарда кан пакьлеге атадан санала. Шуңа күрә туганлык та атадан килә. Ул Илһамга кияүгә чыкканда энесе тумаган да иде әле. Инде үсеп, буй җиткергән, дәрәҗәле морза, булдыклы углан булып җитешкән. Кызык, аларның әле бер мәртәбә дә күрешеп сөйләшкәннәре юк. Атаена охшаса, киң бәдәнле, нык аяклы, базык гәүдәле булырга тиеш. Нугайлар туганда ук атка ябышып туалар. Гомерләре ат өстендә үтә. Елгырлар, өлгерләр. Казан татарлары башка. Гәүдәгә дә, төскә-биткә дә чибәррәк. Бер караудa гашыйк итәләр. Ә күзләре нигәдер борынгы мангыт ыруы кызларына төшә. Бәкләр, морзалар гына түгел, ханнар да нугай тәтәләрен ярәшә. Бер-бер хикмәте бар, күрәсең.

Алгайның мәктүбе аны бик сөендерде. Анда түбәндәге юллар бар иде: "Мөхтәрәм вә гыйззәтле тәтәм! Мин Казан йортының олуг ханы, җизнәм Мөхәммәдәмингә сугышчыларым белән ярдәмгә барырга һәрвакыт әзермен. Хәбәр булуга, егерме меңлек гаскәри атларга атланачак. Көтегез!"

Бу хакта Үрбәт ханның үзенә әйтмәде әле, бераз сабыр итәргә булды, җаен көтте. Һәм бик дөрес эшләде. Бүгенге аңлашу—моның дәлиле.

***

Үрбәт катыннан чыгуга, Мөхәммәдәмин йөгертеп кенә Шаһи солтанны чакыртып китерде. Шаһиның халык арасында Алып сыңары дигән аты чыккан. Чөнки муенына камыт житәрлек түгел. Көрәштә дә аңа тиңнәр юк. Шуңа күрәме, үзен солтан дип атый.

—Ни боерасың, и, олуг хан,—дип, кергә-керешкә Шаһи солтан маңгаен идәнгә орды.

—Сине, Шаһи солтан, озын да, җаваплы да сәфәр көтә,—диде Мөхәммәдәмин,—ышанычлы кешем булганлыгың аркасында әлеге мөһим эшне сиңа тапшырырга ниятләдем.

—Ышанычың өчен рәхмәт, хан, беләсең, мин һәрвакыт әзер.

Шаһи солтанга йомышчы морза бер төргәк китереп тоттырды.

—Бу—ярлык,—диде хан,—синең аны ачарга да, укырга да хокукың юк, ярлыкка минем мөһер сугылган. Ул Мәскәүнең олуг кенәзе Иван Васильевичка юлланган. Синең бурыч ярлыкны исән-имин аның үз кулларына тапшыру. Олуг кенәзнең үзенә! Син Мәскәүдә июньнең нәкъ егерме дүртенче көнендә булырга тиешсең. Әле вакытың житәрлек, ашыкмыйча, ял итә-итә генә бар. Ләкин егерме дүртенче июньне бер генә мизгелгә дә исеннән чыгарма. Теленне тозакка сал. Төшенденме?

—Төшендем.

—Сакчыларның ышанычлыларын сайла. Чикне узгач, һөҗүм итүләре дә ихтимал, һәр очракка әзер бул,—дип, хан янә бер тапкыр ярлыкның мөһимлегенә ишарә итте.

—Эчкеләр...

—Юк, өметләнмә, эчкеләрдән бер гаскәри дә бирмим. Алар монда зарур. Хәерле юл!

Мона кадәр дә ханның биремнәре ашыгыч һәм көтмәгәндә була иде. Көн-төн ат сыртыннан төшмиләр, ияр өстендә үтә иде юлга бирелгән вакыт. Ә монысы сәер бирем: үзе ашыгыч, үзе сузымлы. Читнең читәне корысын, ди, хан Иванга бер-бер этлек эшләргә җыенмыйдыр бит? Юк, монысы булмастыр, мөгаен, урыслар күптән инде кадерле кунак. Казанны басып бетерделәр, әнәтрәк. Сәүдә алар кулына күчте, алтын-көмеш түбәләреннән ашкан.

Шаһи солтан 1505 елда, Мөхәммәдәмин кушканча, июнь аенның егерме дүртенче көнендә Мәскәүгә аяк басты. Аллаһының бик хозур бер көне иде ул. Кояш нурлы йөзен күрсәтүгә, дөньяны пакьләндереп, шифалы янгыр явып үтте. Агач яфраклары чем яшел төскә керде. Һава саф, кешеләр көр күңел белән мал-туарын көтүгә куа. Мәскәүдә көтү иртә кузгала икән. Гаскәриләр дә аякларында. Казанлыларны туктатырга кыҗырап-кыҗырап алгалыйлар-алуын, тик куллары кыска. Чөнки вәкиллекне каладан чыгып, махсус калагай каршы алды. Кораллы сагы да бар. Алдан чапкын җибәреп, киләсен хәбәр итеп куйган иде Шаһи солтан.

Бүләкләрне барлап, ашап-эчеп, киемнәрне алыштыргалаганчы өйлә житте. Иван Васильевич шул өйлә вакытында кабул итте дә инде аны. Шаһи солтан башта патшаны танымыйча торды, булышчысы, ахры, дип уйлап куйды. Чөнки бу таушалган өрәктәй арык адәмнең олуг кенәз булуы мөмкин түгел иде. Жан сакчының:

—Башынны ор, әй, башынны ор,—дигән ачулы кисәтүеннән соң гына айнып китте. Дикъкать беләнрәк карап бакса, чыннан да бу адәм олуг кенәз үзе икән.

—Жә, сөйлә, туганым Мөхәммәдәмин хан ниләр майтарып ята анда?—диде Иван солтанның сонга калган сәламләүләреннән соң. Тавышы үзгәрмәгән, нәкъ элеккечә, дөбердәп чыга.

—Мөхтәрәм галиҗәнап, Рәсәй жиренең олуг кенәзе Иван Васильевич, ханның юлламасы—сер юллама. Мин аннан хәбәрдар түгелмен, барысы да кәгазьгә төшерелгән,—дип, Шаһи солтан төргәген сузды. Аны йомышчы дьяк саклык белән генә сүтте. Аннан ары:

—Кычкырып укыргамы?—дип сорады.

—Юк,—диде патша,—сер ди бит, ә серне ачарга ярамый.

Ул озаклап һәм жентекләп Мөхәммәдәминнең ярлыгын укырга тотынды. Бераздан туктап калды. Ишек алдында сугышчыларны маршка йөртәләр иде күрәсен, "айть-два"лары сарай эченә үк үтеп керә. Иванның кәгазьдәй ак йөзенә сырлар кунды. Моны күреп алган баш сакчы атылып урамга чыкты да, ачу белән:

—Отставить, балваны, великому князью мешаете,—дип кычкырды.

Иван, ниһаять, ярлыкны укып чыкты. Аннан соң ризасызлык белән:

—Нәрсә, сез анда, мәкинә башлар, юлдан адашмаслык та акылыгыз калмадымы әллә?—дип, илчегә чекерәйде.

Тик ул бу сорауны җавап алу өчен бирмәде. Уйлануы иде. Чөнки берничә көн элек кенә Кляпиктан чапкын хәбәр китергән иде. Хан гаскәр белән мәшгуль, катлауланулар килеп чыкмагае, дигән. Илче әлеге шиген беренче тапкыр гына белдерми иде инде. Бодай күрсәтеп, арпа алган мокыт хәленә төшүен бар. Әйтик, Мөхәммәдәмин, илче гөманынча, Мәскәүгә яу да чапсын, ди. Бу аның өчен үз теләге белән башын элмәккә тыгу лабаса. Мәскәү карамагында төрле орышларда катнашып, зур осталыкка ирешкән, заманча коралланган йөз мең танаулык гаскәр бар. Якын-тирәдә аңа каршы торырлык көч юк. Бу Мөхәммәдәмин ханга бик яхшы мәгълүм. Гаскәрне оештыруда үзе дә турыдан-туры катнашып, Литва орышында баш җиһангир да булды. Тар-мар ителәчәген алдан белә торып, бу дуамал җәнҗалга барырга аның башына тай типмәгән лә. Гаскәре мәскәүлеләрдән өстен булган очракта да, андый адымга бармас иде Мөхәммәдәмин.

Иваннын, уйлана торгач, чигәсе кыса башлады. Бу араларда өянәге көчәя генә бара. Керфек тә какмый үткәргән төннәре ешайды. Ләкин һич бирешәсе килми. Фани дөнья белән алыш-биреше бетмәде әле аның.

Мондый чакта ул, табиблар киңәшен тотып, йодрыгын бер төйни, бер йомшарта. Шуннан соң маңгаена тир бәреп чыга, авыртуы басыла төшә. Хәзер дә шушы сыналган хәрәкәтләрен ясап, бераз җиңеллек алды.

Шаһи солтан алып килгән ярлык та Кляпик фаразларының дөреслеккә туры килмәвен дәлилли. Киресенчә, хан Мәскәү үзе һөҗүмгә әзерләнә икән, дип борчыла бит әле. “Мине тәхеттән алып ташларга җыенасың икән, туганым олуг кенәз Иван Васильевич”, дип үпкә белдерә.

Кляпик бер-бер саксыз сүз ычкындырган, ахры. Тинтәк. Казанга тиз арада яңа илче билгеләргә кирәк димәк ки.

Шулай да, Мөхәммәдәмингә әлеге мәгълүматны кем җиткерде икән? Әллә чынлап та казанлылар яшертен эш йөртәләрме? Бәлкем, бу ярлык күз буяу гынадыр? Юк, булмас. Ләкин тикшерү зыян итмәс.

***

1505 елның егерме дүртенче июнендә Казан каласында да ялтырап кояш чыкты. Мәскәүдәге шикелле үк матур көн туды. Табигатьне яшәртеп, шундый ук шифалы җәйге яңгыр явып үтте.

Мәскәүдән аермалы буларак, Казанда зур тамаша иде. Казан ярминкәсе дип даны таралган сәүдә тамашасы. Елга бер мәртәбә үтә торган бу олы ярминкәгә хәзерлек чираттагысы тәгалләнгән көннән үк башлана. Быел да бик зурдан кубып хәзерләнделәр. Катнашырга теләүче сәүдәгәрләр, эшмәкәрләр дә бихисап. Кытайдан, Персиядән, Румнан, Литвадан кадәр килрләр. Соңгы елларда урыслар бик көчәеп китте, бүтәннәрне кысрыклый башладылар. Төпләнеп көн күргәннәре дә шактый.

Хан иртән иртүк киңәшмә җыйды. Анда баш углан Уйгыннан кала, тагын берничә кеше генә катнашты. Яшерен киңәшмә иде бу.

—Мин, Барча Казан җиренең бөек ханы Мөхәммәдәмин, Аллаһының ризалыгы белән, Казан йортының элекке данын кайтару максатларында, яңа сәяси һәм икътисадый боерык эшләдем,—диде хан җыелышучыларны берәм-берәм күздән кичереп,—бүген әлеге боерыгымның тәүге чараларын гамәлгә ашыруны башлап җибәрәбез. Бу эшне мин сезгә тапшырам, житәкче баш углан Уйгын бәк. Хәерле сәгатьтә. Амин.

—Баш өсте, бөек хан!

—Калага баш углан Уйгын бәк хуҗа булып калачак, чөнки мин гаиләм

белән вакытлыча Идел буендагы утарыма күченеп китәм.

—Сез юкта калага баш карачы хужа булып кала иде,—диде арадан берсе—кануннарны бозу булмасмы?

—Булмас, углан. Ник дисән, иң беренче булып, Кәлимәтнең үзен кулга аласыз. Аннан соң урыс илчеләре Кляпикны, Телешевны зинданга озатасыз!

Ханның бу катгый сүзләре яшь угланнарның канын кайната иде. Аларның тизрәк мавыктыргыч бурычны үтәргә тотынасылары килә башлады, түземлекләре төкәнде.

—Шуннан соң ярминкәгә һөҗүм итәсез,—дип күрсәтмәләрен бирде Мөхәммәдәмин,—урыс сәүдәгәрләренең мал-мөлкәтен тартып аласыз, бөртеген дә әрәм-шәрәм итмичә казнага тапшырасыз. Һөҗүм үтергеч булсын. Гарәпләргә, кытайларга, литвалыларга, румлыларга зыян китермисез.

***

Кәлимәтне өендә эләктерделәр. Дөрес, әүвәл җан сакчылары белән чәкәләшеп алдылар-алуын. Ихтимал, карышмаган да булырлар иде. Ләкин хәлне аңлатып вакыт үткәрмәделәр, бәйләп ташладылар да, авызларына чүпрәк тутырдылар.

Түшәкчеләрнең, йомышчыларның, пешекчеләрнең кан качкан йөзләренә игътибар итмичә, Уйгын бер төркем яшь эчке белән баш карачы катына узды. Кәлимәт өйлә намазына басар өчен тәһарәт алырга хәзерләнеп йөри иде, ахры. Угланнарны күргәч, комганын идәнгә төшереп җибәрде. Үзен алырга килүләрен шундук аңлап алган иде ул. Куркынып як-ягына каранды, ләкин берниндн ярдәмгә дә өмет итә алыр чамасы юк иде. Баш углан, ханның уң кулы, тиктомалдан өйгә бәреп кермәс. Димәк, бу—бунт!

—Чыгып китегез, хәсисләр, өемнән, хакыгыз юк, мин Мәскәү патшасы Иван Васильевичның ышанычлысы,—дип яшелле-зәңгәрле тавышлар чыгарып кычкырды Кәлимәт,—Казан йортының мәртәбәле баш карачысы...

—Син инде баш карачы түгел,—дип күзләреннән ут чәчрәтте Уйгын,—Мәскәүгә сатылып, дәүләтебезгә зур зыян салганың өчен, ханнарның башын ашаганың өчен Барча Казан җиренең бөек ханы Мөхәммәдәмин боерыгы белән мин сине кулга алам.

—Хакың юк, хәсис, мин Иван Васильевичның ышанычлысы, башың белән җавап бирерсең. Якын килмәгез, кара-у-ул!—дип тузына башлаган иде Кәлимәт, бик тиз бөтереп алдылар.

Кляпик үзен илчеләрчә тыныч тотты.

—Мөхтәрәм әфәнделәр, миңа ханның язмача әмерен күрсәтегез, шуннан соң берсүзсез буйсыначакмын,—диде.—Бу вакытлы аңлашылмаучылык кына булырга тиеш. Мин вәкаләтле илче. Кагылгысыз шәхес!

Ләкин ул тыныч булып күренергә генә тырыша иде. Телешев белеп каргылдаган икән, дип сызланып куйды. Мөхәммәдәминне тәхеткә утыртырга килгәндәге буранлы төндә кенәз бик зур икеләнү белдергән иде. Хәер, икеләнү генәме, татарларга ышаныч юк, дип турыдан-туры әйткән иде. Ул үзе дә олуг кенәзгә ханның гаскәре белән чамадан тыш мавыгуы хакында мәгълүмат җибәреп торды. Тик шулай да, бервакытта да Мөхәммәдәмин баш күтәрү юлына басар, Мәскәү илчесенә кул сузарга җөрьәт итәр диган уйны күнеленә дә кертеп карамады. Ике йөзле булган икән кара йөрәк, басурман, барыбызны да төп башына утыртты, әнә. Ярый ла, исән-имин котылып булса. Ышан бу башкирсәрләргә, дөмектерергә дә күп сорамаслар.

Мөхәммәдәмин мондый эшләрнең рәтен белә иде, әлбәттә, шуна күрә

кәгазьләрен дә алдан хәстәрләп куйды. Тик угланнар аңа карап тормадылар, урыс илчесенә барыбер татар йодрыгының тәмен татырга туры килде.

—Господа, без рук, господа... я сам,—дип йөгертә-йөгертә үзе киенеп тә куйды Кляпик.

Ярминкәнең дә иң кызган чагы иде. Искәртмәстән генә камап алдылар. Уйгын үзенең Арча егетләре белән эчкә ыргылды.

—Кулларыгызны аркага куеп, йөз белән җиргә авыгыз!—дип кычкырды ул сәүдәгәрләргә.

Кешеләр аптырап калды. Ник шаша бу угланнар, нигә бәйдән ычкынган эт шикелле котырыналар?

—Кемгә әйтәләр, кулларыгызны аркага куеп, йөз белән җиргә авыгыз!—дип түземсезләнде баш углан.

Халык әле һаман ышанмый. Хан мактамас угланнарны моның өчен. Мактамас. Ярминкәнең ямен җибәреп теге...

—Тиз! Җиргә авыгыз!

Уйгын бар көче белән кылычын бакыр чәчле бер юан урысның муенына селтәде. Өзелгән баш, юл тузанына буялып, тәгәрәп китте. Аһ иттеләр. Бу инде яшь угланнарның чираттагы күңел ачуы гына түгел. Бу—һөҗүм!

Ярминкәлеләр өсләренә су сипкәндәй төрлесе төрле якка ыргылды. Угланнар кирәк кешеләрне үзләре куып тота башладылар. Кылычлар чыңлый, сөңгеләр ялтырый. Кемнең кем икәнен дә аеру бетте. Гарәпме, кытаймы, урысмы, татармы—кыралар гына. Тоташ суеш. Кычкырыш, бакырыш.

Угланнарны җанвари вәсвәсә биләп алды. Кан исе борынгы бабаларыбыздан килгән ерткычлык хисләрен бар көченә уятып җибәрде. Бу аларга һични белән чагыштыргысыз хайвани ләззәт китерә иде.

Казан ярминкәсенең үз кешесенә әверелгән Кытай сәүдәгәре Мао Уйгынның кылычыннан качу өчен ниләр генә кыланмады, бәгырь. Дүрт аяклап мүкәйләп тә карады, түше белән җиргә ятып шуышты да, аяк-кулларын да чәбәләндерде. Үзе дә у-шу остасы иде. Тик ярдәме генә тимәде. Ахыры:

—Угланнар, минем ун балам кала, аларны кем ашатыр, кем тәрбияләр?—дип үкерергә керешә. Юк, күзе-башы тонган Уйгын кеше хәленә керерлек дәрәҗәдә түгел иде инде. Җаен китереп, тәки кытайның гәүдәсен урталай ярды.

—Уйгын, нишлисең син, аңыңа кил,—дип, аны дусты Хәмзә морза иярennән җиргә сыдырып төшерде,—безгә хан урыс сәүдәгәрләрен генә таларга кушты ич. Нигә дип ул кытай сәүдәгәрен үтердең инде?

Баш угланның күзләрен кан баскан иде. Күзләре зәһәри дуамаллык белән яна, куллары калтырый. Башта сүзнең ни-нәрсә турында барганын да аңышмыйчарак торды. Бераздан гына:

—Кытай, нинди кытай, мин бернәрсә дә белмим,—диде.

—Урыс сәүдәгәрләре, бик беләсең килсә, өйләрендә сыра чөмереп, кәеф-сафа корып утыралар,—диде Хәмзә,—тауарларын ялчылар сата. Безгә өй борынча йөрергә кирәк.

—Әйдә соң, киттек,—диде Уйгын,—җый угланнарны!

Озак та үтмәде, угланнарның бер өлеше, вак төркемнәргә бүленеп, кала буенча таралышты. Беренче булып, исемлерәк сәүдәгәрләр сайлап алынды. Уйгын үзе Афанасий Калистратов атлы сәүдәгәрнең капкасын какты. Шомакай дигән даны таралган иде Калистратовның. Йөзе шома, гәүдәсе шома, сүзе шома. Ул, билгеле, ярминкә хәлләреннән хәбәрдар иде инде.

—Һай, хуш киләсез, кадерле кунагым булырсыз,—дип Уйгынны үзе ишек ачып каршы алды.—Кая, анда, Маврикия, өстәлеңне яңарт, күрмисеңмени,

мөхтәрәм ханыбызнын гаскәриләре килгән.

Китте сайрап, сандугач урынына сайрый. Уйгынга сүз кыстырырга да ирек бирми. Ул арада житен чәчле, нечкә билле, тырпайган күкрәкле, зифа буйлы туташ эчемлекләр күтәреп чыкты.

—Рәхим итегез, хәрби әфәнделәр,—дип, сәүдәгәр елмая-елмая подноска акча янчыгы да китереп салды.

Уйгынга житә калды. Усал үгездәй сөзеп карап алды да, подносны бер сугуда идәнгә бәреп төшерде. Бу шул кадәр тиз һәм искәрмәстән булды ки, Маврикия кычкырырга да өлгерә алмыйча калды. Афанасий шушы киеренке шартларда да югалып калмады, кызга ябырылды.

—Үкчәнне ялтырат, күрмисенмени, хәрби әфәнделәр ризыкларынны охшатмады, башкасын чыгар.

—Тотып бәйләгез бу үгезне,—дип әмер бирде Уйгын.

—Юк, юк, зинһар өчен, нәрсә кирәк барысын да үзем бирәм,—дип юмаларга тотынды Калистратов. Тик угланнарны юмалау мөмкин түгел иде. Болар сиңа Кәлимәт шикелле майлы калжага алданучылардан түгел. Коры кашык та авызларын ертмый, ботканың майсызын да бик шәпләп сыпырталар.

—Бөек ханыбыз Мөхәммәдәмин гамәлегезне хупламас бит, угланнар, үзем өченнән бигрәк, сезнең өчен кайгырам, яшьләр ич әле сез,—дип мыгырдануында булды йорт хуҗасы.—Хан безнең йортыбызда үзе дә кадерле кунак, Ходай аңа озын гомер бирсен.

—Бәйләгез!—дип оран салды Уйгын.

Ай-ваена, хәйләләренә дә карамастан, Калистровны зинданга илтеп яптылар. Ә фатирындагы бар алтын-көмешләрне, зиннәтле киемнәрен, бәллүр савыт-сабаларын казнага тапшырдылар.

“И взя царь весь драгий товар, бесчисленное богатство, у купцов русских в казну свою, насыпа палату полну до верха русского злата и серебра, и подела себе царь венцы драгие, и посуды, и блюда серебряные и златые, и царский наряд драгий свой устрои...”

Казан елъязмачысы да бу вакыйгага карата үзенең менә шушындый мөнәсәбәтен белдерде.

***

Погром атна буе дәвам итте. Бу болганчык суда бушлай балык тотучылар да байтак булды. Төптә посып яткан адәмнәр башларын калкытты. Угланнар соңгы көннәрендә шуларны тоту белән шөгыльләнделәр. Ниһаять, кала гадәттәге тормыш белән яши башлады. Хан да кайтты. Уйгын аңа барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде, беренче көнге кансызлык галәмәтләрен дә яшереп калдырмады.

—Мин синең каршыңда бик зур гаеплемен, бөек хан, урынсызга кылыч уйнатулар да булды,—диде.

—Зыян юк, бәк,—диде Мөхәммәдәмин,—утын ярганда йомычка оча инде ул.

Мөхәммәдәмин баш угланнан риза калды. Аның өчен бу бик мөһим иде. Димәк, ышанычлы. Чөнки алда тагын да саллырак эшләр тора, бәк әле үзен күрсәтәчәк.

—Тик торган сөңге тутыга ул, углан, аны һәрвакыт кулда тотарга кирәк,—дип хан ният пәрдәсенең бер почмагын күтәреп алды.

Уйгын йодрыкларын шыгырдатып кысып куйды.

Мөхәммәдәмин өйлә вакытында Үрбәт катына юнәлде. Алар хәзер ир белән хатын гына түгел, фикердәшләр, жаваплы дәүләт әһелләре дә иде. Назга, ярату-мәхәббәткә эшлекле мөнәсәбәтләр дә килеп кушылды.

Казан ханлыгы тоткан сәяси юнәлешне бермә-бер борып куйган 24 июнь вакыйгасы аларның уртак җимеше ләбаса. Әмма бу, беренче чиратта, Үрбәт бикәнең казанышы. Мөхәммәдәминне үзгәреш-яңарышлар зарурилыгына беренче булып ул ышандырды, ул котыртты. Моны хәтта урыс елъязмачысы да (билгеле, ачу белән) таныргa мәҗбүр иде. Менә аның сүзләре:

"Махметемину же царю люба бысть братия жена вельми. И нача она помале, яко очнь, разжигати сухие дрова, яко чернь, точити сладкое древо, яко прелуковая змия, научима от вельмож своих царевых, охапившеся о выс (т.е. обнявшись за шею) шептати во уши царю и нощь, да отвергнется от великого князя, да не словет Казанский царь раб его, и во всех землях да не срам будет и уничижение будет всем царем, и всю Русь да побьет живущую в Казани и корень их изведет…»

Үрбәт катыннан җыр ишетелә иде. Мөхәммәдәмин ишек чаршавына посып, колагын монга салды. Җыр салмак кына агучы елганы хәтерләтә иде. Озын, сузынкы.

Каргай башы ку (буш, корыган) булыр,
Карыдан куәт кайткан соң
Каты ягы (җәя) тартмак сур (кыен, җәза) булыр,
Карача күздән нур тайган соң
Карап күрү моң булыр.

Шундый бирелеп, мөкиббән китеп җырлый иде Үрбәт, ул хәтта ире яшеренгән урыныннан чыккач та абайламый торды. Күргәч, дерт итеп китте.

—Бик мәгънәле җыру җырлыйсың, бикәм,—диде Мөхәммәдәмин,—ниндидер хәер-фатихага охшаган димме.

—Хәер-фатихасы да бар инде, хан. Сәфәрләрең уң булсын дим. Мул итеп мал-мөлкәт, ганимәт төяп кайтыгыз, дим. Күп әсирләр насыйп итсен ходаем, дан-дәрәҗә, исәнлек-саулык бирсен. Җырым белән шуларны телим инде мин, Мөхәммәдәмин.

—Амин!

—Әле менә "Идегә" дастанын кабат күнелемнән үткәреп утырдым,—дип рухланып сөйләп китте Үрбәт. Күрәсең, бу әңгәмәгә алдан ук җентекләп хәзерләнгән иде. Ханның рухи тотрыклылыгын саклау, тоткан мәсләгеннән читкә тайпылырга ирек бирмәү өчен ханәкә әллә нинди адымнарга барырга әзер иде.—Дастанда татарларның да, нугайларның да, кыпчакларның да фаҗигасы тасвир ителә. Бөтен җиһанны дер селкетеп торган мәшһүр Алтын Урда яшәүдән тuктый. Кемнәр аңа кул сала соң? Шушы олуг дәүләтне бар иткән бөек Бату ханның үз нәселе. Үз тәненә үзе кадалган чаян сыман чыңгызлылар да үз-үзләрен чагалар.

Кырым, Казан, Аждархан
Башлы-башлы ил булды,
Алтын Урда таралды.

Менә шундый ачы юллар белән тәмамлана дастан. Әгәр инде Казан үзенә баш дәүләт булган икән, аның даны да Алтын Урда данына тәңгәлләшсен иде. Башка чыккан баш бала төп йортның гадәтләрен куган ише.

—Ханәкә, син боларны ничек шулай җентекле сыйфатта беләсең соң?—дип гаҗәпкә калды Мөхәммәдәмин. Чөнки ул үзе урыс арасында җитлегүе сәбәпле, татар тарихының нечкәлекләрен белми, хәтта ки хәбәрдар да түгел иде. Үрбәт тартып кертте аны әлеге мавыктыргыч җиһанга. Үзенең

нәсел-нәсәбен, ыруын, халкының гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, жырбиюләрен белмәгән ханның чын дәүләт житәкчесе булуы мөмкин түгел икән. Мөхәммәдәминнең күнеленә, ниһаять, шушы хакыйкать барып иреште.

—Сине ходай мине бәхетле итү өчен саклаган,—диде Мөхәммәдәмин.

—Рәхмәт инде, жанашым. Онытып торам, минем сина бер бүләгем дә бар бит әле.

—Бүләкне ир-егет бирә аны, аппагым,—дип көлемсерәде Мөхәммәдәмин,—никах кануннарын бозарга ярамас.

—Бу гади бүләк түгел, бу бөтенләй үзгә бүләк, аны бүләк дип тә әйтеп булмыйдыр, мөгаен...

—Бикәм, газаплама зинһар, күрсәт тизрәк ул бүләк түгел бүләгенне.

Үрбәт эчке бер дулкынлану белән түрдәге сандыкның ефәк япмасын ачты. Сандык эченнән остабикә яулыгының яртысы чамасындагы кара нәрсәне кулына алып:

—Каргай башы ку булыр, хан билгесе ту булыр,—диде дә Мөхәммәдәмингә сузды.

—Кыл байрак?!

Мөхәммәдәмин янә бер гажәптә иде. Ирен сөйгән хатынның өенә нур явар, ди. Шул иде бу.

—Мин ана хан күтәрмәк тамашасына хәзерләнеп йөргәндә тап булдым,—дип аңлатты Үрбәт.—Беләм, хәзер кыл байрак йөртмиләр. Әмма дә ләкин бу Олуг Мөхәммәд хан туы. Ул сина да жиңү китерәчәк.

—Башка яңалыкларың булса да, әйтә күрмә берүк,—диде Мөхәммәдәмин чын күңеленнән,—мин аларны күтәрә алмам, йөрәгем ярылыр.

—Иң саллысы ту иде,—диде Үрбәт бәхетенә сыеша алмыйча,—тагын печтик кенә бер хәбәрем бар. Шатлыклы хәбәр. Алгай морзадан мәктүп алдым, гаскәремне тупладым, жизнәйдән әмер генә көтәм дигән. Юл уңаеннан үзенең дә Казанга сугыласы килә. Хан ничек карар икән, дигән.

—Кадерле вә дәрәжәле кунагым булыр, шушы сүземне житкер,—диде Мөхәммәдәмин.—Минем кырык меңле гаскәремә Алгай морзаның егерме менен кушсаң, жәмгысы алтмыш мең. Иншаллаһ, жиңү безнен якта булыр. Ту безгә юл күрсәтер.

***

Алгайның Казан каласында булганы юк иде әле. Иксез-чиксез нугай далаларыннан соң шәһәр ана кәбәрткә шикелле кысан тоелды. Шулай да тора-бара күнә башлады кебек, кала үзенчә, дала үзенчә матур икән. Тик ул монда барыбер төпләнеп яши алмас иде. Ә менә ара-тирә тутасы белән жизнәсе янына кунакка килеп, сафа сөрергә һич тә каршы килмәстер, мөгаен. Казанда туташлар да бик зифа күренә. Тик артык нәзберекләр, өрсәң дә очып китәрләр төсле. Тутасы да нишләптер шуларга охшап калган. Очыртырсың нугай кызларын, жиргә төп сыман тамырланганнар алар. Ат өстендә дә ир-егетләрдән калышмыйлар.

Хан кайнишен Уйгын бәк белән таныштырды. Бик тиз дуслашып киттеләр. Ләкин Үрбәт энесеннән тотам да калмады. Беренче мәртәбә күрешүләре бит. Туган-үскән жирнең коры курасы да чәчәк кебек күренер, ди. Үзе кайтып йөри алмый. Чөнки ир хатыны. Ханның исә андый ерак жирләргә чыгып китәргә жае юк. Аннан соң, нугайлылар теге вакытта Себер ханзадәсе Мамык ягында булып, Мөхәммәдәминне тәхетен ташлап китәргә мәжбүр иткәннәр иде. Араларыннан елан үтте.

Шөкер, Үрбәт мөнәсәбәтләрне акрын-акрын булса да жайлап килә инде. Алгай бәк, әнә, егерме меңлек Нугай гаскәрен Мәскәү кенәзлеге чигенә

тезеп куйды. Монысы да тәтәсе хакына, билгеле.

Тик Мангыт-йортның үзендә дә сулар болганыштрыбрак тора икән. Үрбәт бик борчылды.

—Хәрам мал төс бирми, тәтә,—диде энесе ерактанрак суктырып.

—Үзебезчә, мангытча турыдан гына бәреп сөйлә әле, туганым,—диде Үрбәт.

—Мангыт-йортта мангытлар баш булырга тиеш, түгел килмешәкләр,—диде Алгай. Анын да кара күзләреннән очкыннар сибелде. Тәтәсе шикелле ул да хис, тойгы кешесе иде, ахры.

—Нугай морза нәселе,—дип төзәтте энесен Үрбәт.—Идегә морза дәүләтебезгә нигез салганда нигәдер Әбелхәер дәүләтеннән читләшеп бетмәгән. Бу шуның шаукымы.

—Тәтәй, Идегә морзага тел тигезмә, заманасы шулай булган,—дип кызып китте Алгай,—хәзер менә нәкъ вакыты. Жизнәкәй дә ярдәменнән калдырмас, шәт.

—Әйе, энем, тик ул дәүләткә Нугай морза исемен йөртү фарыз. Гаделлек барыннан да өстен.

Алгайның бу сүзләрдән буасы ерылып китте, тигез ак тешләре ялтырап күренде. Даланыкыларча чибәр иде морза. Киң жилкәле, базык гәүдәле. Камыт аяклары да килешеп тора. Хәтта калын иренле зур авызы да, табактай жәлпәк йөзе дә үзенә үлчәп ясагандай нәфис булып тоела иде.

Тәтәсе дә нәкъ ул уйлаганча уйлый икән ләбаса! Шуңа куана иде. Әлбәттә, Урда Нугай морза исемен йөртәчәк.

—Ханәкә, ниятләребез туры килә икән,—диде Алгай.

—Туры килмичә, без мангытлар ла,—дип елмайды Үрбәт.

Чәйдән соң алар ат менеп, кала карарга чыктылар. Кешеләр танымасын өченгә өсләренә гади кием киделәр, атларны да гомуми утардан гына иярләделәр.

Бераз баргач, Алгай артына борылып карады да, озак кына Кремльне күзәтеп торды. Әле офыкка ал төс кунарга өлгермәгән. Шулай да төш вакытындагы тибрәлмә аксыл дулкыннар инде юкка чыккан, көн дә сүрәнләнә төшкән.

Кремльнең аеруча матур чагы. Калкулыкка кунаклаган Хан сарае әнә ничек балкый, әйтерсең лә, биниһая зур учак өстендә утыра. Мәчет манараларының алтын айлары да кояш нурларында жем-жем жемелдәшә.

—Казан бик матур кала. Тик Нугайда мондый һәрьяклап ныгытылган кирмән төзүнең хажәте юк,—диде Алгай морза аклангандай,—дала үзе саклый.

Нишләптер Үрбәт атланган атның авызлыгы ычкынды. Алгай аны тиз генә эләктереп алды.

—Дошман атларының Нугай даласында тояк эзе дә калдырганнары юк дип беләм,—диде Үрбәт энесе авызлык белән мәшәкатьләнгән арада. Нугай турында әңгәмә кору аңа әйтеп бетергесез рәхәтлек китерә иде.

—Шуңа күрә Әбелхәердән аерылып чыгарга, мөстәкыйль Нугай урдасы төзергә кирәк,—дип тәтәсенең сүзен хуплады Алгай.

Әңгәмә бүленде. Чөнки үзләре дә абайламастан, ниндидер кешеләр төркеме эченә кереп кысылганнар иде. Көчкә арындылар.

—Кабаланма, бу сиңа дала түгел,—дип кисәтте Үрбәт энесен.

—Әйе, кала дала түгел ик-ә-ә-н,—дип сузды морза.

Хан капкасы янында янә тукталдылар.

Капка үзе бер гажәеп корылма икән. Ян-ягы кирмән кебек үк, юан имән бүрәнәләрдән өелгән. Астыннан калага кереп-чыгып йөриләр, ә өске

өлешенә биек итеп[1] сыргавыл (күзәтү манарасы) төзегәннәр. Кем килә, кем китә—һәммәсен энә күзеннән үткәрәләр, ди. Шәһәргә ничә чыпчык очып кергәнне дә белеп торалар, имеш.

Капкалар берничә. Кагыйдә буларак, ул капкаларга олы юллар килеп тоташа. Алабуга капкасыннан Алабуга даругасына юл китә, Нугай капкасы исә Мангыт якларына юл күрсәтә.

Үрбәт атын Түбән бистә ягына борды. Бистә Кремль тавынын түбәнге ягында, Болак буена җәелеп утыра. Каланың тигез урыны да бар икән, дип уйлап куйды Алгай. Ә ыгы-зыгы монда тагын да куерак иде. Җир буе сузылган сәүдә рәтләре тулы халык. Ни генә юк? Ата-анаңнан кала һәр нәрсәне табарга була монда, дип мактана казанлылар үзләре. Байлык, житешлек галәмәте инде.

Кызыксынып китеп, Алгай күз кабаклары өреп тутырылгандай кабарган шакмак гәүдәле бер кеше янында тукталды. Сәүдәгәр аны түбәнчелек белән башын иеп сәламләде.

—Хус киләсес, хус киләсес,—дип авызында ничә теше булса, барысын да күрсәтеп елмайды. Хезмәтчесе хуҗасыннан да өлгер икән, морза алдына ефәк тукымалар китереп өйде. Күзләр камашырлык. Җаның теләгәнен сайлап ал.

—Кайсы мәмләкәт кешесе буласын?—дип белеште Алгай.

—Чин мәмләкәтеннән, әфәндем, исемем Чжоу. Касан белән бик дус торабыс. Татар кыслары кием-салымга бик һәвәс, матур киенергә яраталар. Сеснең бичәне дә чибәр дип беләм. Бүләк алмасагыс, гөнаһлы булырсыс. Рәхим ит, кайсыларын сайлыйсыс?

—Безнеңчә дә яхшы сөйләшәсең,—дип төпченүендә булды морза.

—Татарлар беснең үсебездә дә бар, белмичә суң,—диде Чжоу кояштай балкып.—Белмәсәң, алыш-табыш итеп булмый бит, әфәнде. Җә, нинди тукыма сайлыйсыс? Чин ефәкләренә тиң юк, үкенмәссес.

—Тәтә, берничә күлмәклек тукыма сайла инде,—дип Үрбәткә карады морза,—сәүдәгәре бик күркәм кеше, буш кул белән китү килешмәс.

Кытай сәүдәгәре яныннан китүгә: "Чичәннәр ярышына рәхим итегез!" дигән өндәмә янгырады.

—Әйдә, тыңлап карыйк әле,—диде Үрбәт энесенә.

—Анысы ни-нәрсә тагын?

—Мангыттагы кушавызчылар тамашасына охшаганрак җыен,—диде Үрбәт.

Базар читендә генә зур чатыр корып куйганнар икән. Аны ак ефәк тасмалары белән бизәгәннәр. Мәйдан уртасына келәм җәелгән. Анда тездән түбән озын күлмәк өстеннән кыска җиңле җинел бишмәт кигән ике адәм басып тора иде. Берсенең сакал-мыегы әле чыгып кына килә булыр, икенчесенекенә инде чал куна башлаган.

Баш чичән аларны тамашачыларга тәкъдим итеп болай диде:

—Бүген сезнең алда Шиһабетдин бине Гәләветдин хәлфә үзенең шәкерте Бикмулла бине Зиннури белән килен-каенана, каеналар хакында халык әйтемнәрен шәрехләп, сүз көрәштерәчәк. Маясы ятим балалар мәнфәгатьләренә тәгаенләнә. Тәнкәләрне мелла Бабдесаттар бине әш-Шырдани дога кылып кабул итәр. Савабы үзегезгә төшәр, иншаллаһ. Бисмилла әйтеп, тамашабызны башлыйбыз.

Гәләветдин хәлфә чөйгә охшаш очлы сакалын сыйпаштыргандай итте дә, куш учларын маңгай турысына китереп, чалмалы башын иде. Остазы үрнәгендә Зиннури шәкерт тә әлеге сәламләү хәрәкәтләрен кабатлады.

—Авызын, борынын тот, биатай, идән себерәм!—диде хәлфә

[1] Сыргавыл—күзәтү манарасы.

тамашачыларга ишетерлек көр тавыш белән.

Шәкерт шушы әйтемне шәрехләргә тиеш. Шарты—тапкырлык һәм шаянлык. Җыелышучылар тын калып, аның җавабын тыңларга хәзерләнделәр. Колаклар торулы.

—Сафура килен булып төшкәч,—дип сөйләп китте шәкерт,—каенанасы: “Бар, кызым, каенатаң ягына кереп идән себереп чык. Яхшы себер, ул бер дә тузан яратмый”,—дип кушкан. Сафура, ярар, дигән дә кулына зур себерке тотып, каенатасы янына кергән. Каенатасы аны, бик тәүфыйклы, бик юаш җирдән килен алдык дип белә, тел яшерү гадәте буенча, килене авызын ачып сүз дә әйтмәс дип көткән икән.

Килен исә:

—Авызың-борының тот, биатай, идән себерәм!—дип оран салмасынмы.

Җавапны охшаттылар, ахры, гөжләшеп алдылар.

—Киленем әйбәттән түгел, мичем әйбәттән,—дип остазына бакты шәкерт. Хәлфә шундук эләктереп алды.

—Кунак хатын әйткән:

—Киленнәрең бик оста икән, бәлешләрне бигрәк тәмле пешергәннәр,—дигән.

Каенана әйткән:

—Юк, киленнәрем түгел, мичем бик әйбәт минем, мичем шулай пешерә,—дигән.

—Нинди гаделсез каенана икән,—дип көлде Алгай морза.

Ә уен кызганнан-кыза барды.

Бирем әйтү чираты хәлфәдә иде.

—Чебендә дә кан бар, килендә дә җан бар,—диде.

Шәкерт тә һушлы күренә, җаваплый да башлады.

—Үткен кыз Үлмәс Сылу килен булып төшкәч, каенанасы аны төрлечә табаларга тотынган. Үлмәс Сылу әүвәл аны сынаганчы дәшми түзеп торган. Каенанасы тагын да узынып китеп, беркөнне бөтенләй чыгырдан чыккан.

—Мин сине чебен урынына сытармын!—дип каршына ук кизәнеп килгән.

Үлмәс Сылу ашыкмый гына кисәү агачны алып:

—Сыталмассың, каенанай, чебендә дә кан бар, килендә дә җан бар,—дип кисәү белән тыныч кына мич болгатырга керешкән, ди.

—Афәрин, шәкерт, булдырасың,—дип кычкырышты халык. Алгай морза да: “Башлы малай”,—дип бәясен бирде. Үрбәт кенә фикер әйтергә ашыкмады.

—Шатланмый тор, асылган җебем өзелде.

—Пәрихәнең каенанасы Миһрибану беркөнне иртән торган да,—дип шәрехләп китте хәлфә,—күргән төшен сөйли икән:

—Менә котларым да калмады, тәүбә, гүя мине муенымнан асканнар, имеш. Пәрихә бердән шатланып:

—Чынлапмы? дигән икән, каенанасы аңа:

—Тукта, шатланмый тор, асылган җебем өзелде дә уянып киттем,—дигән.

Монысына кулны бик саран чаптылар. Халык шәкертне охшатарак төшә иде. Һәм ул аларның ышанычын аклады.

—Ыштан дисәм, оялам, дамбал дисәм, казахча, бот капчыгыңны салып бир, биатай,—дип чираттагы биремне тәкъдим итте шәкерт. Халык дәррәү килде. Ләкин чичәннәрне Үрбәт ошатмады.

—Әйдә, киттек, морза, шушы да булдымы тамаша-бәйге,—дип, атының

тезгенен тарткалады,—шул тозсыз мәзәккә авыз ерган булалар.

—Ә шәкерт башлы малай,—диде Алгай тәтәсе белән килешмичә.

***

Иван Васильевичнын хәле күзгә таба тагын да мөшкелләнебрәк китте. Начар ашый, начар йоклый. Черем итеп алганда да саташып, тешләнеп бетә. Беренче хатыны Мария төшенә кереп йөдәтә башлады. Югыйсә, чәчләрен кистереп монастырьга җибәрелүенә генә түгел, вафатына да ике дистә ел вакыт үтеп киткән иде инде. Үз язмышын княгиня түземлек вә сабырлык белән кабул итмәде. Аны берничә тапкыр элмәктән алганнар. Шуннан соңгы гомере бер ялгызы үткән, диләр. Соңгы сулышына кадәр ире Иванга бәддога укыган, имеш. Яшь чагында Иван моны игътибарга да алмады, көлде генә. Ни дисәң, хатынын монастырьга яптырган патшаларның ул һич тә тәүгесе түгел. Мөгаен, соңгысы да булмастыр.

Мария кап-кара чиркәү киеменнән. Үзе ләм-мим дәшми. Фәкать карап кына тора. Ә карашы без кебек, үтәли тишә, үзеңне-үзең кая куярга белмисең, муенга бау саласы килә башлый.

Иван шыбыр суга төшә. Уянгач та калтырануы басылмый интектерә. Ихтимал, гөнаһлары да бардыр. Тик ул гөнаһлар Русьнең бөтенлеге, абруе, православие диненең сафлыгы, пакълеге хакына кылынды лабаса. Византия династиясе белән туганлашуы, Софияга өйләнүе дә шул максатка юнәлдерелгән иде ич.

Иван хәле аруланган араларда монастырьдан-монастырьга, чиркәүдән-чиркәүгә йөреп, елый-елый ходайдан гөнаһларын ярлыкавын үтенә. Аның һич тә тәмуг кисәве буласы килми.

Шундый догалы көннәрнең берсендә аны ниндидер могҗиза белән баш углан Уйгын бәк кулыннан ычкынган дьяк Иван Телешев эзләп тапты.

—Хыянәт, олуг кенәз!—дип, патшаның аяк астына ауды.

Иван нуры сүнә башлаган күзләрен илче ягына борды. Телешевнең түгәрәк йөзендә болындагы ялгыз кибән сыман борыны гына утырып калган иде. Күз төпләре кара-күк төскә кергән. Киемнәре дә карачкыга эленгән иске-москы шикелле салынып төшкән.

—Ни булды сиңа, кенәз, кешелегең калмаган,—диде Иван хаста кешеләргә хас кайгыртучанлык белән. Илче сүзләренең асылы әле аның аңына барып җитмәгән иде.

—Хыянәт!—дип түземсезләнеп кабатлады Телешов.—Мөхәммәдәмин хан бөтен килешүләрне бозды. Казанда урыс кешеләрен, сәүдәгәрләрне кылычтан үткәрделәр, мал-мөлкәтләрен таладылар. Илче Кляпик кулга алынды. Мин белгәндәй яшеренү чараларын алданрак күреп куйган идем. Шөкер, менә синең алда басып торам. Бер атна эчендә кайтып җиттем. Ике ат кына "яндырдым", авызыма юньле-башлы тәгам да алмадым... хәлемне күреп торасың...

Олуг кенәз башын кулларына салып, бик озак сүзсез утырды. Күзләре дә йомык, керфекләре ник бер селкенеп карасын. Әллә мәрткә китте инде, дип борчылды Телешев. Чиркәү эче тып-тын, патшага хезмәт күрсәтүче руханилар да бернәрсә булмагандай карусыз гына басып торалар. Монда бөтенләй башка тормыш, аның дөньяви мәшәкатьләр белән берниндн уртаклыгы да юк. Әйтерсең лә, адәм баласы гөнаһларын ярлыкау өчен генә туган.

Ниһаять, Иван күзләрен ачты.

—Минем иң зур гөнаһым куеныңда шул поганый татар ханы Мөхәммәдәминне җылыту булган икән,—диде ишетелер-ишетелмәс кенә.—Ходай миңа шунын өчен хак җәзасын бирә...

Иван янә тынып калды. Ә бераздан какча җилкәләре калтыранырга тотынды. Бу хәлендә ул бик кызганыч күренә иде.

Кара хәбәр моның белән генә бетмәгән иде әле.

—Ул басурман Сура елгасын кичкән. Нижнийга яу белән килгән,—дип илче бу хәбәрне дә җиткерде. Үзе, чыдасын гына инде карт, дип борчылып куйды.

Бу юлы дьякның шикләнүләре рас килмәде. Киресенчә, олуг кенәзнең бөкре гәүдәсе тураеп киткәндәй булды. Яшьләре дә кипте. Күзләренә кешеләрне утырган урыннарына сендерә торган элекке зәһәрлеге кайтты.

—Монысы булмас!—дип кычкырды ул.—Йөз меңле менә дигән гаскәрем бар минем. Хәзер үк набат суксыннар.

Шул көнне олуг кенәз Иван Васильевич төштән соң тәхет залына Василий Холмский, Даниила Шеин, Яков Захарьевич кебек Мәскәүнең иң дәрәҗәле боярларын, кенәзләрен чакыртты. Анда казначий Дмитрий Владимирович һәм архимандрит Андрониковский да бар иде. Олуг кенәз өлкән улы Василий Ивановичны рәсми рәвештә үзенең варисы дип игълан итте.

Икенче көнне урыс тәхетенең варисы Василий өченче җитәкчелегендә гаскәр Түбән Новгород тарафына юл алды. Ләкин патшаның бугаз киерүенә дә карамастан, урыслар бу яуга әзер түгел иде. Варис та кемлеген күрсәтә алмады. Муромга җитәрәк бөтенләй тукталып калдылар.

Елъязмачы бу вакыйга турында ачынып түбәндәге җөмләләрне теркәп куйды: “Они же паче себя стрежаху, а не земли своея, и вышли страхом объяти быша, безумни, убояхуся и трепетаху, избранными воины блюдущеся из града выйти, толико имуща не мало воспретити царю (т. е. хану)”.

Мөхәммәдәмин кала читендә үк дошманга ыргылырга тиешле атлы гаскәрен ук рәвешендә тезде. Иң алдагы меңлек чирү чөй сыман урыс гаскәрләрен ерып эчкә керергә, ыгы-зыгы тудырырга, бүлгәләргә тиеш иде. Як-яктагыларга исә бу өерләрне камап алып, юк итү бурычы куелды. Орышның әвәлге чорында әсир алу белән булышмаска килештеләр. Кырырга! Исән калганнары соңыннан каршы торып та азапланмаслар, үзләре әсир төшәрләр, чутына да чыга алмассың.

Уйгын җитәкчелегендәге каһарманнар чирүе Кирмәнне кулга төшергәч кенә кузгалачак. Аның төп вазифасы воеводаны, гаскәр башларын кулга алу, ганимәт җыю.

Алгай морза исә үзенең мангыт-нугайларын иң алгы дулкынга куюларын сорады, җизнәсе алдында үзен күрсәтәсе килә иде булса кирәк.

—Алайса уң як канатны тулысы белән үзеңә ал,—диде Мөхәммәдәмин.

Мөхәммәдәмингә ак атын китерделәр. Җайдак киемендә ул Гали хәлфәгә охшап тора иде.

—Аллаһы Тәгалә көч-куәт өстәсен!—диде хан фатихасын биреп—ыру башыбыз Олуг Мөхәммәднең кыл байрагы—ту безгә җиңү алып килер. Кузгалдык. Алга!

Хан беренче булып ыргылды, аның артыннан бөтен яу күтәрелде. Торабара һәр чирү алдан билгеләнгән урынын алып, угланнар карамагына күчте, хан яраннары белән ышыккарак тайпылды.

Бу ташкынны туктату мөмкин түгел иде инде. Уңда да, сулда да, алда да, артта да Мөхәммәдәминнекеләр. Бөтен тирә-якны тутырып, тояклар аһәңе яңгырый.

Тояк тайга җиткерер,
Тай дүнәнгә җиткерер.

Дүнән атка житкерер,
Ат морадка житкерер.
Алтын ияр акбуз ат
Төшендә тотып син менсән,
Ат—морадка житкәнен.

Кала читендәге алачыкларны, йорт-жирне яндырып-туздырып Кирмәнгә якынлаштылар. Бернинди каршылык күрсәтүче дә юк. Жину инде уч төбендә. Якында, кул гына сузмалы.

Тик атлы чөй көткән нәтижәне бирмәде. Чөнки Нижнийның воеводасы Хабар калгай, мәскәүлеләрдән аермалы буларак, жебеп төшмәде. Гаскәрен Кирмәннән бөтенләй чыгармады. Шуна күрә чөйдәгеләр дә, ян-яктагылар да, хәтта булышчы чирүдәгеләр дә кузалак арбалар шикелле Кирмән стенасына бер үк вакытта килеп төртелделәр. Алгай дала кешесе булса да, әзерлеклерәк булып чыкты. Нугайлар килә-килешкә тимер ыргаклы арканнарын стена очына очырдылар. Шуыша-шуыша үрмәли дә башладылар. Ләкин бу гамәл тончыгып калды. Башта түбәдән кайнар су койдылар, аннан соң таш аттылар, бүрәнә тәгәрәттеләр.

Бераздан бөтенләй мәхшәр башланды. Урыслар шарт та шорт ут коралларын шартлатырга тотындылар. Казанлылар өчен бу яналык түгел иде. Үзләренен дә сынап караганнары бар. Ләкин ошатмадылар. Кылычсөнгегә житәме сон? Аны корган арада тулы бер чирүне тар-мар итеп була лабаса. Аннан сон, ул урысларга да литвалылар аша керде, бармак белән генә санарлык.

Воевода Хабар тапкыр гаскәри иде. Татарларга каршы торырлык көче юк иде анын. Йөзгә-йөз килгәндә, таптап-изеп кенә узачаклар. Нииндидер көтелмәгән нәрсә уйлап табарга кирәк иде. Һәм ул аны тапты. Олуг кенәз, әсир төшкән Литва сугышчыларын ерагырак яшерү нияте белән, Нижнийга кудырган иде. Кайсы ачлыктан, кайсы чир-сырхаудан аяк сузып, тора-бара өч йөз борыннан кырыгы гына торып калган иде. Ин ныклары, ин тазалары. Иван орышны бөтенләй яна ысуллар, яна кораллар кулланып алып бара белүче бу Аурупа әсирләрен үз һөнәрләре буенча файдалануны күздә тота иде, билгеле. Менә жае да чыкты. Воевода аларны жыйды да:

—Кемнен исән-имин туган иленә кайтасы килә?—дип сорады.

Әсирләрнен кырыгы да бер адым алга атлады.

—Йә, хуш,—дип кылычын сыйпап куйды Хабар.—Монын өчен бер генә шарт бар: татарларны моннан китәргә мәжбүр итү.

—Ә ничек?—дип сорады әсирләр.

—Пищалкаларыгызны үзегезгә кайтарабыз, штубы өзлексез ут чыксын. Татарва уттан курка,—диде воевода,—тик шуны алдан белеп торыгыз, татар гаскәрләре үләксәгә жыелган чебен кебек, ава торалар, килә торалар...

—Ә без кыра торырбыз...

Дөрестән дә, гаскәр каушап калды. Нугайларнын исә утлы коралга, шартлауларга беренче тапкыр юлыгулары иде, куркуларыннан кычкырыша-кычкырыша яу кырыннан кача ук башладылар.

—Ахырзаман, ахырызаман...

Бу хурлыкны күреп, Мөхәммәдәмин шашар дәрәжәгә житте.

—Алгай морзаны алып килегез!—дип әмер бирде.

Күп тә үтми, морза күренде. Ул чатанлый иде. Ләкин хан анын чатанлавына игътибар итмәде. Үзен-үзе белешмичә:

—Чирүенне кулына ал, куркак жан, нәрсә жебеп төштен?—дип кычкырды.

Алгай каршы сүз әйтмәде, кан баскан ачулы күзләрен әйләндереп,

җизнәсенә карап алды да, чатанлый-чатанлый китеп барды.

Мөхәммәдәмин тиз генә Уйгынны чакыртты.

—Синекеләргә чират житте, баш углан, хәлне төзәтергә кирәк,—диде. Ул орышның барышыннан һич тә канәгать түгел иде, үз-үзенә урын таба алмый, йөрәге алгысына, җаны өзгәләнә...

—Алгай морзаны сөңгегә күтәргәннәр,—дип аваз салды тоткавыл сакчы,—әле генә хәбәр китерделәр.

Мөхәммәдәмин нидер әйтмәкче булып авызын ачкан гына иде, өлгерә алмыйча калды. Нәкъ шушы мизгелдә чатыр авызында көчле шартлау тавышы яңгырады...

Шул ук көнне гаскәр бернинди ганимәтсез Нижнийны ташлап китте.

***

Мөхәммәдәмин каенишен югалтуны бик авыр кичерде. Нугайлар үзләренә котырына, гүя аерылган корт күче. Морзаның үлемендә ханны гаеплиләр, ике арада чак кына бәрелеш булмый калды.

Аллаһы боерса, каенишенең үчен кайтарачак әле ул, кайтарачак!

Үрбәт ирен төрлечә юатты. Ул үзе дә җанын кая куярга белмичә кайгыра иде. Төпчекләре иде бит. Атаенын бар гамәлен, бар мал-мөлкәтен үзенә мирас итеп алырга тиешле төп варис иде. Ул хәсрәтен Мөхәммәдәмингә күрсәтмәде, эчтән генә янды. Иренең болай да яралы йөрәгенә кан саудырасы килмәде.

***

Көннәрдән бер көнне, һич уйламаганда, Җөһдә ханбикә йокысыннан уянмады. Ул Мөхәммәдәминнең үз вазифасын бик белеп, зур төгәллек һәм җаваплылык белән җиренә җиткереп башкара торган турылыклы хәләл җефете иде. Ханның хатыннарына күзәтчелек итү, гаиләне йодрыкта тоту, кием-салым, бүләкләрне кабул кылу, аш-су, мәҗлесләр оештыру кебек вазифалар йөкләнгән иде аңа. Түшәкчеләр, пешекчеләр, кәнизәкләр, асраулар өстеннән дә ул тора иде. Кыскасы, сарайдагы хатын-кызларга бәйләнешле һәр чараны ул оештыра иде. Шуңа күрәме, бәйләнчек, вакчыл иде ханбикә. Бигрәк тә Үрбәткә каныга, "хәрамлашасың, алдап-йолдап ханны үз ягыңа аударасың, чиратны бозасың", дип бәйләнә иде. Чынында әлеге сүзләр Мөхәммәдәмингә кагыла, чөнки чиратны ул санга сукмый, күбрәк яшь хатыны тирәсендә чуала. Җөһдә моны белә, әмма белә торып, үчен Үрбәттән ала иде.

Менә шул Җөһдә түшәгеннән тормады. Алдагы көнне генә сарайда Коръән укытып, абыстайлар мәҗлесе уздырганнар иде. Мөнәҗәтләр әйтештеләр, бәетләр тыңладылар. Хәтта думбра да суктылар. Каланың иң танылган өч-дүрт дистә остабикәсе генә килгән иде. Сарайныкылар күпме тагын. Бу Җөһдә үзе тәкъдим итеп, хан тарафыннан хупланган даими үткәрелүче мәҗлес иде. Һәр елны Җөмәдел ахир аенын беренче җомгасында Рагаиб кичәсенә туры китереп үткәрелә иде ул.

Бу кичәдә хәзрәте Рәсүл галәһиссәламның атасы хәзрәте Габдулла илә анасы хәзрәте Әминәнең никахлары булып, беренче тапкыр күремешләрдер. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнын нуры хәзрәте Әминәгә күчкән көндер. Сарайда бу вакыйганы шулай хөрмәтләп үткәрәләр иде.

Ханбикәне бимазаларга берәү дә кыймады. Йончыгандыр, мәҗлестән соң рәхәтләнеп ял итсен, диделәр. Шулай өйлә житте, намазга басарга вакыт, ә ханбикә тормый да тормый. Түшәкчесе түзмәде, бүлмәсенә узды.

—Ханбикә, бер-бер йомышың юкмы?—дип, аваз салды. Чөнки белә, хуҗабикәсе көйләтергә маһир.

Түшәкченен сүзләре бүлмә эчендә йотылып калды. Җавап булмагач, түшәкче хуҗабикәсенә күз саласы итте. Тегесе үзенә хас булмаганча, чалкан төшкән, авызы ачык, йөзенә балавыздай аксыл-саргылт төс кунган...

Әллә сырхауланып киткән инде, дип уйлады кыз һәм йөгереп чыгып имче тутакайны алып керде.

—Бикәнә ахирәт күлмәге хәзерлә,—диде им-томчы тыныч кына. Ай-вай да килмәде, әйтерсең, гадәти хәбәр житкерә.

—Кит, булмаганны!—диде түшәкче дерелдәгән кулларын кая куярга белмичә,—ханбикә бит ул...

—Ханбикәләрне дә ходай үзенә ала,—диде тутакай,—күрмисенмени, күзләре керәчләнгән.

—И, кадерле бикәм, ниләргә дип безне ятим иттен, ташлап киттен,— дип, гадәт буенча сыктарга тотынды түшәкче,—синсез ниләр эшләрбез без? Ашавыбыз ашау, йокыбыз йокы булмас син булмагач. И, ходаем, түземлекләр бир, бу кадәр хәсрәтне күтәрерлек көч бир...

—Вакытыннан алда шыншыма,—диде имче битараф кыяфәт белән, күрәсен, ханбикәгә рәнҗүле иде ул.—Бар, хәбәр сал, ханга житкерсеннәр.

Жөһдәне дәрәжәсенә туры китереп, зурлап, олылап жирләделәр. Ясинны Бураш сәед үзе укыды. Хан гүр сәдакасын да аңа бирде. Кырыгын бик күп кеше жыеп үткәрделәр. Үрбәт бу мәшәкатьләрнен эчендә кайнады. Бик тату яшәмәсәләр дә, якташлар иде ич. Икәве дә дала кызы, Нугай һавасын сулап буй житкергән абруйлы бикәләр. Язмыш аларны көндәш итте. Ир бүлештеләр. Инде Жөһдәнең бернидә хажәте юк. Фанидан бакыйга һич нәрсә күчми шул. Жиһанга нинди хәлдә аваз салган булсаң, шул ук хәлдә китеп тә барасың. Калган кешегә генә барысы да кирәк.

Үрбәт тә кара кайгыга төште. Моңа Кырым ханбикәсе Нурсолтанның Мөхәммәдәмингә язган хаты сәбәпче булды. Ул аны очраклы рәвештә генә кулына төшергән иде. Сүзләрдән, әйтерсең лә, гәрәбә тезә, кәгазьгә сәйлән булып ятканнар. "Барча Казан жиренен мөхтәрәм вә гыйззәтле ханы Мөхәммәдәмингә ходай озын-озак патшалык насыйп итсен, саулык-сәламәтлек, бәхет, күңел тынычлыгы бирсен", дигән мөрәҗәгатеннән соң, акыллы киңәшләрен бирә, "Әдәпле бул, халык сөяр, гыйффәтле бул, алла сөяр, сабырлы бул, үкенмәссең; чыдамлы бул, картаймассың",—дип теләкләрен житкерә.

Боларына ике куллап риза Үрбәт. Тик анасын бу гына канәгатьләндерми шул. Үгет-нәсыйхәтен дәвам итеп, мәктүбен түбәндәге юллар белән тәмамлый: "Бернәрсәгә дә карама, тагын өйлән, кәләшеңне үзең сайла, яшь булсын, ишле нәселле булсын. Ходай кушып, варисың тумасмы?"

Нурсолтан ханбикә, билгеле, хак. Ул Олуг Мөхәммәд ыруының киләчәге турында кайгырта. Югыйсә, ханлык башкалар кулына күчәчәк. Чөнки Мөхәммәдәминнең дә, Габделлатыйфның да балалары юк. Аталары Ибраһим ханның ике жәмәгатеннән биш улы булган. Уллары менә ни өчендер орлыксыз. Үрбәтнең беренче ире Илһам хан да варис калдыра алмады. Мөхәммәдәмин дә шул чут. Шуларның кысырлыгы аркасында Үрбәткә дә бала табу, бала сөю, бала багу бәхете тәтемәде.

Нурсолтан ханбикәнең әлеге гаделсезлек белән килешәсе килми. Бәлкем, гаеп хатыннарындадыр?

Акыл белән боларның барысын да кабул итә Үрбәт. Ләкин йөрәк бар бит әле, күңел бар. Ә йөрәкнен Мөхәммәдәминне һич тә үз янынннан жибәрәсе килми.

Мөхәммәдәмин анасына ничек җавап биргәндер, анысы билгесез, тик ул вафат булган хәләл җефете урынына янә дә никахка керергә хокуклы. Мәҗбүри түгел, билгеле, шулай да хокуклы. Ир-атка шунысы да бик

житкән. Нәфес куарга дисәң аларга куш. Нәфес ул тыя алсаң гына юаш, ирек бирсәң, бирән кебек туймас.

Үрбәт иренең җәясен төрлечә тартып карады. Әлегә бернәрсә дә сизелми. Сизелмиме, сиздермиме? Анысын хак Алла үзе генә белә. Өйләнү башына китереп сукса, барыбер үз дигәнен итәчәк, "яшь ханбикәне кабул итәргә хәзерләнегез" генә диячәк. Берни дә кыла алмыйсың, хәзерләнәсең.

Ханәкә көрәшергә карар кылды. Ходай биргән чибәрлеген дә, назъяратуларын да, хәйләләрен дә тозак итеп корды. Хатын-кызның кырык чырасы бар бит аның, берсе сүнсә, икенчесе кабына. Кием-салымын яңартты. Ак түшкә күлмәкләре генә дә дистәгә житте. Чөнки белә, Мөхәммәдәмин ак төс ярата. Урын-җирләрен дә үзгәртте. Охшатсын гына. Сандугачтай сайрый, күгәрчендәй гөрелди. Үзе гүя наз гөленнән яратылган.

Ә эчендә—ут. Нишләргә соң? Яр бирмәк—жан бирмәк, дигән борынгылар. Мөхәммәдәминне ул хатыны булып та, анасы, тутәсе, сеңлесе булып та ярата иде. Мөхәммәдәмин аның сулаган һавасына, эчкән суына әверелгән иде. Шул халәттә ничек кул кушырып утырмак кирәк?

Үрбәт бер көнне наз-сөешүләрнең иң кызган чагында гына:

—Ил теләге—ир, ди, хан, варислар турында да уйларга вакыт житкәндер, мөгаен, чараларын күрергә җыенмыйсыңмы соң?—дип читтән уратып кына әйтеп куйды.

Мөхәммәдәмин бу бүлдерүне өнәмәде, зур учлары белән хатынының авызын каплады.

Үрбәт коелып төште. Әһә. Ошатмады, димәк, күңеленә корт төшкән икән инде моның, дип хөкемен дә чыгарып куйды. Кабат сүз кузгату мәгънәсезлек кенә булыр иде. Нишләмәк кирәк, маңгаеңа язылган язмышны тир белән генә сыпырып төшереп булмый шул. Күрәчәктән качып котылу да юк. Ничекләр яшь кәләшне кияү катына хәзерләп кертерсең? Аның өчен иң авыры шушы булачак. Үзен дә ханның карт хатыннары Жөһдә белән Фатыйма хәзерләгән иде. Ул чагында көндәшләренең нинди хис кичерүе Үрбәтнең уена да кереп карамаган иде. Хәлләре хәл булган икән, бәгырькәйләрнең. Үз башыңа төшкәч кенә беләсең икән.

***

Мөхәммәдәмин хәзер көнен тулысы белән диярлек гаскәриләр янында уздыра. Нижнийга уңышсыз яу чабу аны бик зур борчуга салган иде. Гаскәрне баштан аяк ныгытырга кирәк. Бу, беренче чиратта, казна хәленә бәйле. Казнаны тулыландыру белән даими шөгыльләнү зарур. Дөрес, егерме дүртенче июнь җәнҗалы шактый керем бирде. Ләкин казна төпсез кое кебек ул, күпме салсаң да йота.

Хәрби шура утырышында да сүз казна хәлләреннән башланып китте. Салым җыюны үзгәртеп кору юнәлешендә эш башланган иде инде. Хан тәкъдиме белән литвалылар үрнәгендә, аны җан башыннан җыю мәгъкуль күрелде. Шуның өстенә, эре җир биләүчеләргә, һөнәр остаханәсе тотучыларга, сәүдәгәрләр, зур милекле затларга, мал-мөлкәтләреннән чыгып, өстәмә салым төшерелә. Әлегә яңалык ватык арба шикеллерәк, шыгырдабрак кына бара. Бигрәк тә бәкләр ризасызлык белдерә. Чөнки алар бит әле гаскәр дә тота. Ул гаскәрләр хан карамагында, бәкләр фәкать корал, ат, ашау-эчү, кием-салым һәм башка кирәк-яракка китә торган чыгымнарны гына каплый. Малсыз хуҗалар. Бәкләр ризасызлыкларын ачыктан-ачык күрсәтмиләр, билгеле, эчтән генә мыгырданалар. Ханга баш бирмәү җилгә каршы төкерү белән бер ич инде ул. Төкерегең барыбер үзеңә төшә. Шуңа күрә утырышның бу өлеше шома үтте. Утлы корал мәсьәләсе исә шактый бәхәсләр уятты. Беренче булып

Бураш сәед күтәрелде. Кашлары җыерулы иде мөфтинең. Башта һәммәсен дикъкать белән күзеннән кичерде. Шул кыяфәттә озак кына басып торды.

—Баш өсте, тәкъсыйр, тыңлыйбыз,—дип, хан аңа ярдәмгә ашыкты.

—Утлы корал дигәнегез, шайтан төкереге ул,—диде рухани чәрелдек тавышы белән.—Мөселман өммәтенә караган гаскәргә утлы корал кертү намәхрәм, Аллаһының каргышы төшәр, берүк якын җибәрмән, разыйбәхиллегем юк.

Сүзен әйткәч тә Бураш сәед җыелышучыларны усал карашы аша уздырды, гүя утлы корал төкерегән чәчәргә хәзерләнә иде.

—Нижнийда шушы утлы корал аркасында уңышсызлыкка очрадык, тәкъсыйр, ничек каршы торырга соң аңа?—дип, хан каш астыннан гына мөфтигә карап куйды.

Сәед чатырдай зур чалмалы башын артка чөебрәк уйланып торгандай итте дә, вәкарь белән генә җавабын җиткерде.

—Мөселман орышчысын Аятелкөрси саклый,—диде.—Хикмәт шунда, угланнар догага тартылмый, бөтен бәланың башы шуннан килә.

Сәед тыны кысылудан интегә иде булса кирәк, тукталып калды.

—Хәзерге заман орышында догага гына салышып җиңүгә өмет баглау үзе бер бәла,—дип, яшьләрчә кызу канлылык белән Уйгын бәк мөфтигә каршы төште.—Ходай да сакланганны гына саклармын дигән.

Гадәттә, сәед белән бәхәсләшмиләр. Фикерләре белән килешмәгән очракта да, дәшми калуны мәгъкуль күрәләр. Кем дөрес, кем дөрес түгел ахыр чиктә хан хөкем чыгара. Шуңа күрә баш угланның күтәрелеп бәрелүен бик үк өнәп бетермәделәр. Бигрәк тә Бураш сәед тузынды. Ханнан фатиха да сорап тормыйча, корт чаккандай, урыныннан сикереп торды да, капчык авызыдай киң итәкле җиңнәрен җилфердәтә-җилфердәтә кулларын буташтырып сөйләп китте:

—Коръәнне ватканыгыз җитмәгән, инде изге догаларыбызга кизәнәсезме,—дип кычкырды,—бәланы аны доганы санга сукмау китерә. Кылычларыгыз шуңа тутыга. Кара син аны, углан башы белән ни сөйли бит, ә? Ходайдан куркыр идең, мәлгунь. Әстәгъфирулла, әйттем исә кайттым. Лә иләһә илләлаһуль-халимуль-кәрим.

Уйгын бәк тә үзенекен сөрде.

—Тәрәккыйлек хәл итә бүген орышның язмышын,—дип, башлаган сүзен куәтләде.—Кадими акыл белән ерак бара алмыйсың, заманы ул түгел.

Әйткәләшне хан сүндерде.

—Мөхтәрәм сәедебез мең мәртәбә хаклы. Дога мөселманның байрагы ул,—диде.

Бурашның эре сөякле какча йөзе яктырып китте, бүлмә буйлап җиңүле карашын йөртеп чыкты. Тик ханның сүзе бетмәгән иде әле.

—Баш угланның сүзләрендә дә хаклык бар,—диде ул батырып,—тәрәккыяткә борылыр чак. Моңа кадәр утлы коралга мөнәсәбәтебез тискәре иде. Нижнийга һөҗүмнән соң бу карашыбызның дөреслеккә туры килмәве ачыкланды. Утлы коралга фәкать утлы корал белән генә җавап бирергә мөмкин.

Аңлыйсызмы дигәндәй, хан беравык бүлмәне күзәтеп торды. Шул арада Бураш сәед аклану сүзен кыстырырга өлгереп калды.

—Мин тәрәккыяткә тәхәллеф түгелмен,—диде.

Хан дәвам итте:

—Якын көннәрдә Бөек Литва кенәзлегенә баш углан Уйгын бәк җитәкчелегендә хәрбиләр, илчеләр чыгып китәчәк. Утлы коралны тәрсәнә[2]безгә кертербезме, шуннан соң тәгаенләрбез.

[2] Тәрсәнә — арсенал.

***

Мөхәммәдәминнең яңа никахын Үрбәт кенә түгел, бөтен сарай түземсезлек белән көтә иде. Һәммәсенен үз мәнфәгате. Жөһдә вафатыннан соң, аның вазифалары Фатыйма ханбикәгә күчсә дә, сарайда барыбер Үрбәт сүзе сүз. Иренә таянып, дуамалланып китүе дә бар. Яшь хатын нәфесле, иркә була ул. Авырга туры килмәгәе, дип борчылалар, адәмнең көне адәмнән бит инде ул.

Үрбәт бимазалана, сарай бимазалана, бер Мөхәммәдәмин ваемсыз гына йөри бирә.

Шулай да бер көнне, көтсен дип, Үрбәткә хәбәр салды ул. Ханәкә коелып төште.

Бу синең кара көнең, Үрбәт бикә, хан, ниһаять, үзенең карарын җиткерәчәк, дип тәшвишләнде.

Үрбәт кием-салымын да шушы рәсми вакыйгага туры китереп сайлады. Мөхәммәдәмин моны шундук абайлап алды.

—Аккошыма бүген соры төс кунган икән,—диде ишектән килеп керүгә, күзе үткен иде аның.

—Пакълек булса, аклык була,—дип кинаяләде үз чиратында Үрбәт.

Ханның сакал очлары дулкынланып куйды. Ул елмая иде булса кирәк.

—Ханәкәбезнең йокысы туймаган, ахры,—дип, шаярткандай хатынының беленнән кочып алды.

Шундый якын иде аңа бу куллар. Уф аллам, тиздән алар яшь кәләшнең беленә дә ятачак бит инде. Һай, яман да икән көнченең хәлләре.

—Үзем дә керфек тә какмадым,—диде Мөхәммәдәмин юынган арада.

Үрбәтнең кулындагы сөлгесе төшеп китә язды.

Мөхәммәдәмин аңа сынап карап торды да әйтте:

—Әллә нинди син бүген, бикә,—диде,—үзеңә охшамагансың.

Ханбикә күңелендәгене чиште:

—Синең керфек тә какмавың гаҗәп түгел, хан, үрсәләнер чагың,—диде.

—Әйе,—дип хуплап алды аның сүзләрен Мөхәммәдәмин,—гаскәрне сугышчан хәлгә китерү күп вакыт, күп тырышлык сорый. Иншаллаһ, очына чыгып киләбез инде. Ә керфек какмауның сәбәбе башка, менә тыңлап кара әле, охшатырсың микән?

Мөхәммәдәмин куеныннан бер кәгазь кисәге тартып чыгарды. Аны учлары белән сыпыра-сыпыра ипләп кенә җәйде дә күзләренә якын китерде, карлыкканрак тавыш белән укый башлады.

Мангыт кызы Үрбәтбикә,
Күрсәң күңел куана.
Ак айдайын бите балкый
Күзләр шуңа куана.

Ике кашының карасы,
Бармак басым арасы.
Үрбәтбикәгә тиң булырмы,
Йирдә адәм баласы.

Кондыздайын кара чәче
Тубыгына тик төшә.
Карагаттай кара күзе
Акылларны хуш итә.
Аңа тиң юк матурлыкта
Йирдә адәм баласы.

Ана тиң юк батырлыкта
Йирдә адәм баласы.

Үрбәт башта аңышмый торды. Нинди мангыт кызы? Ә-ә, яшь кәләшен янә Мангыттан сората икән. И, аллам, буталып бетте инде.

—Мактана аласың, ханнан шагыйрь ясадың бит тәки,—диде Мөхәммәдәмин.

Чын күз яшьләре менә шунда килде. Тик бу инде шатлык, куаныч, ярату яшьләре иде.

—Рәхмәт, җанашым, солтаным, хәләлем, бердәнберем, бәгырь ташым,—дип сөйләнә-сөйләнә, үзен-үзе белешмичә сулкылдады бикә.—Мин бит сине яшь кәләшең турында хәбәр җиткерергә кергәнсен дип торам...

Инде Мөхәммәдәмин өнсез калды.

—Иске авыздан яңа сүз, нинди нахак бәла тагасың син миңа, бикә?—дип, гаҗәпсенеп хатынына бакты.

—Сон, Нурсолтан ханбикәнең хаты... Җөһдә...

Үрбәт сүзен очлап чыга алмады, иренең күкрәгенә башын куеп, янә яшьләрен түкте.

—Җүләрем син минем, җүләрем,—дип хатынының аркасыннан сөйде Мөхәммәдәмин.—Берәү гыйшкына төенеп, төн йокламый сөеклесенә атап шигырь чыгара, ә ул аңа яшь кәләш тәкъдим итәргә җыена икән. Борчылма, анаем Нурсолтан бикә бу хакта ничә еллар колак итемне ашый инде. Анысы дөрес. Тик нишлисең, ходай насыйп итмәгән. Югыйсә, матур-матур малайлар бүләк иткән булыр идең...

—Мин алардан да көнләр идем сине,—диде Үрбәт.

***

Мөхәммәдәмин урысларның ишле гаскәр белән Казанга яу чыгулары хакында хәбәрдар иде инде. Мәскәүдә ышанычлы шымчылары бар аның. Бу максатта зур-зур акчалар да тота. Мәгълүмат бик тиз килеп ирешә.

Ул шул көнне гаскәри даирәсен орыш буласы урынга алып чыкты. Шунда киңәш-табыш итештеләр.

Табигатьнең йөзе ачылган чак иде. Алмагачлар шау чәчәктә. Канәферләр дә алардан калышмый, күркә шикелле кабарынганнар. Быел үләннәр куе, тыгыз. Урыны-урыны белән ат бәкәлен капларлык булып киләләр. Тиздән тирә-як аллы-гөлле чәчәкләргә күмелер.

—Болынның карар җире дә калмас инде,—дип авыр сулыш алып куйды Мөхәммәдәмин,—карагыз сана, нинди матур гүзәллек! Кызганыч, орыш белән матурлык тәңгәл килми шул. Ә без җиңәргә тиешбез.—Ул бераз уйланып торды да баш угланга мөрәҗәгать итте: "Уйгын бәк, ничек уйлыйсың, булдыра алырбызмы?"

—Моның башкача булуы мөмкин түгел, галиҗәнап,—диде Уйгын,—чөнки без үз ватаныбызны саклау өчен орышка чыгабыз.

—Бахшы ничек уйлый?—дип сорады Мөхәммәдәмин.

Тимбайның фикере күптәннән әзер иде булса кирәк.

—Күршеләр ярдәменнән башка очлап чыга алмабыз кебек тоела,—диде,—көчләр нисбәте һич тә безнең файдага түгел бит...

—Булмаганны сөйләмә,—диде Мөхәммәдәмин яратмыйча. Чөнки бу аның иң авырткан җире иде.

—Белүемчә, алдан урысларның җәяүле гаскәре килеп җитәчәк. Аларга тын алырга да ирек бирмичә, беренче булып үзебезгә һөҗүм итәргә кирәк,—диде баш углан,—шәһәргә якын җибәрмәскә, алыш-бирешне ялан-кырда хәл кылырга.

—Мин үзем дә шулай уйлыйм,—диде Мөхәммәдәмин,—искәрмәс түмгәк чана аудара, ди. Тик урысларны да акылсызга санарга ярамый. Алар да бит җинәргә дип килә.

Мөхәммәдәмин учын маңгаена терәп, тирә-якны янә җентекләп күзәтеп торды. Ялан киң, атлыларга да, җәяүлеләргә дә урын җитәрлек. Кылычларны уйнатырга менә дигән. Шулай да искәртмәс һөҗүм дә көткән нәтиҗәне бирмәскә мөмкин. Чөнки урыслар сукыр чебендәй ишле. Хәйлә кирәк монда, хәйлә! Дошманны ялгыш юлга кертеп җибәрү зарур.

—Инде мине тынлагыз,—диде ул яугирләрен күзеннән кичереп.—Баш углан тәкъдим иткәнчә, көймәләреннән төшер-төшмәс үк урысларны яуга өстерү отышлы булачак. Максат уптым илаһи ябырылырга ирек бирмичә, дошманны өлешләп-өлешләп кыру. Әлбәттә, хәйләсез дә булмас.

***

Кенәз Димитрий Казанны алуына шик тотмый иде. Тик татар оясына менә шулай, үз утарындагы сыман, бернинди каршылыксыз, юл ачылыр дип көтмәгән иде ул. Әллә берәр чир кырып бетергәнме үзләрен? Бәлкем, җиеләселәрен белеп, качып ук киткәннәрдер? Күр инде, күз күреме җитмәс болын кинлекләрендә ник бер җан иясе күренсен? Уклар, сөңгеләр, кылычлар белән каршы алырлар татарлар, бик аяусыз орыш булыр дип хәзерләнгәннәр иде ич. Ләкин хәрби кеше өчен чын җиңү—көч белән, осталык белән, корал белән җиңгән җиңү. Шуннан да татлырак канәгатьләнү була да алмый орыш кырында.

—Атлы гаскәрнең монда кирәге күренми, кенәз,—диде Димитрий—Жилка Бельскийга,—Мөхәммәдәмин орышсыз гына бирелергә уйлаган, күрәсең. Кызуында эшне бетереп куйыйк соң алайса.

Кенәз Федорның да каны уйнап торган чак, яшь әле. Аның да күңеле ашкына, үзен танытасы килә. Бакырдай җирән мыегының очларын бөтереп куйды да әйтте:

—Уйларыбыз туры килә икән, үзем дә нәкъ шуны тәкъдим итәргә тора идем, өлгерә алмыйча гына калдым,—диде,—тәвәккәллик, кенәз!

—Беренче төркем белән житәкчелек итүне сиңа тапшырам,—диде Димитрий Иванович канәгать кыяфәттә,—тик шуны бел, яхшы татар—үле татар, әсирләр белән мавыкмагыз.

Көймәләр бер-бер артлы ярга борыннарын төртте. Бельский шунда ук кораллыларны тезә барды.

—Ярминкә үчен кайтармыйча кулдан сөңгене төшермәскә!—диде ул фатиха сүзендә.—Без яшь патшабызга җиңү бүләк итү өчен килдек. Тәнре безнең белән!

—Кенәз, ганимәткә күпме вакыт бирелә?—дип сорады Иван исемле шадра сугышчы. Күренеп тора, күпне күргән мут солдат.

—Бер атна,—дип кычкырды Бельский барысына да ишетерлек көр тавыш белән.—Рәхәтләнеп талагыз, кала сезнең карамакта. Тик мал артыннан куып, кызларын буш калдыра күрмәгез. Бик татлы диләр поганкаларны. Ха-ха-ха!

—Борчылма, кенәз, кимен куймабыз,—дип авызын ерды Иван,—шулай бит, егетләр?

—Ура-а-а, ур-а-а...

Бельскийның атын китерделәр. Бик күркәм алмачуар толпар икән. Ашкына, тыныч кына басып та тора алмый. Яу аты икәнлеге маңгаена язылган.

—Быргычы, уйнат быргыңны! Байракларны күтәрегез!—дигән әмер яңгырады.

Мөхәммәдәмин Кремль тавындагы яшерен сыргавылыннан урысларны күзәтеп торды. Яу зилзиләсен үзе тәгаенләгәнчә тагын бер мәртәбә күңеленнән кичерде. Әлегә ул канәгать иде. Ник дисәң, урыс черчетын[3] һөҗүмгә өстерергә туры килмәде, алар, әнә, капкын эчендәге икмәк кисәгенә алданган күсе шикелле үз ирекләре белән аның хәйлә капчыгына ябырылдылар.

—Ашыкма, көймәләрдән төшеп беткәннәрен көт,—диде ул янындагы Мансур угланга.

Тыныч бул дип әйтүе генә ансат, йөрәге, әнә, күкрәген ватып чыгардай булып тибә. Ана чирүе янында булырга кирәк, ә хан һаман җибәрми.

—Хан, мин үземне утлы табадагы кебек хис итәм,—диде ул йөзенә ялыну-ялбарулы кыяфәт чыгарып.

—Урысларны озаграк тоткарларга тырыш, ләкин чамасын белеп кенә, җиндек дип уйласыннар. Хәйләбезнең асылы шунда,—дип, Мөхәммәдәмин янә бер мәртәбә угланны кисәтте.

—Барысы да тәгаенләгәнчә булыр, галиҗәнап.

Ниһаять, гаскәр яшеренгән урыннан чыкты. Урыслар моны көтмиләр иде инде, каушап калдылар. Ләкин артта Идел, чигенергә юл юк. Орыш шулай, көтелсә дә, көтелмәгәнчә башланды. Китте кычкырыш, китте бакырыш. Сөңгеләр, кылычлар ялык-йолык килә. Күзләрне кан басты, күңелләр катты. Кан исе, үлем исе таралды.

Шадра Иван, гүя базардагы итче, турый гына. Зур, калын гәүдәсе әле монда, әле тегендә пәйда була. Тәм табып, ләззәтләнеп кизәнә.

—Мә, поганый, ал кирәгенне!

—Күреп кал, менә мин ул синең Газраилең. И-их!

Мансур углан шадра сугышчының ду галәмәт килеп, уңлы-сунлы татарларны кыруын күреп алды да, Батырша яугирны чакырып алды.

—Бер кәфер котырына анда, бар хәл ит,—диде.

Батырша җан кыючыны эзләп китте. Үзе дә гәүдәле егет. Җиргә нык басып йөри торганнардан. Ике баһадир көч сынашырга тотынды. Ә көчләр тигез. Әле Батырша өстен чыга, әле Иван куып алып китә. Иванга уңайрак, сөңгесенең сабы озын, якын җибәрми. Йөзләреннән тир ага, күзләренә керә. Үзләре аны сизми. Газраил якаңнан каптырырга торганда тир кайгысымы соң?

Бер ыргымда Батырша артка чигенгән атлы булды да, бөтен житезлеген, бар көч-куәтен җыеп, көндәшенә ыргылды. Иванның сөңгесе бик азга гына соңгарак калып сузылды. Алар күкрәккә күкрәк очрашты. Батыршаның борынына сасы ис бәреп керде. Күрәсең, урыс ару гына төягән иде. Күз иярмәс тизлек белән ул сөңгесен кылычка алыштырды да шадраның муенын сызып узды. Икенче мизгелдә Иванның канлы башы гәүдәсеннән аерылды. Казан кызларын татый алмады тәки. Ана хәзер ганимәт тә кирәкми иде инде.

Урыс яугирләре арткannан-арта бара, алар тулысы белән орыш кырында иде инде. Җилкага тәүге хәбәр дә килеп ирешге. Чапкын орышның уңышлы башланып китүе, тиздән гаскәрнең шәһәр бистәсенә аяк басачагы турында кенәз Бельскийның белдермәсен житкерде. Чираттагысы орышның бистә эчендә барганлыгын хәбәр итте.

Кенәз Димитрий бала йонынnан гына торган кыска сакал-мыегын бармаклары белән тарагандай итте. Ул үз-үзеннән дә, гаскәреннән дә канәгать иде.

—Шәраб салыгыз,—диде адъютантларына,—бар кешегә дә. "Минем тәүге җиңүем өчен!" тост тәкъдим итәм.

[3] Черчет – яу.

Чыннан да, бу чакта урыслар бистәгә бәреп кергәннәр иде. Казанлылар каршылык күрсәтмичә генә чигенеп, юкка чыктылар.

—Ганимәт, ганимәт!—дип аваз салды кемдер.

Гаскәр ач кандала шикелле өйләргә ябырылды. Күп тә үтмәде, урыслар шатланышып, ава-түнә йөриләр иде инде.

—Бистә халкын талыйлар, ә без посып ятабыз. Хурлык ич бу,—дип зарланышты яугирләр.

—Урыслар безне качтылар дип уйласын өчен бу,—дип хәйләне ачты Мансур углан,—тиздән йөзгә-йөз киләчәкбез, батырлыгыгызны шунда күрсәтерсез.

Мөхәммәдәмин үзе дә орыш казанының кайнау ноктасына килеп житкәнен аңлаган иде инде. Урысларның калага үтеп керүләре дә ихтимал.

—Уйгын угланга хәбәр салыгыз, төмәнен кузгатсын,—диде ул.

Планы гади дә, заманча яңа да иде ханның. Дөрестән дә, дошманны камап алу, сиздермичә генә аны үз ихтыяҗына буйсындыру, орышны башыннан ахырынача тәфсилләп күзаллау бу чор стратегиясендә өлеш-өлеш кенә кулланыла иде. Мөхәммәдәмин исә аны бербөтен итеп гамәлгә ашырды.

Мансур угланның чирүе алдавыч кына иде. Баш углан Уйгын житәкчелегендәге төп көч урысларның арт ягындагы аулак урында тупланган иде. Хан шуларны орышка кертергә әмер бирде.

Урыслар җиңү шәрабы эчеп хозурланган бер мәлдә, Уйгынның атлы төмәне аларның арка якларына китереп бәрде. Бу шул кадәр көтелмәгән һөҗүм иде ки, Бельский билендәге кылычын суырып алырга да өлгермәде, алмачуарның тезгене татар угланы кулына күчкән иде инде. Ул чарасызлыктан, гарьлегеннән нишләргә белмичә ач бүредәй улады:

—У-у-ух...

Ул арада чаптырып Уйгын килеп житте. Бельскийны аның каршысына китереп бастырдылар.

—Кенәз, мин сине Барча Казан жиренең бөек ханы Мөхәммәдәмин исеменнән әсирлеккә алам,—диде баш углан,—гаскәрбашын да шушы язмыш көтә.

Ләкин Димитрийны орыш кырыннан алып чыгып киткәннәр иде.

Воевода юлдагы атлылар төркемен Зөя елгасы тамагында көтәргә булды. Нишләргә белер ул хәзер. Үчен бише белән кайтарыр. Ә монысы вакытлы күңелсезлек кенә. Андый хәлләр була инде ул. Олуг кенәзгә хәбәр салырга кирәк, өстәмә көчләр дә җибәрсен.

Ул кенәз Василий Голенинны депеша белән җибәрде. Чапкын 9 июньдә Мәскәүгә кайтып егылды, олуг кенәзгә Казан хәлләрен, куе буяуларга манып, бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Имеш, Мөхәммәдәминнең дә гаскәре йөз меңле икән. Нугайлар, себерлеләр дә ярдәмгә килгән икән. Имеш, һөҗүмне дә татарлар башлаган, атлы гаскәрне көтәргә ирек бирмәгәннәр.

Әлеге мәгълүматлар Василийның бер колагына керде, икенчесеннән чыгып китте. Аның өчен капманиянең уңышлы тәгәлләнүе мөһим. Кемнәр әсир төшкән, күпме сугышчы башын салган—бу аның эше түгел. Гаскәрбашы бар, ярдәмчеләре, карасыннар. Аңа фәкать җиңү генә кирәк. Шуна күрә кичекмәстән үзенең шәхси карамагындагы сайланма гаскәрне Димитрийга ярдәмгә җибәрергә карар кылды. Кенәз Василий Холмскийны чакыртып, бик нык кисәтте.

—Миңа Мөхәммәдәмин ханны тотып алып кайтыгыз,—диде үтә бер кырыслык белән,—Ак күлдә аңа урын әзер инде.

***

Йәликәй карт балыкны Тарлаш кичүеннән түбәндәрәк тота. Монда җәтмә салырга бик унай. Идел бу урында агымын тизләтә төшә. Шуна күрә, ахры, төбе чиста, төп-тамырлар да, агач-ташлар да бимазаламый. Коралга зыян тими. Балык, Аллага шөкер, күп, тота гына бел. Йәликәйне бу яктан өйрәтәсе юк, нәсел-ырулары белән балыкчы алар. Хан табынына да балыкны ул җибәрә. Йәликәй балыгы үзенә бер тәмле була, дип әйтә икән хан, рәхмәт төшкере.

Хан җәенгә мөкиббән, һаман шуны сората. Тик зурысы булсын. Ә олы җәенне кармакка каптырырга кирәк, җәтмәгә эләкми ул, эләксә дә ертып чыга. Чос балык. Теләсә-нинди җимгә ыргылмый, сайланып кына сыйлана, каһәр. Ана кош ите бир. Анын да ис керә башлаганы булсын.

Карт балыкка оныгы Хәмәтшәехне да алып йөри, өйрәнә торсын, ди. Малай ушлы. Әйткәнне бик тиз эләктереп ала. Кайсы балыкнын өстә йөргәнен, кайсысынын төптә ятканын, кай яктан җил искәндә балык киткәнен, уылдык чәчү чорларын—барысын да яттан белә. Җиде генә яшь бит әле ана. Хәер, заманасы шулай, яшьләр белән ярыша алмыйсын. Әнә, кичә ханнын ашчысы сөйләп торды, кайсыдыр мәмләкәттә утлы корал уйлап тапканнар, имеш. Үзе иләмсез шартлый, ди. Тавышыннан йөрәкләре ярылып үлүчеләр бихисап икән. Тимерне ярмага әйләндерә, ди. Тисә, кара канга батыра икән. Шул коралны урыслар да эләктергән, ди. Угланнар бик куркып торалар, имеш. Урыслар белән бик зур орыш буласы икән.

—Бабакай, кармагын өч мәртәбә этләде бит инде, әллә күрмисенме?—дип, Хәмәтшәех аны уйларыннан арындырды. Җәт-җәт кармак җебен саварга тотынды Йәликәй. Ләкин җәеннен дә алданасы килеп тормый шул, күгәрченне эләктереп шылган, әнә.

—Җимне әрәм иттен,—дип уфтанды малай.

—Чәпчемә сәнә, юеш борын, кош буа буарлык, тагын ауларсын,—диде карт тешсез авызын шапылдатып.

—Һы, тапты ялчы,—диде малай эре генә,—әллә кулы кычытып тора дисенме?

Алар берара сүзсез генә утырдылар. Тынлыкны янә Хәмәтшәех бозды.

—Бабакай, карале, кара, су өстендә әллә нинди кара нәмәстәләр,—дип, Иделгә төртеп күрсәтте.

Чыннан да, су өстен тутырып, агач төпләренә охшаш нәрсәләр ага иде. Карт кулын маңгаена куеп, шул тарафка чекерәйде. Күзләре кояшка чагылу сәбәпле, ул нәрсә акканын анык кына күрә алмады. Яшьләре дә комачаулый.

—Бүрәнәдер,—диде карт.

—Бабакай, бүрәнә түгел алар,—диде Хәмәтшәех. Малайнын күзләре үткенрәк иде, билгеле.

—Тарлаш тамагындагы урманга төштеләр микәнни?—дип гөманлады карт.

—Кеше гәүдәләре бугай, бабакай...

—Юкны сөйләмә, юеш борын, шул каләр кеше гәүдәсе каян килсен?

Карт, ниһаять, күзләренен җаен тапты. Казан тирәсендә орыш кузгалган икән, дип уйлап алды, җәт-җәт кенә кармакларын урый башлады.

—Улым, әйдә, җыен, өйгә кайтыйк, Аллам сакласын!

Бу вакытта Казан каласы итәгендә өченче көн дәһшәтле сугыш бара иде. Ул кенәз Александр Ростовский, Касыйм ханзадәсе Җангали җитәкчелегендәге атлы гаскәр килеп җитүгә кабынып китте.

—Холмскийны көтсәк, ышанычлырак булмасмы?—дигән теләк белдерде Ростовский,—олуг кенәзнен гаскәрендә утлы корал да бар.

—Холмский иң хәлиткеч этапта, Кремльне алу этабында гына кирәк булачак. Ул килеп җиткәнче бетерәсе эшләр дә күп әле,—диде гаскәрбашы.

—Минем бөркетләрнең түземлекләре төкәнде анда, тыяр хәл калмады,— дип сүзгә кушылды Җангали.—Ул Казан калай әтәчләренең кикрикләрен шиңдерергә бик вакыт.

—Күрдеңме,—дип эләктереп алды шаһзадәнең сүзен Димитрий,—татарлар үзләре казанлыларны куралмый. Кан кайтару өчен менә дигән форсат.

Мөхәммәдәмин сыргавылыннан урыс гаскәрләренең хәрәкәт-гамәлләрен җентекләп күзәтеп торды. Яшерен ирәвелгә[4] җибәрелгән унлыкбаштан да чапкыннар эз суытмый.

—Урыслар нишләптер песи булдылар, бу һич тә аларга охшамаган,—диде чираттагы чапкын,—астан уеп, өстән җуеп куймагайлары.

Мөхәммәдәминнең киң маңгаена сырлар ятты: димәк, һөҗүмгә хәзерләнәләр. Ул үзе дә шуңа исәп тота иде. Чөнки кенәз Димитрий яшь кеше, аның озын-озак көтәргә түземлеге җитмәс, тизрәк орышка ыргыласы килер.

Бу юлы Уйгын яугирләрен үзәккә куйды хан. Ябырылып килүче урыс атлыларының арасына чөй кебек ярып кереп, аларны төркем-төркем таркату бурычы куелды баш угланга. Ә ян-яктагылар ул төркемнәрне камап алырга тиеш иде. Мондый күпсанлы гаскәр катнашындагы орышта фәкать хәйлә һәм житезлек белән генә җиңүгә ирешергә мөмкин.

Димитрий исә өметен ишлелеккә баглый иде. Яу булып өерелеп килергә дә, тын алырга да ирек бирмичә, дошманны изеп-таптап китәргә. Монголлар шул рәвешле, әнә, ничәмә-ничә мәмләкәтне, ничәмә-ничә халыкларны тәпәләп узганнар, үзләренә буйсындырганнар. Рим шул ысул белән бөек Карфагенны тезләндергән, Мисырны, Урта диңгез буе биләмәләрен кулына төшергән. Аттила җиһангир Уралдан Ауропага кадәр кылычын ялтыратып узган.

Мөгаллиме, мәшһүр Византия императоры ыруы вәкиленнән булган синьор Константин колагына тукыганнарны бөртекләп хәтер иләге аша уздыргач килде әлеге нәтиҗәгә Жилка. Китапча фикер йөрткәндә, бу чыннан да бик төпле, бик шома тәгълимат иде. Ул, һичшиксез, яшь воеводага дан, җиңү китерәчәк.

Ростовский әлеге тираданы тыныч кына йотты. Сүз көрәштерүдән ни файда, ул барыбер үзенчә эш итәчәк. Җангали шаһзадә исә эре тешләрен ыржайтып елмайды. Воеводаның дуамаллыгы охшый иде аңа. Чөнки ул үзе дә яшь кеше, ул да бөеклеккә дәгъвә итүче.

Орыш иртә белән башланды. Җилсез, дымык иртә иде бу. Идел өсте тип-тигез. Ара-тирә вак балык артыннан куучы чуртаннар гына, чупыр-чупыр килеп, суны болгатып алалар. Мул булып чык төшкән, ярдагы үләннәр ямь-яшел булып яшәреп утыралар.

Ослан тавы түбәсеннән кояш елмаеп балкыганда да тыныч иде әле. Ул бүген үзгәрәк күренә. Ни өчендер шәфәкъ кызыллыгы бик тиз бетте, анын урынына кояшның як-ягында ак колакчыннары бар иде. Моны коры, кызу көнгә юрадылар.

Кинәт кенә офык караңгыланып китте. Җиһан берьюлы дөпелдәгән меңнәрчә тояк тавышы эчендә калды. Бу шул кадәр көчле иде ки, хәтта җир гүли башлады. Шом өстенә шом өстәп, кешеләр кычкырыша, атлар кешни. Һавада әле чыкмаган кан исе асылынып тора. Ахырызаман диярсең.

Урыс явы менә шулай котырынып килде.

[4] Ирәвел — разведка.

Уйгын бер талпынуда иярендә иде инде. Яңа сауган сөт шикелле ап-ак толпары өстендә ул әүлия затны хәтерләтә иде.

—Атларга менегез!—дигән әмер яңгырады.

Иң алда—Олуг Мөхәммәдтән калган кыл байракны тоткан яугир. Аннан аз гына калышып, хан байракларын йөртүчеләр урын алды.

—Тезгеннәрне бушатыгыз!

Атлар бер тын белән дәррәү килеп кузгалдылар. Тояк астыннан кыелган үләннәр оча, кибеп бетмәгән чык тамчылары чәчри. Бер якта татарлар, икенче якта—урыслар. Татарлар үз йортларының иминлеген саклау өчен күтәрелсә, урыслар Казан иленә коллык тышавы салырга, антихристларны буйсындырырга килгән. Бу—изге гамәл. Шуна күрә берәве дә башын аямый, һәркайсы үзен хаклы дип саный. Орыш мәрхәмәтсез, рәхимсез булачак.

Инде кояш та күренмәс булды. Ә ара якынлашканнан-якынлаша. Әнә, атларның мышлавы да ишетелә башлады, тир исе борынга килеп бәрелде.

—Көферләргә—үлем!

—Бей, поганых!

Гарасат кузгаткан дулкынны тыеп булмаган кебек, бу өерне дә туктатыр көч юк иде инде. Бәгырьләр катты, хисләр качты. Башта бер генә уй: ялмавызыннан өстен чыгу.

Гаскәр маңгайга-маңгай бәрелешә. Кылычларга, сөңгеләргә тәүге кан ябышты. Буталышып беттеләр, кемнең кайда икәнлеген дә белеп булмый. Дошман атчабарлары эченә чөй булып керү, аны төркемнәргә бүлү планы да орышның башында ук челпәрәмә килде. Урыслар сукыр чебен кебек ишле иде.

Уйгынның ак аты Чыңгыз ханның Сәтәре шикелле әле бер җирдә, әле икенче җирдә калкып чыга, үзе күз иярмәс җитезлек белән сөңгесен уйната.

Мөхәммәдәмин сыргавылына ябышып катты, керфекләрен дә какмыйча орыш кырын күзәтә.

—Кенәзне сөңге очына ал, кенәзне!—дип кычкырып җибәрде ул берзаман, әйтерсең лә, аның сүзләре шунда кадәр барып җитә иде. Ни сәер, баш углан әлеге күрсәтмәне ишеткәндәй, Ростовскийга якынлашу хәстәренә кереште. Воеводаны сафтан чыгару бик ярап куяр иде, әлбәттә. Башсыз калган гаскәр койрыгы өзелгән кәлтә белән бер ул, качу ягын карый.

Җан сакчылары кенәзне нык саклыйлар, якын килергә ирек бирмиләр, чынлыкта ул җанлы бөҗра эчендә. Шунлыктан, иң элек сакны какшату зарур. Уйгын бу эшне якыннарына тапшырып, үзе кенәзне сагалый башлады. Һәм җаен туры китереп, Ростовскийга сөңгесен очырды. Кенәз шул ук мизгелдә аяк астына мәтәлеп тә төште.

—Егет икәнсең, булдырдың,—дип, Мөхәммәдәмин баскан урынында сикергәләп куйды.

Уйгын, ниһаять, урысларның зур гына төркемен Идел буена кысрыклады. Һәммәсен кылыч астыннан үткәрделәр, берәү дә котылып кала алмады. Менә шуннан соң китте инде мәхшәр. Урыслар тәртипсез рәвештә чигенә башладылар. Ә чигенер урын юк. Чөнки арка ягыннан хан гаскәрләре килеп керде. Чолганышта калдылар. Ары сугылалар, бире сугылалар, тик кайсы якка гына сугылма, угланнарның сөңгесенә килеп төртеләсең.

Үтереш, суеш туктаусыз өч тәүлек дәвам итте. Холмский бу ызгыш табынының соңына гына килеп житте. Аны килә-килешкә утлы коралы-ние белән капкынга эләктерделәр, әсир төшкәнен дә абайламыйча калды кенәз.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# ЕЛЛАР. ГАИЛӘЛӘР. ЯЗМЫШЛАР...



*Р. Фәхретдин гаиләсе белән. Сулдан уңга: Нурҗамал, Зәйнәб, Габдеррәшид (утырган), Габдрахман, Риза Фәхретдин, Габделәхәд. Уфа, 1897 ел.*



*Казан зыялыларыннан берсе Локман Арсланов үзенең җәмәгате белән. 1913 ел.*



*Ә. Мәңгәр һәм Гайшә ханым кызлары Сафия белән. Тәнзин. 1938 ел.*
*Мәңгәр Әхмәтвәли Ибраһим улы (1891—1978)—эре сәүдәгәр, эшмәкәр һәм җәмәгать эшлеклесе. Үткән гасырның 50 нче елларында Төркиядә "Казан" журналын нәшер итә, ул шулай ук татар халкының милли-мәдәни мирасын барлауга юнәлтелгән "Мәңгәр фонды"н оештырган шәхес тә.*



*Закир Рәмиев (алдагы рәттә, уңнан беренче), Садрый Максуди (аның артында) һәм аларның кайбер гаилә әгъзалары. 1914 ел. Бельгия. Льеж шәһәре.*



*Язучы, тәрҗемәче Сәрвәр Әдһәмова (1901—78) улы Тансык белән. Нәҗметдинов Тансык Кави улы (1927—2008)— галим-физик. Озак еллар Казан университетында эшләде. 1928 елда төшерелгән рәсем.*



*Драматург Мирхәйдәр Фәйзи (1891—1928; туганнары арасында өстә, уң яктан икенче). 1927 ел.*



Айрат
Суфиянов

# КИЕРЕНКЕ КЫЛЫ КҮҢЕЛНЕҢ...

## Сагынам

Мәңгелек өчен гасыр да—
Түгел мизгелдән артык...
Кагылмый аңа, янамый
Безне йотачак вакыт.

Аңлап, тантана итәме
Мәңгелек бездән көлеп?
Әллә соң ул битарафмы?
Йөз сорауны бер җавапсыз
Тилмертә билгесезлек,
Кайчандыр кочкан шикелле
Безне дә үлемсезлек.
... Тагын тузанга батабыз
Акланыр өчен килеп.

Мәңгелек өчен гасыр да
Бары бер мизгел генә.
Ачмый үз серен чиксезлек
Кешенең гомеренә.
Тән–читлеккә сыйган җанның
Карамый гозеренә.

... Бер көнем юк, мизгелем юк
Күкләрне юксынмаган.
Җанның халәтен сагынам—
Вакытка буйсынмаган...

* * *

Өзелергә житеп чыңлаганда
Киеренке кылы күңелнең,
Җиргә, күккә, бөтен тереклеккә
Гашыйк кеше, юк, мин түгелмен.

Ул көчлерәк, түземлерәк миннән,
Миһербанлы, сабыр, акыллы:
Кешелекнең киләчәген күрә
Корт төшмәгән алма аркылы.

**Хак Тәгалә аның калебенә**
**Ирештергән шигырь–доганы.**
**Армый–талмый ул укырга тели**
**Яңгыратып бөтен дөньяны.**

**Сагынса да башка бер үлчәмдә**
**Камиллекне күргән халәтен,**
**Ул ышана: фани дөньяга да**
**Кирәктер, дип, минем сәләтем.**

**Сүзләрдән ул тере чәчәк чигә –**
**Үлемсезлек белән кавышкан...**
**Аңа карап, ак көнләшү юллап,**
**Көн елмая татлы сагыштан...**

**Өзелергә җитеп чыңлаганда**
**Җиде кылы моңлы күңелнең,**
**Туган якны җәйгор[1] нуры чәчеп**
**Кочкан кеше—ул мин түгелмен...**

* * *

**Мин төш күрәм... Сулар һавам беткән,**
**Корыч кыршау кыса муенны.**
**Кор–кор килеп кара козгын чукый**
**Ирекләмен дигән уемны.**
**Төшемне дә билэп алды инде,**
**Ах, язмышның хәтәр уены...**

**Мин төш күрәм... Эчәр суым кипкән.**
**Тирә–якта дошман яулары.**
**Түбәнәеп, мескенләнеп калган**
**Туган якның текә таулары.**
**Сына язып, җиргә башын бәреп,**
**Сандугачсыз елый таллары.**

**Мин төш күрәм... Басар җирем тапмыйм.**
**Үзем бармын... әллә, юкмын да?**
**Сөрән сала заман: и, кешеләр,**
**Коткарыгыз, очам упкынга.**

**Дертләп китәм, уяндыммы икән?..**
**Аңларлык та хәлдә түгелмен.**
**Акылыннан язган кәккүк кебек**
**Төшендә дә әллә өнен күреп,**
**Әй кычкырды ярсып күңелем.**

**...Акылыннан язып, саташыпмы,**
**Шул ук төндә кәккүк кычкырды.**
**Нәрсәгә соң юрыйм икән диеп,**
**Хәвефләнеп, кара кулмәк киеп,**
**Күк астында гүя чор торды...**

[1] Җәйгор – салават күпере.

* * *

Давыл сукты... гүя набат,
Күккә карап соңгы кабат
Талпынды да сынды нарат.
Туфрак дымын сулап,
Белмим, нәрсә уйлап,
Ыңгырашты тамыр...
Өскә чыкса? Ничек
Булган кодрәтенең
Какшаганын таныр?..
Җансызлыкның тәнен
Кортлар җиңел ертып,
Үзәккә юл тотып,
Татып аның тәмен,
Таралырлар—артып,—
Шул төбәкнең ямен,
Гамен аска тартып...

Давыл сукты... гүя набат,
Күккә карап, соңгы кабат
Талпынды да сынды нарат.
Кояш сүнде, баеп...
Хыял—колын—ал таң
Тояклары таеп,
Өзгәләнде кинәт.
Ирененең бер як чите белән
Төн колагын тешләп
Йоклап китте һәм төшендә күрде:
Нарат исән иде...
Җил дә исә иде
Кояш чыккан яктан.
Әйтерсең лә тормыш
Яңа учак яккан...

## Кемгә соң сайрап дәшим?

Мин адаштым... шуңамы чор
Адашты, юлдан язды?!...
Сагынып кайткан сандугач та
Таный алмады язны.

Сайрый—сайрый гөлгә кунды.
Гөл иссез, төссез иде.
Матурлыктан җәяү качкан
Кешеләр хиссез иде.

Тәүге тапкыр моңы белән
Сандугач көчсез иде.
Битарафлык тырнагында
Аңа күңелсез иде.

Тукталды да сайравыннан
Утырды ямансулап.
Язны таный алмаганга
Сыгылып, авыр сулап.

Гөл бөгелде, гөл таҗларын
Тарталар кортлар аска.
Кайгы булып замананың
Җилләре баса башка.

Шуңамы соң, сандугачым,
Сагышка сарылгансың,
Үзең алдан тойгангамы
Йөрәгең ярыласын?!.

Татлы түгел, ачы түгел
Күземнән тамган яшем.
Аңлый алмыйм, әллә күптән
Мин шундый хәлдә яшим?

Кемгә соң сайрап дәшим?..

**Редакциядән:**
*Чаллыда яшәүче шагыйрь Айрат Суфияновка 50 яшь тулды. Каләмдәшебезгә яңа иҗат уңышлары телибез.*

*Хикәяләр конкурсына*

Мәгъсум Хуҗин

## ИПИ. КОЛЫН. БЕЗ.

КҮРШЕМ ХИКӘЯСЕ

Әни келәттән вак иләкне алып керергә кушты. Мин кабаланып чыгарга барганда:

—Эресе дә кирәк икән, улым Гәрәйхан,—диде.—Жилпучка чыкканда, иләкләр дә кирәген оныткганмын лабаса, улыкаем. Әниеннен хәтере нәп-нәкъ тишек иләк, име, кызым Сәгадәт.—Сенлем бу гыйбарәнен мәгънәсенә төшенмәде, әнигә җавап кайтармады. Моны аңлатуны мина кушуы икән әнинен, кайбер эшләрне читләтеп йөкләргә оста ул. Ә сенлемнен мондый, әни әйткәнчә, йомры фикерләрне ишетә торуы хәер.—Гәрәйхан, улым, иләкләрне он лары эченә элеп куйган. И-и, үзең дә беләсен лә моны. Сәгадәт, кызым, әллә абыеңа булышасыңмы сон?

Сенлем сәке йөзлегеннән шуып кына төште дә мина тотынды, житәкләшеп йөрергә ярата, бәләкәй шул, өч яше дә тулмаган.

Беләм инде, безгә эш табу өчен генә иләкләрне "оныткан" әни. Бер нәрсәне дә онытмый ул, үзе әйткәнчә, хәтере чуендай нык анын, мина, хәтереңне йокы чүлмәге итмә, улым, Гәрәйхан, дип кисәткәли.

Сенлем Сәгадәт вак иләкне алып бирүгә өйгә йөгереп кереп тә китте. Мин өйалдыбызның дәвамы итеп урталай ярылган бүрәнәләрдән (әти шулай дия иде) салынган келәтебездә вак-төякне җайлап матавыкландым (монысы—әни сүзе), шуңа күрә әни:

—Син йомыш-юлга жәһәт ич, улым, хәзер нигәдер озакладын,—дип каршылады, матавыклануны әйтмәде.—Йә, ярар, ашыкмыйк, жае-чираты белән барысына да өлгерербез, Аллаһы боерса.

—Әни, дим, келәтнен богау йозагы күгәргән бугай.

—Шулайдыр, улым, шулайдыр. Әтиегез сәфәргә киткәннән бирле онытылмасынга гына ачабыз ич келәтне.

Әни сүзләре арасына кыстырып: "Кайтмый да кайтмый әти сәфәреннән. Берсекөнгә ел тула киткәненә".—димәкче идем, моны әни үзе үк санавын искәреп, тыелдым. Озаклавым сәбәбен келәт халләре белән аңлатып бетердем.

—Бизмәнебез лар өстендә яткан, шуны калакка элгәндә, зур лар почмагына бәрелде дә и-и шыңлады инде ларыбыз!

—Әйе, улым Гәрәйхан, әйе. Ике ларыбыз да буп-буш. Тик мондый чакта, шыңгырады, диген, яме. Тавышы кайтып ишетелгәндер, кайтаваз булып, дим.

—Шынгырады. Лар шынгырады.

—Менә дөрес.

Әни он иләргә һаман җыена гына әле, ә оны һаман күренми. Җилпучка эре иләкне куйды, вак иләк, тузанын кече яктагы чипәккә каккач һәм сөрткәч, җилпучка терәлеп эшсез калачак икән.

Оны кайда соң?

Әни алъяпкычы күкрәгеннән бәләкәй ак төенчек алды. Ерак басуларга утауга һәм уракка барганда, әни төш турысында ашарга дигән ризыгын, һәм яртылы шешәдәге чөгендер чәен дә, баш-башларын яшелдән үзе чиккән тар һәм кыска шушы һәрчак ап-ак тастымалга төрә иде.

Әни онны акрын или. Элегрәк иләкне җәһәт биетә иде ул, карап-соклanып торуы ук сөенеч иде.

Оны иләк төбеннән җилпучка коелып бетсә ярый ла, онның бер генә бөртеге дә көрпә арасында посып кысыла күрмәсен.

Сеңлем белән мин әнинең сөенә-шатлана он иләвен сәке йөзлегендә карап утырабыз, Сәгадәт куеныма сеңгән, шулай олы итә ул мине, ә күзләрен салмак биюче иләктән алмый.

Әни онны эре иләккә салды, тастымалны онның бөртеген дә калдырмыйча какты, шулай да иләкнең төбе генә капланды диярлек. Эре иләктә иләгәнгәдер, көрпәсе минем учымны да тутырмаслык иде.

Кинәт әни:

—Зиһенем чуалды, әй. Күмәч пешергәндәгечә вагында иләмәкче икәнмен,—диде, болары безгә—балаларына атап әйтүе түгел, үзалдына сөйләнүе иде бугай.—Онны вак иләктә иләр чакмы соң...—Безгә таба борылды да миңа төбәлеп өстәде:—Балакайларым, вак иләкне дә алып кереп дөрес иттек. Анысының да барлыгын онытырга ярамый.

Әни тагын безгә таба борылды да:

—Карлыгачларым сез минем,—диде. Кабат борылганда:—Сандугачларым сез минем,—дип иркәләде.

Бераздан без әнинең бәхет һәм оҗмах кошларына, саваплы җимешләренә, ышанычлы таянычларына һәм тагын, тагын әллә кемнәренә, әкияти игелек иясләренә әйләндек тә куйдык. Әлегә без белеп, тирәнтен аңлап житкермәгән сүзләрне табып кына торды әни. Тапмаска ди, безнең әни ич ул. Сеңлем әни сүзләрен аңына тезеп бара булыр, аңламаганнарын миннән йә әнинең үзеннән сорый ул аннары.

Әни йөзен бездән кинәт яшерде дә, башын иярәк төшеп, күзләрен җиңнәренә сөртте. Әллә тирләгән инде, юктыр, тирләсә маңгаен да сөртер иде, маңгайга тир алдарак та чыгучан. Елыймы әллә? Әнә, ак күлмәге җиңнәренә юеш таплар сыланган. Әтидән башка тормыш алып баруы авыр шул әнигә, ә әти сәфәрендә озаклады, китүенә ел тула, һаман кайтмый.

—Әни!—дип кычкырып җибәрдем мин.

—Юк, юк, өлкәнем, еламыйм мин, еламыйм, күзләрем талып китте. Ипекәй пешерәбез ич, андый чакта...—Әни, тукталып торгач:—гел ихластан иң азы көлемсерәргә кирәк. Ихластан,—дип кабатлады һәм безгә балкып елмайды.—Сүнмәс кояшларым сез минем, әтиегез белән минем.

—Әни!—дип кабатлап кычкырдым мин, сеңлем Сәгадәтне, әни янына җибәрмәс өчен, куеныма ныграк итеп кыстым.

Ишек шакыдылар, бала кешедер, кыңгырауга басарга буе житмидер, шуна күрә кемлеген сорамадым. Анда озын ук гәүдәле, ыспай киенгән, дулкынлы кап-кара чәчләрен ипле тараган, өлкән үк яшьтәге абзый-бабай басып тора иде.

—Исәнмесез,—диде ул, дәү кулларын (күп эш башкарганнардыр алар) күкрәгенә кушырды.

—Әйбәт үк!—Шәп иде, тик минә сез кулыма алган каләмемне төшердегез, дип сөмсер кою килешми ич.—Керегез.

—Бик теләп керәм. Ачык чырай белән каршылавыгызга рәхмәт. Сезгә зур йомышым төште минем.

—Үтәргә көчемнән килсә.

—Килә!—Калын ук тавышлы икән. Сөйләвендә сәеррәк галәте барлыгы шунда ук сизелде, мона мин шул көнне кат-кат игътибар иттем—бер җөмләсендә тавышын тамак төбеннән тартып чыгара, икенчесендә талып җырлагандай кебек.—Пинжәкне элергә үреләсе юк икән, чөйләрегез ишек төбендә үк,—диде ул, монысы инде йомшак көйле тавыш иде.—Аяктан сандалларны салабыз.

—Әлбәттә! Хәзер чәй куям. Өйдә үзем генә, балалар эштә, хатыным авылдан иртәгә кайта.

—Кирәкми чәй!

—Мәй юк.

—Мин ул зәхмәтле нәмәстәкәйне гомеремдә ялгышып та авызыма якынайтмадым!

—Минем авыз гел үк коры тормады,—дип якыннан таныш түгел кешегә ачылып киттем мин.—Булгалый авыз чылаткан чаклар.

—Шулаймы? Очратмадым сезне андый хәлдә. Ә гайбәт тыңламыйм.

—Булгалады,—дип төзәтү кирәклеген аңладым мин, чөнки бу кешенең арттыру-күпертүләрне, киметү-ваклауларны ошатмавы аңлашыла иде, туптурыдан яру килешеп тора ачык күнелле агайга, аның үзен тотышыннан шундый бәя чыгардым.

—Ярар, яшьтәш,—бәлки, яшьтәшләрбез дә, бәлки, ул моны алдан белешүенә таянып әйтәдер,—вакытны бушка уздырмыйк. Сезне эшегездән озакка бүлдерү ярамас, гаепләрсез югыйсә. Якыннан танышуны бүтән очрашуларга да калдырыйк. Шулай... Мин Гәрәйхан исемле булам. Күрше йортта яшим.

—Күргәләдем кебек сезне.

—Юк, сез мине белмисез. Мин сезне беләрәк төшәм, ике китабыгызны укыдым. Быел әле. Яшьлектән, тәгәле, балачактан төрле тарафларда йөреп үзебезчә укымагач, авырдан бирелә татарча китаплар.

—Сезнең татарчагыз әйбәт.

—Балачакта авыл тәрбиясе эләккәнгә шулай. Әти һәм әни тәрбиясе. Һәм монын нәнүк кенә сере дә бар. Анысын соңрак әйтермен. Бәлки.

Мин Гәрәйханга йомшак кәнәфидән урын күрсәттем, үзем диван башына таянып утырдым.

—Хәзер үтенечемне тыңлагыз.—Ул шакмаклы бумази күлмәгенең җиңнәре төймәләрен ычкындырды, түгәрәклеген җуймаган йонлач беләкләрен сыпырды, зур эшкә тотына ягъни.—Мин сезгә кимендә хикәялек хәлләр турында сөйлим, сез шуны языгыз. Карышмагыз!—Тавышы ай-йай калын соң!—Икебез арасында ихлас якынлык урнашса, мин сезгә хикәяләрне еш сөйләрмен, күп алар миндә. Боларын язу-язмавыгыз үз карамагыгызда. Ә менә хәзер сөйләнәчәге язылырга тиеш! Тик үзем яза алмыйм. Үзебезчә, татарча уку бөтенләй тәтемәде миңа. Дөрес, ижатка бәйле һөнәрем бар барын. Әйе, бер-беребезне ышанычлы тыңларга күнексәк, монысы инде башка хикәя булыр йә... озын ук хикәянең бер өлешен алыр. Бүтән һөнәрем, дим. Бәлки, Ходай миңа язуга куә-талант бирмәгәндер.

Мин эндәшмәдем, аны бүлдерергә ярамавы аермачык иде.

Һәм Гәрәйхан хикәясенең “Әни!” дип куркынып ике тапкыр кычкыруына кадәрге өлешен, төртелмичә-тотлыкмыйча, бер тында сөйләп чыкты. Шул төшкә җитмәкче, капылт туктады. Башын иеп, тезләренә таянып, киң һәм биек мангаен—шома мангаен—шактый вакыт ышкып утырды. Болай итеп уйлануы ихтыярын-көчен җыю кебек тоелды.

Ниһаять, башын күтәрәрәк төште, кулларын кәнәфи таянсаларына куеп, миңа текәлеп, сөйләү алымын үзгәртмичә дәвам итте.

—Ипи пешерәбез, шөкер.—Әнинең йөзе яктыра башлады.—Күптән ипекәйдән авыз иткәнегез юк.

Әни шулай диде, иткәнебез, димәде, югыйсә үзенең дә күптән-күптән икмәк ашаганы юк инде.

Җилпучның урта төшендә он өеме тора, әнинең ике кушучына сыеп бетәрлек. Тәбәнәк лардан он ала торган, әти ясаган соскыч бу оннан тулмый да тулмый. Ә бит көрпәсе чәй чокырының төбен генә капларлык чыккан иде, эре иләк тырышкандыр.

Әти күкрәгенә терәп ипи кискән саен:

—Ундырып та пешерәсең инде икмәкне,—дип әнине мактый иде.—Дәүлеге тәгәрмән ташына иш, тәм, ашап туйгысыз. Галәмәт! Гел шундый икмәк белән сыйланырга насыйп итсен безгә. Һәркемгә теләгем шундый. Без тук яшәп, бүтәннәр ачлыктан интекмәсен.

Бу оннан гына андыен да дәү түгәрәк ипи чыкмас шул.

Әни икмәкне бәләкәй бөтен итеп әвәләп пешерде.

Шушы төштә тагын бүтәнгә күчик. Сез мине, татарчагызны саклагансыз, дип мактадыгыз.

—Мактау, дип…

—Мактау! Адәм баласы икмәк тәмен һәм үз теле тәмен беркайчан да онытмаска тиеш. Боларның икесен дә башлап әни пешереп бирә. Бу очракта шулай әйтү мәҗбүри.

Ана телемне онытмавым серләрен, диик, шушында аңлаешлырак әйтим.

Әйе, мин илебезне буйлый-иңләей йөрдем. Болары турында җыеп кына соңрак әйтермен. Телне онытмауның сәбәбен ачыклыйк элгәре. Читтә гел русча аралашып яшәгән кешегә үз телеңне саклавы авыр авырын. Әмма ки авыр да түгел.

Мине әти латин хәрефләрен укырга һәм шул әлифбада язарга өйрәткән иде бит. Теге утыз җиденче елда сәфәренә киткәнче, әйе. Сеңлем белән мине авылдан куган (моның ничеклеген сөйләүне ахыргарак күчерик), Омск шәһәре читендәге детдомга илтеп тыктылар. Бер генә татар да, мөселман баласы да юк иде анда. Бик авыр булды укып китүе, рус хәрефләрен һәм дә русчаны белми идем ич. Утырам бер дәрестә уйланып, һич ни анламыйм. Укытучы апа кара тактага язган хәрефләрне-сүзләрне балалар дәфтәрләренә күчерәләр, рәттән өч-дүрт хәреф тезелгәннәре кыска сүзләр икән, “папа” һәм “мама” кебекләре. Ә минем дәфтәр бите чип-чиста.

Укытучы апа моны күрде дә ручканы карага манып кулыма тоттырды, дәфтәргә төртеп күрсәтте—яз, дип әйтүе икән. Тактадагы бизәкләрне тиз генә күчердем, алар миңа нәни рәсемнәр шикелле тоелды. Ә рәсемнәр ясарга әтием өйрәтә башлаган иде бит. Укытучы апа, дәфтәрем бите бизәлүен күргәч, ике баш бармагын да бастырып мактады.

Укытучым турында сузыбрак сөйләвем—аңа гомерем буе рәхмәтле булудан. Онытылмый һәм онытылмаячак Мария апа. Мин аңарга, апа, дия

идем. Башта ул бу сүзне анламады.

—Тетя, да?—дип сорады, бу сүзләрне мин белә идем инде.

—Әйе, әй, тути!

Ул дәфтәремә "апа" дип латин хәрефләре белән язды, элгәре язуына күрсәтте, аннары уң кулын күкрәгенә куйды. Мин—апа, дип әйтүе иделер. Апа, дигәч, ул, кашларын күтәреп-төшереп, йомшак кына елмаер булды.

Озынга китте Мария апа турында сөйләү, әмма мин АПА турындагы истәлекләрне кыскартырга базмыйм. Хикмәт бит ана телен онытырга ярамавына барып чыга. Бу турыда тәфсилле искәртергә, телебезне онытмагансың, дип, үзегез мәҗбүр иттегез. Инде тыңларга үзегез мәҗбүрсез.

Апа мәсьәләсе унай хәл ителеп, дип рәсмиләштерик, ай чамасы узгач, укытучым мина дәресләрдән соң ашагач ук—детдом бу, монда барысы да өлешле, ашауны калдырсаң, корсагың тиз шинә—классыбызда мине көтәчәген анлата алды, әлбәттә, куллар хәрәкәте дә булышты.

Укытучы дәфтәрләребезне җыйган иде, дәрестә генә барысына да күз йөгертеп өлгермидер, безнең чатый-ботый бизәкләрне иркенләп карарга теләгәндер. Анын кулындагы газета белән тышлаган дәфтәремне таныйм. Апа дәфтәремне ачты һәм андагы латин хәрефләре белән язылган сүзләрне астан йомшак кына сыпыргач, мина текәлеп калды. Дәфтәргә бит мин татарча сүзләрне шактый ук өстәгән идем. Башымны күтәреп:

— Татар...—дидем.

Апа, ике янагымнан тотып, башымны үзенә таба борды, "апа" ны анлаган чактагыча, ике баш бармагын бастырып күрсәтте.

Иртәгесен апа мина күн тышлы калын дәфтәр бирде. Аны ачты да шунда баш, авыз, борын сүзләрен язарга күрсәтеп кушты. Латин хәрефләре белән яздым, апа аларны беләдер дип уйладым. Аннары бер кулым дәфтәрдәге сүзләр астында шуып йөрде, икенчесе баш-күзләрне күрсәтә барды. Апа шул сүзләр турысына латин әлифбасында русча язып куйды. Шулай итеп, гомеремдә бердәнбер сүзлегемне төзи башладым.

Тора-бара калын дәфтәргә татар сүзләрен исемә төшкән саен тездем, дүртенчегә күчкәч, янәшәләренә мәгънәләрен өстәдем. Инде русча ярый ук пупалый идем, мәгънәдән соң русчасын яздым. Белмәгәннәрен ападан сорадым. Шулай итүем, әлбәттә, Мария апа булышлыгында, ана телемне оныттырмады. Ишәя барды калын дәфтәрләрем, сүзләрне сонрак алфавит буенча язып күчердем. Шул дәфтәрләрне хәзергәчә саклыйм. Рәхмәтләрем хәзер дә яусын Мария апага.

Тик сезгә күрсәтмәячәкмен сүзлек-дәфтәрләремне. Алар үз кирәгемә генә язылды. Хәер, кем белгән, бәлки...

Ә, ә-ә... Мария апа белән бергәләп башлаган дәфтәр таушала төште, хәзер аны хатирәләр янартканда гына актарам.

Шулай... Инде ана теленне саклау хакында сүз башлагач, сезгә бер вакыйганы искәртеп кенә булса да узам. Китапчагарак күчә сөйләвем, әй...

Бервакыт югалды бит минем шушы дәфтәрем! Дүртенчедә укый идек инде. Югалды! Югыйсә гел дә билгеле урынына, тумбочкамның түбәнге бүлегендәге китап-дәфтәрләрем астына ук куя идем.

Мария апа:

—Сине директор чакыра,—диде һәм анын бүлмәсенәчә, инбашыма сөеп кагылгалап, мине озата барды.

Директор, мин керүгә үк, өстәл уртасындагы дәфтәргә төртеп күрсәтте.

—Синекеме?

—Ә-ә... әйе...—Бу вакытта мин русча яхшы ук сибә идем. Ни сәбәпледер, гәүдәмне төп-төз турайттым да:—Моя тетрадь!—дип тавышымны

күтәрәрәк әйттем.

—Нәрсәләр язылган анда?

—Сүзләр.

—Нигә латин хәрефләре белән?

—Монда китерелгәнче мин шул алфавитны гына белә идем. Менә русчасын бу алфавитта өстим.

—Беләм...—дип сузды директор.—Советка каршы әллә нәрсәләр яза, дип, сине чагып китерделәр аны миңа. Мә сиңа юка дәфтәр. Хәзер татарча сүзләреңне шунда яза бар, аннары монысына күчерерсең. Дәфтәрең әлегә миндә торсын. Бу югалтуың турында берәүгә дә әйтмәгән идеңме?

—Юк! Мария апага да әйтмәдем.

—Ул белә. Мин әйттем аңа. Әйберләреңне сак тот. Монда бит детдом,—бер сүзен русча кыстырыйм,—детдом, сыночек... Кайберләрегез бер үзе йөз төрле холыклы. Ана телен безнең онытуыбыз да житеп ашкан. Ә синең баш әйбәт эшләгән. Алты кешелек кенә бүлмәгә күчәрсең. Үз яшьтәшләрең янына. Монысында уникеме әле сез?

—Унбиш.

—Мария апаң белә моны. Тәки яңа исем тактың син Мария Николаевнага, хәзер без дә, Апа, диябез аңа.

Шулай... Детдомда миңа баштан ук ике әйбәт кеше очрады, анда әйбәтләр дә күп иде анысы, болары иң, иң әйбәтләре: рус Мария апа һәм белорус директорыбыз. Бәхетемә инде. Аларның икесенә дә хәзергәчә рәхмәтләремне укыйм.

Инде ана теле турындагы фикерләрне йомгакка чорныйк.

Ил буйлап-аркылап күченгәләп йөргәндә, ана телемне онытмавымның файдасы күп тиде. Әйтик, казакъ аксакалы үзенчә сөйли, мин—татарча. Аңыша идек. Әзәрбәйжаннар һәм Урта Азия кешеләре белән аралашканда да миңа тылмач кирәкмәде. Төрле шәһәрләрдә дә татарлар белән тиз табыша идем. Алардагы татарча китапларны укырга тырыштым. Әмма кириллица нигезенә корылган алфавитыгызны мактамыйм. Латиндагы “Qq, Gg” хәрефләре юк. Алар булса, катылык һәм йомшаклык билгеләре кирәкми. Катылык билгесе куелырга тиешле санаган төшегезгә хәреф йомшаклык билгесе сылыйсыз. Була алмый алай! Йомшаклык билгесенә эшне бик тә күбәйткәнсез. Хәтта “Tabigat”, “nihajət” сүзләре ахырына да чәписез мескенкәйне.

Гәрәйхан хәтсез ара сүзсез утырды, ялгызы гына итеп тойды бугай үзен. Мин аңа комачауламадым, бәлки, хатирәләрен янартуыдыр, андый чак тыныч узарга тиеш. Ул аска карап утыра бирде. Ниһаять:

—Шулай-й-й...—дип сузды.—Әйе... Шулай... Ә бит мин сезгә әнинең ипи пешерүе, авылдан китүебез, аксак атыбызның колыны, авылда нигә бер атна торып килүем сәбәбе, әлбәттә, әти-әни һәм сеңлем язмышы турында сөйләргә, шулар хакында хикәя яздырмакчы нияттән кергән идем. Үзәк шуларда кебек иде. Әмма ки ипи белән ана теле янәшәлегән санга сукмаска маташканмын. Аңгыра баш мин! Анысы, сезгә сөйләнә торган Беренче хикәямдә үземнең кемлегемне тулырак белдерү дә заруридыр. Хәзер хикәя хәлләрен кыскарак тотарга мәҗбүрмен. Вәләкин мин укырга теләгән хикәяне барыбер язачаксыз!

Һәм мин, Гәрәйханның әмергә тиң яңгыраган үтенечен бурычым санап, ул сөйләгәннәрне—болары да озынгарак сузыла, кыскартылмастыр—хикәя калыбына-кысасына салырга тырышырмын. Юк, вакыйгаларны ул сөйләгән тәртиптә үзгәртмичә тезим, минем тарафтан кайбер шомартулар булырдыр,

анысы. Бу өлештә Гәрәйхан ана теле турында сөйләүгә керешкәнче үк искәрткән ямьсезлек-фаҗигаләр шактый ук икән.

Ипи пеште. Әни аны агач көрәге уртасына туры китереп алды, олы якка күтәреп чыкты, үзе тукыган кызыл ашъяулыкка куйды. Өстәлгә ямь җәелде. Ашъяулык почмагын икмәк өстенә кайтарып япты.

—Йөрәгемнең шинмәс гөлләре сез,—диде әни сеңлем Сәгадәт белән миңа, тик мин сүзләренең мәгънәсен аңламадым, хәзергәчә аңламыйм. Югыйсә әни:—Сез... йөрәгемнең... шинмәс... гөлләре...—дип бүленгәләп кабатлауны да кирәк тапкан иде.

Әтигә тиешле кибән башын, ул сәфәрдә йөргәч, өчкә бүлде әни, сөйдергеч телемнән дә өчебез авыз иттек. Мин сөйдергеч телемнең тешләнгән кисәген кечкенә тастымалга төреп урамга чыктым, күрше малайларына да татытасы идем. Капка төбендә үк атыбыз тора иде. Колхоз абзарыннан кайткалады ул, тай чагында ук киткән үзе бездән, ә һаман онытмый. Хәзергә аны җикмиләр, якында ун гына көнлек коңгырт колыны бар, төсе нәкъ әнисенеке инде, көп-көрән.

Ипием кисәген атыбызга суздым. Атыбыз, икмәкне иснәгәч, кушучымны колынына таба этәрде. Малларда да ана җанлылык беренче шул. Күр инде, ашый белә икән ич колыныбыз, сөйдергеч телем кисәген бетергәч, учымны ялады. Кичен ике уенчак бәрәнен ияртеп кайтачак сарыгыбызга әрәмәлектән йолкыган печәнне бер учма алып чыгып атка ашаттым.

Караңгы төшәр чактарак күп балыклы елгабыз буеннан ике оя казларыбыз менде. Капка төбендә, без кайттык, дип кангылдаштылар. Аларны кечкенә капкадан Сәгадәт сеңлем белән икәүләп ачып керттек. Лапаска, рәхмәт яугырлары, дип мактап, әни япты.

Колын... Колын...

Аны, сугыш кубасы еллдагы күрше авыллар сабан туйларында өч көн рәттән чабыштырып, яндырганнар. Сугыш башланган көнне үлгән. Беренче килеп, сабан туе мәйданына керүгә егылып җан биргән.

Менә шул, баштарак, сезненчә итеп, хат юлга чакырды, дигән идем. Уң күршебез Мофаззал абзыйның төпчеге чормадан язулы дәфтәр тапкан. Анда Мофаззал абзый безнең көрән колынның нәкъ сугыш кергән көндә үлүен, шул ук көнне күмүне үзе оештыруын бүтән мәгълүматлары янәшәсенә теркәгән. Шул колынның—Чабышкының каберен Мофаззал абзыйның төпчеге белән карап-төзәткәләп тотабыз.

Ә-ә... әйе... Әти-әни, сеңлем исәннәрдер кебек. Аларның күрүләре билгесез бит. Эзләтүләремә, билгесез, дип кенә җавап бирделәр.

Мәгълүматлары арасында, мин белгәннәрендә, әйе, хаклыктан читкә таю тартымнары юк, хәер, белмәгәннәре дә дөп-дөрес булыр, үтә дә гадел һәм башкаларга игелек кылучан иде Мофаззал абзый. Бу яктан минем әти белән бик тә охшашлар иде алар.

Шулай... Дәфтәрдә безнең гаилә фаҗигасе дә язылган. Шул төшләрен күчереп алдым. Сезгә укытырмын. Бәлки.

...Күршебезгә карчыгым, умачлык булыр дип, бераз он биргән иде, дигән Мофаззал абзый. Алар аннан икмәк пешергәннәр. Гәрәйхан үзенә тигәнен урамга алып чыккан. Колхозга биргән колынлы Аксак атлары еш кайтып күренә иде. Гәрәйхан ипие сыныгын колынга ашаткан. Шуны Куштан Мөртәт күргән. Силсәвиткә барып чаккан. Кичке унайда тентеделәр күршеләр биләмәсен. Он эзләгәннәр, атка ипи ашатырлык он аларга каян килгән, дип.

Гәрәйхан белән Сәгадәт икәү генә калдылар. Әниләрен алып киттеләр. Өтермәнгәдер...

Мофаззал абзый дәфтәре читенә, шушы турыга: "Шул китүдән кайтмады күрше киленебез. Әйбәт кеше иде. Мәрхүмәдер инде," дип өстәгән. Әтиләрен, район түрәсенә каршы төшкәнгә, былтыр ук алып киткәннәр иде. Гаделсезлекне җене сөймәде, туры сүзле, эш рәтен шәп көйли иде. Балалар аны озак сәфәрдә дип белделәр.

—Менә ничек булган икән әтинең "сәфәре".—Гәрәйхан сөйләвеннән озак ук өзелеп торды.—Авылга шушы кайтуымда гына белдем моны. Әнине алып киткәндә, Куштан Мөртәтнең, ире белән очраштылар, рәхмәт әйтсен, дигәне мәгънәсенә шуннан соң гына төшендем.

Хәзер мин сезгә кайбер вакыйгаларны тезеп кенә узам. Югыйсә сөйләвем озынга ук тартылды. Ә соңрак әйтәсе әһәмиятле хәлләр кысрыкланмаска тиеш.

Сеңлем Сәгадәт белән икәү генә кундык. Коры сәкедә яттык. Сеңлем, теге абый (Куштан Мөртәт) баш асларыбыздан мендәрләрне тартып алды, нигә, дип кат-кат сорады. Курыктык. Йокы кермәде. Төн уртасы идедер, тәрәзәгә акрын гына чиртteләр. Ике тапкыр. Күрше Мофаззал абзый иде, ризыклар керткән, кием-салымнан урын җәйде, әнинең озын бишмәтен өстебезгә япты.

Ике көннән безне детдомга җибәрделәр. Сеңлем Сәгадәтне миннән Казанда ук аердылар. Ул балакайның өзгәләнүен күрсәгез сез! Еларга яшь җитми. Исәнме икән сеңлем Сәгадәт? Әллә Софья булып киттеме икән? Бик тә сабый иде шул, нәрсә хәтерләсен инде ул балакай. Исәндер кебек. Әти-әни дә исәннәрдер кебек. Монысына өметләнеп-ышанып булмый, инде минем үземә җитмеш җиденче яшь бит, яшьтәш.

Әйе, аннары детдом. Әйтәм ич, сездән дә сәвитскирак мин. Шулай тәрбия кылдылар. Хәтта партмәктәптә укыдым. Шуннан соң төзелеш трестында партком секретаре иттеләр. Белгечлегем төзүче минем, төзүче инженерлар институтын тәмамладым. Пенсиягә чыккач, инде унҗиде ел янәмәсе лаеклы ялда, Казанга кайтып урнаштым. Бер урында торып эшләмәдем монда. Шабашка чыккаладым. Төзүче ич, кирпечтән йорт өя һәм балта-чүкеч тота беләм.

Авылдагы каралтыларны Мофаззал абзый һәм малайлары караштырып тоткан. Әмма йорт, келәт, абзар-лапаслар бик тә ингәннәр иде. Кайткан елда ук өйне һәм каралтыларны элеккечә үк итеп яңадан торгыздым.

Торгыздырттым. Әйе, элеккечә үк итеп. Әмма өр-яңадан. Горбачев кебек үзгәртеп кормакчы булу файдасыз. Үзгәртеп кору, имеш. Әкәмәт! Әнә, ничеккә үзгәрде замана.

Әйе... Шулай...

Уйлый төшсәң, бөтен дөньядагы юньсезлекләр безнең илдән башлана. Үзгәртеп коруга чаклы террорчылык бу хәтле чәчәк атмаган иде. Мәскәү радиосының соңгы хәбәрләрен тыңлаштырыгыз сез. Сәгать саен тапшыралар. Гел үтереш тә һәлакәт. Бераз күперттем бугай, әмма күпчелек хәбәрләре шулардан гыйбарәт.

Ә чынлыкта бүгенгебез үткәннән начар. Киләчәгебез тагын да хөртиме? Кайчакта шундый уйларга да киленә, яшьтәш. Хәзерге сәясәтлыгырдаучылар сәясәте—бетерүгә көйләнгән. Бармаклар арасыннан сыгып чыгарылган хезмәт хакы, бәяләрне чөюләр... Кемнәрдер чаңгы шуарга төнлә чит илгә барып кайталар, гади халыкның дачасындагы чыбык-үсентеләрне санап йөриләр...

Аңлыйм, тагын читкә керүемне аңлыйм. Хәзерге әңгәмәләрдә гел шулар куертылгач, безнең әңгәмә сытылмасын, ә бүселеп торсын өчен искәртүем.

Минем бер танышым Минзәлә ягыннан. ГЭС төзегәндә су астында кала болар авылы. Зираты белән. Ә танышым, шахтада чиләнеп кайтып, шәп йорт житкергән генә була. Шушы агай нишләгән, дисезме? Өенә ут төртә. Биленә таянып карап яндыра. Йортын алырга боерганнар икән.

Вөждансызлар талый илне.

Ни өчен без матурлык корырга өйрәнә белмибез, ә? Нигә гаепләләр җавап тотмыйлар? Ерткычлыклары өчен берәү дә хәтта гафу да үтенми. Әйләндерегез менә шушыларны хикәяләргә! Фактлар тулып ашкан. Бүтәннәр язсын, дисезме? Алай уйласагыз, монысы сезнең тарафтан егетлек түгел. Ин киме шулай.

Йә, кайда минем әти-әнием? Кайда минем сабый сеңлем Сәгадәт? Буйдак калдырып, кем өзде минем шәҗәрәмне? Кем чыжлатып кисте?

Шулай... Шундый-шундый хәлләр, яшьтәш.

Шәҗәрәнне дәвам итү өчен, өйләнергә иде, дисезме? Ә сез балаларым, оныкларым минем кебек нужа чикмәячәкләр, синең язмышың кабатланмас, дип ышандыра алыр идегезме сон? Кемдер шундый гарантия бирер идеме? Сүзнең тәгаен сезнең хакта түгеллеген аңлыйсыз, әлбәттә. Мин үзем андый гарантия бирә алыр идемме?

Йорт-жирне тәртипкә салуымны сөйли идем. Шул төшкә кайтыйк. Читкә тайпылуыма ачуланмагыз. Кемлегем, уйлау рәвешем таныш сезгә хәзер.

Шулай... Буталчык, дуамал замана, башкаларның авызына китергән икмәкләрен каеру заманы. Сәвитский чактагыдан кимендә өчләтә яман.

Шулай... Кабатлыйм: йорт-жиремне торгыздым. Янадан. Әмма элеккечә итеп бурычка кермәдем. Мофаззал абзый исән иде, ул карап эшләтте, кирәк-ярагын табышты. Бер генә киңәш сорады. Теге Куштан Мөртәтнең олы малае каралты-йорт салуда авылда ин оста икән.

—Энем Гәрәйхан,—диде Мофаззал абзый,—шул егетне баш оста итик,—диде.—Килешер. Әтисенә тартым гадәтләре юк аның, бөтенләй үзгә ул. Авылны төзүдә аның белән киңәшәбез. Баш оста булырга үзе дә телидер. Әтисенең гөнаһысын юаргадыр исәбе.

Карышмадым. Баш оста түләү алмады. Эшне бетергәч, табын түренә утырып ризыгымны тәмләп жыйды, догасын кылып, рәхмәт әйтте. Мин ишеткән бердәнбер сүзе—шул рәхмәте.

Келәткә ике ларны үзем ясадым. Бүлемнәрле итеп. Ларлар буш түгел. Шөкер. Өйгә йозак салмыйм. Авылдашлар шуна сөенә. Келәт ишегендә—теге елларның богау йозагы, чистартып төзәттем аны. Келәтне бикләмичә ярамый, ризыкларны сакта тоту тиеш. Ачкычы—күршеләрдә. Алар бакчабызны калдауландырмаганнар.

Өйнең ике ягындагы түр сәкеләр дә элеккеләре шикелле. Миче зур. Тегермән ташыдай алты зур ипи иркен сыя. Әнинең мичкә ипи сала торган һәм пешкәнен ала торган көрәген кырып чистарттым. Әйбәт куәс тә юнәттем.

—Их-х, мин, аңгыра баш,—дип урыныннан җәһәт торды Гәрәйхан күрше һәм телефон өстәленә куйган төргәген алып килде.—Мин кибеттән түгәрәк булкилар алган идем ич. Кеше йортына беренче кергәндә, кулыгызда ризык булсын, дип өйрәтәләр иде бит әти-әни.—Гәрәйхан биек маңгаен ышкыды...—Күрше, мин тиз әйләнеп керәм, йәме,—дип, пинжәген дә кимичә, ана күз генә ташлап, чыгып та китте.

Мин, бүген кулга каләм тотып булмаячагын төшенеп, кәгазьләремне җыйнаштырыга кереп тә житте Гәрәйхан.

—Менә бер бөтен ипи сезгә! Авылдагы өебез мичендә пешергән идем.

—Рәхмәт.

Без сүзсез озак ук, озак утырдык. Мин актаргаларга китап алмакчы идем дә уңайсызландым. Гәрәйхан сөйләгәннәрне күнелемнән сөзеп уздырдым. Гәрәйхан маңгаен каты ук ышкый, аннары бармакларын чигәләренә күчерә, тагын маңгай каты басып ышкыла, куллары йодрыклана да бармаклар җәелә. Кыбырсый күрше Гәрәйхан, ә карашы бер ноктага текәлеп каткан. Чит фатирда булуын һәм өйдә мин барлыгын абайламый да ул.

Бу юлы урыныннан кинәт сикереп үк торды һәм:

—Юк... Юк! Әйе... Әйе!—дип калын тавышын тамак төбеннән тартып чыгарды.—Ярамый... Дөресме? Тиз кирәк. Тиз! Нидер бар. Күнелем сизә. Сизә!

Идәнне сытардай итеп басып, озын гәүдәсен туры тотып, өйдән горурәнә кабаланып чыгып та китте. Монысында инде пинжәк калуына игътибар итмәде.

Озак юанмады. Ишекне бикләмәгәнмен, Гәрәйхан аны акрын гына ачып керде, аяк киемнәре тартмасына лап итеп утырды, төз гәүдәсе алгарак сыгылган иде. Карашы дөньяда чама юк кешенекедәй, миңа текәлеп утыра бирә. Кинәт йөзе яктыра, алай гына түгел, ә балкый. Күзләреннән яшь ага да ага. Сөенеп елмая да үзе, шул елмаюын тирән җыерчыклар кысылышып алыштыра. Эндәшми, мин ни булуын сорарга базмыйм. Елмая ич, хәвеф-хәтәр юктыр, дим.

Күз яшьләре һаман ага да ага Гәрәйханның, шакмаклы бумази күлмәге сыгарлык.

Ул миңа кулындагы кәгазьне сузды. Телеграмма иде. Татарча язылган: "Кайт! Сәгадәт апа монда".

—Киттек!—дидем мин, тавышны күтәреп үк әйттем бугай.

—Ә-ә... ә-ә-ә... ә...

—Киттек, дим! Хәзер үк! Сез әзердер ич хәзер үк китәргә? Әзерме, дим!

—Ми-ин...

—Киттек! Машина бар! Гараж янәшәдә!

Хәләлемә, авылга киттем, дип язу сызгаладым, кече кызыбызга шалтыраткан идем, туры килмәде.

Күптән түгел генә идәнне сытып басып йөргән әзмәвер Гәрәйханны, алпан-тилпән атлаучы ап-аек Гәрәйханны, гаражгача култыклап алып бардым. Күршем мине карусыз тыңлады, өзә-төтә нәрсәләрдер әйткәләде.

Мишә буендагы Гәрәйхан авылына сәгать тулуга кайтып та җиттек.

—Әнә, әнә, безнең йорт!—дип урыныннан кузгала ук башлады Гәрәйхан, ул күрсәткән капка-коймага икеме, өчме ихата бар иде әле.—Әнә, әнә, Сәгадәт сеңлем ич инде! Мин колыныбызга ипи ашаткан төштә үк басып тора. Сәгадәт сеңелкәем ич инде! Туктатыгыз машинаны!

Һәм Гәрәйхан машинаның ишеген каерып ук ачты, кулын маңгаена куеп безгә карап торучы озынча гәүдәле ханымга таба йөгерде.

Машинаны аларга җитмичә туктаттым, чыгып, коймага сөялеп утырдым. Аларның ничек күрешүләрен карый алмадым, күзләремнән яшь ага иде.

Гәрәйханның һәм Сәгадәтнең бүленгәләп-бүленеп, сүз үзәген оныткалап сөйләшүләре колакларыма шулай ук өзә-төтә керә иде. Инде бу хикәяне язганда, аларның сөйләшүен бер урынга тезүне хуп күрдем.

—Сәгадәт... Сәгадәт, сеңлем...

—Абый... Гәрәйхан абыем минем...

—Ничек белдең авылыбызны?

—Әти-әни әйтте.

—Ничек—әти-әни?!

Тынлык.

—Төш күрдем. Элгәре яныма әни үзе генә килде. Кайт авылыбызга, диде. Татарчанны исенә төшер, диде. Шуннан соң барысын да хәтерләрсең, диде. Саташамдыр дип уйладым. Иремнең өчесен уздырганнан соң бу. Без икебез дә мәктәптә укыттык, ул—физикадан, мин—математикадан. Тәмам урыслаштык, ул да, минем кебек, кем кешесе икәнен белмәде. Әйбәт иде ирем Гавриил. Тату яшәдек. Бик, бик. Балаларыбыз булмады. Татармы, әллә бүтәнме икәнен белмичә китте шул Гавриил. Мин әти-әнине эзләтә алмадым, хәтта исемнәрен дә белми идем ич.

—Хәзер…

—Хәзер беләм. Менә бу күршеләребез дөресләп әйттеләр. Шул инде, беренче төшемне саташуга санадым. Кайтыр идем, кая кайтасын белмим. Шуннан соң әти белән әни төшемә бергәләп керделәр, яныма ук парлашып бастылар. Парлашып ук, кайт авылыбызга, диделәр, абыең Гәрәйхан көтә, диделәр. Йокымнан торып, алар өйрәткән адресны, синең исемне язып куйдым. Район үзәгенә барып белештем, таптылар безнең авылның кайдалыгын. Инде әти белән әнинең төштәге кинәшен тотмыйча ярамый иде. Икенче төшемне күреп ай чамасы, юк, егерме көн узгач, кайтыр юлга җыендым. Икенче төшне күргәч ук хәтеремә татарча сүзләр ашыга-ашыга тезелешеп килә башладылар. Авылыбыздагы бердәнбер татар гаиләсеннән ике китап алып, аларны кат-кат ермачладым, күп сүзләрне шулардан өйрәндем.

—Могҗиза артыннан могҗиза…

—Йорт-җиребез житкелекле иде, урманлы яклар бит, Иртыш буе, Омскидан өскә таба.

—Омск, дисең…

—Йортыбызны мәктәпкә бирдем.—Сәгадәт уйга калды бугай, сүзсез торды.—Мин бит, абыем, бөтенләйгә кайттым,—диде ул аннары.—Бөтенләйгә!

—Шулай булмыйча! Җибәрмим дә мин сине. Нигезебез торып баса ич.

—Йорт-җиребез өчен акча алмаска иде исәбем. Директор апабыз, Серафима Николаевна, диде, паспортта шулай язылган минем, үзгәртерәм, үз исемемә кайтам. Ә директор апабыз, әле кая-кемгә кайтып керәсең билгесез, диде, мөмкинлегебезчә түлибез сиңа, диде, карышма, диде, әйбәт яшәдек, килешеп эшләдек, авылың чит итмәс сине, авылыңда рәхәт яшәргә язсын сиңа, диде. Син теләгәнчә булсын, бу акча йортыгыз өчен түләү түгел, ә сиңа ярдәмебез, диде. Саклarбыз йортыгызны, диде. Дөнья бу, алдагысын кем белгән, монда килгәләрсең… кайткаларсың, бәлки, диде. Ярый ла абыең анда булса, дип өстәде ахырдан. Абыем, шәт, рәхәт яшәрбез, Аллаһы шулай боерсын иде. Ирем каберен карап торырбыз, яме, абыем. Гавриилны әйтәм…

Алар өйдә дә бер хәлдән икенчегә тиз күчеп сөйләштеләр. Өйдә тәртип иде, Сәгадәт җыештыргалап өлгергәнме, әллә Гәрәйхан шулай тотамы, белмәссең, хәер, икесенең дә өлеше бардыр. Күршеләр чәйгә дәшкән иде, Гәрәйхан:

—Элгәре үзебездә ризык җыйыйк,—диде. Елавыннан туктаган, халәте минем белән танышкандагыча иде.—Сеңлем,—дип бүтәнгә күчте ул,—мин авылдан киткәннән бирле еламаган идем, бүген туйганчы еладым, рәхәтләнеп. Күз яшьләрем күбәйгән икән…

—Елаудан файда… Мин еладым. Еш. Ирем вафатыннан соң күзләрем кызарып бетте. Мәрхүмкәй, кайсы халык кешесе икәнен белмичә китте. Сабыйлар идек шул, өч яшен дә тулмаган чактан нәрсә хәтерлисең соң…

Ярый ла миңа әни белән әти булышты, үз дөньябызга кайтырга, дим.

—Икесенә багышлап аш мәҗлесе уздырырбыз. Күрше әби тәртипләрен төгәл белә. Әти-әни исән түгелләрдер шул. Алар бит аң җиткергән, туган җирне оныта алмаслар иде. Бәлки, икесен дә кулга алуга ук... Андый хәлләр дә еш кабатланган. Исән булсалар, сине һәм мине күптән, бик күптән эзләп табарлар иде әти белән әни...

Гәрәйханнар урамын әйләндем, аннары елга буена төштем. Мин кайтып кергәндә, алар кече якта чөкердәшәләр иде.

—Яшьтәш, кая югалдыгыз?—дип каршылады Гәрәйхан.

—Мишә буенда йөрдем.

—Дөрес иткәнсез. Мишәне күрергә кирәк, аны анларга өйрәнергә кирәк. Гаҗәеп елга бит ул!

—Мишә безнең төбәктән башлана.

—Байлар Сабасы ягыннан икәнсез.—Һәм Гәрәйхан миңе:—Килегез әле монда, бәһасез байлык күрсәтәм үзегезгә,—дип янына чакырды.—Онны ике чиләктә Сәгадәт сенлем белән бергәләп алып кердек. Сенлем бүген иртәнге якта искәрткәнчә, вак иләкне бу юлы да ул, ә эресен мин күтәрдем. Сенлем Сәгадәт вагы белән иләде, эресе кирәкмәде. Күрдегезме, җилпуч тум-тулы! Ипи салабыз!

Алар миңа төш узгач кына китәргә рөхсәт иттеләр. Машинаны урамга чыгаргач та җибәрмичә тордылар.

—Әле ничек сезгә керергә башым җитте. Сездән башка бу хәлләргә чыдамас та идем,—дип мактап җибәрде мине Гәрәйхан.—Рәхмәт сезгә.

—Абый, тагын кайтыгыз, яме. Туганыбыз булырсыз, яме. Авылда туганнарыбыз юк икән, ераграк туганнарыбыз да калмаган. Авылыбыз кешеләре әйбәтләрдер. Бу күршеләребез әйбәтләр ич.—Сәгадәтнең миңа әйткән беренче сүзләре иде болар. Абыйлы төп нигезен табуына ышана башлаган идедер. Шулай да күзләре чишмәләре ташыр чиккә җитәр-җитмәс, шул зәңгәрсу күзләре эзләнә, калын иреннәре сизелеп дерелти, калку ук бит урталалары мимылдый иде.—Абый, абый, апаны да алып кайтыгыз, яме, дим, яме. Ара ерак түгел икән. Ә минем йөрер арам... Ип... ипи... Гавриил...

Көтмәгәндә-уйламагандагы сүз көчешеннән минем битем-йөзем калтыранды, аннары кысып җыерылды да ишелеп җәелде. Гәрәйханның да йөзеннән бәхетле елмаюы югалды, ул капка төбендәге эскәмиягә лап итеп утырды. Икебезне дә бер үк нәрсә шомга салды бугай.

Тынлык. Озакка сузылды. Сәгадәт Гәрәйхан абыйсы сүз башлавын көтә кебек, карашы анарга текәлгән. Ә абый кеше, башын учлары белән каплап, иелеп утыруын белде. Ниһаять, ул гадәтенчә җәһәт торып басты, гәүдәсен дер селкетте. Һәм, берни үзгәрмәгәндәй елмаеп, миңа:

—Сез бүген китмисез,—диде.—Өегезгә шалтыратырсыз, чыбыксыз телефон моннан Казанны тота. Капка ачык, чигерегез машинагызны. Юк, алды белән керегез дә машинаны ишегалдында борып куярсыз. Иркен ич анда.

Кичен күршеләрдә чәйләдек. Гәрәйхан мине яныннан җибәрмәде, Сәгадәт гел безнең тирәдә йөрде.

—Күрше яшьтәш,—дип пышылдады миңа Гәрәйхан,—минем үземне генә калдырмагыз, ышанычлы терәк сез миңа бүген. Үземнең генә сыгылуым ихтимал.

Шундый хәлләр.

Сәгадәт тарафыннан нәрсәдер көтә идек без. Әмма ул баягы борылышкөчешне онытып торыптыр (Гавриил...), үзен иркен тотты, йөзеннән көләчлек җуелмады, хәлләрнең анынча тезеләчәгенә ышана идедер. Хәтер

күзенә анын кыска арада да сизелерлек чулыгуы күренде. Сәгадәтнен авылына кайтуы янадан тууына тиңдер ләбаса, унай тәэссоратнын да, күнелне төптән кузгатуына өстәп, буй-сынынны сыгылдырып тиз абыктыруы бик тә мөмкиндер.

Шулай да абый белән сенелнен бәхет кочагында рәхәт изрәүләренә һич нәрсә комачаулый алмаячагы шиксез иде. Мин алар бәхетеннән бәхетле идем.

Без олы яктагы сәке йөзлегендә сөйләшеп утырабыз. Мин—ян тәрәзә уңаенда, янәшәмдә—Гәрәйхан, Сәгадәт бүлмә тактасына кырынлап терәлгән. Сүзебез моннан башлана да жир читенә барып житә.

—Күрше,—диде мина Гәрәйхан,—иртән мин сезгә әнинең безне ожмах кошларына һәм бүтәннәргә тинләвен әйткән идем. Шунда әнинен бер чагыштыруы онытылган икән. Агылыем белән тагылыем сез минем, әтиегез белән минем, диган иде ул. Онытмагыз моны хикәягә кыстырырга дип искәртүем.

Сәгадәт әнисе сүзләренең мәгънәсенә төшенмәде, әмма моны кайтарып сорамады, без анлатмадык. Ул тагын бөтенләй бүтәнгә күчте.

—Абый, мин моннан шуып кына төшә идем, әйеме,—дип сәке йөзлеген сыпыргалады Сәгадәт, шома йөзлеккә башын боргалый-боргалый карады.—Абый, өебез элек шушындый ук идеме?

—Нәкъ. Үзгәреш, шөкер, яналыгы. Йортнын беренче ниргәсен,—бу сүзне Сәгадәтнең анламасын абайлап,—астагы дүрт яктагы дүрт бүрәнәсен үзем көйләп салдым. Күрше Мофаззал абзый бүрәнәләрне тәгәрәтергә булышкалады, йомычкаларны жыйды.

—Өебез әйбәт. Рәхмәт үзенә. Әти белән әни күрмәгәннәр менә... Безнең якта, тегендә, йортларны зур итеп салалар, үзебезнен дә шундый.

Сәгадәтнен кече якта табак-савыт шүрлеген рәтләве күренеп торды.

—Абый, монысы минем чәй чокырым инде әллә?

—Әйе. Мофаззал абзыйлар күп әйберне саклаганнар.

—Алыйм әле мин моны. Чәйне шуннан эчәрмен. Абый!

—Әү, сенлем.

—Мин авылым урамнарын әйләнмәкче идем.

—Күр инде, минем шуңа баш житми, әй! Әйләнәбез! Бүген сонладык. Иртәгә, яме. Иркенләп. Мин авылга кайткан көндә үк әйләнеп чыккан идем.

—Абый, син гармун уйный иденме?

—Уйныйм. Ил йөреп кайткач та урамнарны гармун уйнап әйләндем. Биш яшьтән үк урамда гармун уйнап үстем. Әти алып биргән кечкенә гармунны.—Гәрәйхан кашлары арасын, чигәләрен ышкыды.—Авылнын элеккедән өчтән бере генә инде, ихаталар анда-санда гына, дигәндәй. Авылда хәзер гармун уйнаганны тынлаучылар да бетеп бара икән. Мине капка төбендә утыручы бер әби генә үз янына чакырды. Исенә төшерде мине. Онытмаган. Кайткансың икән, рәхмәтләр яугыры үзенә, диде. Кечкенә чагыннан ук урамда монлы итеп гармун уйнап йөри иден син, диде.

—Абый, гармун уйна!

—Гармун... Хәзер Мофаззал абзыйлардан гармун алып чыгам.

—Абый, Гәрәйхан абыем, син баскычка утырып уйнарга ярата иденме? Шулаймы? Хәтеремә дөрес кайтаммы?

Мишә буендагы бүген бәхетле йорт-жиргә гармун моны житмәгән икән...

Ипи пеште. Сәгадәт күршеләрне чәйгә алды. Очып кына йөри ул бүген. Табынны жәһәт жыештырды, өйдәге вак жиһазлар күченгәләгән икән, аларны:

—Синеңчә, үзенчә урыннарына кунакласыннар, абый, яме,—дип урнаштырды.

Мин китәргә рөхсәт сорадым. Без сәке йөзлегендә кичәге тезелештә утыра идек. Сәгадәт абыйсы каршына басты.

—Абыем, күтәр башыңны. Миңа туры кара.

Гәрәйхан бераздан гына тураеп утырды. Ике куллап үрелеп, сеңлесен яңакларыннан калтыранып сөйде.

—Мин, абый, авылыбызны йөреп чыкмыйм. Шушы ниятем дөрес. Ачуланма. Кичә иремнең исемен әйтүгә тукталуым сәбәбен икегез дә аңладыгыз. Бу хакта сүз кузгатмавыгызга рәхмәт. Гавриил... Япа-ялгызы калды ул анда. Ярамый миңа анардан ераклашырга. Аның исеме Габделхак булмадымы икән, дим. Шундыйрак исемне бозыбрак кабатлаштырды кебек ул теге, теге чакларда, өч яшең дә тулмаганда исемнәрнең бозылгалавы гаҗәпме соң... Аны туктый-туктый әйтте бугай, Габ-Габ-дел-хак дип. Үзенә Габделхак дип эндәшүләрне сагынгандыр, сабыйкаем. Неп-нечкә сабый тавышы хәзер генә колакларыма ишетелә башлады.

Гәрәйхан йөзен җыерды да йодрыкларын бер-берсенә каты ук китереп бәрде, зур учларын сеңлесенең иңбашларына салды, Сәгадәт кулларын абыйсы җилкәсенә куйды. Алар бер-берсенә текәлешеп тордылар, сүзсез фикерләшүләре иде ахрысы бу халәт.

Күзләре яшьсез иде.

—Җыен,—диде Гәрәйхан, аның тавышы боеручан калын иде.

—Мин әзер.

...Машинам кызулануны оныткан, иплән кенә юырта. Бу сәфәрендә бик тә сак йөрү тиешлеген аңлый диярсең. Әллә машинадагы калачлар исән юл буйлап ашыкмыйча таратасы киләме иде, белмәссең. Бәлки, гел дә бүтән сәбәптер.

Биек ак күмәч исе Гәрәйханнар ихатасына бөркелгән иде. Теге чакта да Гәрәйхан белән Сәгадәтнең әнисе пешергән кечкенә бөтен икмәктән дә шундый туклыклы ис таралгандыр.

Әйдә, машинакай, кызулыйк. Арткы бүлемдә уйлары дәрьяларына чумып баручы Сәгадәт белән Гәрәйханны самолетка өлгертәсебезне онытмыйк. Машинакай, җилдерт, әйдә, җилдерт.

Сәгадәт билет хәстәрләде. Тиз әйләнде. Түгәрәк күзләре елмаюлы иде. Абыйсына ике билетны кулларына аерып тотып күрсәтте.

Сеңлесе читкәрәк киткән арада Гәрәйхан шома йодрыкларын җәенке колачында бер-берсенә акрыннан тизләтеп бәрде. Елтыр чаткылар чәчрәде дә йодрыклар эзе-күләгәсе күз алдына кунып-эленеп калдылар кебек.

Гәрәйханның тавышы йомшак-иркә иде:

—Шулай, яшьтәш, безнең кызлар барган җирләреннән кайтучан түгел.

*2002—2006 еллар.*

Рашат
Низами

# ТӨНГЕ ЯҢГЫР

Кафе, музыка, ап-ак люстра шәмдәленнән сирпелгән яктылык, шәраб исе катыш җиләс һава, уен-көлке сүзләр, кычкырып яисә пышылдап сөйләшүләр—хәзер инде болар барысы да хәтернең теге ягында торып калган...

Ә нинди матур, көләч, сине яшьлегенә чакырып торган, җаныңны йолдызлар галәменә кадәр күтәрердәй кабатланмас кичә иде бит ул!

Ун ел... Әйе, моннан нәкъ ун ел элек алар университетның филология факультетын тәмамлаган иделәр. Фәлән елның фәлән көнендә Казанда җыйналалар да, аннары аларны ун ел буе зарыктырган очрашу көтә! Сиринә бу көнгә түземсезләнеп әзерләнде, очрашуга ашкынып, очар коштай канатланып килде. Теге чакта сабакташларының күбесен, кулларына юллама тоттырып, кош баласын оясыннан очыргандай, район һәм авыл җирләренә тараттылар.

Кызык бит: кемнәр кая китеп кем булган да, тагын кемнәр тормышында ниләр майтарды икән? Гаилә хәлләре турында да сүз булмый калмас, билгеле. Тик менә Сиринәнең...

Шуларны уйлый-уйлый, кафе ишегеннән атлап керүе кая, кемдер аңа ифрат ягымлы тавыш белән эндәште:

—Исәнме, Сиринә!

Кем дисә, каршында... курсташлары арасында чибәрләрдән саналган, егетләрнең егете Данил басып тора иде. Ул әлләни үзгәрмәгән дә шикелле—килеш-килбәте, төс-кыяфәте нәкъ элеккечә...

Түгәрәк якты йөз, килешле иреннәре өстендә җеп сыманрак нечкә-озынча мыек сызыгы, маңгаена төшебрәк торган карасу чәчләр, зәңгәрсу күзләр—боларның барысыннан да яшертен, тыенкы бер матурлык, тумыштан ук бирелгән табигыйлек бөркелеп тора. Төсле-ялтыравык мода журналларында ир-атлар өлгесе итеп бирелә торган фотосурәтләрнең бер читтә торсын, чынлаптыр менә...

Укытучылар гаиләсендә туып-үскән бу егетнең тәрбиясе дә соклангыч иде. Җаен китереп кенә, ягымлы елмаеп һәркемнең хәлен сорашыр, кирәксә—ярдәменнән калдырмас. Шушы ачыклыгы, гадилеге артында күзгә күренмәс бер тылсым, кул җитмәслек сер посып ята шикелле... Тамчы да үзгәрмәгән—һаман шул икән! Сиринәнең генә түгел, әле тагын башкаларның да плащларын салдырырга, гардеробка бирергә булышты. Җинүчән, тормыш сөючән, шат күңелле елмаюы белән ул бүгенге бәйрәмне алдагы минутларда да гел бизәп-ямьләп торды.

Затлы тәгам белән тулган табын артында:

—О-о, Фәридә? Син кайларда хәзер?..

—Ну, безнең Марат!

—Афәрин, Данил!—дигәнрәк сагыну-соклану авазлары һәркемнең күнелен алгысытып җибәрде.

Табын дилбегәсе үзеннән-үзе Данил кулына күчте. Гүя ул—дирижер! Аның салмак, вакыт-вакыт җитезрәк тә талпынган кул хәрәкәтләре аралашу, сөйләшү, сүз әйтешү кебек күнелле, әмма шактый чуалчык та тамаша белән идарә итү, аны эзлекле бер сызыкка салу өчен яратылган диярсең. Сүз арасында кызыклы, тапкыр сүзләргә бай булган көлкеле анекдотлар кыстырырга да җай таба үзе.

Берәүне дә онытмады Данил, һәркемне сөйләттерергә тырышты, һәр сабакташына сүз бирде. Җыр, музыка, вальслар тынып торган арада тост арты тостлар яңгырады. Һәркемнең әйтер сүзе, уртаклашасы хис-хатирәләре җитәрлек иде...

Ә шулай да иң кызыклысы, иң истә кала торганы Данилнең тосты булгандыр, мөгаен. Каян шулкадәр сүзләр, көтелмәгән чагыштырулар уйлап таба диген син аны.

—Рөхсәт итегез миңа да бер тост әйтергә...

Сөйләшенеп куйгандай, табын кинәттән тын калды, һәркемнең күз карашы Данилга төбәлгән иде. Аңардагы эчкәрге бер энергиядәнме, зал эче электрланган кебек тоелды бу мизгелдә...

—Сүземне бераз читтәнрәк башлап китмәкче булам,—диде ул, күз карашын нигәдер кафенең инде караңгылык каплап өлгергән тәрәзәләренә күз текәп.—Төннәрен Ай ни өчен якты була да, ни өчен нурланып балкый шулай? Сәбәбе бик гади: чөнки Җир шарының теге ягыннан аңа Кояш нурлары кайтарылып төшә. Әгәр Ай шушы нурлардан мәхрүм ителә икән, ул—җансыз, караңгы бер планетадан гайре берни түгел! Аны беркем дә күрмәс, аңа карап берәү дә соклана алмас иде... Менә шушы хакыйкатькә таянып, мин ирләрне—Айга, хатын-кызны—Кояшка тиңләр идем, дусларым. Хатын-кызның яктысы, нурланышы, җан җылысы төшкәнгә күрә генә без, ир-ат заты, тормыш галәмен яктыртып, үзебезнең барлыкны сиздереп-күрсәтеп торабыз. Шушы чагылыш булмаса, без дә караңгы, җансыз бер планета... Яшәсен әниләр, апалар, сенелләр, яшәсен хатын-кызларыбыз! Егетләр, хатын-кызлар хөрмәтенә аягүрә басуыгызны сорыйм...

Мондый бик тә урынлы, ачык һәм төгәл әйтелгән сүзләрдән, ай-һай, кем генә баш тарта алыр иде микән? Рюмкалар чәкәште, калак-чәнечкеләр җинелчә зеңләп алды.

Сагынышканнар. Күбесенчә эш, гаилә мәшәкатьләре белән уза торган игезәк, бертөслерәк көннәрдән соң бүгенге очрашу чынлап та бәйрәмчәрәк, яңачарак төсмерләргә манчылган иде шул. Музыкага, вальска ияреп, бүген тормыш-яшәеш тәгәрмәче дә кызуырак әйләнде шикелле бу минутларда.

Залдагы шау-шулы, мавыктыргыч манзара эчендә вакытның узганын сизми дә калдылар. Сәгать төнге унике тулган, китәргә, таралышырга да вакыт җиткән икән.

Саубуллашулар тәмамлангач та, Данил белән Сиринә ничектер үзеннән-үзе якындагы урам чатында бергә тукталып калдылар. Очраклы түгел булса кирәк, аларның тыенкы гына бер-берсенә тартылуы табын артында утырганда ук икесенең күз карашлары белән күпмедер дәрәҗәдә ныгытылган иде.

—Сиринә, төн уртасында үзенне генә калдыру килешмәс, рөхсәт итсәң, өеңә кадәр озатып куяр идем. Әллә...

Данил, әйтәсе сүзләрен бер мәлгә күнеленнән барлагандай, тукталып калды. Нәрсә әйтергә, ни аңлатырга тели икән? Сиринә бу сорауларга җавап

эзләрлек хәлдә түгел иде, бары тик:

—Рөхсәт, әйдә, такси тотабыз,—дип кенә әйтә алды. Әмма, үч иткәндәй, төнге шәһәр урамында бер генә такси кисәге дә очрамады.

Августның кичке салкынча җиле әллә кайдан авыр болытларны куалап китергән дә тротуар чокырындагы юкәләрнең ябалдашын чайкалдыра. Болытлар белән томаланган караңгы күк җиргә якынайган, шәһәр өстенә тәмам ишелеп төшкән иде. Кинәттән толым-толым салынып, коеп-коеп эре яңгыр яварга керешә! Төнге күләгәләр эреде, күз ачып йомган арада яңгыр пәрдәсе артына кереп югалды. Биек йортларның калай түбәсенә һәм асфальтка бәреп яуган яңгыр шавы гына ишетелә. Биектәге су торбаларыннан савылып тишкән нәни гөрләвекләр, еландай бөтерелеп, аяк астыннан шуыша...

Ышыкланыр урын да юк ичмасам! Ярый әле Данилның сумкасыннан зонтик килеп чыкты: кулчатырны җәеп, икесенең баш өстенә күтәрделәр. Икесенә—бер зонтик, бераз ышыкланыр өчен әлегә ул да ярап тора. Бер зонтик астына сыенышкан арада ничектер култыклашып та өлгергәннәр икән, аяклар исә үзеннән-үзе алга таба атлады.

—Мин гостиницага урнашкан идем, моннан ерак түгел. Чаптык шунда!

Ни хикмәттер, Сиринә каршы килеп бер сүз дә әйтә алмады. Хәер, шаулап торган шушы яңгыр астында тарткалашып, бәхәсләшеп торуның мәгънәсе бар идеме соң? Кунакханә ишеге төбенә килеп басканнарын сизми дә калдылар. Звонок бирү белән баш киеме алтынсу тасма белән коймаланган швейцар карт ишекне ачты. Берни сорашмады, артта аның: «Вот яңгыр бу...»—дигәне генә колакка чалынып калды.

Баскычтан икенче катка сүзсез генә күтәрелеп, Данил урнашкан бүлмә каршысына килеп туктадылар. Төн уртасында кинәт чылтыраган телефон авазыдай, ачкыч шылтыраганы ишетелде...

Итәге юешләнгән плащларын, кипсенгә дип, урындык җилкәсенә элделәр. Дамир суыткычтан шампан шәрабе һәм шоколад чыгарган арада Сиринә, читкәрәк китеп, мангаен бүлмә тәрәзәсенең салкынча пыяласына терәде... Төн эченнән актарылып килгән кисәтүле аваз булып, тәрәзәгә яңгыр тамчылары бәрә дә бәрә, бүгенге төнгә билгесезлек төсмерләре өсти. Шәһәр эчендә тома караңгылык, ерактагы йолдыз яктысыдай, урам утлары гына берән-сәрән тоныклык җемелдәшә.

Данилның Түбән Кама шәһәрендә гимназия директоры булып эшләвен, гаиләсе барлыгын ишетеп белә иде Сиринә. Болар хакында төпченүне кирәк санамады ул. Аның үзенең дә гаиләсе бар лабаса. Заводта инженер булып эшләүче иренең Мәскәүгә бер атналык командировкага китеп баруы нәкъ менә шушы вакытка—аларның ун елдан соң очрашу көненә туры килеп торуын кара син... Юкса кинәттән яңгыр коя башламаса, әгәр иренең ерак сәфәрдә чагы булмаса, ул шушы чит бер кунакханә почмагына килеп керергә батырчылык итәр идеме соң? Юк, әлбәттә. Менә әле хәзер дә күңеленең кайсыдыр бер төшендә эчке курку, дулкынлану, икеләнү катыш тартышулы уйлар бөргәләнә...

Кыскасы гына, бераздан дөньяны аңлатып булмастай онытылу, җиңеллек, кайнар дулкын басып китте, яңгырлы төн аларны үз кочагына суырып алды... Сөйләшү-бәхәсләшү, уен-көлке сүзләрне, бер-берсенең карашларын—боларның барысын, барысын да караңгы төн һәм яңгыр җиле билгесезлеккә, ерак-еракларга үзе белән юып алып китте...

***

...Тәгәрәп, үлеп йоклаганын да сизми калган. Уянып китсә, баштарак кайда икәнлеген аңышмыйчарак торды, стенадагы обойның чит-ят бизәкләре аны тиз арада чынбарлыкка кайтарды. Йә Хода, нишләде ул?.. Күрәләтә үз аягы белән гөнаһлы дөньяга атлап керде түгелме?..

Иртән Сиринә гел икенче кеше булып уянган иде. Бөтен күзәнәкләре, урындыктагы кулмәгенә үрелгән бармак мускулларына хәтле: "Нишләдең син, нишләдең..." дип кычкыра иде шикелле. Күзәнәкләрдән күтәрелеп менгән әлеге кайтаваз салкын бер курку булып күңеленә үрмәләде: "Нишләдең, ни кылдың син?.." Үз күңеле белән көрәш, киеренке халәт, мәхәббәт һәм нәфрәт арасында адашып калган бу төн, бер уйласаң, мең еллык вакыт үлчәменә тиң иде. Аермасы шунда—тыныч вакытлар белән чагыштырганда мондый төннең озынлыгы бүтәнчәрәк тамга белән үлчәнә. Уянгач та Сиринә үз күңелендә ике "мин"нең яши башлавын, ике хиснең тартышканын аермачык тойды. Аларның берсе—бүгенге төн өчен балаларча оялу, уңайсызлану булса, икенчесе—талгын гына яшәп яткан көннәренә кинәттән бәреп кергән үзгәреш, кылычтай үткер яңалык тойгысы иде. Аны яңадан салкынча бер курку биләп алды: әгәр уянып, Данил аның белән сөйләшә башласа, ничекләр итеп күзенә карар да, нindиерәк сүзләр белән җавап бирер ул? Канатларын каера-каера, аны хәзер фәкать бер уй үзенә йолкып алды: күзенә чалынмаска, тизрәк качарга, ераккарак китәргә бу тоткынлыктан!

Сиринә үзен бик тиз кулга алды, таралып йоклап яткан ярым-ялангач Данилны уятмаска, шауламаска тырышып кына саклык белән киенгәннән соң уч төбедәй ак кәгазь битенә калтыранган куллары белән шулай да берничә сүз язып өлгерде:

*Мине эзләмә, шалтыратма!*

Гомер булмаганны, андагы хәрефләр калтырча килеп чыкты бугай. Өч сүздән торган, сыңар каурый кисәгедәй талпынган язуны өстәл өстендә калдырды да, чит-ят күзләр күреп калмасын дигәндәй, ашыгып-кабаланып тизрәк урамга чапты.

Өенә кайтып кергәч тә тизрәк ваннага ашыкты, ни өчен икәнен үзе дә аңлап бетермәстән, озаклап юынды, тавыш-тынсыз елаганнан соң гына азмы-күпме тынычланып киткәндәй булды. Бу—үз-үзеңне аклау, күрәләтә алдарга тырышуның бер чагылышы иде булса кирәк.

***

...Соңгы вакытларда Сиринә менә ничәнче көн инде яңадан төш белән өн арасында саташып яши башлады. Үз уйларың эчендә бикләнеп яшәргә язмасын икән ул, борчуларын йотып йоклаганга күрә, еш кына йөрәге какканга да дертләп уяна. Бүген иртән дә әнә шундыйрак билгесез халәттә уянды ул... Йокылы күзләрен ачар-ачмас килеш хәрәкәтсез ятканда йөрәгенең тибешен аермачык тойды. Әле яктырып та өлгермәгән, шушы ярымкараңгылык чыбылдыгында ниндидер көч аны әле күккә тарта, әле төпкә, тирәнгәрәк өстери, икенче бер дөньяга күчерә шикелле... Теге чактагы яңгырлы төн аны көннәр, айлар эченнән һаман да эзәрлекләп килә. Шушы бер төн аның бөтен тормышын, язмышын тамырдан үзгәртеп ташларга җыена лабаса? Ике кеше арасындагы йомык сергә шаһит бердәнбер төн...

Чү! Авырттырган, төн йокыларын качырган, берьюлы ачы да, татлы да тоелган могҗиза төймәләнеп килә түгелме? Карынында бала ралгысы типкәнен тойган саен шатлана да, вәсвәсәле уйлар чоңгылына кереп бата Сиринә. Сәбәбе—ире Габделхәй белән ун ел чамасы бергә яшәп ятсалар да, күпме генә өметләнмәсеннәр, ни хәл итәсен—балага уза алмады ул. Икесе дә табибтә булып карадылар, ике врачнын берсе «гаеп»не ирендә дип тапты (ни әйтсән дә, ракета гаскәрләрендә хезмәт иткән егет); икенчесе исә Сиринәгә бала табарга сәләтсез дигән мөһерне сукты. Менә, ышанып йөр син врачларга, кайсысынын сүзе дөресрәк икән дип гажизләнүдән күз аллары карангыланды. Ятимнәр йортыннан берәр баланы асрамага алырга ниятләре дә юк түгел иде, тик бу эш төрле сәбәпләр аркасында һаман сузыла килде.

Бәлки, хәерлегә булгандыр, әнә бит Сиринәнең тәне-жанында нинди могҗизаи үзгәрешләр башланды... Ләкин әлеге яналыкнын четрекле, котылгысыз тәкъдире шунда хи, Ходай кушып туачак сабый тәнендә иренен түгел, Данилнын каны агачак бит... Табигать ирексездән бүләк иткән бу серне ире әлегәчә белми, билгеле. Курыкмыйча, шикләнмичә ни жанын белән әлеге серне мендәр бүлешкән иренә чын дөресен ничекләр сөйләп-анлатып бирмәк кирәк? Чын дөресен сөйләп бирсән, Сиринәсен анлармы ул, анын халәтенә керә белерме? Аяктан егарлык мондый яналыкны кабул итәрлек көч табармы-юкмы үзендә? Бу хәбәрне күтәрү, аны йөрәгенә якын алырга егетлеге житәрме? "Сөйрәлчек?"—дип йөзенә бәреп әйтсә, хурлыгын кая куярсын...

Агачка үз туфрагы, карлыгачка үз күге дигәндәй, Сиринә көтмәгән-уйламаган жирдән тәкъдиренә төшкән бу авырлыкны күтәрергә бөтен барлыгы белән әзер. Әмма, ни генә дисән дә, үзен генә белгән ялангач хакыйкать белән шулай күзгә-күз карап яшәү бер дә жинелләрдән түгел. Әлеге яшертен йөкне шулай карусыз гына үз жилкәсе, үз дәрманы белән алга таба да ялгызы гына тартып барырга көче-жегәре житәрме анын?

Соңгы вакытларда Сиринәнең эчке дөньясы әнә шундыйрак ачы да, татлы да булган сораулар шаукымында бәргәләнә иде.

Теге чакта, янгырлы төннән сон, жир тишегенә керердәй булып ничаклы оялган, үзен-үзе ташка бәреп ватардай булып ничекләр өзгәләнгән иде бит ул! Шул чактагы халәте өчен, бәлки, бик тә урынлы һәм дөрес булгандыр мондый каршылыклы хиссият. Ә хәзер... хәзер инде Сиринә узкәндәгеләр өчен үкенми дә, оялмый да... Данилны да гаепләми, чөнки ул чакта анын дөньяга яратып карый белгән бәрхет күзләрендә комсызлык, әрсезлекнен тамчысы да юк иде. Үзендәге яшәү хисен, якты өмет очкыннарын Сиринәгә дә бүләк иткән ул—бары шул...

Тик менә утлы-кайнар бер сорау көн арты көн узган саен Сиринәнен күнелен һаман саен ныграк яндырып төшә: дөресен сөйләп бирсә, тормыш юлыннан янәшә атлап баручысы аны дөрес анлармы? Анлармы...

Ни кылырга, кайсы юлны сайларга? Ул, мәгълүм бер әкиятнең каһарманы сыман, ике юл чатында басып тора иде.



Лилия
Сәгыйдуллина

## МИЗГЕЛЛӘР ЙОЛДЫЗЛЫГЫНДА

***

**Мин сүзләрдән туйдым—буш сүзләрдән:
Әйтерсең лә, төшсез чикләвек.
Алтын җыям дисәм—бакыр гына.
Энҗе таптым дисәм—чүп тә чүп.**

**Кайда була төшләр-төшенчәләр?
Корт төшәме? Яшен аламы?
Әллә алар сүзнең хуҗасына—
Кешеләргә охшап барамы?**

**Бәлки, гаеп—миндә? Күңел күзе
Үткенләгән барса югалтып,
Буш катламнар арасында бик еш
Чын саф табыш булмый очратып.**

**Мин сүзләрдән туйдым—буш сүзләрдән!
Тик күрмимен сүзләр гаебен.
Сүз-көзгедә—вакыт чагылышы:
Күзәтәмен заман гарибен.**

**Бу көзгене вакыт юшкыныннан
Тазартырга кемнәр алыныр?
Каләм көче генә җитәр микән?
Галәм көче микән табылыр?**

### Томан

**Югарыда, шиксез, кояш та ул...
Бездә, әнә, кояш югалтылган.
Берәр эшне бозган сабый сыман
Мыштым гына ята гамьсез томан.**

*Лилия* СӘГЫЙДУЛЛИНА—*шагыйрә; "Абага чәчәге", "Мизгелләр йолдызлыгы"*

Җан өшеткеч шушы сорылыктан
Нур иясе барлык онытылган.
Ябынган да дөнья бетон юрган,
Мәрткә охшаш йокысына чумган.

...Томан таратырга җил кирәкме?
Кояш күрү безгә иртәрәкме?...

***

Әллә сөю чып-чын булмаганмы?
Әллә хәтер бик үк «уңмаганмы»?—
Онытылган...

Җилкән ясап сердәш-йолдызлардан,
Ай-көймәдә икәү йөзгән чорда
Ай тотылган.

«Син!»—дип сукмый йөрәк сәгате дә,
Аңлап булмый әле сәбәбен дә—
Ул ватылган.

Мәңгелеккә тиңдәш һәрбер минут
Бер кадерсез чүп-чар әйбер кебек
Югалтылган.

Тик буйсынмый өнгә төшләр генә!..
Күпме таңнар төшләр күмә-күмә
Яшь йотылган?!

Ваклый торгач тормыш тегермәне
Сөю орлыкларын көне-төне—
Онта калган.

Син хәтердән уелгансың, димим,
Мин бит анда үземне дә күрмим—
Онытылган...

...Сөю ахры шулай яратылган:
Соңгы чиккә җәя тартылган да—
Ук атылган.

## Серенада

Тәрәзәмне ачып куйдым—
Җәйнең бүген соңгы төне.
Күңелемә үрим әле
Хушлашулы сихри көйне.

Төн сулышы—серенада.
Уйланылган һәр нотасы.
Автор, шиксез, виртуоздыр:
Табып булмый бер хатасын.

Тынлык оркестры уйный.
Ә ай—аның дирижеры.
Үз күрепме, күз кысалар
Музыкантлар—йолдызлары.

Хушлаш, диләр, җаең белән,
Курыкмый көт көз-кышыңны.
Мәңгелек яз килер, диләр,
Үз итәлсәң шушы моңны.

Минем җанда—серенада:
Һәм хушлашу, һәм тантана.
Төн һичкайчан соңгы булмый!
Төн үлгәч тә, көн башлана.

***

Ай чакырды күлгә—
Баш тартмадым:
Үз күреп лә дәшә
Җан тартканым!..

Колач ташлап йөздем—
Тоталмадым.
Төпкә кадәр чумдым—
Табалмадым.

Күрдем Айның күлдән
Югалганын.
Күл-көзгедә дулкын
Уйнаганын.

Челпәрәмә килде
Хыялларым:
Юк, булмаган ахры
Ай—язганым!..

Ярга чалкан аудым,
Өмет җуеп:
Күктә Ай тирбәлә,
Моңга тулып...

***

Минме шигырь язам? Әллә шигырь
Яза мине? Яза... Төзәтә...
Таңгәллекләр эзли... Аермалар...
Үзе аша мине күзәтә.

Җиһан тибешен тоя шигырь җаны.
Шул ритмны ала үзенә.
Дөнья аһәңенә аваздашлар—
Рифмалары сафка тезелә.

Памук* белән тәмуг, Ван Гог һәм йог
Парлап килә шигырь янына.
Эйфель башнясы күк җанга якын
Басу капкасы да табыла...

Кошлар моңы, җиһан тыны—кайсы
Яшәү чыганагы шигырьгә?
Хак җавапны белсә шигырь белер.
Онытa серне кайчак шагыйрь дә...

* Памук Орхан—төрек язучысы (Нобель премиясе лауреаты—2005).

*А. Тимергалинның "Татарга нигә кагыйдә?" дигән мәкаләсе (2007, № 7) буенча сөйләшү дәвам итә.*

Халисә Ширмән

# КУЛ ЯЗГАННЫ КОЛАК ИШЕТСЕН

Соңгы елларда безнең әдәби телгә рус теленең тәэсире бик нык көчәйде. Бу тәэсир лексикада гына түгел (лексика, ягъни сүз катламында ул күптән бара инде), синтаксиска да күчте. Җөмлә төзү тәртибе безнең күз алдыбызда үзгәреп ята. Рус һәм татар телләрендә җөмлә төзү тәртибе төрле. Билгеле булганча, татар телендә ия хәбәрдән алда килә; аергыч, хәлләр, тәмамлыклар үзләре ияргән сүздән алда киләләр; аныклагыч аныкланмыштан соң урнаша. Бу сүзләрнең туры тәртибе дип атала. Җанлы сөйләмдә, эмоциональ сөйләмдә, лирик әсәрләрдә, шигырьдә (гадәттә, логик басым яисә ритм-рифма таләбе буенча) сүзләр кире тәртиптә дә урнашырга мөмкин. Хикәя җөмләдә исә сүзләр туры тәртиптә урнашырга тиеш. Шушы гади генә кагыйдә бик еш бозыла башлады, рус теленнән мәгънәсез калькалар (турыдан-туры тәрҗемә итү) активлашты.

"Кайсы якларга сәфәр тотасыз?" (куда путь держите?), минем вазифага керми (не входит в мои обязанности)", "Нидә соң эш?" (в чем дело?), "Бүген кич буш буласызмы?" (вы свободны вечером?)—мондый төрдәге җөмләләр нормага әйләнеп бара. "Син нәрсә", "сез нәрсә", "ә нәрсә" сүзтезмәләре рус теленең "Ты что?", "а что?"сыннан турыдан-туры калька—тәрҗемә. "Миңа уйларга кирәк". Бер караганда, дөрес төзелгән җөмлә кебек күренә, тик бу да рус теленнән кергән калька: "Мне надо подумать" дигән җөмләнең тәрҗемәсе. Саф татар телендә "уйлап карармын", "ярар, уйлармын" вариантлары әйтелергә тиеш. Фигыльдә инфинитивның -рга/-ргә формасы активлашуы, аның функцияләре киңәю шулай ук рус теле белән бәйле күренеш. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң башланган бу процесс хәзер инде норма дәрәҗәсенә күтәрелде, тик әле XX гасыр башында да бу форма белән параллель рәвештә -мак/-мәк кушымчасы кулланылган.

Алынмалар мәсьәләсе аерым урында тора. Татар теленең гомумхалык сөйләменә караган катламында рус-Европа алынмалары күпләп кулланыла башлады. Аларның әйтелеше дә хәзерге заман урта буын татар кешесе өчен кыенлык тудырмый—барыбыз да урта белемле, рус телендә яхшы аралашабыз. "Компьютер, больница, расписание"—мондый сүзләрне халык сөйләменнән кысрыклап чыгару мөмкин түгел кебек күренә. Хәзер инде "персидәтел, бүлнис, бальнис" әйтелешләрен дә сирәк, моны олылар сөйләмендә генә очратабыз. "Расписание"ның "җәдвәл", "компьютер"ның "санак" булуын татар факультеты студентлары гына беләдер, мөгаен, ләкин "расписание" татарныкы булмаган кебек, "җәдвәл"е дә татарныкы түгел, алынма сүз. Бер алынманы икенче алынма белән алмаштыру үзен никадәр дәрәҗәдә аклый икән? Рус теленең йогынтысын болай гына тоткарлап буламы? Халык сөйләмендә кулланылмаган гарәп-фарсы алынмаларын әдәби әсәр телендә куллана алабызмы? Гомумән, әдәби телдә гомумхалык теленә кереп киткән рус алынмаларын куллану мәслихәтме, әллә аларның гарәби игезәкләрен куллану кирәкме? "Председательме", әллә "рәис"ме? Әдәби әсәр язганда мондый сораулар белән очрашмаган язучы булса, ул бер дә тел турында уйланмаган язучы инде. Мин үзем, мәсәлән, соңгы 10-15 елда газета-журнал битләрен чуарлаган авыр аңлаешлы гарәби

алынмаларны әдәби телдә куллану ягында түгел, тик барыбер "больница" сүзе урынына "хастаханә", "поликлиника" урынына "шифаханә" сүзләре күңелгә якынрак—гомумхалык телендә кулланылмаганнарын белгән хәлдә дә, әдәби телнең югарылыгын, зәвыгын күрсәтү өчен мин аларны әсәрләрем теленнән төшермәячәкмен, минем геройларым "мәктәп" сүзе барында беркайчан да "шкулга барам" дип сөйләмәячәкләр. Шул ук вакытта "вертолет"ны мин "боргалак" дип, "колхоз"ны "күмхуҗ" дип яза алмыйм.

Әлбәттә, татар телен саклап калу мәсьәләсе бары тик дәүләт җитәкчеләре тарафыннан гына хәл ителә алачагын аңлыйм. Татарстан җөмһүриятендә рәсми эш кәгазьләре ике телдә—татар һәм рус телләрендә алып барылган очракта гына татар теле дәүләт теле буларак гамәлгә куела ала. Балалар бакчасында, мәктәптә тел өйрәтү бик кирәкле эш, ләкин мәктәпне тәмамлап чыкканнан соң укучыда татар теленә ихтыяҗ бетә һәм тел, астрономия дәреслегендәге "парсек" термины кебек, кирәксез бер истәлек булып кала, хәтердән җуела яисә шәһәр гаиләсендә "кухня теле"нә әверелә.

Әдәби телгә караган тагы бер мәсьәлә—сүзләрнең вариатив язылышы.

Бер үк сүз төрле авторлар тарафыннан төрлечә языла, нәшриятларда төрлечә басыла (мәсәлән, газета, гәҗит, газет, гәзитә). Әгәр без мондый төрлелек юлыннан китсәк, "әдәби язылышны бөтенләй югалтачакбыз. Әдәби тел ул—нормага салынган тел. Анда сүзләрнең язылышы аерым кагыйдәләргә буйсына, норма таләпләренә җавап бирә. Бу кагыйдәләр тел галимнәре тарафыннан эшләнгән, тел комитеты, дәүләт, мәгариф системасы тарафыннан расланган булырга тиеш. Җәмгыятьтәге аерым бер кеше генә бу кагыйдәләрне төзи алмый, андый вәкаләткә ия түгел. Кызганычка каршы, безнең шушы таләпләргә җавап бирә торган орфографик сүзлегебез 1983 елда ук дөнья күргән. Шуннан соңгы, ягъни егерме биш елга якын вакыт арасында телгә кергән сүзләрнең язылышы ачыкланмаган. Димәк, "рус телендәге "компьютер" сүзен татар телендә ничек язарга соң?" дигән сорауга җавап табып булмый, чөнки безнең расланган, рәсми рәвештә кабул ителгән яңа орфографик сүзлегебез юк һәм бу сүз үзенең рус телендәге язылышы белән татар әдәби теленә кереп урнаша.

Күңелне тырнаган тагы бер мәсьәлә (шул ук орфография белән бәйле)—тыныш билгеләрен кую мәсьәләсе. Менә кайда ул анархия, менә кайда ул иркенлек! Кем ничек дөрес дип уйлый, шулай куя тыныш билгеләрен. Олылар сөйләвенә караганда, элек автор куйган һәр өтерне, һәр сызыкны җентекле рәвештә тикшергәннәр, кагыйдәгә туры килүкилмәвен ачыклаганнар. Бәхәсле очракларны нәшрият коллективы җыелып хәл иткән. Шагыйрь әйтмешли, "аһ, үтте-китте ул вакытлар..."

Айдар Хәлим мәктәп әдәбият дәреслекләренең аянычлы хәлдә булуы турында язды. Ә тел дәреслекләре ни хәлдә соң? Чыгарылыш сыйныф укучыларыннан "Иң авыр имтихан нинди фәннән?" дип сорасагыз, күпләре "Татар теленнән" дип җавап бирәчәк. Безнең татар теле дәреслекләре укучыда татар теленә карата өнәмәү ("нәфрәт" дигән сүз дә тел очында гына, анысын ук әйтмик инде) уята. "Нишләп башка телләргә (инглиз, француз, алман телләренә) өйрәтү дәреслекләре алай катлаулы түгел?" дигән сорауны еш ишетергә туры килә. Җавап гади: бу дәреслекләрнең авторлары—укытучылар. Галимнәр түгел! Һәр көн бала белән (студент белән түгел!) күзгә-күз очрашып, аның телгә сәләтен, мөмкинлеген аңлаган, тойган, шуннан чыгып аңгәмә корган укытучылар. Мин үзем галим кеше, һәм бу юлларны язу миңа җиңел түгел. Минем аңлавымча, мәктәп дәреслеген язганда галим консультант булырга тиеш; күп дигәндә, укытучы белән автордаш була ала, чөнки ул—югары уку йортлары өчен дәреслек язучы галим. Тел өйрәтә торган мәктәп дәреслеген галим кеше язарга тиеш дигән карар кайда язылгандыр—белмим, тик ул, күрәсең, химия-физика кебек төгәл предметларга аналогия рәвешендә кабул ителгәндер. Бәлки, бу хезмәт укытучылар үзләре дәреслек язмаганга күрә галимнәргә

йөкләнгәндер. 5нче сыйныф укучысы татар телендәге кушымчаларның (аларның санын күз алдына китереп карагыз) сүз ясагычларга, модальлек белдерә торганнарга, бәйләгечләргә бүленешен яттан белергә тиеш! Модальлекнең нәрсә икәнен академик грамматика язучылар белә инде, әлбәттә. Ә ни өчен аны 11 яшьлек бала белергә тиеш ди әле!! Аваз белән фонеманы аеру, синтетик һәм аналитик иярченле кушма җөмләләрдәге тыныш билгеләрен ачыклау, ассимиляция-диссимиляция күренешләрен тану 14-15 яшьлек бала күңелендә тудырган телдән куркуны инде берничек тә бетереп булмый. Иң кызыгы шунда: татар телен сөйгән бала югары уку йортының татар теле яисә журналистика факультетларына укырга кергәч, яңадан шул ук мәктәп программасын үзләштерә башлый, чөнки татар теле буенча мәктәп программасы белән вуз программасы нигездә тәңгәл килә...

Соңгы елларда басылган кайбер китапларны, журналлардагы әсәрләрне укыгач, "Бу әсәрен язганнан соң, автор бер генә тапкыр булса да үзе укып чыкты микән?" дигән сорау туа. Кайбер очракта халык мәкален үзгәртеп, "Кулың язганны колагың ишетсен" дип әйтәсе килә, чөнки телдәге кытыршылыкларны бетерүнең иң кулай юлы—язганны кычкырып укып карау. Телнең аһәңен ишетеп кенә тоеп була...

Мин бу мәкаләмдә моңа кадәр ишетелмәгән өр-яңа фикерләр әйттем дип уйламыйм. Бу фикерләрнең кайберләре язучылар, шагыйрьләр, әдәбиятчы яисә телче галимнәр тарафыннан әйтелеп, кайберләре аерым коллективларда сөйләнеп тә, җәмәгатьчелеккә чыгарылмаган. Тәкъдимем шундый: һәр язучы, һәр шагыйрь, һәр укытучы, һәр әдәбият сөюче укый торган "Казан утлары" журналында әдәби тел тәнкыйтенә багышланган рубрика—әдәби тел дәресләре ачып җибәрергә кирәк.

---

## *Алхәбәр*

"...Әй, ул көнчелек корты!.. Шул вакытта ул Низаметдин күнеленә тәмам баш-аягы белән кадалды. Кадалды да, башта жанын өшетте, аннары анын канын, каны белән бергә анын барлык жылылыгын, жылылыгы белән бергә анын барлык хисләрен, хисләре белән бергә анын бөтен кешелек сыйфатларын суырырга тотынды.

Һәм Низаметдин бераздан көнчелек дигән шул явыз кортнын агулы теле булган шик белән йөзгә-йөз торып калды. Ана һаман тәскә-биткә чибәр, сау-таза, гел күбәләктәй очынып кына йөри торган (бәхетеннән шулай очынып йөрүе дип кем уйлаган?!) жинел сөякле Гөлфирәсе моннан сон инде анын белән тормас, аны ташлап китәр дә башкага чыгар шикелле тоелды"...

**Әхәт Сафиуллиннын "Сынаулар аша"** повестенда бер бәхетле гаиләгә килгән авыр сынаулар тасвирлана. Ир белән хатын да сынауларны уза алырмы?

Әсәрне алдагы саннарнын берсеннән укыгыз.

Шамил
Монасыйпов

# ТӘРӘЗӘГӘ ЯЗМЫШ ЧИРТКӘНДӘ...

*Яшәүгә һәм Азатлыкка шул лаектыр—*
*Алар өчен көн дә яуга кергән кеше.*
Гёте. «Фауст».

Безнең музыкабыз тарихында күркәм, кешелекле, гамьле, борчулы, барыннан да бигрәк югары художестволы иҗат үрнәкләре биргән композиторларыбыз байтак. Шулар арасында—ике гасыр урталыгын кичкән һәм иң якты, масштаблы шәхес буларак танылган Ренат Еникеев исемен беренчеләрдән атап китәсе килә.

Ул милли музыкабыз мәйданына гаярь рәвештә атылып килеп керде, драматик һәм фаҗигаи-героик темаларга мөрәҗәгать итеп, инде 60нчы елларда ук совет идеологларының консерватив карашларына каршы килеп, татар инструменталь музыкасын бөтенсоюз һәм дөнья сәхнәсенә чыгару бәхетенә иреште.



Үзенең идея-художество позицияләрен яклап иҗат итү чорында Р. Еникеевка партия-дәүләт машинасы тарафыннан булган бик күп басымнарны кичерергә туры килә. Ләкин мондый басымнар, башкачарак фикер йөртүгә каршы юнәлгән киртәләр, матур-татлы вәгъдәләр аның рухын сындыра алмый. Хакимият белән тарткалашу нәтиҗәсендә композитор корбанга бара, күп кенә рәхәти мөмкинлекләрен югалта. Бу җәһәттән аны караңгылык патшалыгын, шуның тарафдары Мефистофельне җиңгән, әхлакый кыйммәтләр өчен фидаиларча көрәшкән Фауст белән тиңләргә мөмкиндер.

Р. Еникеев иҗатында инструменталь музыка аерым бер урын алып тора, чөнки ул бу жанрны үзенчә яңа биеклеккә күтәрде. Аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә соната, баллада, виртуоз шәлкемнәр хәзинәсе, фортепиано өчен өр-яңа формалар барлыкка килде.

Композиторның симфоник музыка өлкәсендәге уңышларын да аерым күздән кичерергә кирәк. Болар—шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә багышланган вокаль-симфоник Поэма, Рапсодия, Крылов мәсәлләре буенча пьесалар циклы һ. б. Ул ансамбль музыкасы жанрында квартет, трио, скрипкалар төркеме өчен дә вакыйгага булырлык, мактауга лаек әсәрләр иҗат итте.

Ул шулай ук күп кенә җырлар, романслар, хор өчен язмалар авторы.

Композитор иҗатында дөнья музыкасы культурасындагы югары казанышлар үзенчәлекле чагылыш таба, кешелек рухын танып белүдәге еләззма буларак зур сәнгать әсәрләре дәрәҗәсенә күтәрелә.

## Балалык һәм үсмер еллары

Ренат Еникеев 1937 елның 13 июнендә Казанда белемле, зыялы нәсел гаиләсендә туа. Әнкәсе ягыннан туганнары—Тукай шәҗәрәсенә якын кешеләр, руханилар. Әткәсе ягыннан Р. Еникеевнын тамырлары атаклы Каргалы Темниковлар нәселенә барып тоташа. Композиторның балачагы авыр шартларда уза: бер яше тулган чагыннан ук әтисез үсә ул. Яшьтән үк мөстәкыйль булырга өйрәнә. Ин яраткан һөнәре—гармоника һәм курайда уйнау. Дүрт яшендә үк инде балалар бакчасы ансамблендә уйный, концертларда катнаша.

Үрнәк саналган 12нче татар мәктәбендә укый, осталыгын үстерә һәм инде 9 яшендә үк республика күләмендәге конкурста җинүче дип табыла. Әйтергә кирәк, әлеге конкурс рәисе, атаклы гармунчы Фәйзулла Туишев малайның кулларыннан тотып өскә күтәрә һәм: «Менә мина алмаш!»—дип, соклануын белдерә.

11 яшендә Ренат музыка мәктәбенә укырга керә, Казанга Шанхайдан килгән оста педагог Н. Карукестан дүрт ел дәвамында дәресләр ала. Шушы елларда үк инде малайның композиторлык сәләте ачыла. Әйтик, ул фортепиано өчен «Бабай», «Монсу жыр» һ. б. пьесалар иҗат итә. Ныклы белемгә ихтыяж сизеп, үсмер танылган педагог—Х. Вәлиуллин, И. Шәмсетдинов, Ә. Бакиров кебек композиторларны тәрбияләгән Ю. Виноградов классына музыка училищесына килә, осталыгын камилләштерә.

Таләпчән, Европа һәм татар музыкасын яхшы белгән бу педагог белән якыннан аралашу булачак композиторны иҗат серләренә тирәнтен якынайта, композиторлык һөнәренен заманча техник чараларын үзләштерүгә ярдәм итә. Талантлы һәм эшкә сәләтле булуы нәтиҗәсендә ул зур уңышларга ирешә. Инструменталь пьесалар, җыр һәм соната, хор, балет сценасы... 1955 елны М. Җәлил сүзләренә беренче татар романсларыннан булган "Бәхет"не яза. М. Хөсәен һәм К. Нәҗми сүзләренә иҗат ителгән хор язмалары әле дә булса үзләренен сәнгати кыйммәтләрен югалтмаган.

## Язмыш белән бергә-бер

Композитор, пианист, музыка белгече буларак җитди тәҗрибә туплаган Р. Еникеев 1956 елны Казан консерваториясенә килә, композиция һәм фортепиано бүлекләрен сайлый. Яна остазы профессор А. Леман ана ирек, мөстәкыйльлек бирә: чөнки, яшь кенә булуына карамастан, егетнең иҗади планнары зурдан.

Җимешләр озак көттерми: Р. Еникеев—беренче ин зур әсәрен—скрипка, альт һәм виолончель өчен трио яза (1958). Совет музыкасында сирәк булган бу жанр әсәре ансамбль сәнгатен үстерү юнәлешендә ачыш, зур яналык була. Милли мәдәният тормышында революцион бер күренеш дип бәяләсәк тә бер дә арттыру булмастыр. Бу әсәрдә Шәрык белән Гарепнен органик бөтенлеге, бердәмлеге, киләчәге, күпавазлы фикерләү рәвеше, тагын бик күп янача сыйфатлар, аерым алганда совет чорына хас чикләнгәнлек, пафос, трафаретлыктан югарырак күтәрелү авазлары тынлаучының ихтирамын яулый.

Күз алдына китерегез: шигъри бизәкләргә төренгән, тирән драматик кичерешләргә, капма-каршылыклар дөньясына, инде азагында шатлыклы авазлар һәм җиңү белән тәгәлләнгән рапсодия! Болар бөтенесе 1948 елны чыккан мәгълүм карар—партиянең «музыкадагы формализм» дигән бәясенә каршы килә торган янача революцион караш.

Мондый батырлыкны өстәгеләр, әлбәттә, гафу итмиләр. Әлеге әсәр, Татарстан композиторларының чираттагы съездында янгыраганнан соң, бик каты тәнкыйть

утына эләгә. Янәсе, шат яшәп яткан халыкка, җәмгыятькә каршы «нотка»лар ничек инде бездә булырга мөмкин? Музыкаль әсәрне тикшерү, анализлау барышында Мәскәүдән (!) килгән функционер Мариан Коваль, сәнгатьтә партиялек дигән принципларга таянып, яшь композиторга беренче булып һөҗүмчән чыгыш ясый. Заманында атаклы Шостаковичны формализмда, ясалмалылыкта гаепләгән тезислар татар егетенә дә эләгә. Мәскәү вәкиленнән соң ТАССРның культура министры да чыгыш ясый һәм «мондый» композитор Дәүләт консерваториясендә калырга тиеш түгел дип ачыктан-ачык белдерә. Шуларга каршы Мәскәүнең музыка белгече Н. Шумская чыга. Ул яшь композиторны француз язучысы Ромен Ролланның «Жан Кристоф» дигән романы герое белән чагыштыра... Романда сәяси ирония белән язылган шундый юллар бар:



*Фортепианода үсмер Ренат уйный. 1950 ел.*

«Мәдәниятнең сулышын, ничек яшәп ятканын да аңламаучы чиновниклар, сәясәт һәм финанс белән шөгыльләнүдән тыш, җәмгыятьнең рухи халәте белән идарә итәргә тырышып сәнгать әһелләренә эт оясы, муенчак һәм ризык тәкъдим итәләр икән, монардан да хәтәр һәм аяныч хәл юк. Ләкин Кристоф өйрәнү-дрессировкага бирелә торганнардан түгел. Ул нинди дә түрәнең үзенә акыл сатканын, музыканы ничегрәк язарга кирәген кабул итә алмый, чөнки сәнгать сәясәткә караганда төплерәк әзерлек сорый".

Тормыш бара бит, һәр нәрсәне үз урынына куя. Р. Еникеевнын әлеге триосы бөтенсоюз сәхнәсенә чыга, хәтта Балтыйк буе республикалары сәхнәләрендә яңгырый.

Шагыйрь әйтмешли, юкка түгел, юкка түгелдер...

Мәскәү консерваториясе профессоры Г. Литинский җитәкчелегендә безнең композиторыбыз кыллы квартет-партита яза, полифония һәм пентатоника өлкәсендә яңа ачышлар ясый.

Р. Еникеевның диплом эше—симфоник әсәр, оркестр белән фортепиано өчен язылган концерт. Бирегә инде галәмнән агылып төшкән зур фәлсәфәләр алгы планга чыга: мәхәббәт, яшәү-яшәеш, караңгы көчләргә каршы көрәш, матурлыкка, яктылыкның җиңәчәгенә ышаныч... Соңрак бу әсәр Татарстан композиторларының пленум утырышында башкарыла. Мәскәүдән килгән хөрмәтле кунак Д. Шостакович, авторны котлап, аның әнисенә болай дип мөрәҗәгать итә: «Сезнең улыгыз бик талантлы, саклагыз аны!»

Мондый дәрәҗәле бәя теләсә кемгә бирелми, әлбәттә... Ләкин көнчеләр, партия куштаннары һаман табыла тора. Татарстан композиторлар союзында «Еникеев эше» дигән нәрсә ачып җибәрәләр. Шөкер, Д. Шостаковичның катнашуы нәтиҗәсендә бу эшне ябалар. Ренатның әсәрләрен, Мәскәү сәхнәсендә тыңлаганнан соң, Россия күләмендәге М. Глинка премиясенә тәкъдим итәргә фикер туа.

Ләкин безнең җирле түрәләр һаман да "сакта" уяу тора: талантлы композиторның бөтенсоюз сәхнәсенә күтәрелүеннән куркалар. Ясалма аппарат үеннарыннан соң концерт та, премияләргә эш тәкъдим итү дә өзелә, композитор эшеннән дә, аспирантурадан да китәргә мәҗбүр була. Хәтта кулга керә язган квартир да тәтеми кала.

## Текә тауга күтәрелү

Академик даирәгә сыешмаган Р. Еникеевне, талантын яхшы белгән кешеләр, ниһаять, Камал театрына эшкә чакыралар. Кайчандыр биредә татар профессиональ музыкасына нигез салучы С. Сәйдәшев эшләгән иде. Ләкин аннан соң оркестр таркалган, музыкага бәйле спектакльләр әзәйде... Р. Еникеевка бары Н. Исәнбәтнең «Гөлжамал» пьесасына гына көй язу мөмкин була. Әмма музыкаль бизәлеш шәп килеп чыкса да, ул файдаланылмый, чөнки музыка өчен гонорар бер түрә музыкантка түләнеп беткән була.

Менә шундый хәлләр!

Егет эшсез калмый, аны филармониягә чакырталар. Г. Рәхимкулов, И. Шакировларның концерт бригадасында пианист-аккомпаниатор буларак биш елдан артык элеккеге Советлар Союзының бик күп почмакларын гизә. Әлбәттә, Илһам Шакиров белән хезмәттәшлектә яна жырлар туа, боларны санап чыгу кирәкмәстер. Алар бөтенесе табигатькә, хатын-кызга, Ватанга дан жырлый.

Вакыты суккан минутларда нота кәгазьләренә күпләр анламый торган серле тамгалар төшә. Яктылык өчен көрәш бара... Беренче соната, икенчесе, өченчесе... Яхшылык белән явызлык көрәшенә багышланган бу сонаталар СССР кимәлендәге күп кенә корифейлар тарафыннан югары бәяләнә. Композиторның Икенчы кыллы квартеты Германия, Италия, Япония, АКШ һ. б. илләрдә зур уңыш белән бара. Кол Гали заманнары, Болгар темасы аның игътибарыннан читтә калмый.

Ә инде Муса Жәлилгә багышланган вокаль-симфоник поэмасы өчен аңа 1983 елны Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирелде.

Композиторның күренекле шәхесләр, бигрәк тә атаклыбыз Бакый Урманче белән дуслыгы хакында аерым бер кыйсса язып булыр иде, мөгаен. Ә инде аның Тукайга, Сәйдәшкә ижади хөрмәте турында әйтәсе дә юк. Сәйдәш әсәрләренең сайланмасын, «Сәйдәшстан» дигән китапны нәшер иткән шәхес буларак, ул бигрәк тә хөрмәткә лаек.

Сүзебезне түгәрәкләр алдыннан шунысын да әйтик, 21нче гасырга композитор яна идея-проектлар белән аяк баса. Болар—халкыбызның музыкаль фольклор байлыгы, төрки халыклар моныннан хәзинәләр, яшь талантларны үстерү юнәлешендәге эшчәнлек һәм башкалар.

Халкына хезмәт итү, якты идеаллар өчен көрәшү—үзе бер бәхетләр ул. Композиторның шигаре Назыйм Хикмәтнең кыска гына шигъри юлларына бик тә тәнгәл килә шикелле:

*Син дә янмасаң,*
*Мин дә янмасам,–*
*Кем таратыр бу дөньяның*
*караңгысын...*



Кадим
Җәмитев

# КАЙТТЫМ ГЕРМАН ҖИРЕННӘН...

СКУЛЬПТОР ЯЗМАЛАРЫ

*Узган ел без укучыларыбызны Әзһәр Шакировның «Артист язмалары» белән таныштырган идек. Инде менә—«Скульптор язмалары»...*

*Журналыбызның редколлегия әгъзасы Гәрәй Рәхим, кульязма белән танышканнан соң, үзенең бәяләмәсендә болай дип яза: «Автобиографик язманың балачак елларын сурәтләгән баш өлешләрендә әле безнең һәм башка әдәбиятларда да күренмәгән, бөтенләй көтелмәгән һәм гаять трагик вакыйгалар сурәтләнә. Монда Икенче бөтендөнья сугышы китереп чыгарган фаҗигале хәлләр белән бергә, ана белән бала арасындагы шулай ук фаҗигале мөнәсәбәтләр турында да сүз бара...»*

*Әйдәгез, иң яхшысы, язманың үзе белән якыннан танышып китик булмаса.*

*Аңа кадәр автор турында беркадәр мәгълүмат бирәбез. Җәмитев Җәлил улы Кадим (1946).—сынчы, рәссам, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Төп әсәрләре: «Су анасы», «Тукай», «Замандаш» (татар мәдәният әһелләренең портретлары сериясе). Казанның Солтангалиев мәйданындагы «Хөррият» һәйкәле (1996). Оренбургта куелган М. Җәлил һәйкәле. Иҗат үрнәкләре белән чит ил күргәзмәләрендә катнашканы да бар. 1973 елдан Мәскәүдә яши.*

## Кереш сүзем

Кемнең генә истәлекле түгел дә, кайсыларыбызның гына кадерле түгел бала чаклары!

Минем үткәннәрем дә үзем өчен шулай ук истәлекле-кадерле. Һәрберебез үтә торган табигый вакыт берәмлеге эчендә мин дә үттем аны. Әмма яшәү-яшәеш шартлары гына табигый була алмады...

Бик тә үзенчәлекле, гыйбрәтле (!) узды минем балалык еллары. Үзенчәлекле булуы ачлыктан черек бәрәңге коймагын яисә ферма күгәрченнәрен өтәләп ашауда гына түгел. Хәтта ки өч яшемә кадәр КОЯШ күрмичә түбәни асты тормышын кичерүләрдә генә дә түгел.

Ходай биргән балачагым анамнан күргән игътибарсызлыкта, ялгызлык-караңгылыкта үтте: шунда... башка сыйдыра алмаслык яман гадәтләр үзләштереп, адәм баласына охшамаган бер карачкыга әверелә яздым мин...

Башта... үлем белән яшәү арасында, аннары кабат КЕШЕ кыяфәтенә кайту

өчен озак көрәшергә туры килде мина... Озак көрәшергә. Нык көрәшергә.

Кайсы вакытларны үз-үземә бик еш әйтеп куям: «МИН КҮРГӘННӘРНЕ БЕРӘҮГӘ ДӘ КИЧЕРЕРГӘ ЯЗМАСЫН!»

...Остаханәм янында гына балалар бакчасы. Килгән яисә киткән чакларымда андагы сабыйларның чыр-чу авазларына колак салмый булдыра алмыйм.

Шәһәрдәме, юлдамы, авылдамы—көр күңелле яшьләрне күреп куанам. Аларның шатлыклы йөзләренә карап, ирексездән үз яшьлегемне күз алдыма китерәм...

Рәхәтен-михнәтен, газап-хәсрәтен кичереп, оҗмах-тәмугларда да булырга туры килде миңа. Анамның «мәрхәмәте» белән. Кичергәннәремне, баштарак, искә алырга да кыенсындым. Тора-бара... уйландыра башлады. «Түзга язмаган» мондый нәрсәне язып ятудан мәгънә бармы?

Менә... кулымда каләм.

Күз алдымда—кичергәннәрем. Каршымда... бер йотым хәмер. Башымда—ничек, нәрсәдән башларга дигән газаплы уйлар...

Яза башлыйм—бармый: йомарлыйм-атам, йомарлыйм да атам. Каләмнәрем бер-бер артлы алышына... Чөнки язардай нәрсәнне билгеле бер "калыпка" салырга кирәк. Ә бу—минем өчен чит басу кыры. Ана "керү" җинел эш түгел.

Шулай да... кыенлыклар белән булса да, үтә тырышып, нәрсәдер "укмаштыра" алдым шикелле... Чытырманлырак телле булса да, укмаша алган язмама дөнья күрергә насыйп булыр, ул укучыга барып житә алыр дип өметләнеп калам.

Кемгәдер кызыклы була алыр бу язмам. Кемдәдер кызгану, икенче берәүләрдә нәфрәт хисе уятыр... Әмма күпләр, бик күпләр ӨЧЕН ГЫЙБРӘТЛЕ дә булыр дип уйлыйм. Аналар өчен бигрәк тә...

## АТАМНЫ БЕЛМӘДЕМ, АНАМНЫ КҮРМӘДЕМ...

### Ике бүлемтекле "өн"

Ин курыкканым КЕШЕ булды минем. "Өй алды ишегенә берүк кагыласы булма—бусагада КЕШЕ утыра, эләктереп кенә алыр!" Тәпи йөри башлауга, әбием мине шушы сүзләр белән кисәтә башлады. Бераздан: "Тәрәзә янына якын килә күрмә, КЕШЕ күрер дә алып китәр үзенне!"—дип куркытып торды. Чабулап йөри башлаганнан сон әбием бу сүзләрне мангаема туктаусыз тукып килде.

Минем өчен КЕШЕнен тегесе дә, монысы да коточкыч иделәр: әллә ничә куллы, әллә ничә күзле-колаклы иттереп күзаллый идем мин аларны. Кешенен башкасын—икенче төрлесе барлыгын, ягъни әбием токымыннан була алуын белми идем әле мин. Минем өчен ике нәрсә генә яшәп килде:ара-тирә яныма кереп чыгучы әбием дә, сирәк-мирәк кенә күренгәли торган газиз анам... Сонрак тагын бер җан иясе өстәлде—"Карак мәче" барлыкка килде (аны әбием шулай дип атый иде). Ул өй тирәсендә сирәк булды—күбрәк тышта, күршеләрдә. Минем "өн"емә—чоланга ул тагын да сирәгрәк керә иде. Керсә дә төнлә генә... тычкан ауларга.

Тора-бара "кече җан Ияләре"—яна дусларым барлыкка килде. Аларны мин үзем аулап җыя торган булдым. Чоланның төрле урыннарында була иде алар; ярыкларда, кечтеки генә тәрәзә өлгесендә, идән астында. Әбиемнең бәрәнге ташый торган зур гына чиләгеннән дә тота идем мин аларны: кара таракан, олы чебен, күбәләк, бүлмә тараканы, кыргаяк, шөпшә, тагын әллә нинди бөҗәкләр... Алар минем тере уенчыкларым булдылар.

Минем өчен "әби", "әни" төшенчәләре әле ул вакытта юк. Әгәр дә әбиемнең йөзен-кыяфәтен ярыйсы гына күзаллый алган булсам, анамныкын—бөтенләй юк. Кайчакларны аны озаграк күрми торып, танымыйча куркып та куяр идем. Андый очракларда тавышы коткара торган булды: күрәмсен, тавыш, төс-кыяфәткә караганда, хәтергә яхшырак сеңеп кала...

Әйе, әбием яныма кергән чакларны, ул нәрсәдер әйтер иде, сөйләшергә чакырыр иде. Улаудан тыш, адәм баласына хас сүз рәвеше авызымнан чыкмагач (бу инде өч-дүрт яшьләремдә), "Әби" дип кенә булса да әйтә белергә вакыт инде!"—дип мыгырданып чыгып китәр иде.

Куркытылган ике КЕШЕдән тыш, мине бернәрсә дә өркетмәде, беркем бернәрсәдән дә тыймады. Ирекле булдым мин... Нигә ул ишек-тәрәзә янына ыргылырга ди миңа? Ике бүлемтектән торган менә дигән "өнем" була торып! Әле... өченчесе дә бар: мич башы ул. Анысында мин кышын торам. Минем шикелле якты дөнья күрмичә яши торган сукыр тычканның өне дә болай ук түгелдер әле...

Беренче "өн"ем—чолан. Анда һәрвакыт энгер-менгер хакимлек итә. Җиләс. Салкын да түгел, эссе дә... Рәхәт. Кояш нурлары анда беркайчан да үтеп керми, керә дә алмый. Ул—кояшсыз як. Кояш булмаган көннәрдә андагы әйберләрне мин капшап кына "күрәм". Ә алар күп түгел: бер кырыйда он тәпәне, тамчы тамып торудан саргаеп беткән ниндидер төргәк, йоклаганда аска җәю өчен кулланыла торган иске-москы. Түрдә—керәчин белән капкачсыз иске генә чиләк.

Чолан дигән нәрсә бөтенләй тәрәзәсез була алмый. Баш сыярлык кына безнекендә дә бар иде ул. Аңа ике кадак белән пыяла кыйпылчыгы беркетелгән. Аның ян-якларыннан, тышта һава тыныч булмаганда, җил улап тора. Дистәләрчә еллар буе Адәм кулы тимәгәнлектән, ул тузан-чебен кунудан тапланып беткән. Шуңа күрә, булган яктылык та аның аша саркып кына керә: андагы әйберләрнең томанлы шәүләсен генә күрәсең. Тышта кояш булганда инде ул әйберләрнең рәвеш-төсен дә чамаларга була.

Икенче "куышым"—чолан асты. Әле ул тавыклар "өе" дә. Тавыклар мине күрәдерме-юктырмы, мин аларны күрмим: анда дөм караңгы. Күзенә китереп төртсәләр дә күрмәссең. Караңгылыкка да ияләшәсең икән ул. Күз ияләшкәчтен, мин анда бөтерелеп чабулап йөри башлыйм. Менә шунда курыкынган тавыкларның сизелер-сизелмәс шәүләсен күреп алам. Алардан ничектер балкыш булган кебек тоела иде.

Тере уенчыкларым белән уйнаганны яратмый иде әбием. Күрсә, барын да чыгарып кына ата. Их, әби, әби... минем өнем—аларның да өне бит! Аларны аулыйсы да юк, кулга үзләре үк килеп керәләр—ычкындырма гына! Тычканны баштарак мәче тотып "бирә" иде. Аннары мин аны үзем ауларга өйрәндем. Мәчегә карап... Мәчечә.

Безнең өчен ул чолан белән чолан асты оҗмах почмагы булды.

Әйе... КИЛМЕШӘК булып кайтып кердем мин анам иленә. Әгәр дә бу хәлне белеп алган булсалар, мине кайберәүләр шундук теткәләп ташлаган булыр иде... Герман җиреннән кайтып кер дә, нинди мәрхәмәтлек көтәргә ди? Герман сугышы күпме хатын-кызларны ирсез—тол калдырды. Инде исән калганнары да—йә чулак, йә бөтенләй аяксыз. Алары да эчүгә сабышып беттеләр. Тән җәрәхәтләре төзәлсә дә, күңел җәрәхәтләре әле һаман шул килеш бит.

...Анам андагы тормышны ташлап кайтырга җыенмаган да. Ике яктан (СССР белән Германия арасында) килешүгә кул куелып, чыгарга рөхсәт булуга карамастан. Хикмәт шунда ки, анам сәер төш күреп, төшендә аны туган җире үзенә чакырган. Мин, биш-алты айлык бала, атамның әмере буенча калырга тиеш булганмын. Үзе белән бергә эләккән иптәше ярдәме белән урлап алып китеп кенә мин дә анам Иленә кайтып керә алганмын. Иптәш кызы немец телен белгән. Нинди кыенлыклар аша булгандыр ул андый сәяхәт юлын үтү—миңа мәгълүм түгел. Шунысын гына яхшы беләм: мин ул юлны кәрҗин эчендә посып-йоклап үткәргәнмен.

Туган җирләренә кайтып төшкәч, анам—үз авылына, ә мин юлдашының авылына кайтканмын. (Мине үзе белән үк ияртеп алып кайтса, кеше шундук беләчәк бит. Рәхмәт ул апага—мине атна-ун көн чамасы үз баласыдай караган, үзенең күкрәк сөтен ашаткан. Аның үз баласы булып, тиздән үлеп киткән икән. Аның үтенече белән миңа Кадим кушканнар: үз баласына шундый исем кушылган икән...)

Авылда шулай бит ул: кечкенә генә яңалык та яшен тизлеге белән тарала. Ышанмаслык хәл—минем белән алай килеп чыкмады. Әш—анамның бәрәр атнага соңрак кайтып керүендә генә дә түгел... Бала, никадәр генә тыныч булмасын, күз аша беленмәсә, колак аша беленә. Тавыш бирми калмый ул. Аннан тыш, тере баланы, әйбер яшергән кебек яшереп булмый: кар базында ябып тотмассың бит... Бөтен хикмәт шунда, безгә кеше кермәс иде. Дошман итүдән түгел (анамның үзен, туралардан тыш, әсирлектә булып кайттың дип чит күрмәделәр кебек), ярлы булудан. Мунча хәтле генә менә-менә ишеләм дип торган йортка кем керсен ди? Кеше бит ул... ни дә булса әҗәткә сорап, йә билгәмгә, йә кич утырырга керә. Кем дә булса кереп утырырлык урындык дигән нәрсә дә юк иде бездә. Ә әҗәткә алып торырлык... Кисмәктәге су белән бакчадагы туфрак булса гына инде. Сирәк-мирәк чыгып куйган тавышны ишеткән кеше—ә ул улаган кебегерәк була иде—"йорт иясе улый", "герман җиреннән кайтканга күрә йортына җен ияләшкән" дип кабул итәрләр иде.

Анамның күкрәктән аерганын яхшы хәтерлим. Имүдән аерылып кына тынычланып булмый бит әле, гадәтләнгән нәрсәгә барыбер үреләсең... "Житәр, әнә теленне суыр!.."—диде анам. Мина шул житә калды да... Аннары, кыен булса да, ана "боерыгын" үтәми булмый бит.

Шулай итеп, "һөнәрләр" үзләштерү китте. Тиздән мин телне эт кебек салындырып дереллдәтергә өйрәндем.

Сигез яшь булганда, телне асылындырып туктаусыз дереллдәтү нәтиҗәсендә, янак сөяге ярыйсы гына үсеш алды, иягем сизелерлек дәрәҗәдә алга бүлтәеп чыкты. Ияк белән бергә—аскы тешләр дә... Ас белән өске тешләр бер-берсеннән ераклашты. Тел басымы астында аскы тешләр кәкре-сирәк булып үстеләр. Телем исә, тешләрне кысканнан соң да, иркен чыгып йөри алды. Чөнки анда баш бармак сыярлык аралык хасил булган иде.

Әйе, КИЛМЕШӘК булып килдем мин бу дөньяга...
Атамны белмәдем.
Анам да ана була алмады.
КИЛМЕШӘК.

Моның ише кимсетү сүзләре туктаусыз яңгырап торды. Нәгълә т төшкән шушы сүздән дә ачырагы булдымы икән? Аны барысы да тукып торды—олы да, кече дә.

КИЛМЕШӘК...

Бу сүз генәме?.. Чыгышымны билгели торган күп кенә "тамгалар" да өстәлә иде әле. "Нимес малае", яисә "Нимеч көчеге", "Уйнаштан туган", "Гитлер калдыгы", тагын әллә нindиләре...

Герман җиреннән Сталин иленә кайтып төшү анама җиңел булмагандыр. Солдат булмаса да, Донбасстан куылып тоткынлыкта булган бит. Бу хакта сөйләргә дә ярамагандыр. Яраган очракта да анам сөйләргә-сөйләшергә яратмады. Ул үзенең фермасын белдә дә аннан арынган вакытларында—әйе, аңларга да була—табигать биргән женси мәсьәләләрен канәгатьләндерүдә булды. Ул хакта күпме ызгышу-талашулар чыгып торгалады. Чоланда гына түгел, бу мина чолан астында булганда да ишетелә иде. Әбиемне дә аңларга була: АНА булып та өйдә тормагач, баласын карамагач, ни хаҗәте бар аның бу тормышта?!

Адәм нәселенә кагылышлы булсам да, мин кыргый бер җан иясе булып үстем. Эчке торыш белән дә, тышкы кыяфәт белән дә. Кабат Адәм кыяфәтенә кайту өчен мина күп газап-кыенлыклар аша үтәргә туры килде...

Шулай да түбәни тормышын кичергән ул еллар минем өчен кайгысыз-хәсрәтсез еллар булды.

## Ниһаять, кояшның үзен күрдем!!!

"Беренче мәртәбә крокодилны кайчан күрдең?" дип сорау артык гаҗәпсенү тудырмас. Ә менә "Кояшны беренче тапкыр кайчан күрдең?" дисәң... Ананы күреп үскән кебек, кояшны да бәләкәйдән күреп үсәсең. Шуңа күрә сорауны болай кую мәгънәсез булыр иде.

Миңа аны... БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР күрергә туры килде, ниһаять! КОЯШның үзен чын-чынлап күрү иде ул... Миңа өч-дүрт яшь тирәсе.

"Күрмәгәнне күрәсе килә, күргәннән качасы килә", ди халык. Күрмәгәнне күрәсе килү, гомумән, җан иясенә хас нәрсә. Күргәннән качасы килмәде минем. Башта мин тышкы дөньяга (күрелмәгән нәрсәгә) ыргылмадым: әллә бар ул миңа, әллә юк. "КЕШЕ"дән куркып кына түгел. Минем үз дөньям кызыклы иде. Идән асты тормышының ямен таптым мин. Дөм караңгыда, әнгер-меңгердә, кысанкылыкта.

Үсә төшү белән "күрмәгәнне күрәсе килү" уяна башлады. Ягъни, Тышкы Дөньяны, монарчы күрелмәгән, күз алдыма да китерә алмый торганын. Аннары, "өннәрем" дә тарая башлады...

Тышкы ДӨНЬЯ...

Нинди серле КӨЧ анда!

Менә шушы КӨЧ, көннәрнең берендә, бөтенләй ярамаган-тыелган нәрсәне эшләп ташларга мәҗбүр итте мине. Ә ул... өйалды ишегенә аша гына...

Әбиемнең өйдә юклыгын чамалап, моңа кадәр якын да килә алмаган өйалды ишегенә юнәләм. Тынымны кысып кына... "КЕШЕ" утыра бит анда!! Ә билгесезлек... барыбер тарта. Берсе җәлеп итә, икенчесе—өркетә...

Ишеккә килеп көчсез кулларым белән келәне күтәрергә тырышам. Ә башымда бер үк уй: КЕШЕ тотып алып китсә?! Үз-үзенне саклап калу тойгысы кисәү агачы алып "коралланырга" мәҗбүр итте мине. Кабат келәгә ябышам. Тартам—ачылмый. Тагын тартам. Тагын, тагын—юк! Күзләремне шатырдатып йомам да тагын тартам. Бу юлы бөтен көчемә. Авыр ишек шыгырдап ачыла башлый... Ишек төбендә "сагалап утыручы" да, кулымдагы кисәү агачы да—һәммәсе онытыла. Күзләрем үзеннән-үзе ачылып китә. Баш сыярлык ярыктан, күзне сукырайтырлык булып, КӨЧЛЕ ЯКТЫЛЫК ыргыла... Нәрсә бу? Аякларым мине мәҗбүри рәвештә тупсага алып чыга. Каршымда... аңлата алмаслык әллә нинди гаҗәеп күренеш: үзе ак та, якты да. Чуар да, кайнар да, һавалы да, җиләс тә... Яшь белән тыгылып, күзләрем йомыла. Яктылык үзенең кайнар "колачы" белән мине хәзер инде уратып-төреп үк ала. Авырлык белән керфекләремне ачам—күзем чагыла. Өстәвенә, яшь белән тулган. Күзләрем кабат йомылганчы күреп өлгерәм: вакыт-вакыт әбием әйтеп ала торган ишек алды дигәнендә йөгереп үтә алмаслык никадәр киң мәйдан. Менә нинди икән ул ТЫШКЫ ДӨНЬЯ!

Каршымда нәрсәләрдер арлы-бирле йөри. Кыткылдаганнарына игътибар итеп алам—тавыклар булырга тиеш. Шулвакыт башым үзеннән-үзе күккә—югарыга күтәрелә. Маңгаемны, баш түбәсен нәрсәдер кыздыра башлый. Кысык күзләрем күккә төбәлеп кала... Битем кыза. Анда, күктә—янып торган түп-түгәрәк бер НӘРСӘ. Яшьләнүдән шешенеп бетсә дә, күзләремне ала алмыйм—шундый кызык, шундый матур, шундый рәхәт... Күзгаласы да килми. Күзләрем мәҗбүри йомыла. Карауны барыбер дәвам итәм, хәзер инде күз кабагы аша. Әйтерсең, каршыма кызгылт-саргылт пәрдә элеп куйдылар. Күктән килә торган яктылык агымы йөземне пешерә, башны әйләндерә.

Шуннан соң, бертуктамый яшь агып, күзләремне бөтенләй ача алмыйча авырып яттым. Озак вакытлар. Саташып-ыңгырашып...

КОЯШ белән танышуымның нәтиҗәсе менә шулай булды. Аягыма басу белән—кабат ишек төбенә... Әбием күрмәгәндә. Бу юлы КОЯШ дигән нәрсәгә бигүк карарга тырышмасам да, карамый булдыра алмадым. Ничек итеп шушындый МОГҖИЗАга карамый түзә аласың, ди!

Мине кабат эссе сукты. Кабат аудым. Озак кына авырып ятып, кабат торып чыктым... Бу юлы инде әбием көчсез иде—тыя алмады.

## Көтелмәгән кунаклар

Шул чакны көтелмәгән хәл: каяндыр безгә кунаклар кайтып төшә. Әбием үзе дә аптырашта—яшь чакларын исәпкә алмаганда, андый хәл булмаган. Кунак булып килеп чыгарлык ерак туганы да юк сыман... Шәүләләрен ерактан күрүгә үк качтым. (Минем өчен әле Кешенен "алып китә" торганы гына мәгълүм.) Алар мине күреп өлгермәделәр. "Йортта ниндидер сәер Җан иясе барлыгын гына сизенделәр. Алар, ирле-хатынлы, бер-ике көннән артыгын тора алмадылар. Шуннан соң авылыбызда "туганы гарип баласын калдырып киткән" дигән хәбәр таралды. Күпмедер вакытларга минем "чыгышым" шулай булып калды да.

Әлеге хәл авыл халкын баштарак кызыксындырмады. Аңа минем кыяфәтем, торышым-тотышым кызыгырак иде. Көтмәгәндә килеп чыгып, үземне күргәч, башта әтәч белән тавыклар да куркып качты. Аларны беренче мәртәбә бөтенләе белән күрү бик кызык булса да, үзем дә куркып читкә тайпылдым. Аларның гәүдә, баш-аяк рәвешен, өстәвенә, төсле итеп күрү—ә алар барысы да чуар булып чыктылар—минем өчен көтелмәгән нәрсә булды. ("Чуар" сүзен аңламасам да, әбиемнән ишетеп белә идем. Аннан тыш, "ак", "кара" сүзләрен ишеткәләдем...

## Әбиемнең усал әтәче һәм ташлар...

Усал булып чыкты ул әбиемнең әтәче. Бөтен әтәчләр арасында дан тотарлык булгандыр. Каршысына чыгучының һәрберсенә—кеше буламы, хайван-ерткыч буламы—шундук ташлана иде. Мине ул беренче мәртәбә яхшы гына талады: гаҗәпләнү катыш югалып калып, мин саклану чарасын да күрә алмадым. Икенче мәртәбә очрашканда—бу инде үзара ярыйсы гына иялләшкәч булды—мин аны эләктерә алдым. Аңынчы башымны тырмапчукып канга батырырга өлгерде ул. Явызны тар гына сулы лаканга ташладым. Җилпенеп карый, чыга алмый. Шулай ята торгач хәлсезләнеп бата башлады. Нәфрәтем көчле булса да, коткардым. Шуннан бирле без аның белән дус булып киттек. Дан тотуы белән үзеннән ким булмаган Әрүл дигән күрше этенә дә ташланган иде ул. Сугыш киткән. Овчарка нәселеннән булган Әрүл ("орел" сүзеннән) тешләпме, аягы белән бәрепме, аның канатын имгәткән. (Ярый, озакка бармады, төзәлде.) Икенче мәртәбә Әрүл үзе ябырылган моңа. Күнеле кимсенептерме, әтәч тегенең борынын чукып алган... очып куныл. Шуннан соң Әрүл аңа юл куя торган булды.



*Су анасы (Болгар кызы). 1990. Кадим Жамитев эше.*

Көннәрнең берендә әтәч-батыр күршеләребезнең яшь әтәчен талап үтерә язган. Канга батырган. Бер күзен чукып чыгарган. Хәтерлим: әтәчебезнең гадәттән тыш батыр булуы аркасында зур тавыш купты. Кыен хәлдә калган әбием, мескен әтәчебездән колак кагарга—суйдырырга мәҗбүр булды.

Безнең баскыч төбендә зур-зур таш кисәкләре тора иде. Байтак өлеше йомшап, чәрдәкләнеп беткән иде аларның.

Әбиемнең сөйләгәне буенча, аның этисе «урта хәллеләр»дән булган. Сөрү җирләре, байтак кына мал-туарлары, атлары... Төннәрнең берендә, чираттагы

җәйнең бик тә кызу чорында, авылда ут чыккан. Андый чакта җил дә булмый калмый: шул җил белән ут таралып, ярты авыл кырылган. Әлеге "урта хәлле" хуҗалык та шушы афәт учагына эләккән. Үзләре котылып калган калуын... Ә менә мал-туардан ике баш сарык кына исән калган. Әлеге ташлар да көчле янгынга дучар була. Тамырына кадәр янып беткән канәфер куаклыгы, янарып китеп, минем яшьлегемә кадәр яши алды. Ул куаклык ишек алдында чирәмле җирдә иде. Чәчәк аткан чакларда авылның бөтен булган яшьләрен үзенә җәлеп итеп торды ул. Аның яныннан үтеп йөрүчеләр, аңа кызыгып, рәшәткә аша үрелеп бирәр генә булса да ботагын сындырып алмыйча үтмәсләр иде. Чөнки, аның чәчәкләре эре, төрле төстә, хуш ис аңкытып әллә кайлардан күренеп торыр иде.

Дистәләрчә еллар буе (ә бәлки гасырлар буедыр да) тупланган байлыктан, булдырылган матурлыктан минем яшьлек чорыма шушы ике генә нәрсә килеп җитә алды: мәшһүр канәфер куаклыгы да, катлам-катлам булып теткәләнеп беткән олы гына ташлар... Бүгенгесе көндә аларның эзләре дә юк инде.

## Мине ярык аша күзәтәләр...

Менә шул ташларның кыйпылчыкларын алып мин бервакытны өстәл, идән ише нәрсәләрне сызгалап бетердем. Аннары баскычка, өйалды ишегенә күчтем. Тиздән капка да, коймалар да калмады. Әлбәттә, болар өчен әбиемнән ару гына эләгә иде. Аркылыга-буйга, кайда түгәрәкләп, кайда бормалы итеп ясый торгач, әллә ниткән сурәтләр дә килеп чыга башлады.

Әбиемә бу "иҗатым" бөтенләй ошамады.

Минем «өн»нән кинәт кенә ишегалдына килеп чыгуым чамасыз кызыксыну тудырды. Коймабыздагы сирәк такталар арасыннан да, капка ярыклары аша да "иҗатымнан" битәр, күбрәк үземне күзәтә торган булдылар. Күрәмсен, кайбер көннәрне күбрәк тә җыела торган булганнардыр—мин аларны ишетәм генә бит. Әбием бу хәлне күреп алып: "Ни пычагыма дип җыелдыгыз тагын, аю биетмиләрдер бит!"—дип, әрләп-куып җибәрер иде. Аннары минем үземне җилтерәтеп алып кереп ябып куяр иде. Мондый ысул белән кәмит карауч ыларны биздерә алмады әбием. Киресенчә, котыртты гына.

Тиздән ишегалды гына мине канәгатьләндерми башлады. Тарайды да ул, күңелсез дә булып китте. Дөнья бит әле ишегалды белән генә тәмамланмый—урам як та бар. Анысы, бәлки, тагын да кызыклырактыр? Ул мине инде күптән үзенә чакырып тора. Әбиемнең туктаусыз әйтеп-тукып тора торган, мине алып китәргә торучы КЕШЕ ишегалдында булмады. Урам якта да юктыр, бәлки, ул КЕШЕ дигәне?..

Чын кешеләргә авырлык белән булса да ияләшә башладым: еректан күргәннәрдән качмый идем инде. Ә менә котмәгәндә якында килеп чыкса... торып кача идем әле мин. Йә койма ярыгыннан, йә үрелеп койма өстеннән күзәтүләр дәвам итте. Аларның бөтен нәрсәләре: баш-гәүдә, аяк-куллары әбиемдәгечә булгач, аларга икеләнеп карау башланды: әбием дә булмагач, КЕШЕ дә булмагач, кем соң алар?

Якты дөньяга акрынлап ияләшә барсам да, Кояшка гына түгел, көн яктысына да озак вакытлар күнегеп булмады. Элеккечә күздән яшь акты, баш авыртты. Кояшта күзне каплап, кояшсыз көннәрне исә туктаусыз бер ачып, бер йомып йөрергә туры килде.

## Тышкы дөнья могҗизалары

ТЫШКЫ ДӨНЬЯга беренче адым минем бакча капкасы аша булды. Анда... тагын да кызыклырак! Барысы да дип әйтерлек ят нәрсәләр: кайдадыр еракта кат-кат тезеп чыккан таяклар эчендә әллә кайларга җәелеп киткән яшеллек (мин ул чакны әле "яшел" төшенчәсен дә белмим, «киртә-бакчаны» шулай ук белмим). Аның артында бер рәткә тезелгән йортлар. Болары аңлашыла: чөнки

алар безнекенә охшаганрак. Алар артында бер-берсенә терәлеп үк торучы олы-биек агачлар. Аннары, тагын ниндидер яшеллек биләмәсе. Алардан да өстәрәк зәңгәрсу сызык—урман...

Баш очымнан гына чыпчыкмы, нәрсәдер очып үтте. Мин... куркуымнан, шунда ук сукмакка сузылып яттым. Аларны гына түгел, карганың очканын да күзәткәнем бар иде инде. Ерактан. Ә менә болай ук... Көтмәгәндә... Озак кына шул рәвешчә күкне күзәтеп ятканнан соң—ә анда күпереп торган, монача күрелмәгән матур-матур болытлар иде—торып, сәяхәтемне дәвам итәргә булдым. Иелә-иелә генә килдем дә киртә астыннан үрмәләп чыктым. Тыкрык иде бу. Кутәрелергә өлгермәдем—ерак кына түгел бер йомры нәрсә... Үзе кыймылдый—тере! Ул нәрсәне күргә, котым алынып мин кирегә... шул ук киртә астыннан. Ә ул—минем арттан. Өйгә атылып килеп кергәнемне сизми дә калдым. "Шул көчектән дә куркырлык булгач, ни пычагыма чыгып йөрисен!"—дигән ачулы сүзләре белән каршы алды мине әбием. Куркудан, көчекнең ни-нәрсә икәнен аера да алмаганмын... Орышты да, чыгып, бакча ишеген нык кына терәтеп куйды әбием.

Әбием ничек кенә орышып куып чыгарып торса да, әрсез көчек минем янга барыбер керә торган булды. Озакламый без аның белән дуслашып китеп, уйный да башладык. Шулай итеп, ул бөтенләйгә торып калды. Баскыч асты аның төп торагына әверелде. Без аның белән күршеләр булып киттек. Бер-беребезгә кунакка да йөрешә торган булдык... Сонрак, мин ана исем дә бирдем. Күзләре өстендә ике ак бөртек булганы өчен "Дурткүз " булып китте ул. Озакламый аның белән аерылышу киләсен, ул аерылышу минем өчен фаҗига буласын мин әле сизми-белми идем. Ә хәзергә әле... без—аерылгысыз дуслар.

## Учак ялкынында... сурәтләр

Дөрләп янган учак янында утырырга яратам мин. Хәтта көннәр буена. Бала чакта да яраттым мин аны. Аның ялкынында әйтә алмаслык әллә нинди Көч бар: бер караганда бер төрле сурәт, икенче караганда икенче сурәт килеп чыга анда. Ниндидер сәер киемнәрдә... Атка атланган сугышчылар... Тавышларын да ишетә идем сыман.

Тере сурәтләр... Андый "сурәтләрне" үзенә дә булдырып карау теләге, гомумән, утның серен белергә теләү шулкадәр көчле иде ки—ә ул ир балаларның барысына да хас дип уйлыйм—әбием югында чырага ут төртеп шуның белән уйнап утыра башладым. Баланың ут белән уйнавы кемгә ошасын—әбием күреп ала да шунда ук шапылдатып арт саныма суга.

Җәйге чорда мичкә-учакка сирәк ягыла бит. Ипи пешергәндә генә. Ипи пешерү ул ике-өч атнага бер тапкыр гына була иде. Ә ут ялкынындагы "атлы сугышчыларны" ешрак күрәсе килә. Учакны үзем "ясап" карарга булдым. Беркемгә дә сиздермичә-күрсәтмичә. Әбиемнән телеп куйган чыраларын, яшереп кенә тота торган шырпысын табып алдым да чолан идәнендә учак ягып җибәрдем. Учак бик тиз дөрләп китте. "Ут аждаһасы" менә-менә килеп чыга дигәндә генә көтелмәгән бер хәл булып алды. Колакларны яңгыратырлык иттереп, бәләкәй генә тәрәзә пыяласы чәлпәрәмә килеп әллә кайларга атылды—күреп калдым. Шул мизгелдә гөрселдәп учак янына ук нәрсәдер килеп тә төште. Аңышырга да өлгермәдем, әлеге котымны алган нәрсәкәй, озакламый хәрәкәткә килеп, шул тәрәзә тишеге аша чыгып та китте. Карасам, учагым сүнгән. Гаҗәпләнү катыш куркудан катып калдым. Ул нәрсә канатланып очып чыгып китте бит—хикмәт менә нәрсәдә!

Мәче башлы ябалак булган икән ул. Күрәмсең, ут үзенең яктылыгы, ялкынының хәрәкәттә булуы белән аны үзенә җәлеп иткән. Көндезләрен яхшы күрмәсә дә балкып торган нәрсәләрне күрми мөмкин түгел бит ана. Әйтик, ниндидер җәнлек иттереп кабул иткәнлер ул аны. Учак янында ук чиләк белән су... Ә ул тәпән өстендә тора иде. Ябалак, атылып керү белән, чиләкне аударган. Ә суы учак өстенә үк туры килгән.

Шунысы уйландырып куя: әгәр дә учак сүнмәгән булса? Янәшәдә генә... чиләк тулы керәчин тора иде бит...

## Тылсымлы такта

Безнең өйдәге әйберләр бармак белән генә санарлык иде. Кайда нәрсә икәнен күз йомып та күрсәтә алдым мин. Инде иректә булсам да, өйдә барыбер сирәк була идем. Кышкы чорны исәпкә алмаганда. Бер керүемдә ят әйбер күрдем. Әбиемнен куна тактасы хәтле бер нәрсә иде ул. Кырыйлары юнып-уеп эшләнгән. Уртасында нәрсәдер ялтырап-уйнаклап тора. Түзмәдем, каршысына ук килеп бастым. Шунда ук кыймылдый торган әллә нинди җанлы сурәт килеп чыкты. «КЕШЕ!» дип уйлап, куркуымнан кырыйга тайпылдым. Өркетсә дә, барыбер үзенә тарта бит: кабат каршысына килеп басам, ул да ялт итеп килеп чыга. Шулай, курка-өркә бер килеп, бер китеп, күпмедер кайнаштым әле мин аның каршысында.

Озак, бик озак вакытлар кабул итә алмадым мин аны үземнен чагылышымдыр дип. Шуннан соң байтак кына еллар буе юкка чыгып торды ул тылсымлы такта. Еллар узу белән акрынлап, ул да, башка әйберләр кебек ук, гадәти әйбергә әверелде. Андагы "КЕШЕ"нен үзем икәнен белдем. "Алтыдамы", "җиделәме" укыганда, ямьсез күрсәтә дип, мин аны ачу белән буяп ташладым. Ул көзге әле хәзер дә исән, тик, аның янына килә алмыйм. Авыр... Тагын ямьсез күрсәтер дип түгел. Килсәм, ятим малай чагым әле дә булса карап торадыр кебек...

## Суда–тычкан, сөттә... бака!

Байтак була иде бездә тычканнар. Югыйсә, аларның урыны инде безнең ише хәерчедә түгелдер. Күрәмсен, ашардай барыбер нәрсәдер булган.

(Баштарак мин аларны мәче ярдәме белән тота идем бит: тоткан тычканын ул башта имгәтә дә уйный башлый, мин аны шулвакыт эләктерәм дә алам. Ә тора-бара үзем тота башладым. Бернинди ярдәмчесез.) Чираттагы тотуымда мин берсе белән кәмит ясарга булдым—чиләктәге суга җибәрдем. Ни эшләгәнен карап тору кызык бит. Әби, бичара, чиләкне чыгарып түкте дә, тычканны, аның нәселен бик каты итеп сүкте. Ә мин бу юлы читтә калдым.

Икенче бер вакыт гөберле бака белән шундый ук кәмит ясадым. Яз житү белән нигез ярык-тишекләреннән килеп чыга иде алар. Су бакасыннан ул бермә-бер олырак та, симезрәк тә. Арып алҗыганчы суда йөздердем дә жилпучтагы онга җибәрдем. Ул озак "уйлап" тормады, сикерде дә он эченә кереп юк булды. Табып, өстерәп чыгарганда ул йоп-йомры күмеккә әверелгән иде. Көтелмәгән нәрсә килеп чыгу миңа ошап китте... "Күмекне" өйгә алып кердем дә өстәлгә әби алдына ук китереп куйдым. Әбинең үзенә дә кызык булды, ахрысы. Ә бәлки ул аны күмекле шикәр (булса да шундые гына була иде) дип кабул иткәндер—кулы белән кагылып карарга булды. Кагылуы кая, "күмек" шунда ук җанланып китеп әбиемнең түшенә сикерде! Әбием шунда коты очканнан хәлсезләнеп калмаган булса, миңа ару эләккән булыр иде... Ничек кенә әле!

"Әүвәл сөткә бака җибәрә торганнар ие. Әчемәсенгә",—дип әбиемнен ничектер әйткәне бар иде. Шулай булуына хәзер мин бик ышанам: баканың тәне салкын бит аның. Ул вакытта миңа мондый нәрсә аңлаешлы түгел... Шуңа күрә мин моны "тикшереп" карарга булдым. Әле генә нигездән тотып алып кергән ике баканы әбиемнең кәҗә сөтенә (чәйгә генә тота иде ул аны) җибәрдем. Бу хәл нәрсә белән беткәндер—сөтне әлеге ике бака эчетмиме генә тота алгандырмы-юктырмы—белмим. Шунысын гына әйтә алам. Бу юлы инде гаепченен кем икәнлеге "ярылып яту" сәбәпле, әбием мине шунда ук эләктереп алды... Аңлашыла: җирдә генә йөри торган бака ничек иттереп бер метрдан артык биеклектә торган сөткә килеп төшсен ди инде—тычкан түгел бит ул!

## Йорт иясе

Белмим, нәрсәдән чыгыптыр—әллә куркыту өчен, әллә "болай гына"—әбиемнең Йорт иясе турында да сөйләгәне бар иде.

Гадәттәгечә, чоланымда торган чак. Бу инде тоткынлыктан азат ителгәннән соң иде. Иртән торып ишекне ачыйм гына дигәндә... ишек үзе ачылып китә. Каршымда... бусагада нәкъ әбием сөйләгән Йорт иясе басып тора. Көтелмәгән хәлдән артыма чигенәм... Кулында аның мунчаладан ясалган куркыныч кара пумала. Йорт иясенең йөзе дә чуен шикелле кап-кара. Күзләре генә акаеп тора. Башында карачкы бүреге. Кайчакларны әбием башында да күргәли идем мин андый бүрекне. Чәчләре тузгыган. Мин болай да ябалак авызымны тагы да киңрәк ачып катып калдым. Ә ул... көтмәгәндә телгә килә: "Нәрсә, терәлеп каттың,—ди миңа Йорт иясе—кая әле, юл бир, әбиеңне күргәнең юкмы әллә!"

Мине бер якка төртеп җибәрде дә эчкә узып нәрсәдер актарына башлады. Бу—әбиемнең төтен юллыгын корымнан чистартып йөрүче булган икән. Язга чыккан саен андый чистартулар ел саен була торган иде шул.

***

Исемсез кеше юк дөньяда... Эт белән сыерның да исеме була. Бирелгән исемемне мин беренче мәртәбә өченчеме, дүртенчеме сыйныфта укыганда гына ишеттем. Гадәт буенча барысы да "Килмешәк", "Немеч" дип кенә йөрттеләр. "Яна" исемгә озак кына ияләшә алмадым: сыйныфташларның берәрсе сирәк-мирәк кенә чын исемем белән дәшеп куйганда—ә укытучыбыз фамилия белән генә дәшә иде—игътибарга да алмас идем. Минем өчен ул әллә минеке атый, әллә башканыкын. Икенче мәктәпкә күчеп, "сигездә" укый башлагач кына төпләнә алды ул газиз исемем.

Мәрхүм әтәчебез ят күргән кебек, урам да ят итте мине. Баштарак гаҗәпләнеп-шикләнеп кенә карадылар. Акрынлап, мин—килмешәк җанга, соңырак—дошманга да әвереллдем. Сынауның дәвамы буларак, китте кимсетүләр, кыерсытулар, үч алулар.

КИЛМЕШӘК...

Башта мин боларны авылда әйтелә торган гадәти сүз иттереп кабул иттем: горурланмадым да, кимсенмәдем дә, әтәчләнмәдем дә. Мин аның нәрсә икәнен «Көрәш мәйданы»на килеп эләккәч аңлый башладым.

## "Көрәш мәйданы"

Тамаша, нинди генә булмасын, һәр җирдә көтеп алына торган нәрсә ул. Авылда бигрәк тә. Элек көч сынашулар-көрәшләр, мәйдан-җыеннар үткәрелә торган булган. Күрәзәче-күз буучылар, кәмитчеләр авылдан авылга йөреп тамак туйдыра торган булганнар. Алар тамак туйдырса, тамашачылар күңел ачкан.

Минем заманда, Сабан туеннан тыш, боларның берсе дә юк иде инде. Алар урынына кино килеп керде. Шулай да, мин бала чакта, киң таралган булмаса да, көрәш дигән нәрсә яши иде әле. Балалар көрәше. Ерак түгел, ирләр җыелыша торган бер урын бар иде. Җыелып, башта алар дөнья яңалыкларын, булган-булмаган хәлләрне, аннары тегесен-монысын сөйләшеп китәләр. Ир-егетләр булган җирдә малай-шалайлар булмый калмый. Менә шунда алар көрәшкә өйрәнәләр инде. Олыларның хуплап көч биреп торуы ярдәмендә, билгеле.

«Көрәш мәйданы»на килеп чыкканда минем барлыгымны, Герман җиреннән килмешәк булып кайтып төшүемне бөтен авыл белә иде инде. Якын килеп тә җитмәдем—качып-посып кына карап торганда, ничектер күреп алып, мине өстерәп "мәйданга" китерделәр. Мин каршылык күрсәтеп тыпырчындым, ыргылдым: алай да булмагач, кайсысыныңдыр кулын канарлык иттереп ярсып тешләп алдым. Ул да ярдәм итмәгәч, уладым, ырладым...

Мине шунда сырып та алдылар. Башта олысы да, кечесе дә тыныч кына сүзсез карап торды. Аннары дәү абзыйлардан берсе:

—Шушы мени инде ул туганнары калдырып киткән кыргый нәрсә?!

—Нишләп инде... Уйнаштан туган үз баласы бит ул аның. Күрше авылда яткан, менә шул,—дип куйды икенчесе.

—Беләсез икән шул нәрсәмне! Германнан алып кайткан килмешәк бит ул...—дип төзәтмә кертә өченчесе.

—Маймыл баласыдыр ул, әнә бит—күзләре баткан, ияге чыккан, теле салынган, үзе бөкре...,—дип, сөйләнде тагын кайсысыдыр.

Шул рәвешчә кызып кына әңгәмә алып барганнан соң "Германнан кайткан нимес көчеге" дигән бер уртак фикергә килделәр. Малайлар өчен мин икенче яктан кызыклы да булып чыктым: төрткәләп, капшап-чиметеп мине "өйрәнергә" керештеләр (алар миннән бермә-бер олырак та әле). Шунда, агайларның берсе карап-карап торды да:

—Ягез әле, малайлар, шушы "нимес калдыгын" сала алырсызмы икән, көрәшеп карагыз әле,—дип, котыртып куйды бик мәкерле генә.

Малайларга шул гына кирәк иде. Берсе, олырагы, мине эләктереп тә алды, шундук егып та салды—каршылык күрсәтергә дә өлгермәдем. Торып басуга, тотып алып икенчесе екты, өченчесе... Бәләкәй булсам да, егетлек горурлыгы инде бар—кимсеттерәсе килми. Каршы торып карыйм. Аңа җавап итеп шундук дөмбәсли башлыйлар. Берничә көннән мин тагын шунда... Тагын уртага эләгәм. Тагын мәҗбүри көрәш китә. Олылар тегеләргә элеккечә көч-куәт биреп торалар. "Булдырдың, Әхмәт малае, яхшы салдың нимес көчеген—шулай кирәк!"—кебек сүзләр яңгырап тора иде анда.

Еш кына авыз-борынны җимереп кайта идем мин. Әбием андый чакларда: «Йөрмәссең, шул кирәк!»—дип, тиргәп кенә җибәрер иде.

## Дүрткүз—минем тереем...

Кызыктыргыч-мавыктыргыч булудан тыш, идән асты тормышының файдалы яклары да юк түгел иде. Ул мине мөстәкыйльлеккә, тормышның төрле кыенлыкларына каршы торырга өйрәтте. Һәрбер җан иясенә хас булган "үз-үзенне саклап калу омтылышы" (инстинкты) мине бик житез йөгерергә дә өйрәтте. Мин, шуңа рәхмәт йөзеннән, еш кына эзәрлекләүче дошманнарымнан котыла ала идем.

Дүрткүз дә акрынлап аңлап минем хәлемә "керә" башлады. Йөзем җимерелеп, кыяфәтсез кайтып керсәм, ул минем каршыма чабып килеп тәнемдә булган җәрәхәтләремне ялар иде дә, «әйдә әле, кирәкләрен бирик», дигәндәй, мине каядыр өстери башлар иде. Дүрткүзнең бер үзенчәлекле ягы булды. Ишек алдыннан аны әллә ниләр "вәгъдә" итеп тә алып чыгып булмады. Бер яктан, бу, аңлашыла да: эт токымына индерелгән "хуҗа биләмәләрен саклау" омтылышы. Икенче яктан, Хуҗаның үзе дә бар бит әле... Әгәр аның Үзен саклый алмасаң, ул вакытта ни хаҗәте бар ул биләмәләрнең? Күрәмсең, шушы нәрсә аны "уйландыргандыр" да.

Тора-бара без аның белән бергәләп тирә-юньне өйрәнә-өйрәнә "көрәш мәйданына" кадәр йөри башладык. Ә ул инде эт халкына хас сыйфаты буенча, алга ыргылып "юл куркынычсызлыгын" тәэмин итеп бара. Әгәр дә барыр юлда мәчеме-тавыкмы очрап куя икән, аларны шунда ук "пыр-р" туздырып кабат чабып килеп җитәр иде.

Ә менә «гәүдәлерәк»ләр—кеше очрап куйганда дүрт аяклы дустым үзе юл бирә: йә ул кая да булса китеп юк булыр, йә чабып килеп минем артыма посар иде. Ә инде "көрәш кырына" җиткәч, үзгәрә торган булды. Ерактан ук "һау-һау-һау!" дип үзен белдерер иде. Әллә аның андагы малайларга сәлам бирүе, әллә... "белеп торыгыз, әгәр дә минем дуска тисәгез!.." дип әйтергә теләве иде. Бөтенләй башкача була иде аның кыяфәт-торышы—әгәр дә мин гаделсез җиңелеп аска эләксәм. Андый чакларны—ә андый чаклар гел дип әйтерлек булып торды—тешләрен ыржайтып ырлап, пыр туздыра алмаса да, ярыйсы гына шурләтә төшеп тамашаны вакытлыча гына булса да туктатырга мәҗбүр итәр иде. Миңа егылган җиремнән торып чабу өчен шунысы да җиткән...

Дүрткүз килеп чыкканнан соң мәчебез үзен икенчерәк итеп тота башлады. Дүрткүз яныма килсә, ул да тиз генә килеп җитеп миңа сыена башлый. Беркөнне

Дүрткүз, әллә анын алдында үзенен өстенлеген күрсәтергә теләп, әллә башка сәбәп белән, мәченен каршысына ук килеп басты да "һау-һау-һау!" дип нәрсәдер әйтте. Кем булдын син әле син, килмешәк—мин синнән барыбер курыкмыйм, дигән сыман, мәче анын борынын җәһәт кенә тырнап та алды. Аеруча бер гайрәт белән. Ачуы бик нык кайнап чыкса да, шуннан бирле Дүрткүз ана якын килергә батырчылык итми башлады.

## Колхоз үгезе

...Беренче мәртәбә бик каты авырып ятканымны хәтерлим мин. Бер яшь тирәсе булгандыр, барыбер үләсе дип, әбием озак кына яныма килеп тә карамаган. Икенче вакыт үгез сөзеп үтерә язды. Монысы инде иреккә чыккач...

Кин дөньяга икенче чыгуымда булды бу... Кача-поса гына аулак урында казынып маташам. Арттан кемдер нык кына төртеп екты—сизми дә калдым. Шунда ук эләктереп күтәреп тә алды. Көтү кайткан вакыт булган икән ул... Гадәттә, үгез сыерлардан алда йөри бит (күреп алган булсам, анын кыяфәтен күрүгә үк куркып качкан булыр идем дә бит...). Туп чөеп уйнаган кебек уйнады ул минем белән. Уйнап туйгач, җирдә тәгәрәтә башлады. Көтүчеме—кемдер мине күтәреп алды. Бөтен тәнем кара янып, җәрәхәтләнеп беткән иде. Озак кына аныма килә алмыйча яттым мин. Күмхуж (күмәк хуҗалык) үгезе булып чыкты ул. Шуннан бирле үгез нәселеннән генә түгел, кәҗә бәкәйләреннән дә курка торган булдым.

Данлыклы үгез булды безнен колхоз үгезе. Анын гарип итеп калдырган кешеләре турында бәетләр көйләргә булыр иде. Бер мәртәбә ул үзенен хуҗасын—ферма мөдирен дә сөзеп аткан. Күп тә үтмәстән, кабат сөзгән. Шуннан сон мөдир абзый инде аягына баса алмады. . .

Безне, мәктәп балаларын, ел да "уктәбер бәйрәме" унае белән фермага кайнар аш ашарга алып баралар иде. Барабан кагып, быргы кычкыртып бернечә рәткә тезелеп марш атлап бара идек без анда. Бер баруыбызда шул үгезнен итен ашатканнар безгә. Ярый әле... белмәдем: ашый алмаган булыр идем. Итен генә түгел, ашын да...

Үгезнен ачуын чыгарма икән. Ачуы чыкса—бетте, котыра! Котырса—инде тыя алмыйсын. Бала чакта шул үгезнен котырган чагын күрергә туры килде мина. Бер мал караучы белән фермада булды ул. Нинди ачуы булгандыр анын—без йөгереп килгәндә тау кадәр үгезне күсәк белән кыйнап маташа иде ул. Үгез мескен, түзде-түзде дә, ярсып, үзенен караучысына ташланды... Көтелмәгән хәлдән агай коты алынып торып чапты. Үгез, мөгезләрен тырпайтып... анын артыннан. Куып йөртә торгач, тәмам котырган үгез бер почмакка кысрыклады аны. Дүрт якта киртә... Югыйсә, бер якка тайпыласы да киртә аша гына сикерәсе—юк. Тегенен йөзе танымаслык булды: бер агарынды, бер кызарынды, бер яшелләнде. Чүгәләп кемнәндер, нәрсәдер ялварырга кереште. Тозакка эләккән тычканны хәтерләтә иде мал караучы агай. Монысы тик торса, үгез дә тик кенә тора, бераз гына кыймылдаса үгез шунда ук мөгезләрен тырпайтып, мангаен төбәп куя. Күпме торырга була шушындый хәлдә? Анын коточкыч кыяфәтеннән генә дә торып качарлык иде бит. Без, малайлар, тын да алмый күзәтеп торабыз. Аларны нибары бер адым чамасы гына ара аерып тора иде.

Үгез, хәзер инде бераз тынычланып, "йә ничек, каптырдыммы үзенне?" дигәндәй, нурсыз күзләре белән корбанына текәлеп карап тора. Тегесе (Адәм баласына акыл дигән нәрсә бирелгән бит) көтмәгәндә бер хәйләгә килә. Кискен хәрәкәт ясап, үгезнен борынына кидертелгән боҗраны (андыйларга һәрвакыт боҗра кидертәләр—бәйләп кую өчен) шатырдатып эләктереп ала. Үгез генә түгел, мондый нәрсәне без, малай-шалай да көтмәгән идек. Ә хәзер инде үгез берни эшли алмый—танавы анын ин авырта торган җире. Менә шулай, акыл ярдәме—хәйлә белән мал караучы үлемнән котылып калды.

*Дәвамы киләсе санда*

Миркасыйм
Госманов

# ОСТАЗ КАЙГЫСЫ

*Университетта укыган чагымда мәгънәви остазларымның берсе, үземә карата ихлас теләктәш булган Хатип ага Госманны (1908-1992) азмы-күпме дәрәҗәдә белүем, аның белән озак еллар дәвамында аралашуым, һәрвакыт диярлек аның ихлас хәерхаһлыгын тоеп яшәвем моннан нәкъ илле ел элек башланган иде. Ул вакытта әле үземнең гомер юлымда, хәтта язмышым борылышларында аның төп рольләрнең берсен башкаручы, хәтта режиссер сыман җитәкчелек итүче шәхес буласын белү генә түгел, бәлки күз алдына да китермәгән идем. Бүген исә, остазның туууына йөз ел тулган көннәрдә, аның төс-кыяфәтен, гадәт-холыкларын, теләк-омтылышларын, шатлык вә кайгыларын хәтердә яңартып, күз-күңел иләгем аша кичерә башладым. Шуңа күрә бу истәлек язмам бер шәхескә караган гыйльми биография дә, галимнең гомум эшчәнлегенә багышланган трактат-монография дә түгел. Ул, бәлки, үземнең ничек хәтер яңартуымны, аны ничегрәк белүем һәм аңлавымны беркадәре генә чагылдыра торган шәхси истәлекләрем генә булып калудан ары узмастыр.*

Мина, чит җирләрдә туып үскән, аңым керә башлаганнан бирле тарихи ватан ягына омтылган бер татар баласына, бары 1958 елның җәендә генә Казан җиренә аяк басу мөмкинлеге насыйп булды. Имтиханнар башланганчы ук, хәтта берәр ай элегрәк килеп төшкән идем Казанга. Икенче көнне үк кабул итү комиссиясенә документларымны тапшырдым. Алар белән озак кына танышып утырган апа кеше, ниһаять: «Имтиханга килгәндә мыекларыгызны кырып ташлагыз, ярыймы?..— дип, ягымлы гына елмаеп куйды.—Юкса бездә «стиляга» икән дип сезгә кырын караулары бар».



Анардан үзем керәсе иткән тарих-филология факультетының кайдалыгын сорадым. Һәм «менә шунда укырмын, бәлкем» дип зур өметләр белән бусагасыннан атлап кергән ак колонналы мәһабәт бинадан чыгып, сул якка, химик факультет корпусына юнәлдем.

Татар теле, әдәбияты бүлеген эченә алган тарих-филология факультеты дүртенче катта икән. Киң баскычтан менүгә, коридорның фойе сыманрак чак кына киңәя төшкән җирендә иң элек «Әдәби сүз» дигән дивар гәзите игътибарымны җәлеп итте. Җәйге тәгътыйль вакыты булганга, зур коридорда бер генә кеше дә юк иде. Шуңа күрә иркенләп әлеге гәзитне караштыра башладым. Күзләрем иң элек бер рәсемгә төште. Чем кара чәчләре бераз тузгыбрак торган олы

яшьләрдәге, чак кына ямьшегрәк дип әйтимме, борынлы, кырысрак чырайлы кеше. Татар теле һәм әдәбияты кафедрасының мөдире доцент Хатип Госман икән. Текстта анар май аенда илле яшь тулу унаеннан бүлектәге укытучылар һәм студентлар исеменнән котлау сүзләре, изге теләкләр әйтелгән иде. Булачак җитәкчебез бик олы яшьтә икән, дигән фикер башымнан узды. Егерме дүртне тутырган егеткә «илле яшь» ул елларда шулай бик зур булып тоелгандыр. Игътибарымны шулай ук, әле генә әйткәнемчә, аның кырыс кеше булып тоелуы җәлеп иткән иде.

Мин аның бер хезмәте белән монарчы да, Казакъстанда чакта ук танышкан булуымны искә төшердем. 1956 елда чыккан «Татар поэзиясе антологиясе»нә язылган кереш мәкаләсен укыган, кат-кат укып сокланган идем. Менә нинди кыяфәттәге җитди кеше язган икән аны!

Гомумән, «Әдәби сүз»нең ул саны һаман истән чыкмый. Хәтердә ин уелып калганы—ике шигырь булуы. Берсе ел саен армиядән кайткан оныкларының гаскәри чалбар-гимнастеркаларын кия-кия сөенгән бабай хакында иде. Авторы Шамил Маннапов дигән студент икән.

Икенчесендә сүз язгы ташу вакытында елгаларда боз кузгалу, боз агу, яр буйларында аларны карап тамаша итүчеләр хакында иде. Кыска гына шигырьдә дә манзара күз алдына килерлек итеп тасвирланган. Тик шигырьнең соңгы юллары, «туган җирнең салкын бозлары» белән аерылышуы да күңелсез, монсу хисләр тудыруы хакындагы сүзләре миңа аңлашылмады да, ошап та бетмәде. Иҗтимагый тонлыкның, кысынкы авыр тормышның образы, символы булган суык бозның китүенә... үкенү? Минемчә, әдәби әсәрдә болай фикер йөртү сәнгатьчә акланмаган алым иде. Укырга керә калсам, аның авторы белән сөйләшер, бәхәсләшер идем, дигән фикер дә килде әлеге мизгелдә минем башка. (Мондый шигырьнең дөньяга килү сәбәпләрен мин тиздән аңлый башладым: «патриотизм идеясе» белән сугарылган, ватан һәм туган җир образларын теләсә ничек күтәргән шигъри әсәрләргә һәр җирдә дә, һәр вакытта да «ишекләр» киң ачылган икән ул елларда... Шуны аңлый башлагангамы, студент ашханәсендә Нәҗип Мальяров белән әллә ничә мәртәбәләр янәшә утырып ашаган чакларымда да, мин әлеге теманы кузгатмадым.)

Дивар гәзите, андагы материаллар белән шулай танышып чыккач, үзем керергә өметләнгән факультетта тагын нинди бүлекләр барлыгын белергә теләп, һәр ишектәге язуларны укып чыктым. Рус теле һәм әдәбияты кафедралары, тарих бүлеге дә бар икән монда. Димәк, факультетның исеме җисеменә туры килә. Коридорның караңгырак бер очында, дөресрәге, тоек тыкрыгындагы ике бүлмәдә татар теле һәм әдәбияты кафедрасы урнашкан икән. Аларның берсе мөдир, ягъни доцент Хатип Госман бүлмәсе иде. Бүлмә купшы, тантаналы рәвештә җиһазландырылгандыр, дип уйлап алдым. Соңрак шушы бер өстәл, бер кечкенә шкаф, ике-өч кенә гади урындык белән «бизәлгән» ярым ялангач бүлмәдә язмышымдагы кискен борылышлар хәл ителер дип ул мизгелдә уйлап та карамаган идем, әлбәттә.

Кире борылып, җиде-сигез адым атлауга күзем «Кафедра истории СССР» дигән язуга төште. Өч елдан соң Хатип ага Госманның менә шунда алып керәсен дә ул минутларда кем белгән...

Ике-өч атнадан аның, ягъни Хатип аганың үзен күрү дә насыйп булды. Имтихан алды консультациясенә җыелдык. Шул дүртенче каттагы бер аудиториядә сиксәнгә якын кеше идек. 25 урынга дәгъва итүчеләр.

Мәһабәт гәүдәле Хатип аганы мәктәп балаларынча аягүрә торып каршы алдык. Аның белән бергә бер егет тә кергән иде.

Хатип ага беркадәре вакыт, чак кына елмая төшеп, аудиторияне күзәтеп торды. Бергә кергән егет исә әллә ничек, ата каз шикелләрәк итеп, муенын боргалап куя иде. Үзенең исем-фамилиясен атаганнан соң Хатип ага юлдашының кем икәнлеген дә белдерде: Мансур Хәсәнов икән, аспирант... Имтиханны алар икесе бергә алачак икән.

Имтиханда җавап бирүнең кагыйдә-тәртипләре хакында беркадәре сөйләгән кафедра мөдире үзенең быелгы абитуриентлардан канәгать булуын да әйтте. Аның фикеренчә, укырга керүчеләр арасында армиядә хезмәт иткән, яки ике-өч ел эш стажы белән килгән абитуриентларның шактый булуы унай күренеш икән. Әйе, аудиториядә утыручылар арасында хәрби киемнәрен салып бетермәгән, яисә төс-кыяфәткә шактый олы егетләр дә аз түгел иде. Соңгы еллардагы яңа тәртип буенча

эш стажы булган яшьләрне конкурссыз алу башлангач, диде мөхтәрәм доцент, татар филологиясе бүлеге «ярыйсы гына балигъләна төште». Быел исә стажлы абитуриентларның үзләре арасында да конкурс булуы ихтимал. Чөнки беренче курска кабул ителүчеләрнең өчтән бер өлеше быел гына мәктәп бетерүчеләр булырга тиеш, дигән фикер бар икән. Аларның әзерлекләре әйбәтрәк, белгәннәре әле онытылып бетмәгәнлеген истә тотарга кирәк, дип искәртте имтихан алучыбыз.

Шулай бераз әңгәмәләшкәч, сүз җинел рәвештә сорау-җавапларга күчте. Сорауларга Хатип ага кыска-кыска, мәгәр гади һәм аңлаешлы итеп җавап бирә барды. Арадан кемдер берсе «акростих, аллитерация» дигән сүзләрнең мәгънәләрен аңлап бетермәвен әйтте. Хатип ага җанлана төшеп, татарча һәм русча мисаллар китерә-китерә тәфсилле рәвештә аңлата башлады. Бигрәк тә аллитерациягә бәйле җавабында очына-очына дигәндәй бер озын гына русча шигырьне дә яттан сөйләде. Ышкы белән чыжлата-чыжлата агач шомартканда йомычкаларның җилпенә-җилпенә очып чыгулары күз алдына килеп баскандай булды... Әгәр аның лекцияләре дә шулай җанлы, сурәтле һәм хисле булсалар?..

Тик миңа, кызганычка каршы, Хатип ага Госман дәресләрендә эзлекле рәвештә булырга, аның лекцияләрен тыңларга туры килмәде шул. Төрле сәбәпләр аркасында...

* * *

Имтиханнар минем өчен бик шома, әллә ничек сизелмичә генә шуып узды. Бары ике-өч мизгел генә истә калган. Берсе татар теле буенча инша язып утырганда булды. Суыртылган кара белән яза торган кытай каләме «чыгымлап», караны кирәгенчә бирмәгәч, мин, гадәтемчә, аны идәнгә таба каратып селеккәли башлаган идем. Бер бит ак кәгазь тоткан Хатип ага яныма килеп: «Идәнгә түгел, менә кәгазь өстенә селкегез»,—дип кәгазьне өстәлнең читенә куеп китте. Шунда гына идәндәге ике-өч кара тапка күзем төште...

Телдән җавап биргәндә миңа үзем өчен бик кулай булган сорау—Галиәсгар Камалның «Безнең шәһәрнең серләре» эләккән иде. Әсәрне характерлый-тасвирлый торгач, авторның аны тәнкыйди реализм алымы белән иҗат итүен әйтүгә, «нинди реализм?» дип, Хатип ага бүлдерде. «Тәнкыйди реализм» дип кабатлагач, ул: «Ярар, дәвам итегез»,—дип, сүзсез генә тыңлады.

Имтиханнар тәмамланып, ике-өч көн узуга кабул ителүчеләрнең исемнәрен игълан итә башладылар. Безнең бүлеккә керүчеләрнең исемлеге дә эленгән иде. Тик исемнәр анда ни өчендер фамилияләрнең алфавит тәртибендә түгел иде. «У»га башланган минем фамилиямнең беренче урынга куелуы гаҗәбрәк булып тоелды. Аның сәбәбен алты-җиде елдан соң гына белдем. Абитуриентларның документлары белән танышып утырган Хатип ага, минем кәгазьләргә юлыккач, «чит илдә туып үскән, күптән түгел генә СССРга кайткан абитуриент белән нишлибез?»—дигәндәй сорау белән ректор янына кергән икән. Михаил Тихонович Нужин: «Имтиханнарын бирә алса, карарбыз»,—дигән. Имтихан нәтиҗәләре билгеле булгач, комиссия утырышында ректор беренче булып «кытайлының» кәгазьләрен күтәреп, өлкән экзаменатордан сораган: укый алырлыкмы? «Әйе» җавабын ишетүгә секретарьга әмер биргән: «Исемлеккә языгыз, кабул ителә!»

Исемлектә алфавит тәртибе бозылу менә шулайрак барлыкка килгән икән. Һәм монда, соңрак аңлавымча, М.Т.Нужинның көчле характеры, аның мөстәкыйль гамәл итәргә омтылуы, партия һәм совет органнарының формаль тәртипләре белән артык исәпләшмәскә тырышуы чагылыш тапкан төсле. Киресенчә булса, минем фамилияне исемлектә «яшеребрәк» куйган булыр иде.

Хатип агадан болар хакында ишетеп утырганда минем искә икенче бер хәл дә килеп төште. Беренче курсны тәмамлап, каникулга Казакъстанга кайткач, мин үзем эшләп киткән ДОСАФка кереп, элекке җитәкчем белән очрашкан идем. Отставкадагы капитан иптәш Тренин әңгәмәләшеп, чәй эчеп утырганда әкерен генә: «Сине анда борчымыйлармы... эзәрлекләмиләрме?..»—дип сораган иде. Ни өчен алай эшләргә тиешләр, дигәч, ул көлеп: «Син китеп ай ярымдай вакыт узуга минем янга тиешле җирләрдән килеп синең хакта бик төпченеп сораштылар»,—диде.

Мин шунда өченче бер хәлне дә искә төшердем. Университетка кабул ителгәч,

монарчы бер кат язганымча («Аяз әкә сабаклары»нда), мин хосусый фатирда бер почмакта яши башлаган идем. Хуҗабыз, вокзалдагы эшеннән көн саен диярлек кызмача булып кайта торган йөк бушатучы Ваня дәдәй, бер көнне, бергә-бергә тәмләп кенә тәтен суырып утырганда, гаҗәпләнгән төсле сорап куйган иде: «Ты вот нормальный человек, но почему тебя так презирают?» Аңлаша торгач, шунысы беленде: ЖЭКтан, аннары хәтта милициядән дә килгәләп, гел минем хакта сорашып, белешеп торганнар икән, янәсе үзен ничек тота, кемнәр белән аралаша, буш вакытларында нишли, дип. Өч-дүрт ай чамасы шулай сорашкалап торганнар...

Боларны, ягъни үземнең Казанда беркадәре вакыт «калпак астында»—махсус күзәтүдә торуларымны искә алуым һич тә очраклы түгел. Мондый хәлләрнең шул заманнарга хас, хәтта «табигый» күренеш булуын белү кайбер кешеләрнең эшгамәлләре сәбәпләрен дә аңларга ярдәм итә икән. Мәсәлән, Хатип ага белән килеп чыккан бер хәл дә гыйбрәтле иде.

Тулай торактан китәргә тиешлегем тәмам анықланып, ләкин фатир таба алмыйча аптырабрак йөргән көннәрнең берсендә коридорда уйга батып тора идем. Хатип аганың, үз бүлмәсенә узышлый, яныма килүен сизми дә калганмын. Ул һәрвакыттагыча ачык чырай белән елмаеп (монарчы һәр очраткан саен шулай туктап хәл сораша, кыскача булса да сөйләшеп алгалый иде), монаеп торуымның сәбәбен сорады. Мин исә, мыгырдап кына, тулай тораклан чыгарырга теләүләрен, фатир табылмавын әйттем дә, әллә ни уйлап, үлчәп тормыйча, студентларын да торак белән тәэмин итә алмаган хөкүмәтнең гел шапырынып мактануына гаҗәпләнүемне белдердем. Соңгы сүзләрем тупасрак рәвештә дә әйтелде бугай. Хатип аганың төсләре кинәт үзгәрде, бер сүз дә әйтмичә, кырт борылып тизтиз атлап китеп тә барды.



Моннан соң ул бөтенләй үзгәрде, элеккечә якты чырай белән күрешми, махсус туктап хәл сорашмый башлады. Хәтта күрмәмешкә салышып та узып китә иде. Күзләр очрашкан хәлдә генә салкын кыяфәт белән сизелерсизелмәс баш изәүдән ары узмый иде.

Шулай ярты елдан артык дәвам итте. Бары җәйге сессиягә әзерләнеп йөргән көннәрдә генә китапханә алдында очраштык (ул вакытларда китапханәнең уку заллары, абонемент бүлеге университетның ихатасы эчендәге иске бинада иде).

Ул мине туктатып, имтиханнарга әзерлекнең ничек баруы хакында сорашты, «Кыйссаи Йосыф» буенча эшләгән курс эшемнән җитәкчемнең (Җәвад ага Алмазның) канәгать булуын әйтте. Ниһаять, «яна шартларга бераз күнегә башладыгызмы инде?»—дип, елмая төшеп сорап куйды.

Әлеге вакыйга, дөресрәге Хатип аганың кинәт үзгәрүе, мине сүзсез-нисез үзенчәлекле рәвештә «җәзалавы» файдага гына булды. Мин үземнең нинди тактсызлык эшләвемне аңладым. Кечкенә генә шәхси проблемага зур сәяси кыяфәт бирергә омтылуның да урынсыз, мәгънәсезлек икәнлеген таныдым. Бигрәк тә олы кешеләр белән сөйләшкәндә алай «чыгымчылап» җавап бирүнең дә әдәпсезлек икәнлеген тойдым.

Дөрес, югарыда ишарә ителгән башка сәбәпләр дә (әйтик, Ваня дәдәйнең сораулары белән башка кайбер хәлләр дә) минем вазгыятьнең катлаулы, хәтта минем өчен ярыйсы гына четерекле икәнлеген аңларга ярдәм итте.

Бәлки әле генә тасвирланган вакыйга Хатип ага Госманның миңа биргән, үземә ярыйсы гына тәэсир иткән беренче сабагы—тәрбия чарасы булгандыр. Һәрхәлдә, моннан соң сорауларга уйлабрак җавап бирергә тырыша торган булдым...

* * *

Консультация көнендә Хатип аганың мавыктыргыч лекцияләрен тыңлармын дигән өметләрем, әйткәнемчә, акланмады. Беренчедән, түбән курсларда аның дәресләре юк икән. Икенчедән, нәкъ шул елларда докторлык диссертациясе өстендә эшләү сәбәпле ул уку-укыту эшләренә чамалабрак катнашкан. Шулай да факультетта күренгәли, ул килгән көннәрен кайбер укытучылар һәм студентлар, кем әйтмешли, «бер тактадан гына» йөри башлыйлар. Кайбер укытучыларның «артык шауламагыз, Хатип ага монда», дип кисәтүләрен ишетергә туры килгәли. Бигрәк тә Диләрә апа Тумашеваның: «Бүген Хатип аганың чәчләре тузгыган, кәефе начар, күрәсең»,—дип көлүләре хәтердә калган.

Эшләренең күп, вакытының тыгыз булуына карамастан, кафедра мөдире факультет һәм бүлек тормышыннан аерылмый иде, минемчә. Моның шулай икәнлеген мин үзем дә сизгәләдем.

Икенче-өченче курсларда укып йөргән елларым минем шактый нык уйланган, эзләнгән, үземнең киләчәгем өчен төптән борчылган вакытларым булган иде. Нәрсә буенча белгечлек алырга? Киләчәктә кем булып эшләргә?—дигән сораулар чоры иде. Чөнки укырга кергәнче корган хыял-планнарым челпәрәмә килгән, нигездән үзгәргән, дөресрәге, плансыз диярлек калган идем.

Беренче курс эшемне текстология («Кыйссаи Йосыф» кулъязмасы) буенча язсам да, аннан «тәм тапмадым» шикелле. Тел белеме белән шөгыльләнергәме дигән уйхыялым, моңарчы бер әйткәнемчә, мине «Шура» журналының библиографиясен төзүгә китергән иде. Журналның үзен уку, андагы искитәрлек дәрәҗәдәге, төрле характердагы, гаҗәеп бай эчтәлекле, гыйбрәтле материаллар белән танышу гаять кызыклы, мавыктыргыч булса да, библиографлык эше дә төп кәсеп өчен житмәс кебек тоелды. Шулай ук мине җәйге диалектологик экспедициягә чакырып йөргән, «Башкортстан татарларының сөйләшен өйрәнербез, сезнең казакъ телен белүегез файдалы булыр», дигән Әнвәр абый Әфләтуновның фаҗигале рәвештә кинәт үлеп китүе дә план-өметләрнең берсен юкка чыгарды.



*Х. Госман һәм М. Госманов (уңда)*

«Шура» журналы буенча төзи башлаган библиография буенча да бер проблема килеп чыкты: журналның университет китапханәсендә саклана торган бердәнбер комплект төпләме тулы түгел икән. Кайбер елларның номерлары житмәгән, икенчеләрендә аерым битләр төшеп калган яки ертып алынган. Болар хакында төп киңәшчем булган Якуб ага Агишевка әйткәч, ул бераз уйланып утырды да, мине Хатип ага янына алып керде. Ул исә мәсьәләне бик тиз аңлап алды да, минем башыма килмәгән бер фикерне әйтте: «Димәк, сезгә Мәскәүгә, Ленинградка барырга туры килер, җитешмәгән мәгълүматларны шуннан алып кайтырсыз!» Якуб аганың: «Мөмкин булырмы бу?»—дип соравына каршы, икебезне дә ияртеп, факультет деканы профессор Гуляев янына алып керде. Ул исә карарны тиз чыгарды:«Командировкага җибәрербез, документларын әзерләгез. Акча бирдерермен».

Шулай итеп, мин кышкы каникул вакытларында, декан исеменнән язылган юллама хатларымны алып, Мәскәүгә, Ленинградка юнәлдем.

* * *

Берничә көн рәттән Мәскәүдәге Ленин исемендәге зур китапханәгә бардым. Истә калганы—милли китаплар бүлегендә эшләүче Ерзин фамилияле (исемен хәтерләмим)

бер зыялы татар карты булды. Ул минем белән шактый вакыт әңгәмәләшеп утырды, үз нәселенең Касыйм якларыннан икәнлеген әйтеп, Кытайда да Ерзин фамилияле кешеләрнең очрау-очрамаулары хакында сорашты. «Безнең нәсел—зур нәсел, анда да булырга тиеш безнең Ерзиннар», диде. Аннары, Мәскәүдә артык вакыт уздырмыйча, Ленинградка барырга, Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәдә, Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтында эзләнергә киңәш бирде, чөнки революциягә кадәр чыккан матбугат Петербургта тулырак тупланган, яхшырак сакланган икән. «Салтыковкада Энже ханым Сәгыйтованы эзләп табыгыз, татар матбугаты тарихын яхшы белә торган кеше ул»,—диде Ерзин агай хушлашкан вакытта.

Ленинград көчле тәэсир ясады мина. Кайсыдыр яклары белән галәмәт зур авылны хәтерләтә торган ул еллардагы Мәскәүгә караганда, Ленинград чыннан да искитәрлек гүзәл, тәртипле, төзек шәһәр икән.

Китапханәләрдә, бигрәк тә Салтыковкада, эшләү аерата нәтиҗәле иде. Энже ханым Сәгыйтованың киңәшләре дә шактый файдалы булды. Әзерләп килгән исемлегем буенча барлык сорауларыма җавап таптым. Энже ханым исә, «Шура» редакторы Риза казый Фәхреддин хакында кайбер мәгълүматларның булуы ихтимал, дип, мина Көнчыгышны өйрәнү институтына барырга киңәш итте. Анда эшне төрки-монгол кабинетына керүдән башларга кушты. Бер-ике ханымның исемнәрен дә атады.

Ләкин анда иң элек икенче бер кешеләр белән танышырга туры килде. Аларның берсе тюрколог-тарихчы Сергей Кляшторный дигән кеше иде. Ул мине, бераз сөйләшеп утыргач, икенче бер бүлмәгә алып барып, озын буйлы, кипкән балык төсле чандыр гәүдәле егет белән таныштырды. Әнәс Халидов дигән гарәп әдәбияты белгече икән. Болар белән соңрак 40-45 еллар дәвамында очрашкаларга, хезмәттәшлек итәргә туры килер дигән уйны ул көннәрдә башыма да китермәгән идем, билгеле.

Институт архивында материалларны карап, әзерләп куярбыз дип, иртәгә килергә куштылар. Яңадан төрки-монгол кабинетына керсәм, анда олы гына яшьтәге бер агай утыра икән. Кляшторный таныштырды: кабинет мөдире профессор Андрей Николаевич Кононов икән. Фамилиясен элек тә ишеткәнем бар иде. Минем Казаннан икәнлегемне кабинет ханымнары әйтеп өлгергәннәр бугай, ул мине үз өстәле янына чакырып алып, Казан, андагы галимнәр, университетта безне кемнәр укытуы хакында тәфсилләп сораша башлады. Бигрәк тә Диләрә Тумашева, аның нәрсәләр укытуы хакында төпченеп сорашты. Бер ара үземнең кайларда туып-үсүем, нинди мәктәп бетерүем хакында да кызыксынды. Казанга кадәр яшәгән җирләрем хакында ишеткәч, кайсы төрки телләрне ничегрәк белүемне сорады. Мин, әлбәттә, мактанып алырга форсат килүен сизеп, казакъчаны, уйгырчаны иркен дәрәҗәдә белүемне әйттем, ул телләрдәге әдәбиятны укуда берни?ди сүзлек кирәкмәвен дә өстәп куйдым. Андрей Николаевич болай да кысыграк бер күзен тагын да кыса төшеп сорау бирде: «Ленинград университетына күчеп, төрки телләр буенча белгечлек алу хакында уйламадыгызмы?» Мин, билгеле, бернәрсә дә уйламаган идем. «Уйлагыз,—диде ул үзе дә уйчан гына.—Безнең хәзерге тюркологларның күпчелеге элекке Радловлар, Катановлар, Ильминский һәм Маловлар кебек җанлы төрки телләрдә сөйләшә алмыйлар... Менә шул телләрне чагыштырып өйрәнергә кирәк иде. Уйлагыз. Теләгегез булса, кафедрама күчергә ярдәм итәр идем». Мин уйга калдым, әлбәттә. Әмма икенче көнне бу уйларны юкка чыгарлык бер сәер мажарага тап булдым.

* * *

Көнчыгышны өйрәнү институтыннан кайтышлый, Салтыковкада да шактый утыргач, эшләрнең яхшы нәтиҗәсен билгеләргә, ягъни «юып алырга» дип ресторанга кереп үз-үземне кунак иттем. Музыка тыңлый-тыңлый ашап-эчеп хозурлануымны ике-өч йотым «ширбәт» белән дә бизәдем, билгеле. Минем өстәлгә тагын өч кеше, бер ир-егет белән ике хатын-кыз килеп утырдылар. Күңелле генә сөйләшеп тә киттек. Ригадан килгән латышлар икән, үзләрен бик ачык тоталар. Чәкешә дә башладык. Төнге уникеләр узуын сизми дә калганбыз. Тагын берәр сәгать урамнар гизеп йөрдек... Сәгать икенче киткәч кенә кунакханәмә кайтып, түшәккә аудым.

Озак йоклап, соң гына торгач, буфетка төшеп, ашыкмыйча иртәнге чәемне эчтем. Бүген кичен китәсе. Эшләр тәмам. Димәк, тагын Эрмитажга барасы да кичен—вокзалга!..

Шундый якты планнар, тук кыяфәт белән номерыма кайтсам, анда мине ике кеше көтеп тора икән. Фамилиямне атап, документларымны сорадылар. Гаҗәпләнүемә каршы, үзләренекен күрсәттеләр. Берсе капитан, икенчесе лейтенант икән. «Әйдә, киен, отделениегә киттек!»—диделәр. Ни өчен диюемә каршы: «Баргач белерсең!»—диделәр.

Отделениедә берәр сәгать чамасы төрле яктан тарткалап, йолыккалап дигәндәй сорау ала башладылар: ни өчен Ленинградка килгәнмен, кемнәр җибәргән мине монда, кичә кичен, төнлә кайларда булганмын, кайчан кайтканмын, ресторанда кемнәр белән утырганмын, алар белән кайчан, ничек танышканмын, ресторан өчен кем түләгән, мин күпме биргәнмен? Номерга кайтканда сәгать ничә иде, ничә кеше уяу, күпмесе йоклый иде һ.б., һ.т.б.? Тора-бара шуны аңладым: номерыбыздагы берәүнең акчасын һәм документларын урлаганнар икән.

Шулай әллә нинди сорауларга җавап бирә-бирә алҗып утырганда, өченче бер хезмәткәр кереп нидер әйткәч, мине икенче бер бүлмәгә кертеп бикләп куйдылар. Ике сәгать чамасы шунда борчулы уйларга батып утырдым. Казакъстандагы капитан Трениннның, Казандагы Ваня дәдәйнең сорауларын искә төшердем... Бары соңгы елларда гына үземә карата әллә нинди сораулы, шикләнүле, иң яхшысы кызыксынулы карашларны тоймый башлаган идем. Әгәр бу хәлдән хәбәр бара калса?..

Менә сиңа «Шура»ның библиографиясен тулыландыру, менә сиңа тагын Эрмитажга бару!..

Ниһаять, чыгардылар. Тик элекке бүлмәгә генә. Тагын сорау алу башланды. Иң элек чемодан төбендә яулыкка төреп куйган акчаның кемнеке булуы белән кызыксындылар. Фатирым хуҗасының үсмер кызы өчен биш-ун кием оек, оекбаш һәм күп итеп һинд чәе алыр өчен бирелгән акча икәнлеген әйттем. «Нигә алмадыгыз?»—дип төпч535енделәр. Кайтышлый Мәскәүдә алырмын, дидем. Акчаны ни өчен чемоданда калдырдыгыз, урларлар бит, дип гаҗәпләнделәр. «Дәүләт кунакханәсендә кем урласын?»—дип үзем дә җүләрлеккә салышып гаҗәпләнгән булдым. «Урлыйлар шул,—диде капитан тыныч кына.—Әнә, сезнең янәшәдәге караватта яткан күршегезнең акчасын да, паспортын да алганнар бит... Элек сездән шикләнгән идек. Тик урлаучы башка кеше булып чыкты, ул тотылды да инде».

Мин шунда гына җинел сулап куйдым. Димәк, җибәрәләр икән, дигән уй килүгә капитан тагын җитди кыяфәт белән сорады:

—Чемоданыгызда әллә нинди серле язулы, аңлаешсыз телдә карточкалар бар, аларда нинди кодлар?

Мин беренче мәртәбә елмаеп, аларның библиографик карточкалар, татарча журнал мәкаләләренең гарәп язулы исемлеге икәнлеген аңлаттым. Сүзгә лейтенант та кушылды, үзенең күршеләре татарлар булуын, аларның исә «нормаль хәрефләр белән безнеңчә» язуларын, шуларны укуларын әйтеп шик белдерде. Моңа каршы татарлардагы язу тарихы турында лекция укый башлаган идем, капитан кырыс тавыш белән бүлдерде:

—Ярар, менә паспортыгыз, китә аласыз. Тик моннан соң студент башыгыз белән рестораннарда буталып йөрмәгез! Университетыгызга язып җибәрербез әле!..

Ленинградка беренче барганымдагы соңгы көнем менә шулайрак узган, янау белән тәмамланган—киләчәк өчен файдалы сабак булган иде...

* * *

Эшләрне кайларда эшләп, ничек тәмамлап кайту хакындагы «исәп-хисабымны» Хатип ага игътибар белән тыңлап утырды да, мин туктауга, бер үк сүзне кат-кат әйтте: «Рәхмәт! Рәхмәт сезгә!» Бары аннан соң гына, йомгак ясаган төсле әйтеп куйды: «Димәк, «Шура» библиографиясе буенча кирәкле мәгълүматлар җыелып бетте дигән сүз!»

Бу мизгелдә миңа кафедра мөдиренең эшләнгән эштән канәгать булуы түгел, бәлки үземә рәхмәтләр әйтүе гаҗәбрәк булып тоелды. Асылда исә Мәскәү-

Ленинградларга баруны, аларны күрүне оештыруы өчен мин үзем беренче булып анар рәхмәтләр әйтергә тиеш идем. Гомумән, шәкертләренен берәрсе уңышка ирешсә, Хатип аганын шулай рәхмәтләр әйтүе анын бер әйбәт гадәте икәнлеген мин соңрак кына аңладым.

Бары шулардан соң гына Хатип ага Мәскәү-Ленинградларда кемнәрне күрүем, кемнәр белән танышуым хакында сорашты. Әнәс Халид исеме яңгырауга: «Шул егетне монда кайтарасы иде бит! Ул безнен өчен бик кирәкле кеше!»—дип күрсенгән иде. (Күп вакытлар узгач кына ул елларда Хатип аганын Әнәсне Казанга чакырып йөргәнлеге чын факт икәнлеген Халидовның үзеннән белдем.)

Бу әңгәмәдән соң мин тәмам тынычландым: Ленинград капитанынын янавы сүздә генә калган икән.

Шулай күңел үз урынына утыргач кына, Ленинградта академик Кононовнын ясаган тәкъдиме хакында да әйтергә булдым. Үзем ни өчендер бераз шүрләп тә тордым. Әгәр: «Йөрмә баш катырып, мондагы шартлар житмиме сина?» янсә «хуплыйм, әйдә барыгыз», дисә?.. Күз алдына әлеге сорау алган капитан да килеп басты... Әмма Хатип ага уйланып калды. Беравык шулай сүзсез утыргач кына ашыкмыйча сөйләп китте:

—Узган уку елы башында безнен үтенечкә каршы Министрлыктан килгән махсус разнарядка буенча гарәпчә укыр өчен Ленинградка өч кеше жибәрергә тиеш идек. Ашыгыч рәвештә. Мин сезне дә күздә тотып, эзләткән идем. Тик сез каникулдан кайтып житмәгән идегез. Шуна күрә, үзегез дә беләсез, ике егет, бер кызны узган елны ук жибәрдек инде. Алар укып кайтырлар дип өметләнәбез... Әгәр Кононовның тәкъдиме үзегезгә ошый икән, кабул итәсе булсагыз, ул чакта ихтыяр үзегездә инде. Уку елы беткәнче төрле яктан үлчәп, әйбәтләп уйлый аласыз. Андый тәкъдим көн саен булып тормый, әлбәттә. Кызыклы тәкъдим, һичшиксез. Ләкин татар теле, татар әдәбияты буенча алган белем дә тюркологиянең бер өлеше бит,—дип бераз тукталып торды да өстәп куйды.—Казанда да эшлисе эшләр муеннан...

Шул очрашудан соң берәр ай чамасы узды микән, анысын төгәл хәтерләмим хәзер, Хатип ага тагын сорады:

—Ничек, Андрей Николаевич тәкъдиме хакында уйладыгызмы инде?

Мин ык-мык килеп, төгәл җавап бирә алмадым. Дөресен әйткәндә, һавасы чистарак, карлары да аграк Казанга кайткач, мин Ленинградка, карлары жепшек, каралып беткән, көне дә төн кебек караңгы шәһәргә карата бераз суына төшкән, әлеге мавыктыргыч тәкъдим хакында да уйламый башлаган идем. Хатип ага моны сизгән төсле әлеге ниятнен минем өчен бик үк кулай булмавына ишарә итте:

—Сезгә, Усманов, шушы Казанда аякларыгызга ныграк басып алу хәерлерәк булыр иде, минемчә. Биографиягезнең үзенчәлеген күздә тотып әйтүем. Монда хәзер сезгә күнектеләр. Кызыксынулар, тикшерүләр бетте сыман. Яна жирдә барсын да яңадан башларга туры киләчәк. Белмәссен, кайда ниндирәк шартлар көтәдер.

Бу сүзләр мине яңадан ныграк уйланырга мәжбүр итте. Уйланырлык та: нәрсә, нинди юнәлеш буенча ныклап белгечлек алу мәсьәләсе һаман хәл ителмәгән. Инде өченче курс узып бара... Библиография төзү һич тә төп белгечлек була алмый. Борынгы әдәби әсәрләрдән берәр истәлекнең текстологиясен өйрәнү юнәлешен алыргамы, дигән хыялым да челпәрәмә килде: «Кыйссаи Йосыф»ны жентекләп өйрәнүче, житәкче булырлык Жәвад Алмазны шартлатып эштән кудылар... Якуб ага Агишевнын сер ачкан кебек шыпырт кына әйтүенә караганда, «югарыдагылар»га аның борынгы «дини» истәлекне өйрәнүе ошап бетми икән... Хәзерге әдәбият белеме дә күнелне тартмый. Шул ук Якуб агадан бер мәлне, Хатип ага нинди тема буенча диссертация яза, дип сорагач, ул сүрән генә: «Нәрсә булсын, шул социалистик реализм инде»,—дип мыгырдап алган иде. Минем дә соцреализм дигән нәрсәне аңлавым чамалы. Тәнкыйди, ягъни критик реализм, социалистик реализм дип бер үк нәрсәне бүлгәләү башыма сыймый. Ике дөреслек, ике хакыйкать була алмаган төсле. Аннары Ибраһим абый Нуруллин тагын «мәгърифәтчелек реализмы» дигән бер яңалык уйлап тапты...

Менә шулай уйланып, икеләнеп йөргән көннәрнен берсендә мина Хатип аганың үземне эзләве хакында әйттеләр. Ул ашыга идеме шунда, кереш ясап тормыйча турыдан ярып сорады:

—Ленинград хакында берәр карарга килдегезме соң инде?

Мин «юк» дип җавап биргәч, сәбәбен сорады.

—Андагы юеш кыш ошамый миңа...—диюдән ары узмадым шикелле.

—Ярар,—диде ул тыныч кына.—Алайса, мин сезгә бер яңа юнәлеш—тарихи язма истәлекләрне, ягъни чыганакларны өйрәнү буенча белгечлек алуны тәкъдим итәм. Димәк, риза булсагыз, тарих буенча да өстәмә белгечлек алырга кирәк дигән сүз. Ничек карыйсыз моңа?

Мин әллә ни аңлап житмәсәм дә, ярар дигән төсле башымны иәдем. Хатип ага шунда ук телефонны алып, «Шамил, син үзеңдәме?»—дип сорады да, мине дә ияртеп кабинеттан чыкты.

Кайчандыр, факультетка беренче кат аяк басканда, «Кафедра истории СССР» дигән язуын укыган ишектән кердек. Кафедраның зур гына бүлмәсе түрендәге тагын бер ишектән уздык. Кафедра мөдире доцент Шамил Мөхәммәдьяров—үземнән тарих буенча кереш имтиханын алучыларның берсе—Хатип аганы аягүрә басып каршы алды.

—Менә, Шамил,—диде Хатип ага,—соравың буенча сиңа әйткән кеше шушы егет була инде. Хәзер үзегез сөйләшегез. Ярар, мин ашыгам,—диде, үзе ишек янында миңа таба карап өстәп куйды.—Синең житәкчең инде шушы Шамил абыең булыр, кара аны, сынатма.

Үзе тиз генә чыгып та китте. Мин аның үземә карата беренче мәртәбә «син» дип дәшүенә игътибар иттем. Элек гел «сез» дә «без» дип, ара калдырып сөйләшә иде.

Озын буйлы, мәһабәт гәүдәле, көр тавышлы Шамил Мөхәммәдьяров янында үземне кечерәя төшкән кебегрәк хис иттем.

Бу хис, ихтимал, язмышымда яңа борылыш, зур үзгәреш барлыкка килүне сизенүемә бәйледер...

Яңа житәкче белән озак кына әңгәмәләшүем бер үк вакытта минем тарих бүлегендә дә укырга, күп итеп өстәмә имтиханнар бирергә тиешлегемне аңлау белән тәмамланды. Берничә кешене махсус төзелгән индивидуаль план буенча укыту хакында ректордан ризалык алынган да икән. Хәзергә ике кешегә. Әгәр мин төрки телле тарихи язма чыганаклар буенча белгечлек алырга тиеш булсам, икенче бер курсташ—Әзһәр Мөхәммәдиев—археология һәм нумизматика белән шөгыльләнәчәк икән.

Тарих бүлеге студентлары узарга тиешле төп курслар буенча махсус план булдырып, мөстәкыйль рәвештә әзерләнергә кирәк икән. Әгәр семестр саен татар бүлеге өчен биреләчәк гадәти дүрт-биш зачет, биш-алты имтиханга тагын тарих буенча сигез-тугыз зачет, унике-унөч өстәмә имтихан тапшыруларны, аларга әзерләнүләрне тасвирлый башласам, үзенә күрә бер аерым язма барлыкка килер иде. Ләкин, кем әйтмешли, сүзем Хатип ага Госман хакында бит.

* * *

Яртылаш дигәндәй тарих бүлегенә күчеп, Шамил абый житәкчелегендә курс эшләре язып, өсте-өстенә имтиханнар тапшыра башлагач, мин татар филологиясе бүлегеннән бөтенләй чыгам бугай дип уйлаган идем. Ләкин Хатип ага минем нәрсәләр эшләп йөрүем, укуларымның ничегрәк баруы белән элеккегә караганда да күбрәк һәм эзлеклерәк кызыксына башлады. Элекләре очраклы рәвештә очрашкан чакларда, яки Якуб ага белән янына кергәнедәге кебек инициатива башка яктан булганда гына сөйләшкән, сорашкалаган булса, хәзер инде үзе махсус чакыртып алып, төпченеп сораша торган булды. Эшләнгән эшләрнең берсеннән канәгатьләнү белдерсә, икенчесенең эшләнеп бетмәвен күрсәтер, өстәмә рәвештә нәрсәләргә игътибар кирәклеген әйтер. Мин аны гел әдәбият, яңа заман шигърияте белән генә кызыксына дип, берьяклырак уйлый идем. Ә ул тарихи әдәбиятны да ярыйсы гына белә икән. Классикларның фикерләрен исәпкә алырга, аларның хезмәтләрен яхшылап өйрәнүнең кирәклеген тәкрарлап торуы да характерлы иде. Мәсәлән, «Коммунист» журналында чыганакларны өйрәнү хакында басылган бер мәкаләне укырга кушуы да истә калган. Ә мәкалә, чыннан да, файдалы булып чыкты.

Ул бигрәк тә Шамил Мөхәммәдьяровның татар тарихы буенча махсус белгечләр әзерләргә тотынуын югары бәяләде. Яңа житәкчедән алган беренче курс эшемнен

Русия белән Шәрык илләре арасындагы язышуларда татар теленнән файдалануга багышланган булуын аерата сөенеп хуплады. Монарчы без гел яна заман тарихын өйрәнү белән генә чикләндек, ә чын тарихыбызны белер өчен борынгы чорларны да өйрәнергә тиешбез, дия иде. Мондый эшкә яхшы әзерлекле Мөхәммәдьяровнын алынуы күктән көткәнне җирдән табу белән бер, дип бәяли иде.

Сөйләшкәли торгач, Хатип аганың үзенен дә Алтын Урда чорына караган әдәби истәлекләрне өйрәнүе билгеле булды. Тагын ике-өч елдан ул Зәйнәп апа Максудова (1897-1980; заманында Буби мәдрәсәсендә белем алган, гарәп-фарсыны һәм иске әдәби төрки телләрне яхшы белә торган олы яшьтәге зыялы ханым) белән бергә әзерләп, кайбер әсәрләрне дәреслек-кулланма рәвешендә чыгара башлады.

Ул вакытларда Алтын Урда чорына, шул заманнардан калган истәлекләргә кырын карау гадәте кимегән, бәлки кайбер мәсьәләләрдә, әйтик, этногенез мәсьәләсендә, бераз кискенләшә, көчәя дә төшкән иде. (Моны кайбер археологларыбызның Ш.Мөхәммәдьяровка, аның Алтын Урда тарихын яклаганы өчен юнәлтелгән тәнкыйтьләреннән дә сизергә мөмкин иде). Шуна күрә Хатип ага әлеге әдәби истәлекләрне шул вәзгыятьтәге чагыштырмача җинелрәк булган юл—офсет юлы белән, «эчке файдалану өчен» дигән исем астында чыгару юлын сайлаган иде.

Заманында Хатип аганың мондый басмалары хакында «курчак туе уйнау» дип мыскыллабрак йөрүчеләр дә булгалады булуын. Әмма чынлыкта олы галим андый юлга басуы белән «өч куянга» да берьюлы бәргән икән. Беренчедән, партия җитәкчеләренен «нигә тагын Алтын Урда?»—дип бәйләнү ихтималына юл бирмәгән. Икенчедән, студентларның белемнәрен кинәйтү, аларның күзен ача төшү өчен кирәкле дәреслек материаллары булдырган. Өченчедән, ин мөһиме, әдәби истәлекләрне киләчәктә нормаль типография ысулы белән бастырыр өчен зарур эш—текстологик җәһәттән сыйфатлы, тиешле дәрәҗәдә эшкәртелгән текстларны әзерләү, булдыру эше башкарылган икән.

Еракка карап, кирәкле саклык белән төгәл исәпләп эшләгән икән остаз.

* * *

Хатип аганың тарихи язма истәлекләргә карата ихтирамлы һәм өметле мөнәсәбәте Казан университетында борынгы кульязмаларны җыю, өйрәнү буенча махсус археографик экспедицияләр эше башланып китүгә дә тәэсир итте. «Кауроый каләм эзеннән» исемле китабымда тәфсилләп язганымча, археографик экспедиция оештыру идеясен Шамил абый Мөхәммәдьяров хуплаган, күтәреп алган, сүздән гамәлгә дә күчә башлаган иде. Татар бүлегеннән экспедициягә катнашырлык «бер-ике яраклы студент» та сорар өчен мине Хатип ага янына җибәргән иде. Ул исә яна идеядән очынып, үзе дә барырга ниятләде. Анын үрнәгендә башка укытучылар да сәфәргә катнашырга теләк белдерделәр. Шул рәвешчә, йөк машинасы әрҗәсенә куелган фанер «алачык» иләнендә түшәлгән саламда яткан килеш, тәялеп киттек Оренбург якларына. Юл уңаенда Татарстандагы кайбер авылларда да эзләнгән булдык.

Баулыга җитүгә машинабыз ватылды. Аны төзәтер өчен бер-ике көн кирәк икән. Шамил абый шул эш белән шөгыльләнгәндә, район гәзитеннән Дамир Зарипов дигән егет редакция машинасында безне, Хатип аганың теләге буенча, Бәйрәкә авылына алып китте. Нәкъ шушы урында тезислар рәвешендә язылган көндәлегемнән, җәяләр эчендәге хәзерге өстәмәләр белән, бер абзац күчерәм (12.09.63).

«Бәйрәкәдә Кәшиф Рәхимов дигән кешегә килеп төштек. Элек язып-сызып йөргән, аннары 30нчы елларда «хаҗга» китеп (ягъни репрессияләнеп!), 20 елга якын «сәяхәт» итеп (сөргендә тинтерәп) кайткан, шулай да сәламәт сакланган бик терекчә карт. Бакчачылык белән шөгыльләнә. Мавыгып. Төрле сорт җиләк-җимеш агачлары… Анардан Әпсәләм авылындагы шифер заводында яндырган яки эреткән (утиль) кәгазьләр арасында гарәпчә язулылары да булуын беләбез. Димәк, үлем китапларны икенче урында да бик оста сагалый икән… Кәшиф аганың очырмасына да мендек, биш-алты кульязма, шактый борынгы татарча фикъһ әсәре дә бар. Басма китаплардан А.Болдыревның «Арабская хрестоматия»се, Каюм Насыйри автографы белән; Шәмседдин Саминен «Лөгате» («Камусел әгълам» исемле 6 томлы төрекчә энциклопедиясе)».

Очырмадан төшкәч, бакчада әзерләнгән чәй янында Кәшиф һәм Хатип агалар,

серле генә итеп, узган чорлар, яшьлек еллары хакында сөйләшеп утырдылар. Кыска-кыска җөмләләр, ишарәле, күбесен үзләре генә аңлый торган сүзләр белән.

Бер ара хуҗа кеше Хатип агадан: «Абыең Таһир, шулай итеп, күпердән уза алмый калды диген. Хәзер сәламәтлеге ничек?»—дип сорады. Моңа каршы Хатип ага: «Ярый инде шунда. Ул да авылда...»—дип кырт кисеп куйды. Аннары икесе дә беркадәре вакыт сүзсез утырдылар. Соңрак, Хатип аганың ачылып киткән чакларда «төрле эзәрлекләүләр булды инде» дигән сүзләрен ишеткәндә, мин Бәйрәкә авылы бакчасындагы әлеге әңгәмәне, сакланып кына сөйләшүләрне искә төшерә идем...

Шулай ук әлеге соңгы җөмлә-репликаларның мәгънәсен мин шактый еллар узгач кына аңладым. Аларда сүз Хатип Госманның абыйсы, заманында, 1930 еллар башында «Күпер», «Семафор» исемле күләмле повестьлары, хикәяләре дөнья күргән, 1934 елда ук, беренчеләрдән булып, СССР язучылар союзына кабул ителгән Таһир Госман-Сулмаш (1900-1983) хакында барган икән. Ишарәләп, кыска-кыска җөмләләр белән сөйләшүләре дә тикмәгә булмаган: кайчандыр матбугат, әдәбият дөньясында бер кайнап алган Кәшиф Рәхимов белән әдәби иҗатын өметле генә башлап җибәргән Таһир Госманның да язмышлары бердәй очланган—сынган, имгәтелгән икән...

Берсе егерме елга якын сөргеннән соң бөтенесенә кул селтәп, авылында, бакчасында бикләнгән булса, икенчесе дә, сугыштан яраланып, гарипләнеп кайткач, шулай ук туган авылында сөякләре сыкрап, йомылып яшәргә мәҗбүр булган икән. Аның хәле авыр булганлыгын да мин сонра гына аңладым. Мәсәлән, 1975 елда, Пермь якларына экспедиция белән барган чакта, безгә Сулмашка кереп чыгарга мөмкинлек туган иде. Шул сәфәр алдыннан Хатип ага миңа үз авылында яшәүче сеңлесе Наилә Госмановага адреслап хат биргән, ләкин абыйсы янына керергә димәгән иде. Күрәсең, унайсызлангандыр.

* * *

Аспирантурада укый башлап, Хатип ага белән ешрак очрашкан, якыннанрак аралашкан елларда аның бер характерлы сыйфаты, гадәте тагын да ачыграк, калкурак күренә башлады. Аның иң зур шатлыгы үзенең шәкертләренең, химаясендәге кешеләрнең уңышлары, ирешкән казанышлары булган икән. Коллегаларының, укучыларының хезмәтләре чыгуны ул ихлас күңелдән үз бәйрәме кебек каршылар. Әлбәттә, фәннилек җәһәтеннән дөрес, тиешле югарылыкта дип инанган чакта (әгәр ошамаса, ул, гадәттә, төксәеп, сүзсез генә кала иде). Кайвакытта кечкенә генә бер уңышка да балаларча сөенер иде. Мәсәлән, Сарай Бәркә шәһәрендә табылган калак сөягендәге өч-дүрт сүздән генә торган бер кечтеки язу хакындагы минем бәләкәй генә мәкалә кисәгенең, дөрес, студент чорымда ук (1962 елда) язылган нәмәстәкәемнең, 1963 елда Мәскәүдә «Советская археология» журналында басылып чыгуын ул шулай үзе өчен бәйрәм сыман кабул итте, кат-кат рәхмәтләр әйтте. «Исмәгыйль ага сәяхәте»нә багышланган диплом эшемнең Мәскәүдә басылуы аның өчен тагын да зур казаныш булып тоелды. «Менә! Яшьләребезнең хезмәтләре Мәскәүләрдә, үзәк басмаларда чыга башлады бит!»—дип зур җыңуләргә ирешкән кеше төсле сөенеп йөрде. Гәрчә, дөресен әйткәндә, ул мәкаләләрнең әһәмияте усал шөпшәләр, зур төклетуралар мыжлап торган җирләрдәге кечтеки черкиләр безләве кебек кенә булса да...

Моңарчы әйтелгәннәрдән дә Хатип аганың университеттагы үз эшчәнлегеннән өмете, төп теләге, максаты—тел-әдәбият фәне, татар гуманитар белемнәре өчен әзерлекле, булдыклы кадрлар, белгечләр әзерләү икәнлеге беркадәре шәйләнсә, сизелсә кирәк. Студентлар арасында берәр өметлерәк кеше күренсә, ул аны үз табышы кебек кабул итәр иде. Бер кечкенә факт. Уфадагы Башкорт университетыннан Рәдиф Гатауллин дигән яшь шагыйрьнең (хәзерге Рәдиф Гаташның) безнең университетка күчүен аның мәгънәле вакыйга кебек кабул итүе: «Менә нинди егетләр үзләре эзләнеп киләләр безгә!»—дип, мәгърур рәвештә имән бармагын күтәрүе истә калган.

Аның иң зур сөенгән-горурланган чаклары, минемчә, кафедраның элекке шәкертләреннән Шәйхи Садретдинов, Нурмөхәммәт Хисамовның, тагын берничә елдан Хатип Миңнегулов белән Марсель Бакировларның—укуларын

тәмамлагач, берничә ел эшләп тәҗрибә туплагач—янадан университетка кайтулары, аспирантурага кереп, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Сәйф Сараи иҗатлары, шигърият теорияләре белән шөгыльләнүләре булган иде, дисәм, әллә ни ялгышмамдыр, шәт. Әйтергә кирәк, аларның барсы да остазның өметләрен акладылар. Ниһаять, Сәгыйть Рәмиевнен эчтәлекле җыентыгы халыкка иреште, Дәрдемәнд иҗаты да, Сәйф Сараи мирасы да гадел бәяләрен алдылар. Ә инде Н.Хисамовның Кол Гали иҗатына багышланган һәм Мәскәүдә үк(!) нәшер ителгән монографиясе остаз өчен күктән көткәнне җирдән табу белән тиң иде, минемчә. Хатип аганың ул монография тышлыгын сыйпый-сыйпый, әллә кайларга төбәлеп хыялга бирелеп утыруы һаман күз алдыннан китми.

Әйе, аның бар тырышлыгы, төп кайгысы—беренче нәүбәттә, гыйльми кадрлар әзерләү иде. Үз миссиясен ул иң элек шушы өлкәдә күрә иде. Мина шулай тоелды.

Студентлардан сәләтле, фән белән кызыксынучы берәрсе күренә башласа да, Хатип ага сөенә иде: «Менә, фән дип ажгырып тора торган бер егет килеп чыкты бит әле!—дип кулларын уа.—Мин анар Мөхәммәдьярның текстологиясен бирергә уйлыйм!»—дип хыялга бирелә. Ләкин андый «ажгырып» торучыларның һәммәсе дә шул омтылышларын саклый алмыйлар, ут кебек кызып башласалар да, кем әйтмешли, көл кебек суынып китеп тә бара торган булалар икән.

Борынгы әсәрләрнең текстологиясендә яшьләрнең күпчелегенә тел мәсьәләсе дә проблема була иде. Иске әдәби телне, гарәп-фарсы алынмаларын да белергә, белер өчен өйрәнергә кирәк бит. Шуның өчен бер ара Хатип аганың өметле студент Равил Фәйзуллинга да гарәпчәне өйрәнергә кушып маташуы мәгълүм (әйе, өйрәттек ди аны—ул үзе сине өйрәтер!).

* * *

Хатип ага Госманның тел-әдәбият белемнәре, хәтта тарих буенча да белгечләр әзерләүдәге эшчәнлеге, ихлас тырышлыгы хакында сөйләгәндә аның кайбер хезмәттәшләре, хәтта үз шәкертләре белән шактый катлаулы мөнәсәбәттә булуын да әйтергә кирәктер. Аның житәкчелегендә эшләгән, диссертация язган, ягъни гыйльми җәһәттән аякка баскан кайбер кешеләрнең соңрак остаз белән сүзгә килүләре, беркадәре дошманлашып та йөрүләре һәм элекке житәкчеләре турында тискәрерәк фикер таратулары да мәгълүм. Шулар тәэсирендә, галимнең үзе арадан китүеннән соң чирек гасыр чамасы гомер узса да, аның адресына, мәсьәләне житәрлек дәрәҗәдә белеп житмәгән килеш шик белдереп, таш аткалаучылар, кызганычка каршы, бүгенгә кадәр очраштыргалый. Мин исә бу очракта кайсысы гаепле, кайсысы гаепсез дигән рәвештә катгый хөкем чыгарырга ашыкмас идем. Бәлки иң элек кадрлар, белгечләр әзерләү буенча кемнәр күбрәк эшләде, нинди нәтиҗәләргә иреште дигән сорауларга җавап эзләр идем. Шулай ук кемнең нинди шартларда эшләгән, житәкчелек иткәнлеген дә истә тотарга тырышыр идем.

Шул ук вакытта мин Хатип ага Госманның үзе дә идеаль рәвештә шома, йомшак холыклы кеше иде дигән караштан ерак торам. Кырыслыгы да бар иде аның. Өстәвенә аның характерына билгеле бер күләмдә, әйе, билгеле генә күләмдә, авторитарлык сыйфаты да хас иде. Патриархаль гаиләдә туып-үскән, тәрбияләнгән, авторитарлык тәртипләре вульгар дәрәҗәдә ажгырып торган җәмгыятьтә яшәгән, эшләгән, житәкчелек иткән, югары түрәләр алдында бөгелергә мәҗбүр булган, үзеннән түбәндәгеләрдән дә шундый ук мөнәсәбәт күрергә өйрәнгән, шулай өйрәнергә тиеш булган кешедән башканы көтү мөмкин түгелдер, минемчә. Ләкин аның авторитарлыгы, шулай әйтергә мөмкин булса, шактый корректлы, ягъни вульгарлашмаган авторитарлык иде. Моның шулай икәнлеген аның кеше фикерен тыңлый белүе, каршы яктан әйтелгән дәлилләр житди, ышандыру көченә ия булсалар, үз фикерләрен үзгәртә алуыннан күрергә мөмкин. Ләкин бер нәрсәдә ул гаҗәп дәрәҗәдә нык вә ихлас иде. Мәсәлән, сәяси идеологиядә. Кайбер конфликтларның шушындый җирлектә туган булуы да ихтимал. Чөнки Ленин-Сталин чорларында формалашкан олы яшьтәге кеше белән Хрущев «җепшеклеге», ягъни КПССның XX съезды карарлары заманында үскән, башкачарак уйларга, гамәл итәргә теләгән яшьрәк кешеләр арасында фикер бәрелешләре булу да табигый, минемчә.

Бу катлаулы мәсьәләдә, ягъни остаз вә шәкертләр мөнәсәбәте мәсьәләсендә, бер остазны гына гаепләү белән чикләнмичә, икенче якның, шәкертләрнең мөмкинлек һәм омтылышларын да исәпкә алырга кирәктер, шөт. Шәкертләр арасында да ниндиләре генә булмый. Бозау төсле күндәм, сукырларча ияреп кенә йөрүчеләре дә, үз белдеге белән уңга-сулга ташланучылары да очраштыргалый. Инсафлы, әдәплеләре белән янәшәдә әхлаксызлары да булгалый. Хәтта бераз аякка баскач, ашаган табагына төкерүчеләре дә... Гомумән әйткәндә, остаз-шәкерт мәсьәләсе ул гомер-гомергә катлаулылыгын, актуальлеген җуймый торган мәңгелек мәсьәләләрнең берседер.

Шәкертнең, укучының остаз-мөгаллимнән узып, үсеп китүе дә табигый күренеш. Андый хәлләр булмаса, фәндә, гыйлемдә алгарыш дигән нәрсә дә, мөгаен, бөтенләй булмас иде. Ләкин остазларга караганда шәкертләрнең артка чигенү очраклары да аз түгел. Үз элгәргеләренең башларын ашый-ашый карьера юлында югары дәрәҗәләргә ирешүчеләр дә безнең узганыбызда җитәрлек булды. Һәрхәлдә, җинел генә чишелми торган авыр, катлаулы, шунысы белән гаять четерекле мәсьәлә бу.

Сүзне артык куертып тормыйча, Хатип аганың үз шәкертләренә мөнәсәбәтенә якынрак килсәк, ул гыйлем-фәнгә ихлас дәрәҗәдә турылыклы яшьләрнең, шәкертләренең күп булуын теләде һәм шуңа җиту юлында сизелерлек нәтиҗәләргә дә ирешкән һәм күңелсез ялгышларга да дучар булган иде. Кайбер укучыларыннан канәгать булмаган чакларында ул: «Аңа юл ачып ялгыштым шикелле, имансыз кеше булып чыкты... Гомумән, гомер-гомергә кеше таный алмыйча җәфаландым мин!»—дип көрсенгәләп алуын ишеткәләргә туры килгән иде. Әйе, башта фән-гыйлемгә үзен ихлас омтылучы сыйфатында тәкъдим итә алган кешенең буш куык икәнлеген белүе, ачы тәҗрибәләр күрсәткәнчә, күңелле нәрсә түгел икән...

Үземне Хатип аганың шәкертләреннән берсе исәпләвемне хәтерләүче укучыда: «Сезнең аралар ничегрәк иде соң?»—дигән сорауның тууы ихтимал. Шома һәм җайлы гына барды, дип әйтер идем бу хакта. Безнең арада фикер бәрелешләре, характер конфликтлары килеп чыгарга сәбәп тә, җирлек тә юк иде шикелле. Беренчедән, ул минем рәсми җитәкчем түгел иде, гәрчә мине үз химаясеннән ташламаса да (әгәр аның шулай даими химаясе сизелеп тормаса, СССР тарихы кафедрасында татар тематикасын теләмәүчеләр мине ашап ташлаган булырлар иде). Икенчедән, безнең гыйлемдәге шәхси интересларыбызда мәнфәгатьләр кисешкән урыннар юк диярлек иде; ул әдәби әсәрләр, шигырь дөньясында яшәгән булса, мин тарихи язма истәлекләр белән мәш килә идем. Археографик табышлар исә уртак хәзинәбез. Өченчедән, безнең мөнәсәбәтләребездә билгеле дәрәҗәдә бер аралык та сакланды. Башта ук авызым бер пешкәнгә, мин аның белән һәрвакыт сак сөйләшергә тырыштым; ул да минем характерымның шактый кытыршы икәнлеген исәпкә алды сыман. Ара саклауны минем аларның өйләрендә ике генә мәртәбә булуым да күрсәтә. Беренчесендә бер ашыгыч документка кул куйдырыр өчен дүрт-биш минутка кереп чыктым, икенчесендә исә... хәер, анысы хакында аерым сүз булыр әле.

Бер ара ул татар шигыре табигатен гел «халык шигъриятеннән» эзләп мавыкты, бездә гаруз алымы булуын шик астына куюга җитә язды. Шушы мәсьәләдә дә күңелсез бәхәсләр чыкты сыман. Чынлыкта төркиләргә гаруз кануннары кергәнче дә шигырьләр әйтелүе шик тудырмый. Гарузның хөкем сөрүе дә бәхәссез түгел, аның кагыйдәләреннән гамәлдә баш тартулар да булмады түгел. Кыскасы, гел бер якка чабулауның нәтиҗәсе иде бу...

Кафедра мөдире татар бүлегендәге кайсы хезмәттәшенең кем һәм нинди булуын да яхшы белә иде. Кайберләренең университеттагы үз вазифаларын яхшы үтәмәүләрен, педагоглык кәсепләренә тугрылык сакламауларын, вак-төяк шәхси мәнфәгатьләр артыннан гына куууларын өнәп бетерми; бигрәк тә аларның гыйльми яктан үсмәүләре, аспирантлык чорларында гына «катып калулары» өчен борчыла иде. Әллә нинди тирән белемнәре булмаса да, купшы сүзләр, модный атамалар сиптереп, күз буярга маташучыларны җене сөйми... Иң кызыгы, бүлектәге педагогларның кайсылары китапханәдә күпме күренүләре белән өйгә нинди һәм ничә китап алып торуларына кадәр белеп, күзәтеп тора иде. Ә бу кемгә ошасын?..

Кафедра мөдире, гыйльми җитәкче сыйфатында Х.Госманны кырыс, авыр кеше дип гаепләүчеләр булгалагандыр, бәлкем. Тик аның бер хезмәткәрен дә эштән куууын хәтерләмим. Ә эштән куарга лаек кешеләр бар иде, һичшиксез... Ул аларның

төзәлүеннән өмет итте. Үзләре теләп китүчеләр, башка җирләргә күченүчеләр булгалады, әлбәттә.

Хатип ага мөдирлеккә үзенә алмаш эзләүдә, әзерләүдә дә зур күңелсезлеккә дучар булды. Тирән белемле, эшлекле, шул ук вакытта табигый тыйнак холыклы профессор Нил Юзиевнең (1931-1996) үзеннән соң мөдир булып калуын теләгән, планлаштырган икән. Ләкин аны 1973 елда Тел, әдәбият һәм тарих институтына бүлек мөдире итеп күчерәләр. Мондый әмер-фәрманнан «карталары буталган» профессор Хатип Госман, ризасызлык белдереп, Юзиевне университетта калдырып булмасмы дип өлкә комитетына бара, андагы зур түрә белән очраша, үзенең тиздән мөдирлектән китәчәге һәм планнары хакында әйтә. Анда исә: «Кадрлар белән идарә итү ул безнең, ягъни партия эше, ә сез үзегез турында күрсәтмә булганны көтегез»,—дип, коры рәвештә сөйләшеп чыгарып җибәрәләр.

Һәрхәлдә, Нил Юзиевнең кафедрадан китүен ул шулай үзе өчен авыр югалту рәвешендә кабул иткән иде. Шулай да 1975 елда кафедра мөдире булып «Чаян» журналының элекке баш мөхәррире Альберт Яхин килүен ул канәгатьләнү хисе белән каршылады.

Югарыдан төшерелгән әлеге карар-күрсәтмә билгеле булуга мин Хатип агадан аның фикерен белергә теләгән идем. Аның: «Аллага шөкер, юкса кафедрага туган-тумачалык, авыл-салалык, якташлык атмосферасы кермәгәй дип курка башлаган идем. Альбертның принципиальлегенә ышанам»,—дигән фикерен яхшы хәтерлим. (Бераз соңрак расланганча, «туган-тумача», «агай-энелек» күренешләре безнең өчен һәрвакыт янап тора торган реаль чынбарлык икән...). Тик Альбертның докторлык диссертациясе уңышсызлыкка очравы, аның кандидат килеш тагын яңа срокка мөдир итеп сайланырга хакы булмавы, минемчә, карт остазның соңгы елларына беркадәре күңелсезлекләр китергән иде.

* * *

Югарыда профессор Хатип Госманның идеологик, сәяси мәсьәләләрдә үзенчә нык булуы хакында әйткән идем инде. Болай дип, мин ин элек аның марксистик-ленинчыл идеологиянең гел дөреслегенә ихлас күңелдән ышануын, шул тәгълиматка эзлекле рәвештә тугрылык саклавын күз унында тотам. Ул гомер-гомергә коммунистлар партиясе һәрвакытта да дөрес юлда, аның җитәкчелегендә тормышыбыздагы барлык кыенлыкларны, кимчелек һәм начарлыкларны бетерергә мөмкин дигән ышаныч белән алданып яшәде шикелле. Еш кына: «Менә күрерсез әле, үзәк комитет фән, мәдәният хакында бер зур карар чыгарачак, шуннан соң барсы да дөрес эзгә салыначак», яки: «Безнең тормыштагы җитешсезлекләрне бары партия карары гына төзәтәчәк, башка юл юк»,—дигән рәвештәрәк әйткали иде. Күрәсең, XX съезд карарларының көчле тәэсире, гәрчә 60нчы елларның икенче яртысыннан соң аларның әһәмияте шактый кимегән халдә дә, Хатип ага күңелендә яңа өметләр асрарга җирлек саклаган булса кирәк.

Казан университетына килгәнче Педагогик институтта Көнбатыш Европа әдәбиятлары буенча да укыткан Хатип ага гомумән марксизм классикларының хезмәтләрен дә яхшы белә иде. Берничә мәртәбә үземә Энгельсның кайсы китабын, аның кайсы төшен, Ленинның нинди әсәрләрен укырга, әгәр элек укыган булсам, кабат карарга киңәш биргәләвен яхшы хәтерлим. Большевистик система әле нык, аның идеологиясе ажгырып торган, шуларның кулгәсенә ышыкланган догматиклар, демагоглар гел «бәйрәм иткән» ул елларда әлеге әсәрләрне җентекләп уку, каруына күрә даруы табылган төсле,файдасын да биреп куя иде.

Дөресен әйткәндә, ул елларда барыбыз да марксизм вә сыйнфыйлык принципларына ышана, аның кысаларыннан чыкмаска тырыша идек. XVII-XVIII йөзләрдә татарча тарихи әсәрләрнең ни өчен аз һәм начар язылуын ачыклаган чакта, мин бу күренешне тарихи әсәрләрнең сыйнфый-иҗтимагый табигатьләре буенча дәүләтчелеккә бәйләнүе, дәүләтчелек бетерелгәч андый хезмәтләргә ихтыяҗ калмавы, шуңа күрә андый әсәрләр бездә язылмавы белән аңлаткан идем. Моны Хатип ага ике куллап хуплады: «Менә, менә! Сыйнфыйлык принцибын куллану ул бар нәрсәне дә аңларга ярдәм итә! Барсын үз урынына утырта. Марксизм ул универсаль тәгълимат!»

Югарыда бер әйткәнемчә, ул «Коммунист» журналын, «Правда» гәзитен даими рәвештә укып бара, алардагы кайбер материаллар хакында безгә үз фикерләрен дә әйткәли иде. Кайвакытларын көлкелерәк хәлләр дә килеп чыккалый иде. Мәсәлән, 70нче еллар уртасында «Правда» гәзитендә атаклы академик Д.С.Лихачев белән мәгълүм археограф, профессор С.О.Шмидт тарафыннан СССРда борынгы кульязмаларны җыю, өйрәнүнең торышы, актуальлеге хакында язылган бер кечкенә генә мәкалә басылып чыккан иде. Анда гомум информация рәвешендә әйтелгән сүзләр рәтендә: «Казанда М.Усманов һәм аның хезмәттәшләре дә кульязмалар җыюда нәтиҗәләргә ирешә»,—дигән сыманрак бер җөмлә дә бар иде. Шуны укыган Хатип ага кулларымны кыса-кыса котлады, тагын рәхмәтләр әйтте. Берәр атнадан «Социалистик Татарстан» гәзите редакциясенә барып, андагы егетләрне (үзенең шәкертләрен, билгеле) «Правда» чыгышына ник бер дә реакция белдермисез, дип пыр туздырып, шунысы белән әлеге бәләкәй мәкаләнең татарча тәрҗемәсе басылуга да ирешкән иде.

Әйе, ул елларда «Правда» битләрендә исем аталу зур нәрсә, хәтта мөһим казаныш кебек кабул ителә иде. Гаделлек өчен шуны да әйтик: әлеге бер җөмлә безнең археографик экспедицияләребезне саклап калуга, гомерле итүгә дә үз өлешен кертте. Ректоратның гыйльми эшләр буенча бүлегендә, юкка акча туздырмау нияте белән, «иске дини китаплар» җыя торган әлеге экспедицияләр эшен туктату хакында фикер туып өлгергән булган. Хатип аганың үзе соңрак әйтүенә караганда, ул әлеге гәзитне селки-селки гыйльми эшләр буенча проректор янына да кереп чыккан икән...

Хатип ага үзен кайвакытларын партиянең вак-төяк чиновниклары алдында да күндәм, буйсынучан итеп тота иде. Моның бер мисалы ике көн дәвамында (ике көн—элек тә, соңра да күрелмәгән хәл!) минем кандидатлык диссертациямне тикшергәндә күзәтелде. Мәсәлән, факультеттагы партоешма секретаре, хезмәтемнең гомум әһәмиятен инкяр итә алмаганы хәлдә дә, кайбер мәсьәләләр буенча миңа шактый бәйләнгән, тырнак астыннан кер эзләп вакланган, шунысы белән мәгънәсезрәк раслаулар да ычкындыргалаган иде. Бер сүз белән әйткәндә, аның тәнкыйте җитди түгел, шунысы белән бөтенләй зарарсыз иде. (Аның каруы башкаларның чыгышларында кайбер күпкә җитди һәм гадел тәнкыйть фикерләре бар иде.) Фикер алышуга катнашкан Хатип ага, ахырда, мине бер читкә чакырып алып: «Тәнкыйтьләрнең кайсыларын кабул итү-итмәү үз эшең, әлбәттә. Ләкин партоешма секретаре,—дип, бу сүзләргә басым ясап,—фикерләренә аерата игътибар итәргә тырыш»,—дип кисәткән иде.

«Казан утлары» журналының бүлек мөдире Фәрваз Миннуллинның сүзләре онытылмый: «Әдәби ел йомгакларында өлкә комитетыннан килгән түрә, галимнәр әдәби процесстан читтә торалар, дип берничә исемне атап шелтә белдергән иде. Моңарчы бер дә кымшанмый торган Хатип ага да ике-өч көн эчендә бер әсәргә рецензия язып китерде»,—дип елмайган иде ул.

Хатип аганың партия чиновникларыннан яскануы, ачыграк әйткәндә, куркуы 20-30нчы елларда «мәзин малае» буларак эзәрлекләнгән чорындагы халәтенә барып тоташадыр. Шул 20-30нчы елларда аның еш-еш торган җирен, эш урынын алыштыруы да, минемчә, тикмәгә генә булмагандыр.

Дөрес, кайвакытларын ул партия исеменнән сөйләргә, хөкем чыгарырга күнеккән авторитетларга каршы каты сүз әйтүдән дә тайчанмый иде. Бер көнне, мәсәлән, Мөхәммәт Мәһдиев белән бергә химик корпус алдында Хатип аганы очратып, юк-бар, ул-бу турында күнелле генә кыяфәт белән сөйләшеп тора идек. Профессор Камил ага Фәсиев килеп чыкты. Ул моннан дүрт-биш ай элегрәк бер зур конференциядә Мөхәммәт белән икебез язган бер мәкаләне, анда Фатыйх Кәрими, Риза Фәхреддин иҗатларына, гомумән элекке татар матбугатына артык зур игътибар итүебез өчен, сыйнфыйлык, партиялек позициясеннән чыгып, теттереп тәнкыйть утына тоткан иде.

Тәнкыйтькә каршы шул конференциянең үзендә үк тиешле җавап бирелгән булса да, күп тә узмый «Социалистик Татарстан» гәзитендә безне ачыктан-ачык буржуаз милләтчелектә гаепләгән зур күләмле редакцион мәкалә (әйтүләренә караганда, шул айда аның өчен Хәсән Хәйригә гонорар түләнгән махсус мәкалә) басылып чыккан иде. Шуна ишарә итептерме, Камил ага, бер кадәре ирония белән, ләкин тулаем алганда дустанә рухта, һәрберебез белән күрешә-күрешә: «Нәрсә, җегетләр, фикер берләштереп торабызмы әллә?»—дип елмайган иде. Әйтеп тә өлгермәде, Хатип ага

шартлаган төсле реакция белдерде: «Нәрсә син, Камил, һаман бәйләнәсен боларга? Житкәндер инде гел кирегә сөрү! Фәндә бераз дөреслек булсын дип болар пычак йөзеннән йөриләр бит, нигә һаман кысарга аларны?..»

Мондый кискен каршылыкны көтмәгән, үз сүзләрен шаяртуга әйләндерергә теләгән Камил ага: «Нинди кысу инде? Мәкаләләре басыла бит»,—дип аклана башлагандай итте. Моңа каршы Хатип ага: «Әллә басылмауларын теләр идеңме?»—дип жикерде. Профессор Фәсиев исә:«Һай, жегетләр, шаярып та булмый сезнең белән»,—дип кулын селтәп, бина эченә кереп китте. Кыяфәтендә баягы күнеллелектән бернәрсә дә калмаган Хатип ага да, саубуллашу урынына башын гына изәп, төп бина ягына юнәлде. Хушлашкан вакытта Мөхәммәт Мәһдиевнең: «Мондый реакцияне һич тә көтмәгән идем»,—дип, уйчан рәвештә әйткән сүзләре мине дә уйландырды.

Кайбер гыйльми мәкаләләре, бигрәк тә Бубилар турындагысы өчен эзлекле тәнкыйтькә дучар булган (туры сүзләре өчен, бәлкем, үзе ишарә иткәнчә, махсус күзәтү астына да алынган), ниһаять, соңрак XX гасыр башындагы әдәби, мәдәни хәрәкәтләр хакындагы китабы да тыелган Мөхәммәтнең болай шикләнгән төстә уйлануларына, ихтимал, нигез житәрлек булгандыр.

Хатип аганың минем өчен идеологик мәсьәләдә табышмак рәвешендә калган тагын кайбер фикерләре, сүзләре, гамәлләре дә бар. Бер көнне ул, мәсәлән, аталар һәм балалар, гомумән гаилә хакында сүз чыккач, уйчан рәвештә болайрак дигән иде: «Бездә гаилә жимерелеп бара. Ата, бала һәм оныклар арасындагы бәйләнышлар юкка чыга. Сәбәбе хосусый милекнең юкка чыгуы белән бәйле булса кирәк. Әйе, хосусый милек ул гаилә эчендәге бердәмлекне тотып, саклап торган нәрсә икән... Ә гаилә ныклыгы бетсә, жәмгыятьнең, халык-милләтнең дә бердәмлеге, ныклыгы бетә дигән сүз... Хосусый милектән баш тарту гомумән дөрес булды микән?»

Олы яшьтәге, мәсьәләләрнең тамырына, нигезенә карарга тырышкан, үзен гел принципиаль партияле дип инанган галим картның бу сүзе миңа кызыклы да, мәгънәле дә, беркадәре сәеррәк тә булып тоелган иде ул мизгелдә. Бер яктан карасаң, хосусый милек ул кешелек жәмгыятендә зур урын биләп торган тарихи күренеш. Ләкин, бездә хөкем сөргән тәгълимат буенча, бары аннан арынып кына кешене кеше изми торган гадел жәмгыять төзеп була. Нәрсә бу, белемле, тәжрибәле затның социализмның большевистик варианты нигезләренә шик белдерүеме әллә?..

Безнең яшьлегебез, гомеребезнең зур бер өлеше вульгар атеизмның, ягъни рухи имансызлыкның ажгырып торган чорына туры килде. Теләсә кем үзенең атеист, Алласыз булганлыгын белдереп торырга тырыша иде. Зыялылар катламы бигрәк тә. Хатип ага да үзен гомумән дингә битараф кеше итеп тота иде. Мондый гадәткә ул, бәлкем, «мәзин баласы» буларак, үзенең кыерсытылган елларында ук күнеккәндер. Хатыны Марфа апаның керәшен булуы, шулай калуы, бер сеңлесенең ире дә керәшен кешесе икәнлеге (Сулмаш авылында ул безне бик тырышып, өстәлгә шешәләр тезеп кунак итәргә омтылып караган иде), һәрхәлдә, ике төрле уйланырга нигез калдырмый кебек.

1969 елның жәендә, Алматыдан кайткан көннәрнең берсендә, төп бинабыз каршындагы «таба» янында очрашырга туры килде. Исәнләшүгә үк ул якындагы буш эскәмияләрнең берсенә барып утырды да: «Соңгы вакытларда күренми тордың, әллә сәфәрдә булдыңмы?»—дип сорады. «Кичә генә Алматыдан әтине жирләп кайттым»,—дидем. Хатип ага шунда ук тезләре өстендә яткан учларын жәеп: «Иннә лилләһи...»—дип башлап, мәгълүм доганы тәгәл укыды да, тиз генә бит сыпырган кебек учларын кавыштырды. «Авыр туфрагы жиңел, иманы юлдаш булсын»,—диде. Шуннан соң гына ни сәбәптән, ничә яшендә үлгәнлеген, һәм ничек озатуыбыз хакында сорашты. «Үзебезчә, мөселманча барлык йолаларын үтәп күмдек»,—дидем мин. «Бәрәкалла, бәрәкалла, шулай кирәк»,—дип түбән карап бераз уйланып утырды да: «Атаң үлгәч, үзеңнең жаваплылыгың артачак инде»,—дип өстәп куйды.

Кеше үлеме турындагы хәбәрне шулай каршылар дип бер дә уйламаган идем әле...

* * *

Хатип ага Госманның минем өчен бераз кызыграк булып тоела торган тагын бер сыйфаты, гадәте бар иде. Ул аның искитәрлек дәрәжәдә үзенчә аккурат

һәм пөхтә булуында, дөресрәге, шул сыйфатның үзенчәлегендә иде. Мәсәлән, машинкага биреләчәк кулъязмаларының тышкы күренешендә. Без, әйтик, язган әйберләребезнең кулдан күчерелгән текстларын тагын үзгәртелгән сүзләре, өстәлгән юллары, хәтта аркылы-торкылы сызылган абзацлары белән бергә, башка акка күчереп тормыйча гына машинисткага бирәбез. Хатип аганың кулъязмасында андый күренеш һич тә булмас. Ул, мәсәлән, язылып, эшкәртелеп бетеп бер мәртәбә акка күчерелгән текстлар өстендә тагын да кат-кат эшләгән, яңа төзәтмәләр керткән булыр. Ләкин сызылган сүзләр, үзгәртелгән юллар, хәтта төзәтелгән хәрефләр өстенә махсус үлчәп киселгән кәгазь кисәкләрен җилем белән ябыштырып чыгар, шуларга әлеге юлларның, сүзләрнең, хәреф билгеләренең үзгәртелгән, ягъни тиешле дип табылган соңгы вариантлары язылган булыр.

Ул вакытларда кулланууда бары тиз саргаючан начар сыйфатлы контора җилемнәре (селикатлы келәйләр) булганга соңрак утыртылган саргылт «ямаулыкларның» төсләре кәгазь битенекеннән аерылып, нәтиҗәдә чуарланып торган була.

Аның бу гадәте, минемчә, иң элек үзенең табигый аккуратлыгыннан, җаны, күңеле шапшаклыкны сөймәүдән, аннары машинистка хезмәтен дә үзенчә хөрмәт итүдән килгәндер, күрәсең. Ниһаять, болай эшләвеннән үзенең язганнарыннан бер сүз-фикер хакында икеләнгәнлеген, эзләнгәнлеген башкаларга белдерергә теләмәве дә сизеләдер, бәлкем. 30нчы еллар аша узган кешеләрдә булуы ихтимал мондый саклыкның.

Кулъязмаларының шундый тышкы сыйфатына карата кафедрада эшләгән машинисткалардан төрле фикерләр ишетергә туры килгәләде. Берсе, мәсәлән, шулай кирәк дип тапса, икенчесе: «Келәй белән пычранып юкка вакыт әрәм итә, без ямаусыз да баса алган булыр идек сызгаланган текстны. Машинка варианты барлыкка килгәч, ул караламаның кирәге калмый бит»,—дип үзенчә хөкем чыгарган иде.

Хатип Госманга хас тәртиплелекнең икенче бер чагылышы сыйфатында аның бервакытта да соңга калмавын, күпләр кебек вәгъдә биргән кешеләрен көттермәвен әйтер идем. Мин, мәсәлән, аны «кайчан килер икән инде», дип көтеп утыруларымны бер дә хәтерләмим. Ә башкаларның көттерүләре еш була иде.

* * *

Иҗади һәм тәртипле кеше буларак Хатип ага сәламәт акыл, олы яшенә күрә әйбәт хәтер белән матур картайды шикелле, гәрчә картлыкта матурлык дигән нәрсә би-и-ик тә чамалы табылса да. Һәрхәлдә, аның 1951 елдан 1975 елга кадәр, димәк, 24 ел дәвамында Казан университетында татар теле һәм әдәбияты кафедрасының, дөреслектә, бөтен татар филологиясе бүлегенең җитәкчесе, аннары 1991 елгача шул кафедраның профессоры, консультант-профессоры булып эшләве, ягъни 40 елдан артык гомерен уку-укыту эшләренә, гыйльми кадрлар әзерләүгә багышлаган булуы күп нәрсә хакында сөйләсә кирәк.

Әгәр ул бастырган әдәби әсәрләрнең, гыйльми хезмәтләрнең, җөмләдән зур-зур монографияләрнең, беренче тапкыр нәшер ителгән урта гасыр әдәби истәлекләрнең һәрберсен атый, анализлый, бәяли башласаң, үзенә күрә аерым бер яңа әсәр—зур очерк, хәтта китап барлыкка килер иде. Ләкин минем максатым, язмамның башында ук әйтелгәнчә, аны искә алу, кеше буларак кайбер гадәтләре, сыйфатлары хакында хәтер яңарту. Ягъни максатым профессор Хатип Госман эшчәнлеген төрле яклап яктырткан биографик монография язу түгел. Андый хезмәтне бүгенге көндә авторлар коллективы гына башкара алыр иде.

Шуны да ачык әйтергә кирәк, Хатип ага үзенең соңгы елларын беркадәре күңелсезрәк хәлдә, канәгатьсезрәк рәвештә уздырды шикелле. Моның бер күренеше 1988 елда аның 80 еллыгын үтә дә формаль, шактый сүрән рәвештә уздырылуында да чагылыш тапты бугай. Юбилейны озак еллар ул җитәкләгән, аның чорында аякка нык баскан татар филологиясе бүлеге нигезендә 1986 елда оештырылган Татар филологиясе, тарихы һәм шәрекъ телләре факультетының зур, гомум бәйрәме итеп билгеләргә дә мөмкин иде кебек. Тик киңәйтелмәгән гыйльми совет утырышында гына кыскача котлаулар белән чикләнелде. Югарыдан, хөкүмәт тарафыннан да берниндн реакция сизелмәде. Димәк, оештырылмаган. Факультет җитәкчелегенең дә

активлыгы сизелмәгән булса, 80нче елларның икенче яртысындагы университетның үз хәле—бер яктан яшәр өчен талпыну, икенче тарафтан җимерелә башлау чигенә килә язуы да—үзен нык сиздерде, гомум сүлпәнлеккә сәбәп булды шикелле.

Ул елларның иман алмаштыру чоры, димәк, элекке авторитетларга карата мөнәсәбәтләрнең үзгәрүен дә онытмаска кирәктер.

Ниһаять, бездә тере кешеләрнең, бигрәк тә галим-голәмәнең юбилейларын билгеләгән чакларда реаль эшчәнлегенең, хезмәтләренең әһәмиятеннән бигрәк, нәкъ шул вакытларда аның нинди рәсми дәрәҗә тотуына, төгәлрәк әйткәндә, нинди кәнәфидә утыруына карап гамәл итү гадәткә кереп бара...

Гомеренең соңгы елында ул күзгә күп чалынмады.

1992 елның 11 гыйнварында кич белән телефон чылтырады. Альберт Яхин икән:

—Хатип ага вафат. Үз түшәгендә. Иртәгә чыгарабыз.

Халык әллә ни күп булмады, дөресрәге, аз иде аны озатканда.

Мәетне җир куенына тапшырып кайтканнан соң, Альберт Яхин җитәкчелегендә дүрт-биш кеше Марфа апаның атап чакыруы буенча, мәрхүмнең яшәгән урынына—өйләренә кайттык. Бу минем Хатип агалар йортында икенче мәртәбә булуым иде.

Аның җан тәслим кылган бүлмәсендә, элекке эш кабинетында, бер караватт, кечкенә генә язу өстәле һәм шыплап китап тутырылган шкафлар гына. Берничә китап, менә без монда, дигән төсле, тышлыклары белән алга каратып куелган. Минем «Жалованные акты» дигән 1979 елда чыккан яшел тышлы китабым да шулай «чекерәеп» тора...

Марфа апаның үз йоласы буенча әзерләгән табыны янында мәрхүм турындагы истәлекләргә бирелеп, монаеп, ара-тирә елмаешып та утырдык...

—Бер елны каникулда авылдан кайтканда,—дип елмайды элекке аспирант Галимҗан Гыйльманов,—остазына кучтәнәч булсын дип, әниебез бер каз, үзе үстергән казның түшкәсен биреп җибәргән иде. Килдем шуны исән-имин чагында тапшырырга дип. Ишекне Хатип ага үзе ачты. Исәнләшеп, аяк киемнәремне сала-сала казлы капчыкны Хатип агага суздым. «Нәрсә бу?»—дип сорады ул. «Каз» дидем, билгеле. Беравык Хатип аганың авызы ачык килеш торды, аннары шартлаган төсле җикеренеп үк җибәрде: «Син нәрсә, мине ишан дип белденме?! Бар, кит моннан! Үзең дә кит, казың да!..» Ничек чыгып китүемне сизмәдем, бары беренче катка төшкәч кенә бераз аңыма килеп, ботинкаларымның бауларын бәйләдем...

...Шактый вакыт дүрт-биш кеше шулай хатирәләргә бирелеп утырган идек.

Кемнәр икәнлеге дә төгәл истә калмаган хәзер.

Уйлап карасам, бергә булган чакларны искә төшерүләрнең үзләре дә өзек-өзек хәлдәге истәлек булып калган икән...

*2008, февраль-март*

---

## Авторларыбыз игътибарына

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу уңай.

Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Тәлгат
Галиуллин

# ТАРИХ САБАКЛАРЫ...

БЕР КИТАПНЫ УКЫП УЙЛАНУ

Хәтерсез халыкның киләчәге юк, диләр. Сүз татар тарихының Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы кебек шөһрәтле вә гайрәтле чорларын онытмау турында гына бармый. Иншалла, дәүләтле дәверләребез хакында тарихчылар, язучылар, демократия җилләре алып килгән форсаттан файдаланып, фәнни һәм әдәби әсәрләре белән укучыларын шатландырып торалар.




Ялган һәм берьяклы, берәүләрне рәнҗетү хисабына икенчеләрне күтәребрәк кую сәясәтеннән акрынлап булса да арындыру вәзгыяте бара. Халык тарихы гел эре бөҗралардан гына тормый шул, аның яшәешендә бер караганда артык олы вакыйга булып күренмәгән, мәгәр аның йөрәгендә утырган, бәгыренә кадалган, аң үсешен, әхлакый-фәлсәфи фикерләү дәрәҗәсен тоткарлаган, менталитетын билгеләгән хәлләрне дә онытырга хакыбыз юк. Әйтик, Сталин репрессияләре чорын хәтердән сызып ташлау, ярлыкау, явызлыкны гафу итү хакыйкатькә хилафлык кылу булыр иде. Большевизм системасының төп авырлыгы татар кебек тарихлы, зыялы халыклар башына төште.

Тарих фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры Рәмзи Вәлиевнең "Өзелгән дога" *(Казан: Татар. кит. нәшр.,—2007.)* исемле китабының үзәк юнәлеше тоталитар режимның татар милләтенә китергән зыянын, афәтен ачуга юнәлтелгән. Бу тема күренекле тарихчыбыз өчен өр-яңа түгел. Совет хакимиятенең төрле ысуллар, пычрак алымнар ярдәмендә, асыл затларыбызны физик юкка чыгарып, татар халкын дәүләтсез, телсез, фикерле, аңлы генофондсыз калдырып, үткәнен оныткан, бүгенгесе, киләчәге өчен көрәшкә сәләтсез маңкортлар көненә калдыру сәясәтен фаш итүне Р. Вәлиев гомерлек яшәү максаты итеп сайлады. Китапта "уннар", "контрлар", "милләтчеләр", "җидегәнчеләр" буларак гаепләнеп, юк ителгән репрессия корбаннары, өстән оештырылган пычратулар, шикаять оештырулар, нахакка рәнҗетүләр турында укыганда, урта гасырга хас хәлләрнен XX гасырда кабатлануын күзаллаганда чәчләр үрә тора, тәннәр чымырдый...

Күренекле тарихчы А. Литвин язганча, 1938 елның ахырына Татарстан коммунистлары оешмасының "11 процентын партиядән кудылар, ә 1,5 меңнән артык әгъзага" халык дошманы дигән хурлыклы исем тагып, репрессиягә дучар иттеләр *(Литвин А. Запрет на жизнь.—Казань, 1993.—С. 21).*

Корбаннар арасында Галимжан Шәрәф, аның нәсел-нәсәбе, Мирсәет Солтангалиев, Гали Рәхим, Жамал Вәлиди, Садри Жәләл, Ибраһим Аитов, Әхмәт Хөсәенов кебек милләтнең асыл уллары булу күңелне аеруча әрнетә, явызлыкка нәфрәт уята. Бу кешеләрнең күбесе татар халкының киләчәген кайгыртып, Совет хакимиятенең буйсынган халыкларны кысуга, сытуга, телләрен юкка чыгаруга алып барган сәясәтен тирәнтен аңлаган чын зыялылар, милләт балалары иде. Алар турыдан-туры хакимияткә каршы чыкмыйлар, тик туган халыкларына башкаларга бирелгән, тиешле хокукларны гына сорыйлар, хәтта "Идел—Урал" штаты да федератив Рәсәйнең бер өлеше буларак кына күзаллана.

Р. Вәлиевнең яна китабында тарихи шәхесләр—репрессия корбаннары -һәркайсы үз йөзләрен саклаган хәлдә бер җыелма образ—каһәрләнгән чор символын тудыралар. Үзеннән-үзе куркып яшәгән, илгә хуҗа булуга лаек түгеллеген сиземләгән хакимияткә урамда хәер эстәп, чүплекләрдә казынып йөргән, йортында бәдрәфе дә булмаган алабайлар кирәк түгел. Аның җиз иләге татарның (башка халыкларның да) иң белемле, иң акыллы, иң гайрәтле, нәселле, милләт язмышы, киләчәге өчен сызланып яшәгән көчле кешеләрне сайлап ала, система агулы угын шулар йөрәгенә төби.

Утызынчы елларда үлем тегермәненә эләккән кешеләрнең күпчелеге—әүвәл инкыйлабка, фетнәне оештыручыларның барча милләтләргә азатлык, бәхетле тормыш, тигезлек вәгъдә иткән шигарьләренә ышанып, яңа тормыш төзү эшенә чын-чынлап керешкән фидакарь затлар. Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура, Садри Максуди, Габделбарый Баттал кебек, большевикларның империячел асылын, Кремльгә кереп оялаган адәмнәр алып барачак сәясәтне вакытында аңлаган, чит илләргә чыгып китү хәстәрен күргән кешеләр күп булмый. Икенче яктан, андый ният булганда да, татар кешесенә чикне үтеп чыгуы, мөһаҗирлектә яшәешен тәэмин итүе җиңел түгел. Хәтта тугандаш Төркиядә дә, "мөселман кардәшебез килгән икән, әйдә, түрдән узып рәхим ит" дип, фатирын, эшен тәкъдим итеп тормыйлар. Фатыйх Кәрими кебек шәхесләр илдән чыгып та китә алган булырлар иде, бәлки. Мәгәр "яңа тормыш" корбаннарының иң зур күпчелеге әлеге дә баягы татар халкының язмышын үзгәртүгә, яхшы якка борып җибәрүгә, мәгълүм мөстәкыйльлек бирелүгә ихластан ышана. Мәсьәләгә мондый караш хәтта Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, Ф. Бурнаш кебек "ортодоксаль" большевиклар позициясен аңлауга да ачкыч була ала.

Милләткә файдасы тиярдәй, киләчәгенә өмет чаткылары уятырдай һәр форсаттан файдаланып калу рухы белән яшиләр бу затлар. Әмма ялгышуларын аңлагач соң була инде...

Шундый афәтнең якынлашуын зирәк сәясәтче, энциклопедик галим Галимҗан Шәрәф беренчеләрдән булып аңлый, совет хакимиятенә ышанып яшәгән беркатлырак татар зыялыларының күзен ача. Аерым алганда, китапта күренекле әдип Гали Рәхим белән "тәрбияви эш" алып баруын тасвирлаган юллар үзенчәлекле.

Совет хөкүмәтенең зиһенле, укымышлы кешеләрне юк итүгә корылган мәкерле сәясәтен аңлап җитмәгән, ялган шигарьләргә ышанып ябрак яшәгән әдәбият галиме Гали Рәхим Галимҗан Шәрәфнең борчылуларына "Без бит филологлар, фольклорчылар гына, безнең ГПУга кирәгебез юктыр", дип беркатлы җавап бирә. Сәяси яктан әзерлеклерәк, сизгер Г. Шәрәф дустына, шулай ук Шәрык педагогия институты доцентына бик төгәл аңлатма тәкъдим итә: "...Социализм юлында да барыбызны төрмә яисә лагерьлар көтә инде, чөнки без бит демократлар, ә диктатура өчен без зарарлы кешеләр, җитмәсә, татар демократлары" (96.). Хакимият үзенең киләчәге, тук, рәхәт тормышы өчен борчыла, шуңа күрә һәр укый-яза белгән затта—язучымы ул, сәясәтчеме, тарихчымы, фольклорчымы—һәркайсында үзенә дошман күрә, дип тә өсти Галимҗан һәм хаклы булып чыга.

Р. Вәлиев җыентыкны ачып җибәргән "Гаепнамә, яисә "татар

контрреволюциясе" бүлегендә күренекле галим, шагыйрь, сәясәтче Галимҗан Шәрәф, аның туганнары Шәһер Шәрәф, Борһан Шәрәфләр турында ачынып, әрнеп, шундый олы шәхесләрне милләт мәнфәгатьләренә хезмәт иткәннәре өчен ялган ялалар белән юкка чыгарган системаны каһәрләп яза. Аның аеруча яратып, мөкиббән китеп сурәтләгән шәхесе—Галимҗан Шәрәф.

"Галимҗан Шәрәф өйрәнелмәгән бер шәхес кенә түгел, үзе бер феномен. Ул шагыйрь дә, дәүләт эшлеклесе дә, милли дәүләтчелекнең теоретигы да, чын көрәшче. Татар телен саклап калу буенча ул, 20-30нчы елларда партиясезләрнең юлбашчысы булып, җиң сызганып тоталитар режим белән көрәшә" (36.).

Аның җил искән унайга карашын үзгәртми торган, кыю, үзкарашлы зат булуын Р. Вәлиев бихисап мисалларга таянып исбатлый. Г. Шәрәфнең корычтай нык характерлы милләтпәрвәр икәнлеге Г. Исхакый мирасына мөнәсәбәттә ачык күренә. Большевикларның илдә яшәүче милләтләргә, зыялыларга карашын даһиларча аңлап, мөһаҗирлек язмышын сайлаган, совет хакимиятен танымаган өчен "халык дошманы", "контр", "ак эмигрант" дигән мөһер сугылган Г. Исхакыйдан рәсми сәясәт куштаннары, хәтта Г. Ибраһимов кебек язучылар да йөз чөергән, мирасыннан баш тарткан елларда Г. Шәрәф татар реалистик прозасына нигез салучы иҗатына ифрат уңай карашын яшерми. Г. Шәрәф фикеренчә, "Олуг әдипнең исемен дәреслекләрдән һәм матур әдәбият тарихыннан алып атуны хуплау мөмкин түгел". Мондый мөнәсәбәтнең нык эчке ышанычтан туган объектив фикер булуына Р. Вәлиев бихисап дәлилләр китерә. Г. Шәрәф татар халкының "Октябрь инкыйлабына кадәрге тормышын Г. Исхакыйдан башка берәүнең дә хакыйкый төгәллек белән дөрес тасвирлый алмавын бик яхшы аңлый" (34 б.). Г. Исхакый белән Г. Шәрәф милләтебезнең киләчәген күзаллауда төп ноктада якын торалар, икесе дә "Идел-Урал штаты"н төзү хыялы белән яшиләр. Туган халкының хокукларын яклавы, җөмләдән, Г. Исхакыйны "киләчәктә яшьләр укыячак" дип раславы өчен "сатлык җан" ярлыгын алып, оештырылган гаепнамә нәтиҗәсендә халкыбызның нык ихтыярлы, мәдәниятебезнең, телебезнең киләчәге өчен янып-көеп яшәгән йөзләгән, хәтта меңләгән зыялыларыбыз кебек Г. Шәрәф тә юкка чыгарыла.

Совет хакимияте Октябрь борылышына чаклы ук танылган, халыкка уңай йогынтысы көчле шәхесләрне аеруча кабул итми. Ә Г. Шәрәф нәкъ менә шундыйлардан. Ул гасыр башында ук киң колачлы, эрудицияле, энциклопедик галим булып җитешә, иң катлаулы фәнни-нәзари проблемаларны чишүгә алына. Аның эксперименталь фонетика фәненә нигез салучы булуы мәгълүм. Ул көчле социолог, философ, 1914 елда "Аң" журналы "Миллиятне ничек аңлыйсыз?" дигән темага сөйләшү башлап җибәргәч, бу мәүзугның әһәмиятен аңлаган Г. Шәрәф, фикер алышуда катнашып, "Ничек аңларга?" исемле, милләт төшенчәсенең асылын ачып-аңлатып биргән чыгышын тәкъдим итә. Теләсә кайсы халыкны милләт дәрәҗәсенә күтәргән төп сыйфат-билгеләр итеп галим тарихи кардәшлек, тел уртаклыгы, нәсел, вөҗдан, рух якынлыгы кебек алшартлар булуы мәҗбүри дип саный. Аның милләт төшенчәсенә биргән билгеләмәсенең бүген дә кыйммәтен җуймаганлыгын Р. Вәлиев ассызыклап үтә. Дин белән ватан уртаклыгы гына милләтнең асылын тәшкил итми икән. Рус белән татарларның ватаннары уртак, мәгәр алар икесе ике милләт, Эфиопия мөселманнары белән татарларның диннәре ислам булса да, алар һичничек тә бер милләт булып оеша алмаячаклар, ди Г. Шәрәф.

Шул таләпләр өстенә милләт буларак җитлеккән халыкның алга киткән әдәбияты, музыкасы, сәнгате, үз тарихы булырга тиеш. Соңгысын (халыкның үткәнен) бозып күрсәтү, хәтерне юкка чыгарырга тырышу милләтнең яшәү дәртен, үзаның, пассионарлык көчен җимерүгә алып килә. Милләтләрне бетерү сәясәтен алга сөргән большевиклар фикерләү сәләтенә ия, үзаңлы, милли рухлы шәхесләрне үтерү юлына бастылар, ди Р. Вәлиев үзенең китабында.

Хезмәтнең яңачалыгы шуннан гыйбарәт: автор башка мәкаләләрендә, чыгышларында әйтелгән фикерләрен гади кабатлау юлына басмый. Татар

халкы, аның аерым шәхесләре язмышына кагылышлы архив, вакытлы матбугат битләрендә сакланган мәгълүматларны әйләнешкә кертә, элегрәк билгеле булганнарын янача укып, тарихта яктыртылмаган проблемаларга үз төгәл бәясен бирә, йөзләгән, меңләгән репрессия корбаннары турында ачынып, әрнеп яза. Кыскасы, безнең алда саф татар әдәби телендә язылган, фәнни бәяләмәләргә, анлатма чигенешләргә, хәтер канатында үткәнгә әйләнеп кайтуларга, киләчәккә фаразларга корылган, тулаем заманча гыйльми, ныклы нигезгә утыртылган хезмәт. Тарихчы-галимнең шул чор татар язучыларын, журналистларын, галимнәрен халкыбызның каймагын тәшкил иткән зыялылары икәнлеген аңлап, йөрәге белән сиземләп бәян итүе—җиентыкның унышлы ягы. "Милли тайпылыш", "Чын бәяне тарих үзе бирә", "Болак арты республикасы", "Гаепсездән гаепленәр" кебек мәгънәле, җисемнәренә, эчтәлекләренә лаеклы исемнәр белән аталган бүлекләр укучыны милли тарихыбызның төрле буыннары белән таныштыра. Дөрес, "Милләт һәм төрек-татар тарихы" дип аталган "амбициоз" бүлектән күбрәкне дә көтеп булыр иде. Әмма ул Зәки Вәлидинең 1915 елда Казанда басылган "Төрек-татар тарихы" исемле хезмәтенә Галимҗан Шәрәф язган бәяләмәне күчереп язу гына булып чыкты. Әлбәттә, һәркемнең ул чор матбугатын алып уку мөмкинлеге булмавын истә тотсак, аңысы да кирәктер.

Китапка исем биргән, авторның якташлары (Яшел Үзән тирәсе авылы кешеләре) турында бәян иткән "Өзелгән дога" бүлеге вәисевләр һәм вәисевчеләр хәрәкәтенә багышланган. "Тарихи һәм әдәби әсәрләрдә шактый урын алган, әмма аңлашылып бетмәгән, капма-каршы бәяләр алган вәисевләр хәрәкәте,— дип башлый сүзен Р. Вәлиев,—дөрес һәм гадел бәяләүне таләп итә" (49 б.).

Чыннан да, XIX гасырның 60 елларында изүгә, талауга, хәерчелеккә, рәнҗетүгә түзә алмыйча—яшәүдән тую нәтиҗәсендә калкып чыккан бу серле һәм берникадәр сәер хәрәкәтне берәүләр "крестьяннар күтәрелеше", икенчеләре дин байрагына таянган көрәш, совет чорында "Шайка Ваисова" дип бәяләсә, тагын башка аңлатмалар да күренгәләсә, Р. Вәлиев бу күтәрелешне "социаль гаделлек өчен көрәш" дип атый һәм төрле елларда әлеге хәрәкәтнең башында торган, үз хыял-максатларына гаҗәеп бирелгән үзаманнарны сурәтли, һәркайсы тарихи роман каһарманы булырлык. Күз алдына вәисевләр хәрәкәтенә нигез салган, үзен "Алла сугышчысы" дип йөрткән мәһабәт гәүдәле, акыллы туры карашлы, аек фикерле, татарларны Болгарстан исеме белән үз дәүләтләрен торгызуга өндәгән, курку белмәс Баһаветдин Вәисев, аның туганы-дәвамчысы Гайнетдин, шул хәрәкәткә турылыклы башка затлар, фикер титаны, олуг гуманист Лев Толстой янында булып, бу юнәлешнең нәзари һәм гамәли нигезләрен ачып салганнан соң, бөек язучы йөзендә теләктәшлек тапкан Гайнан Вәисев образлары алга килеп баса.

Революциягә кадәр вәисиләр хәрәкәте, аерым шәхесләрнең эшчәнлеге турында күп языла. Совет чорында М. Сәгыйдуллинның курка-курка, ярымдөреслек белән бирелгән информатив мәкаләсеннән гайре берни күренми. Чит ил галимнәре татар халкы яшәешенә бәйле хәлләргә, бигрәк тә бәйсезлек, демократик тәртипләр өчен көрәшүчеләргә игътибарлы. Өеңдәге хәлне күршеңнән кереп сора дигәндәй, сәясәтче-галим Ш. Келькеже, тарихчы, телче Г. Беннигсен вәисиләр хәрәкәте турында сокланып, Франция инкыйлабчылары белән чагыштырып фәнни-гамәли хезмәтләр язып чыгалар.

Үз илебездә бу тарихи шәхесләребезне өйрәнү соңрак башлана. Алтмышынчы елларның икенче яртысында булачак галим, аспирант Рәмзи Вәлиев үзенең туган төбәгендә оешкан хәрәкәт белән кызыксына башлый, архив, вакытлы матбугат материалларын өйрәнә, "Габдулла Тукай һәм Сәрдар Гайнан Вәисев" кульязмасы авторы Мидхәт Вәисев белән аралаша.

Әлбәттә, тоталитаризм шартларында Рәмзи Кәлим улы вәисиләр турындагы эзләнүләрен матбугатта тиз генә чыгара алмый, сәяси климатның йомшаруын көтәргә мәҗбүр була. Хакимият тарафларыннан кисәтүләр сискәндереп кенә

тора. Мәскәү профессоры Котдус Дәүләтшин вәисиләр хәрәкәте турында уңай сүз ката һәм фидакарьлегә өчен "рәхмәтен" шунда ук ишетә, аны фирка ҮК каршындагы диннәр буенча җаваплы эшеннән азат итәләр. Мин чәчләре иртә агарган, озын буйлы, сабыр, тыныч холыклы, итагатьле һәм милләтпәрвәр шәхесне яхшы ук белә идем. Котдус илленче елларның икенче яртысында Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына кергән татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, көтмәгәндә-уйламаганда Мәскәүгә барып төпләнде (көнчелек кытыкларыбыз килеп, бездән аермалы буларак, унышлы өйләнде дип тел шомартып та йөрдек), фәлсәфә фәннәре докторы булды, Казан белән арасын өзмәде, фәнни конференцияләргә, Татарстан язучылары корылтайларына кайтып йөрде. Югары кимәлдәге татар зыялысы буларак, К. Дәүләтшин тарихыбызны нәкъ булганча күрсәтү, үткәнебезне бизәгән олы шәхесләрне күтәрү өчен армый-талмый көрәште. Кыскасы, Котдус үзе турында да хезмәт язарлык яисә әдәби әсәр иҗат итәрлек олы чылбырның лаеклы буыны иде.

Вәисиләр хәрәкәтен объектив өйрәнүгә мөмкинлек ачылуга, алар хакында Рәмзи Вәлиевнең гыйльми мәкаләләре күренә башлады.

Бу күтәрелешне бертуганнар, балалар, оныклар оештырган, гаилә, нәсел мәнфәгатьләрен генә яклаган бер юнәлеш дип бәяләүне яисә аның сәяси-иҗтимагый таләп-омтылышларын таратып карауларны кире кагып, Р. Вәлиев татар халкының хокукларын, киләчәген яклаган Гыйззәтулла Хәмидуллин, Сәетбаттал Хәбибулла, Нәҗметдин Ижбаев кебек патша хакимияте тарафыннан эзәрлекләнгән көрәшче шәхесләрне күтәрә, татар халкының лаеклы яшәеше, киләчәге өчен эшләгән фидакарьлекләренә мәдхиясен яудыра. Вәисевләрнең авылдашы Шиһабетдин Сәйфетдиновның ифрат ягымлы образын әдәби алымнар кулланып, яратып сурәтли. Тарихи әсәр каһарманы булуга дәгъва итәрлек бу көрәшче үзе ышанган идея өчен ниләр генә күрми: эзәрлекләүләр, судлар, каторгадан качулар, кыйналулар... Берсе дә калмый. Аның ихтыяр көче, сынмас рухы турында шул чорның популяр "Волжский вестник", "Московский вестник" кебек газеталары сокланып язалар. Ул налог түләмәскә, хакимияткә буйсынмаска, солдатка бармаска өндәп хатлар тарата, хәтта Сахалин төрмәсендә дә үгетләү эшен дәвам иттерә.

Татар әдәбияты тарихында, вәисиләр хәрәкәтеннән аермалы буларак, гадел, инсафлы, туган халкының язмышына битараф булмаган язучыларны пычрату өчен уйлап табылган уйдырма "җидегәнчелек" чын бәясен алмаган, коткы таратучылары ачылып бетмәгән иде. "Җидегәнчелек" тирәсендә барган буталышны өйрәнүгә Р. Вәлиев вакытлы татар матбугаты, архив материаллары нигезендә язылган "Чын бәяне тарих үзе бирә" исемле махсус бүлек багышлый (165-185 бб.).

Яла ягу, талантлы язучыларны пычрату эшен, ягъни провокацияне М. Парсин башлап җибәрә. Менә китапта аның мәкаләсеннән китерелгән куркыныч юллар: "Җидегән"—1928 елда Уфада оешкан татар язучылары оешмасы. Оештыручылары: фабрикант улы Кутуй, сәүдәгәр улы Минский һәм динче-милләтче шагыйрь Ченәкәй. Бу оешмага член булып мулла малае Нәкый Исәнбәт һәм мәгълүм Зыя Камалиның кияве Сәйфи Кудаш керәләр..." (1946.).

Дөрес, соңыннан система М. Парсинның үзен дә аямый, Сталин төрмәләренең "тәмен" җитәрлек татыта. Инкыйлаб турында романтик поэмалар язып, болай да "кызыл язучылар"ның алгы сафында атлаган Ф. Бурнаш та "җидегәнчеләр"не фашлау компаниясенә кушылып китәргә була. "Кайчандыр партия архивына караган фондларда аның бу турында хатлары саклана. "Җидегәнчелек"не ул Украинада, Белоруссиядә, Казакъстанда "табылган" милләтчелек хәрәкәтләре белән бер бәйләнештә бәяли, Бурнаш нәкъ сталинча яза". (197 б.). "Җидегән"не сәяси яктан гаепләп чыккан Ф. Бурнаш мәкаләләрен анализлап, "Өзелгән дога" авторы үкенү, рәнҗү, сызлану хисләрен тыя алмыйча: "И Бурнаш, Бурнаш...

Алла ниләр көткәнне белсән иде син..." (197 б.),—ди.

Канлы дәвер әдәбиятына да тарихчының үз төгәл бәясе бар. "30нчы еллар татар әдәбияты тарихы өр-яңадан эшләп чыгуны таләп итә. Монда бернинди культлар ясамыйча, бер талантка да табынмыйча, ничек булган, шулай күрсәтергә кирәк", (206-207 бб.) дию белән тарихчы нигездә хаклы. Үткәнне актарып, ул чорның бөтен пычраклыкларын, күбекләрен күрсәтү белән мавыгып, шул чорда М. Җәлилнең "Хат ташучы"сы, "Алтынчәч"е, Х. Туфанның "Ант" поэмасы, Ә. Фәйзи, Н. Исәнбәт, Ф. Кәрим, Ш. Маннур, С. Батталларның вакыт сынавын узган әсәрләре турында онытмасак иде.

Архивларда, вакытлы матбугат битләрендә сакланып калган, Р. Вәлиев китабында күпләп китерелгән гаепнамәләрне укыганда, ирексездән үзебез яшәгән "демократик" чорыбыз турында уйланырга мәҗбүрсең. Башка исем белән йөртелгән, әмма асылы, эш алымнары әллә ни үзгәрмәгән оешманың үз милләтләренә турылыклы татар егетләрен, мәдрәсә шәкертләрен, гомумән мөселманнарны террористлар, ваһхабачылар дип пычраткан, намуслы кешеләрне рәнҗеткән очракларны искә-ятька төшерәсең дә, үзеннән-үзе шундый нәтиҗәгә киләсең: кылны өзәм-өзәм дип торган Домокл кылычы безнең баш очыннан бөтенләйгә алып ташланмаган икән. Заманалар башка, шомарту, котырту, гайбәт тарату, аннарны чуалту ысуллары, булмаганны бар дип тәкрарлау алымнары шул ук, тик бераз шомартылган, чорга яраклаштырылган икән. Егерменче гасырның икенче яртысыннан китапта китерелгән мисал шуңа инандыра.

Үткән тарихыбыз, гасырлар түрендә булып узган вакыйгалар турында гына язмый Рәмзи дус. Аны XX гасырның икенче яртысында урын алган, шәхесне изүгә, сытуга, аны бары тик рәсми сәясәт агымына килгәнчә генә уйларга, язарга мәҗбүр итү очраклары да борчый. "Туры сүзле, баш бирмәс шәхес" исемле очерк аның фәнни җитәкчесе, күренекле тарихчы, профессор Әгъләс Борһановка багышланган. Рәсәйнең киләчәге турында уйланып язылган, үткен, кыю мәкаләләре белән иҗтимагый тормышыбызда актив катнашып яшәүче, аек акыллы, сиксәннең өске ягында булуына карамастан заманча фикерләү сәләтенә ия шәхес күбебезгә таныш. Терекөмеш кебек хәрәкәтчән, уртача буйлы, таныш-белешкә, уңышлырак хезмәт язган һәр галимгә, язучыга, журналистка җылы сүзен кызганмый торган Әгъләс Хөсәен улын, Мәскәүдә яшәсә дә, Татарстанның Фәннәр академиясендә (ул аның шәрәфле әгъзасы), Казан университеты, татар конгрессы уздырган җыелышларда еш очратып була. Кайда яши ул, ничек барысына өлгерә дип шатлану катыш көнләшеп тә куясың. Ә бит ул кичергән хәсрәтләр берничә тормышка җитәрлек. 1966 елда галим "Октябрь революциясе һәм вак буржуаз партияләр" дигән темага докторлык диссертациясе яклый һәм шул елларда абруйлы мөнбәрләр биләгән галимнәрне догматик берьяклы фикерләүләре өчен тәнкыйть итә. Галим үз хезмәтендә большевиклар вак буржуаз партияләрне (димәк, демократияне) сакласалар, илдә тоталитар режим урнаша алмаган булыр иде дигән фикерне алга сөрә. Шул ышанычыннан галим чигенми, "Башкача эшләргә минем фәнни намусым кушмый",—дип кенә җавап бирә оппонентларына. Сталинга, Троцкийга янача бәя биргән "фәнни намус" ана кыйммәткә төшә. Өлкә комитеты әмере белән аны университеттан укытудан читләштерәләр, Казанның башка уку йортлары ишекләрен шакып карау да файда бирми.

Авырлык белән Мәскәүлең гражданлык авиациясе институтына эшкә урнаша. Чирек гасыр дәвамында докторлык эшен ВАКта расламыйлар, хезмәтне Казаннан Мәскәүгә, Мәскәүдән Казанга типкәләп йөртәләр... Ә гомер уза тора. Бары тик илдә тоталитар система сүтелә башлагач кына аның эзләнүләре югары бәя ала, соңгы унөч ел эчендә генә дә аның ике йөздән артык хезмәте, җиде китабы дөнья күрә (2000 елга чаклы). "Фәнни хезмәтләре өчен Россия гуманитар университеты ана махсус академик стипендиясе билгеләде", (164 б.)—дип яза Р. Вәлиев һәм түбәндәгене өсти: "Хәзер үзем дә аспирантлар белән җитәкчелек итәм һәм бу эштә остазымның карашларына таянам. Алар шуннан гыйбарәт:

кыюлык, дөреслек, намусына хыянәт итмәү". Әгъдәс Борһанов яңа буын татар зыялысының илаһи бер үрнәге, ихтирамга лаеклы шәхесләребезнең берсе. XIX йөздә яшәсә ул, һичшиксез, җәдиди мәгърифәтче булыр, ә репрессия елларында гомер итсә, Шәрәфләр белән күрше камерада утырыр иде... Кыюлар, милли җанлы фидакарьләр бер чорда да "таш капчыкка" кытлык күрмәделәр.

Рәмзи Кәлим улының һәркемгә тәгаен, анык бәясе бар. Нахакка утыртылганнар яисә репрессия корбаннарына автор үзенең җылы мөгаләмәсен яшерми. Вакыты белән хискә дә урын бирә. Ә инде фирка, ГПУ оешмалары вәкилләрен ул тамак ялына хезмәт итүче, җылы урындыкларын саклау өчен теләсә кемне, хәтта ата-анасын гаепләргә әзер курчаклар, ялагайлыклары белән куркыныч, мөстәкыйль фикерләүгә сәләтсез бәндәләр дип бәяли.

Дөньяга, яшәешкә карашлары төрле кешеләрнең психологиясен, холкын ачу нияте белән ул төрле анализ, шул исәптән чагыштырмалы һәм әдәби алымнардан иркен файдалана. Аерым алганда, каһарманнар арасында үзара сөйләшүләр—диалоглар кору, алар булып (рольгә кереп) сөйләшү алымнары хезмәтнең ышандыру көчен бермә-бер арттыра. Менә бер мисал. "1932 елның салкын гыйнвар ае иде. Дзержинский урамындагы Иминлек идарәсе йорты янына җинел машина килеп туктады...

Машинадан бер хәрби чыгып, тиз генә идарәнең имән ишекләре артына чумды. Бары тик ишектән чыккан пар гына, өерелеп, түбәгә үрмәләде. Машина да ике йорт арасына кереп юкка чыкты. Әйтерсең лә икесен дә җир йотты.

—Күрдеңме?—диде каракүл бүреген баса төшеп кигән кыска тунлы кеше.

Киң җилкәле, кара кашлы, күзлекле, фетр итеклесе дәшмәде. Үзен кемдер сагалап торгандай тоелды аңа.

—Өч хәреф,—диде ул, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп.

—Кандыбин бу, Шомбай! Кандыбин!—диде тегесе сүзсез катып калган иптәшенә.

—Кем соң ул Кандыбин?—диде каракүл бүреклесе, һаман да акрын тавыш белән. Хәер, Гали Рәхим инде күптән кычкырып сөйләшми башлаган иде" (7 б.). Галимҗан Шәрәф иптәшенә Кандыбинны диктатураның "кан кою буенча" ОГПУның Татарстандагы вәкиле, иң куркыныч кеше икәнлеген аңлатып бирә. Кем язганын белмәсәң, бу юлларны Сталин төрмәләре тәмугын үтеп, исән калып, "Колыма хикәяләре"н, Афәт" романнарын иҗат иткән олуг язучыларыбыз Ибраһим Салахов яисә Гурий Тавлин әсәреннән өзек дип фаразларга мөмкин булыр иде.

Рәмзи Вәлиев нинди вакыйга яисә кем турында гына язмасын, төп нияте—туган халкын, телен яшәтү, тарихын дөрес бәяләү. "Шуңа күрә без, үзебезнең бабаларыбыз белән горурланып, аларга охшарга тырышып, татар милләтенең якты киләчәге өчен бердәм булып барын да эшләргә тиешбез. Моның өчен безнең барыбызга да тарихыбызны дөрес аңлап, бер фикергә килүебез кирәктер. Төрлебез төрле якка тартсак, унай нәтиҗәләр булмас: гадәттәгечә, кәрәш түгел, ызгышу, талашу, бер-береңә ярлыклар тагу гына булыр. Шайтанга шул гына кирәк" (99 б.). Үзәк болай да халкыбызны төрле төркемнәргә таркатырга ашкынып торганда, зыялыларыбызга моннанда файдалы һәм изгерәк теләк теләп булырмы икән? Юктыр дип уйлыйм. Р. Вәлиевнең нәкъ менә шул чор фаҗигасе, аның тәэсире, йогынтысы әле хәзер дә сизелеп торган күренешләре турында фәнни нигезле, үткен каләм, үтемле сүз-җөмләләр белән язылган "Өзелгән дога" китабы—бик вакытлы язылган һәм яратып нәшер ителгән хезмәт киләчәге.

# КҮПКЫРЛЫ ГАЛИМ

Күренекле мәгърифәтче галим һәм танылган педагог Әнвәр Хәйри (Әнвәр Нәҗип улы Хәйруллин)—менә инде 40 ел буена фәннең авыр бер тармагы булган борынгы китаплар өйрәнү өлкәсендә уңышлы эшләп килүче сирәк очрый торган белгеч.

Әле Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда ук, Казан ханлыгы чорына караган бер бакыр кувшин табып алып, Ә. Хәйри шундагы чокып язылган язуларны укып, тәрҗемә итеп, фәнни хезмәт язып, студентларның фәнни эшләре бәйгесендә беренче урынны алган иде.



Гаилә корып, читтән торып укуга күчкәч, ул Казандагы 80нче мәктәпкә гарәп теле укытучысы һәм Татарстан дәүләт музеена фәнни хезмәткәр булып эшкә урнашты һәм 1969—74 елларда шул ике урында эшләде. Фәнни эшчәнлегенең башында ук борынгы китаплар белгече буларак эшкә керешеп, ул музейның әдәбият бүлеге экспозициясен төзүдә турыдан-туры катнашты, татар халкы мәдәнияте тарихының төрле чорларына, төрле шәхесләренә караган экспонатларны эзләп табу һәм музей фондларына сатып алу буенча бик актив эш алып барды. Ул Казанда һәм республика буйлап оештырылган фәнни экспедицияләрдә бик күп гаҗәеп кызыклы һәм сирәк очрый торган борынгы экспонатлар, кулъязмалар һәм басма китаплар, шәхси әйберләр, кабер ташлары, бакыр савытлар табып алды. Әнвәр Хәйри һәрбер танылган татар язучысына алфавит тәртибендә махсус папкалар ачып, шунда аларның шәхси документларын, фотоларын куеп, тасвирлама төзеп, иҗатларын каталоглаштырып музейда әдәбият бүлегенең махсус фондын төзеде. Яшь галим һәртөрле фәнни конференцияләр, әдәби кичәләр, язучыларның һәм галимнәрнең Казан халкы белән очрашуларын оештыра һәм әдәбият бүлегендә экскурсияләр уздыра иде. Әнвәр Хәйри Татарстан дәүләт музееның күп кенә филиалларын ачуны үзе оештырды яки оештыруда катнашты. Спас районының Көек авылындагы А. Алиш музее, Нурлат районының Колбай-Мораса авылындагы Г. Кариев музее, Аксубай районының Кармәт авылындагы Х. Туфан музее, Әлмәт районындагы Р. Фәхреддин музее, Чистай районындагы Г. Исхакый музее, Әтнә районындагы һәм Казандагы Ш. Мәрҗани музейлары, Чаллыдагы Г. Акыш музее, Аксубай районындагы Г. Кашапов музее... әнә шундыйлардан.

Дәүләт музеенда эшләгәндә Ә. Хәйри, 70нче еллар башында әле бу, борынгы Болгар чоры кабер ташларын музей ишек алдында асфальт астына түшәп салганнарын күреп, лом белән үзе каерып алып, зур ызгыш белән аларны юкка чыгудан саклап калды.

Инде борынгы кулъязмалар белгече буларак исеме фәнни даирәләргә яхшы ук танылып өлгергән яшь галим Әнвәр Хәйрине 1974 елның май аенда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына, яңа оешып килүче татар иҗтимагый фикер тарихы фәнни төркеменә эшкә чакырдылар, һәм ул анда 1991 елның ноябрь аена кадәр фәнни хезмәткәр булып эшләде. Биредә эшләү дәверендә Әнвәр Хәйри үзен чынлап торып җитлеккән җитди галим, татар халкының рухи мәдәнияте тарихын,

Ислам динен һәм Шәрык мәдәниятен тирән белүче олуг белгеч итеп күрсәтте. Институтта эшли башлагач, аңа «Г. Курсави һәм Ш. Мәрҗани әсәрләрендә дини тәгълиматны һәм суфичылыкны рационалистик тәнкыйть итүнең төп принциплары» дигән бик катлаулы фәнни темага монография һәм кандидатлык диссертациясе язуны тапшырдылар. Чыганаклар фәкать гарәп телендә генә булуга карамастан, бу авыр хезмәтне ул уңышлы башкарып чыкты. Гарәп, фарсы, төрек һәм борынгы төрки телләрдә теләсә кайсы чорда язылган һәм басылган теләсә нинди кулъязма, ташбасма һәм басма чыганаклар белән иркен эш итә ала торган яшь һәм талантлы галимнең һәр мәсьәләдә башкаларга бәйсез үз фикере формалашкан иде...

Үтә дә сабыр холыклы һәм искиткеч түзем, эшчән, эштән башка нәрсәне белмәгән яшь галим фанатикларча фәнгә хезмәт итүен дәвам итте, бар юанычын һәм күңел тынычлыгын үзенең яраткан хезмәтендә тапты...

1980—82 елларда XIX гасыр башы мәдәният тарихына караган язмаларны 1916—18 елларда басылган «Аң» журналыннан күчереп транслитерация ясады ул. «Проблемы истории татарской общественной мысли Татарии дооктябрьского периода» дип аталган коллектив фәнни-тикшеренү эшендә җаваплы тикшерүче булып катнашты. Фәнни эше буенча, 1989 елда мәшһүр татар галиме Ш. Мәрҗанинең ике томлык «Мөстәфадел-әхбар...» исемле зур күләмле тарихи хезмәтен хәзерге татар теленә тәрҗемә итеп, кереш сүз язып, төзеп, китап итеп чыгарды. Ул шулай ук К. Насыйриның «Фәвакиһел-җөләса...» исемле бер томлык энциклопедик хезмәтен дә хәзерге татар теленә тәрҗемә итте.

Эштән тыш, ял вакытлары исәбенә, Әнвәр Хәйри 1993 елда, хәзерге татар теленә тәрҗемә итеп, Р. Фәхреддиннең «Болгар вә Казан төрекләре» исемле зур күләмле китабын бастырып чыгарды. Бу китап 1997 елда Казанда тулысынча латин хәрефләрендә дә басылды.

Әнвәр Хәйри «Этногенез и этническая история татарского народа» исемле күмәк фәнни-тикшеренү эшендә дә авторларның берсе булып катнашты һәм шул теманың «Проблема этногенеза и этнической истории татар в дореволюционной и советской (до 1930 года) татарской исторической литературе» дип аталган зур бер бүлеген язды.

Институтта эшләгәндә Әнвәр Хәйри, борынгы китаплар белгече буларак, институт галимнәренә, югары уку йортлары укытучыларына, төрле фәнни оешмаларга бихисап күп фәнни киңәшләрен бирә иде, аның янына ярдәм сорап хәтта чит шәһәрләрдән, чит республикалардан белгечләр килә иде. Аңа институтта «аяклы энциклопедия» дигән кушамат та тактылар әле.

Әнвәр Хәйри—аркасына зур юл капчыгы, ике кулына зур-зур чемоданнар тотып борынгы китапларны эзләп табу өчен оештырылган фәнни экспедицияләрдә бик күп катнашты. Борынгы китапларны саклап калу мәсьәләсендә Әнвәр Хәйри берни белән дә исәпләшми иде. Институтның элеккеге директоры М. К. Мөхәррәмов вакытында, Татарстан китап палатасында озак еллар ятып, куяр урын булмау сәбәпле, бик күп борынгы китапларны бер йөк машинасы белән институтка төяп китергәннәр иде. Бераз вакыт торганнан соң, монда да ул китапларга урын юклыкны сылтау итеп кырга алып чыгып яндырмакчы булганнарын ишеткәч, Әнвәр Хәйри төялгән машинаны берүзе бушатып, китапларны кайсын үзенең эш бүлмәсенә, кайсын подвалга яшереп куеп, саклап алып калды (соңыннан, күп еллар үткәч, аларны институтның мирасханәсенә тапшырды). Шушы "башбаштаклыгы" өчен аңа директор приказы белән каты шелтә белдерелде һәм аның болай да кечкенә хезмәт хакы минималь күләмгә төшерелде.

Әнвәр Хәйри күп кенә борынгы китапларны сүтелә торган иске өйләрнең чормаларыннан, идән асларыннан, туфрак һәм тирес өемнәре астыннан, каберләргә күмелгән җирләреннән казып алып, саклап калды.

1984 елда ул мәшһүр татар галиме Р. Фәхреддиннең Уфада Диния нәзараты архивында табып алган 16 том кулъязма мирасын Башкортстан Фәннәр академиясенең Тарих, тел һәм әдәбият институтына тапшырды һәм шулай итеп аларны юкка чыгудан саклап калды, 10 том кулъязма мирасының микрофильмын исә үзе эшләгән институтның архивына алып кайтып бирде. Татарстан дәүләт музеенда, Казан дәүләт педагогия институтында, үзенең институтында ул гарәп хәрефле борынгы кулъязма һәм басма китапларга фәнни каталоглар төзеде.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләү дәверендә Әнвәр Хәйри төп фәнни эшеннән тыш күп төрле фән тармаклары буенча да зур эшләр алып барды һәм аларның, сөзмәсен төрле фәнни җыентыкларда, китапларда, журналларда һәм газеталарда бастырып (гомуми күләме 70 табаклап булган 120 дән артык мәкалә, фәнни хезмәт бу!) радио һәм телевидение аркылы халыкка җиткереп, фәнни белемнәрне пропагандалау буенча зур тырышлык куеп эшләде.

Әнвәр Хәйри Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар..."ен Әхмәд Һади Максудиның «Гыйбадәтел—Исламия"сен, Р. Фәхреддиннең «Болгар вә Казан төрекләре»н һәм тагын күп-күп китаплар һәм фәнни хезмәтләрне редакцияләде...

Татар халкының рухи мәдәнияте тарихына багышланган бик күп хезмәтләр авторы буларак, Әнвәр Хәйрине олуг затларыбыз Н. Исәнбәт, Б. Урманче, Г. Бәширов, Г. Шамуков, Ф. Хөсни бик хөрмәт итәләр һәм форсат чыкканда ана җылы сүзләрен дә җиткерәләр иде.

Әнвәр Хәйри үзе эшләгән институтта татар иҗтимагый фикер тарихы бүлеге нигезендә Ислам динен өйрәнү бүлеген ачуны башлап йөрде. Аның эш юналешләрен билгеләп, фәнни концепциясен язып, ул хәтта бу бүлекне ачуда ярдәм сорап Мәскәүгә, академик Камил Вәлиев янына барды, СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты галимнәре белән очрашып, сөйләшүләр үткәрде, фәнни конференцияләрдә һәм вакытлы матбугатта шушы фикерне кат-кат күтәреп чыкты. Бу мәсьәләдә аны мәшһүр сәнгатькяребез Бакый ага Урманче һәм танылган драматург Туфан Миңнуллин да яклап чыктылар. Озак йөри торгач, бу бүлек тә ачылды...

Әнвәр Хәйри хәзерге чорда Ислам динен тирәнтен өйрәнеп, курыкмыйча ана объектив бәя биргән беренче татар галиме булды. 1980 еллар азагында, 1990 еллар башында Ислам динен халыкка кайтарып, халкыбызны өзелгән асыл тамырларына яңадан тоташтырып һәртөрле дини чаралар, бәйрәмнәр уздырганда да, Ислам диненең Борынгы Болгарда дәүләт дине итеп кабул ителүенә һиҗри белән 1100 ел тулу бәйрәмен үткәргәндә дә ул башлап йөрүчеләрдән булды. Татарстанның сынлы сәнгать музее бинасында "Татар халкының борынгы шамаилләре" күргәзмәсен дә үзе башлап оештырып йөрде, шамаилләрнең язма текстларын тәрҗемә итте, оештыру өчен бөтен сәяси җаваплылыкны үз өстенә алды. Әлеге зур бәйрәмгә килүче чит ил кунакларына күрсәтерлек зур һәм затлы эш булып чыкты бу.

Әнвәр Хәйри Коръәннең иң күп укыла торган 57 сүрәсен, ягъни яртысын бүгенге укучы аңларлык хәзерге татар теленә тәрҗемә итеп, фәнни транскрипциясен һәм аңлатмаларын биреп, 1990—1991 елларда "Казан утлары" журналында бастырып чыгарды. Аның бу эше безнең илдәге һәм чит илләрдәге дин әһелләренең унай бәясен алды. Ул, «Иман шартлары», «Дин дәреслеге», «Намаз» китапларын хәзерге татар теленә тәрҗемә итеп бастырып һәм матбугатта бик күп догаларны дөрес укылышлары һәм тәрҗемәләре белән чыгарып та бик күпләргә туры юлга басарга, дин юлына кайтырга булышты.

Шул ук елларда Әнвәр Хәйри үзе эшләгән институтта, Милли китапханәдә, Казан шәһәре Укытучылар йортында гарәп телен, гарәп язуын һәм иске татар телен, Ислам дине нигезләрен өйрәнү буенча махсус курслар, дәресләр алып барды.

1992 елда Әнвәр Хәйрине Татарстан Диния нәзарәтенең Гыйльми Шурасы рәисе итеп сайлап куйдылар һәм, дин тарихы белән фәнне тирән белүче һәм халкыбызны Ислам диненә тартучы галим буларак, аны ике корылтайда рәттән мөфтилеккә тәкъдим иттеләр. Ләкин ул моннан баш тартып, фәнгә турылыклы булып калды.

1991—1995 елларда «Мирас» журналында эшләгәндә, Әнвәр Хәйри «Дин вә әхлак» дип аталган зур бер рубрика алып барды һәм шунда: Р. Фәхреддиннең «Ислам дине нинди дин?», «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр», Г. Ибраһимовның «Борынгы Ислам мәдәнияте», М. Бигиевнең «Кавагыйде фикъһия», З. Камалиның «Фәлсәфәи игътикадия», Р. Гайнетдиннең «Намаз», Жуда әс-Саххарның «Гадел хәлифәләр тарихы», Й. әл-Кардавиның «Хәләл һәм хәрам» исемле монографик хезмәтләрен тәрҗемә итеп биреп барды, Ислам тарихына һәм Ислам динен өйрәнүгә кагылышлы бик күп башка хезмәтләр бастырды.

1997 елда Әнвәр Хәйри «Ислам дине бәйрәмнәре» исемле китабын бастырып чыгарды һәм ул анда әле беренче тапкыр барлык мөселман бәйрәмнәренә фәнни бәя бирде, аларны фәнни системага салды һәм аның бу хезмәте Ислам динен өйрәнү фәнендә яна бер сүз булды...

Әнвәр Хәйри халык педагогикасы тарихын, тәрбия, әхлак мәсьәләләрен бүгенге татар халкына янадан кайтару буенча да зур эш башкара. Р. Фәхреддиннең педагогика өлкәсенә караган 15ләп китабын тәрҗемә итеп, "Сабыйга", "Ялкын" һәм «Идел» журналларында бастырып чыгарды һәм тулысынча Татарстан радиосы аркылы бөтен татар халкына ирештерде. Гомумән, Әнвәр Хәйри «Азатлык", «Татарстан», «Яңа гасыр" радиоларыннан чыгышлар ясап, халкыбызны һәм бүгенге яшьләребезне әхлакый тәрбияләү эшенә үзеннән бик зур өлеш кертә. Бу изге эше белән Әнвәр Хәйри республиканың "Сәләт" яшьләр хәрәкәте эшчәнлеге кысаларында да даими шөгыльләнә...

Әнвәр Хәйри үткән тарихыбызга һәм аның бөек шәхесләренә шулкадәр зур хөрмәт белән карый ки, 1986 елда ул үзенең еллык ялын Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында уздырды һәм улы Айдар белән анда тузып кадерсезләнеп беткән Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Баруди, Ф. Әмирхан, Х. Әмирхан, М. Мөштәри һәм башка зыялыларыбызның каберләрен, чардуганнарын һәм кабер ташларын үз акчасына төзәтеп, тәртипкә китерде, әмма ләкин бу изге гамәле турында беркемгә дә әйтмәде...

Әнвәр Хәйри халык медицинасы тарихын да өйрәнә. Ул гарәп, фарсы, төрек һәм борынгы төрки телләрдән 6 кульязма китапны хәзерге татар теленә тәрҗемә итеп, «Мирас» журналында бастырды. Институтта эшләгәндә Әбу Гали Сина мирасы, К. Насыйриның этнографик әсәрләрендә халык медицинасы мәсьәләләре, борынгы болгар чоры медицинасы буенча фәнни хезмәтләр язды. 1996 елда Әнвәр Хәйрине Казан медицина академиясеннән Россия медицина академиясенә бер айлык махсус курсларга җибәрделәр. Бу курсларда катнашучыларның барысы да—БДБ илләрендәге һәм Россиядәге медицина югары уку йортларының медицина тарихы кафедралары мөдирләре—профессорлар. Бер Әнвәр Хәйри генә медицина белеме алмаган кеше буларак катнаша. Ул анда гарәп, фарсы, төрек һәм борынгы төрки телләрдәге кульязма китапларга нигезләнеп "Борынгы Болгар дәүләтендә медицина" дигән фәнни доклад ясый һәм үзенең белеме белән таң калдыра. Аны бу темасын алдагы елда Мәскәүдәге Медицина музеенда докторлык диссертациясе итеп якларга чакыралар, ләкин төрле сәбәпләр аркасында ул анда бара алмый кала. П. Лумумба исемендәге Халыклар Дуслыгы университетының медицина тарихы кафедрасына, 1нче, 2нче, 3нче, 4нче Медицина университетларына шул темага лекция укырга чакыралар.

Күпкырлы фәнни эшчәнлеге белән беррәттән, Әнвәр Хәйри укытучылык эше белән дә озак еллар шөгыльләнде. Ул 30 ел дәвамында Казанның төрле югары уку йортларында гарәп теле һәм иске татар теле, татар язуы тарихы, рухи мәдәниятебез тарихы, Идел буенда Ислам тарихы, халык медицинасы тарихы, халык педагогикасы тарихы, татар мәгърифәтчеләре тарихы һәм башка фәннәр буенча укытты.

Әнвәр Хәйри үзе эшләгән институтның, Казанның һәм республиканың җәмәгать эшләрендә дә актив катнашып яшәде. Ул Татарстан Милли музееның Гыйльми Совет әгъзасы, Татарстанның Сәнгать музее киңәшчесе, Г. Тукай, К. Насыйри һәм башка бик күп музейларның фәнни киңәшчесе, «Ватан» Татар җәмгыятенең президиум әгъзасы, "Мәрҗани" оешмасының дини мәсьәләләр буенча методик советы рәисе, Татар иҗтимагый үзәгенең дини оешмалар һәм чит илләрдә яшәүче татарлар белән эшләү комиссияләре рәисе, «Мирас» республика мәдәни фонды президиумы әгъзасы, «Биләр фонды" һәм «Биләр мәчетен янадан торгызу фонды» әгъзасы (бик тә актив әгъзасы, Биләрнең беренче җәмигъ мәчетен торгызу нияте белән янып-көеп йөри!) булып торды.

Күпьеллык нәтиҗәле фәнни-тикшеренү һәм мәгърифәтчелек эшчәнлеге өчен ана 1999 елда—"Татарстанның атказанган фән эшлеклесе", 2008 елда исә "Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Ахырда, йомгаклап, шуны әйтик: Әнвәр Хәйри—сүз кешесе түгел, эш кешесе. Биредә ул башкарган тәгаен эшләр, кылган игелекләрнең бик аз өлеше генә санап үтелде әле.

**Фаяз ХУҖИН**,
*археолог, тарих фәннәре докторы.*

# "БЕЗ ҮЗЕБЕЗ—СЕБЕР ТАТАРЫ"

БУЛАТ СӨЛӘЙМАНОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Себер татарларыннан чыккан һәм гаять үзенчәлекле талантка ия шагыйрь Булат Сөләймановка, исән булса, бу айда 70 яшь тулган булыр иде.

Булат Вәлиулла улы Сөләйманов 1938 елның 28 маенда Төмән өлкәсенен Вагай районы Сопра авылында колхозчы гаиләсендә туган. Мәктәпнең беренче сыйныфы бусагасын бәләкәй Булат 1946 елның сентябрь аенда атлап керә. Ләкин озакламый салкын җилләре-янгырлары белән көз килеп житә, ә малайның өстенә дә, аягына да киеме юк. Чөнки сугыштан соңгы ел бу, шуның өстенә Булатларның гаиләсе дә ишле. Ләкин ничек итсә итә, кайсы вакытларда мәктәпкә бара алмый торгаласа да, ниһаять, 1954 елда Булат жиденче сыйныфны тәмамлый ала.



Аннары ул ике ел буе колхозда эшли. Әмма тагын да укыйсы килү теләге егетне беркайчан да ташламый. Һәм ул 1956 елда Тубыл шәһәрендә урнашкан татар урта мәктәбенә юл тота. Егетне бирегә бик теләп кабул итәләр, ләкин озакламый тагын матди як кыса башлый: ул авылга кайтып китапханәче булып эшкә урнашырга мәжбүр. Ә урта белем турындагы аттестатны ул имтиханнарны экстерн тәртибендә тапшырып ала.

Сонрак Казан дәүләт университетына укырга кергәч ул үзе укыган һәм китапханәче булып эшләгән Карагай авылы кешеләренә сагынып бик жылы хатлар яза.

Данлыклы Казан дәүләт университетында да озак укый алмый Булат, аңа янадан хезмәт юлын дәвам иттерергә туры килә. Алда—Фрунзе, Сургут, Баку, Төмән шәһәрләре... Төрле-төрле эшләр...

Ләкин шунысы мактауга лаек: әнә шул хезмәт юлыннан аерылмыйча Булат 1974 елда Мәскәүнен А. М. Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый.

Б. Сөләймановның беренче шигырьләре алтмышынчы еллар башында "Татарстан яшьләре" газетасында басыла. Соңга таба "Казан утлары", "Ялкын" журналларында, "Беренче карлыгачлар" (1970) исемле күмәк жыентыкта, "Идел" альманахында (1976) шигырь бәйләмнәре белән күренә. Аерым шигырьләре русча тәржемәдә "Юность", "Сибирские огни" журналларында, "Литературная Россия" атналык газетасында һәм альманахларда да ("Тверьской бульвар", 1970, "Вдохновение", 1979) басылалар. 1980 елда Татарстан китап нәшрияты шагыйрьнең "Таңнар фонтаны" исемле беренче мөстәкыйль җыентыгын бастырып чыгарды. Бу китапка язган кереш сүзендә танылган шагыйрь Сибгат Хәким яшь каләмдәшенең иҗатта зур киләчәге тоемлануын билгеләп үтә һәм бу талант иясенең үз якташлары—Себер татарлары—алдында жаваплылыгының хәзер бигрәк тә артып китүен басым ясап әйтә.

Булат Сөләйманов турында Себердә яшәүче рус шагыйрьләренең дә байтак истәлекләре бар. Мәсәлән, Александр Гришин аның белән танышып китүен Булатның "Юность" журналында шигырьләре басылу һәм аңа "Мин—Себер

татары" дигән шигыре өчен редакция бүләге бирелү белән бәйли. Гришин әлеге истәлегендә Булатның шәхси сыйфатларына да туктала, анын үтә намуслы һәм тиз тәэсирләнүчән, кайчакларда кызып-кызып бәхәсләшергә яратучан, әмма соңыннан үпкә сакламый торган ихлас кеше булуын билгеләп үтә. Ә Гришинның Булат язган "Ишкәк" дигән шигырьне русчага тәрҗемә итү процессы күпләр өчен үрнәк була ала. Нәтиҗәдә, рус укучысы да сокланып укырдай байтак шигырьләр хасил булган.

Булат үзенең Себер татары булуы белән бик тә горурлана иде. Төмәндә басылучы газеталарда ул үз халкының борынгы тарихы һәм хәзерге хәле турында күп кенә үткен эчтәлекле мәкаләләр чыгарды. Әлбәттә, ана каршы төшкән усал-усал язмалар да булды. Шулай итеп Булат шагыйрь генә булып калмыйча, актив иҗтимагый эшлеклегә дә, хәтта кайберәүләр әйткәнчә, "куркыныч милләтчегә" үк әйләнеп китте.

Мин үзем шәхсән Булат Сөләйманов белән ике ел аралашып кала алдым. Төмән газеталарында анын ялкынлы мәкаләләре чыккач, мин—әле ул чагында Казанда яшәп ятучы кеше—илһамланып киттем дә күләмле генә мәкалә язып, аны СССР Язучылар берлегенең Төмән бүлегенә юлладым. Ә үземә җавап итеп Булаттан шундый сәер хат алдым: "Себер татарларынын тормышын җанландыру буенча комитет мөрәҗәгате".

Бераздан миңа "Себер татарлары" дигән фәнни-практик конференциягә чакыру да килеп төште. Ул 1990 елның 17—18 июнендә Тубыл шәһәрендә узачак икән. Без Казаннан бер төркем галим бардык. Булат абыйны әле бер дә якыннан күргәнем юк иде. Шуңа күрә тизрәк танышасым килде дә, ул утырган президиум өстәле янына килеп Булат абыйга:

—Яхшымысыз, Булат абый!—дидем. Ә ул миңа шактый ук кырыс кына итеп:

—Яхшымысыз түгел, яхшыман!—диде.

Шулай итеп минем телдәге Төмәнчә сүзне үзенең Вагай вариантына төзәтү иде инде бу!

Конференция беткәч, безне Себер татарлары яшәгән авыллар белән таныштырдылар. Ә Булат абый безнең белән бераз гына йөрде дә, аерылып калды.

Төмәнгә кайткач мин анын өенә шалтыратып вәгъдәсен исенә төшердем. Борынгы Себер картасын бирергә ышандырган иде ул. Ләкин бу карта мине бик сөендерә алмады, чөнки Г. Ф. Миллерның "Себер тарихы" дигән мәгълүм китабындагы картадан ксерокопия генә иде ул. Ләкин Булат абый аны миңа бик зурлап: "Әнә бит XVII гасырда ук татарлар" дип язганнар сүзләрен әйтеп тапшырды.

Булат абый 1988 елда Татарстан китап нәшриятында "Ак метеор" дигән, ә 1986 елда Мәскәүдә "Дикая рябина" дигән китапларын чыгарды. Вакытлы матбугатта анын исеме күренгәләп торды. Булат Сөләйманов шигырьләре Төмән дәүләт университеты бастырып чыгарган "Төмән крае әдәбияты" дигән өч томлык җыентыкка да кертелгән.

Булат Сөләйманов 1991 елның 11 гыйнварында вафат булды. Ләкин анын исеме якташлары теленнән төшми. 1998 елдан башлап ел саен Төмәндә "Булат Сөләйманов укулары" дигән фәнни-практик конференция уздырылып килә. Казарово поселогының бер урамына Булат Сөләйманов исеме бирелгән. Шагыйрь туып-үскән зур гына йортта мемориаль такта тора...

**Хәнисә АЛИШИНА,**
*филология фәннәре докторы.*

Булат
Сөләйманов

# ЧАЛ ИРТЫШНЫҢ ҮЗЕ КЕБЕК...

ШИГЫРЬЛӘР

***

**Мин—төп Себер татарымын чыгышым белән,**
**Гомер сөргән монда минем бабаларым.**
**Чал Иртышның үзе кебек, борынгыдан**
**Яшәп килә монда татар балалары.**

**Мин килмешәк түгел монда, туган җирем,**
**Гомерлеккә сине ташлап китә алмам.**
**Җирнең тарту көчен җиңдек, и Себерем,**
**Ләкин синең тарту көчең җиңә алмам.**

## Самотлор

**Йөзек кашы бит син Себернең!**
**Үзәгендә туган көмеш ай.**
**Астын өскә җирнең айка хет,**
**Сиңа тиңдәш күлләр юк бугай.**

**Бозлыклардан хасил булдыңмы?**
**Күктән иңгән сиңа күк төсе.**
**Әкиятләрдән әллә күчтеңме?**
**Себернең син сихри көзгесе.**

**Серле сандык серсез ачылсын,**
**Бар дөньяны, әйдә, сокландыр!**
**Киләчәккә синең күз белән**
**Туган илем карый, Самотлор!**

## Түбән Варта

**Парадмыни, тезелешеп**
**Йортлар кунган ап-ак карга.**
**Изүләрең җилгә ачып,**
**Ашыгасың кайсы ярга,**
**Түбән Варта?**

**Яшь бөркетләр каласы син,**
**Прописка юк «куяннарга».**
**Саз эченнән агып чыгып**
**Обка койган урамнарда**
**Ап-ак күбек.**

**Ә җилләре уттай салкын,**
**Исә борын заманнардан.**
**Кигән кием-толыбың да**
**Ап-ак йонлы бураннардан,**
**Түбән Варта.**

**Бозлар белән капланса да,**
**Об сулары барыбер ага.**
**Факелларда таң шикелле**
**Тынлык яна, тынлык яна—**
**Күктә яра.**

Кабына да сүнә кояш,
Тынмый көрәш Самотларда:
Буровойлар тишәр чорны
Иман барда, илһам барда,
Түбән Варта.

Девоннарга манып каләм,
Бар бит эшләр башкарасы.
Үз тарихын яза бүген
Кар иленең башкаласы—
Түбән Варта!

## Салехардта ак төн

Салехард.
Июнь ае.
Бабай белән бергә икебез.
Бик ерактан,
Озын юллар үтеп,
Бүген генә килеп җиттек без.

Төн.
Бар җир тынган.
Шәһәр йоклый күптән.
Сәгать инде төнге бер тулган.
Ә шулай да кояш батмый һаман,
Ни булган?

Бер уйласаң,
Әкияттәге кебек,
Бу хәл шомлы булып күренә.
Ә бабайның әле кичке намаз
Укыйсы бар—
Көтә,
Тилмерә.

Салехардка килгәч,
Беренче кат
Әнә шулай йоклый алмадым.
Мина нәрсә...
Бабай гөнаһланды,
Укый алмый кичке намазын.

## Аучы өенә кире кайтмады

Аучымы,
Аучынымы нидер аулады...
Кара урман шомлы шаулады.
«Озак йөрмәм дигән иде бит».

Авылдашлар тирги давылны,
Күмеп киткән өчен авылны.

У–у–у...
Әллә җилләр, әллә бүреләр?..

Йокламады авыл төн буе,
Һәркемнең дә иде бер уе:
"Менә–менә кайтып керер ул".

Төн үтте...
Төн артыннан тагын көн үтте.

Аучы өенә кире кайтмады...
Авыл өстен болыт каплады.

***

Кара төндә, аулак өйдә
Ике йөрәк бергә янды.
Ә урамда—яңгыр яуды.
Аннан... кызның күзләреннән
Тамчы булып өзелеп—өзелеп
Мәхәббәте җиргә тамды.

## Чынлап баксаң

Кемдер әйтте—мәрҗән,
Кемдер энҗе диде.
Чынлап баксаң,
Таң нурлары кунган
Гади тамчы иде!

## Акбүз ат

Ак таңнарым өлгермәде
Җәяргә ал канатын,
Очкан уктай, томаннарга
Ыргылды хыял атым.

Эһ дигәнче ул юк булды.
Китмә—китмә, Акбүзем!
Сагышларым белән торып
Калдым мин тик берүзем.

Сөт сыман ап—ак томаннар—
Әллә җирнең сагышы.
Калды йөрәгем күк ярсып
Типкән тояк тавышы.

Акбүз атым, сине эзләп
Ил гиздем еракларда.
Кешнәвеңне ишетмәдем,
Әйтче, син кай якларда?!

Нигә ташлап киттең мине,
Төннәремне эретеп?
Мин бит сине үстердем лә
Хыялымда йөретеп.

Бәлки, җирсеп бер кайтырсың
Еллар үткәч каршыма.
Даган табып, бәхеткә дип
Кактым капкам кашына.

***

Бу дөньяда мин бер гади юлчы гына,
Юлда йөреп, юлда язам шигырьләрем.
Аларга да шуны телим: илләр гизеп,
Үзем кебек, юлда гомер сөрүләрен.

Фирдәвес
Гәрәева

# КӘЧЕ БАРЫЙ

Мин бу язмамны авылыбызның иң гөнаһсыз кешесе булган Барый истәлегенә багышлыйм. Алып барып укып, үзен сөендерермен дигән идем дә бит... Ураза гаете алды көндә гүр иясе булган дигән хәбәр үзәкләрне өзде. Башта ышанмый тордым. Ул гел яшәргә тиеш иде кебек бит!

Без—Кәче авылы балалары. Арча районындагы иң зур һәм бай тарихлы авылларның берсе ул. Авыл уртасыннан Казансу ага. Арьягы, Югары очы, Түбән очы һәм шулар арасында элек Тегермән очы дип йөртелгән ике урамы да бар. Без Казан суына бик якын урнашкан әнә шул Тегермән очы урамында үстек. Казансу ул вакытта гайрәтле, тирән, тиз агышлы иде. Яз көннәрендә бакчаларны су басып китә, аннан ләм каплый, бәрәнге уңа. Аның суы чиста, ярларында сап-сары ком, тирә-ягында чәчәкле болыннар җәйрәп ята. Бала-чага су коена, балык тота, хатын-кыз кер чайкый.

Шул сигез йортлы гына урамда сугышка кадәр туып калган 12 малай үсте. Яшь тирәләре бер чама. Алар өй саклады, мал-туар карады, көтү көтте, көченнән килгәннең барын да эшләде. Әниләрне эштән өчаякта (мич каршында йомычка ягып пешерә торган таба) бәрәңге пешереп каршы алды, аларга зур таяныч булды. Самавыр, комган, чүмеч агартырга да тезелешеп су буена алар төшә иде. Шул арада тиз генә Текә турда су коеналар. Монда яр текә, аннан сикерәләр дә. Су ул урында бик тирән, әллә ничә дилбегә дә житми диләр иде. Бераз киткәч, кызлар туры, анда кыз балалар чыр-чу килә, яулык белән балык сөзә, комга тотынып "йөзә"—аяк суда чапылдагач ярый.

Менә шул унике малайның берсе гел үзенә бер төрле булды. Малайлар кайсы фанердан ясаган "сумка", кайсы букча тотып мәктәпкә киткәч, укытучылар Барыйның укый алмасын әйткәннәр. Аңа ямьсез, "Тиле Барый" дигән кушамат тагылды. (Туганнары алдында гафу үтенәм.) Шулай итеп, ул яшьтәшләре белән бик аралашмый башлады, һәр туган баланың яшьтәшенә әйләнде. Бөтен бала-чаганы исеме белән белде, таныды. Ямьсезләнеп начар сүзләр кулланмады, татулык яратты, шукларга: "Тимә инде",—дип кенә әйтеп куя иде. Гел үзенчә, без аңламаганча яши бирде. Кара-каршы сөйләшмәде, үзе уйлаганны әйтә, сөйли, сораганга җавап бирәсе килсә бирә, теләмәсә—юк. Ул күп йөри, авылның бар кешесен белә торган булды. Тиешле вакытын туры китереп кенә яңалыклар белән таныштыручы да ул иде: кемгә кем кайткан, кем авырган, кемне мәңгелеккә озатканнар һәм башка бик күп "соңгы хәбәрләр".

Сугыштан соң туган малайлары Фәйзрахман дөнья яктысын күрә алмый үсте. Барый аны җитәкләп йөрде, аның белән йөргәндә гел сөйләште. Әллә ниләр сөйли, Фәйзрахман башын кыңгыр салып тыныч кына тыңлап бара. Абый кеше аның тормышына яктылык өсти, дөньяны күңел күзе белән күрергә өйрәтә иде сыман. Барый Фәйзрахманның күзе булса, Фәйзрахман

абыйсының акылы иде. Бер-берсен шулай ихлас анлый белгән тагын ике ир туган булды микән дөнья йөзендә? Аларга карап бер сөенәсен, бер көенәсен. Ходаем, сәламәтлек бир, шушы кешеләр язмышын насыйп итмә, дисен.

Авыл мәктәбен тәмамлап, балаларнын кечерәкләре шәһәргә китте. Әти-әнисе янында Барый булды. Һади абый да күрми иде, ләкин бик оста итеп ятьмә үрә, кулыннан килгәнчә өй эшләрен башкара һәм искиткеч итеп гармун уйный иде. Сабан туе кичләрендә тальянын алып капка төбенә чыга һәм таннар атканчы үзәкләрне өзеп моң агыла Тегермән очына.

Барый исә үзенчә монлана, үзенчә эшли—анисы кәефенә карап. Кайвакыт чиләк-көянтә белән Аргы яктагы чишмә суына бара. Иртән киткән Барый төрле тукталышлар ясап, тәмләп сөйләшеп, жайлап басып, көянтәне бер жилкәгә генә куеп өйлә вакытларына кайтып житә. Гәүдәсе гомер буе төз булды анын. Уртача буй, конгырт чәч, зәп-зәнгәр, чиста, сабый балаларда гына була торган эчкерсез күзләр, салмак, кайвакыт ялгышып китә торган адымнар. Ул Казанга үзе дә күп йөрде, һәм әле һәр кешене озата, каршы ала да иде кебек. Әнисенә авыр йөкне күтәреште, янында ярдәмче булды. Сонрак ул авыл кешеләреннән тыш күрше авылларны, Казан кешеләрен дә танып белә башлады. Барый Мәскәү, Свердловск якларын да күреп кайтты, ул заман өчен бу зур сәяхәт инде. Аны һәр жирдә үз итәләр, ана кечкенә генә кучтәнәч йә бүләк бирә алса, кеше сөенә, күнеле тынычлана, юлы унар, теләгәне кабул булыр кебек тоела. Барыйнын күнеле чиста. Ул рәхмәт әйтми, кучтәнәчләргә үзенчә сөенеп, матур елмаеп: "Һы",—дип куя. Сорашканны яратмый, сөйлисе килсә сөйли, әйтәсе килсә әйтә, әйтәсе килмәсә сүзне икенчегә бора. Анын үз законнары. Ярдәмгә мохтаж кешеләргә дә үзенчә булыша: утын кисә, кар көри, су кертә. Күршеләренә күчеп килгән Хәдичә апай бервакыт Барыйга кар көрәргә кушкан. Барый болай дип жавап биргән: "Свой огород сам копай!" Йә ул аны күбрәк эшләтә башлаган, йә көйсезрәк вакытына туры килгән. Һәм әле русча белү дә күрсәтелгән. Хәдичә апа—укытучы.

Әйе, хәйләкәр дә иде ул, гел булышам дип тормады, йөкнен авырлыгына һәм кешесенә карап ярдәм кулын сузды кебек. Ә менә кеше әйберсенә беркайчан да тимәгән, арбадан бер уч печән төшеп калса да, китереп сала торган булган.

Чакырмыйча, әрсезләнеп кешегә кермәде. Мин анын күршеләр булып яшәп безгә өч мәртәбә кергәнен хәтерлим. Беренчесе энем Рәшитләр туенда—сөенечтән, ә икесе әти-әни мәрхүм булгач. Әнинен өчесен үткәреп, авыр бер тынлык урнашкан мәлдә ишектән Барый килеп керде. Урындыкта озак кына сүзсез утырды да: "Бик әйбәт ие Бибисара апай, имә",—диде. Күзләрендә ике бөртек яшь күренде. Әтидән сон тагын шул хәл кабатланды һәм өстәмә бер жөмлә әйтелде: "Кайтып йөрегез, ташламагыз". Өйдә жан өшеткеч бушлык иде. Мин бу сүзләрне гел хәтеремдә янартып яшәдем. Ул без кайтканга ихлас куана иде. Сонгы хәбәрләрне әйтеп ала, ашыгып нәрсәдер сөйли, елмая.

Без ана гел гажәпләнеп яшәдек. Акыл да дөрес үк түгел, кылган гамәлләре дә үзенә бер төрле, мөстәкыйль яшәрлек түгеллеген күрсәтеп тора, ә үзеннән дөм акыллы кешеләрдән чыкмаган акыллы фикерләр дә чыккалап куя. Ана кинәш бөтенләй кирәкми, ул үзенчә яши, фикер йөртә.

Сонгы вакытта Барый энесе Наил белән киленнәре Миләүшә тәрбиясендә Казанда яшәде. Аны авылда юксыналар, сагынып искә алалар иде. Бик юксынганнары эзләп табып, килеп тә йөргәннәр икән. Без дә бардык, сенелем Гөлфия белән аны күреп куандык, күнел тынычлыгы бүләк итеп жибәрде ул безгә. Ә үзенен шатланулары! Ул ямьле, сөенечле күзләр, ашыга-ашыга сорашулар, исенә төшкәнен тизрәк сорап калыйм дип талпынулары!

Барый һаман әле үткәне, авылы белән яши иде булса кирәк.

Икенче тапкыр барганда минем тормышымда үзгәреш булган иде. Бу хәлгә Барый ничек карар икән? Без киләсен әйткәч, ул Миләүшәне өйдән чыгармаган, капка бикле булыр да кире китәрләр дип курыккан. Бу юлы ул сорауларның күбесен Фәриткә яудырды һәм кинәт кенә матур елмаеп: "Фәрит, мин сине Фирдәвесне урлагансың дип торам",—диде. Барый безнең яшьлегебезне белгән, онытмаган кеше. Бу сүзләре белән ул безгә хәер-фатиха биргән кебек булды, миңа бик рәхәт булып китте.

Барый яшьләр тормышын күнеле белән тойган, кемнең кемне озатканын, яратканын белгән кеше иде. Ул аны ничек белеп бетергәндер, анысы безгә сер. Бик кирәкле хәбәрне җиткерүче дә Барый, ул аны җайлап кына әйтә. Поездан төшеп бераз баргач: "Кара, "теге" кайтты ул, алдагы поездда",— дип куя. Әй, рәхмәт яугыры кеше, бу бит шулкадәр тансык, ишетәсең килгән сүз. Ул кайткан! Димәк, мин аны күрәчәкмен. Йә Барый мине ял көне очратып, аның киткәнлеген хәбәр итә, димәк, клубка чыгып торасы да юк. Мондый сүз миңа гына түгел, көткән һәр яшь кешегә әйтелә иде бугай. Әллә үзе якын күргән аерым кешеләргә генә әйтте микән? Парлашып капка төбендә торганда, айлы-йолдызлы күкне карап йөргәндә әкрен генә яннан үтеп китә иде шул. Ул кичләрнең дәвамы гына кебек бүгенге көнебез. Барыйга да шулай тоелгандыр, ул безнең яшьлегебез кешесе иде бит. Фәриткә теге сүзләрне шуңа әйткән дә инде ул.

Әй, изге зат! Син юк инде, ләкин син күп кешеләрнең хәтерендә әле. Очрашкан саен кемдер искә ала үзеңне. Халык күнелендә якты хисләр, истәлекләр яши. Барыйдан соң нәүмизләнен калган авылның туфрагы аны үз куенына алды.. Авыр туфрагың җинел булсын.

Шушы каршылыклы язмышлы кешеләрдән гыйбрәт алып, миһербанлырак булсак иде. Комсызлык акылларыбызны томаламасын иде.

...Барый исеменә теге ямьсез сүз кушылмый хәзер.

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында саклanган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр h.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

*«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# Д

**ДӘҮЛИ** (Дәүләтшин) Нәби (Нәбиулла) Хәсән улы (1.6.1910, Спас өязе Иске Камка ав.—18.5.1989, Казан), язучы. ФЗӨ мәктәбен тәмамлагач Донбассның металлургия предприятиеләрендә эшли. Беренче язмалары Донецк шәһәрендә татар телендә чыга торган "Пролетар" газетасында басыла башлый. 1935 елда Казанга кайта. "Яшь сталинчы" газетасында эшли, бер үк вакытта Казан педагогия ин-тының кичке бүлегендә укый. Лирик-публицистик характерда "Бәхет" (1937), "Ал чәчәк" (1939), "Уйлар" (1940), "Кырык шигырь" (1941) исемле шигырьләр һәм поэмалар җыентыкларын бастыра. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә. 1941 елның августында Орша шәһ. янында барган сугышта әсирлеккә төшә, Германиягә озатыла. Фашист концлагерьларының бөтен михнәтләрен кичерә. 1945 елның апрелендә төрмәдән кача, декабрендә Казанга әйләнеп кайта. 1956 елга кадәр сәнгать остаханәләрендә художник-оформитель булып эшли. Әсирлектә булуына шикләнеп карауларына, эшкә алмауларына, ТАССР Язучылар оешмасыннан куылуына карамастан, Д.нең сугыштан соңгы иҗаты оптимизм һәм гражданлык рухы белән сугарылган. Ул иҗади хезмәт романтикасын, халыклар дуслыгын, Туган илне мактап шигырьләр иҗат итә. 1950 еллар ахырында аның шигырьләре кабат басыла башлый: "Юлда" (1957), "Көндәлек битләре" (1960), "Яңа көннәр туганда" (1962), "Авыл дәфтәре" (1966), "Мин җирдә калам" (1980) җыентыклары. Д.нең проза әсәрләре документаль-автобиографик характерда. Аның "Яшәү белән үлем арасында" (1958; русчага тәрҗ. "Между жизнью и смертью", 1960) повесте авторның фронтта һәм әсирлектә күргән кичерешләре турында. Шушы ук тема "Җимерелгән бастион" (1965; русча тәрҗ. "Разрушенный бастион, 1967) повестенда да дәвам итә. Д.—балалар өчен пьесалар, миниатюралар, әдәби-публицистик мәкаләләр, очерклар авторы да. Д.нең күпчелек әсәрләре рус телендә дә нәшер ителде, башкорт, кыргыз, әзербайҗан, казах, төркмән, украин телләренә тәрҗемә ителде. "Почёт билгесе" ордены белән бүләкләнгән.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1969; Утро. День. Вечер: Стихи. М., 1975.

Әд.: Халит Г. Н.Дәули шигырьләре уңаеннан // Совет әдәбияты. 1940. №3; Галеев М. Яшәү белән үлем арасында // Татарстан. 1996.№9; Маннапов Ш. Кайтмый еллар, кайталар җырлар // Казан утлары. 2000. №6.

*Р.А.Мостафин.*

**«ДӘФТӘРЕ ЧЫҢГЫЗНАМӘ»** («Дастане Чыңгызнамә»), 17 йөз ахыры татар әдәбияты истәлеге. Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларындагы тарихи язмаларга һәм риваятьләргә нигезләнеп билгесез автор тарафыннан төзелгән. «Д.Ч.»нең авторы дип дин эшлеклесе, 1670-71 елгы Крәстиян сугышында катнашкан Идрис-хафиз фаразлана. Әсәр Чыңгыз хан нәселе, Аксак Тимер, Гайсә улы Әмәт, Идегәй, төрле ханнарның яшәү урыны, биләмәләре турындагы 6 повесть-бүлектән тора; соңгы өлеше «Татар елъязмасы» буларак та мәгълүм.

Әсәрнең теле гади һәм тасвирлы, әйтемнәргә, фразеологизмнарга бай. «Д.Ч.»не беренче булып И.Хәлфин өйрәнә. 1822 елда ул татар-рус кушымта рәвешендә урнаштырылган сүзлеге б-н әсәрнең җыелма текстын бастырып чыгара. Басма Казан ун-ты студентлары, Казанның 1 нче ир балалар гимназиясе укучыларына татар телен өйрәнү өчен әсбап булып хезмәт итә. «Д.Ч.»нең ин тулы басмасын 1882 дә Ф.Җиһаншин нәшер итә. 40 тан артык күчермәсе билгеле.

Әд.: Усманов М.А. Татарские исторические источники. XVII-XVIII вв. К., 1972; Абилов Ш.Ш. Книга дастанов // Средневековая татарская литература (VIII-XVIII вв.). К., 1999; Иванич М. «Дафтар-и Чингиз-наме» как источник по истории кочевых обществ // Источниковедение истории Улуса Джучи (Золотой Орды). От Калки до Астрахани. 1233-1556. К., 2002; Газиз Г., Рәхим М. Татар әдәбияты тарихы: Феодализм дәвере. К., 1925.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ДЕКАДЕНТЛЫК**, (лат. decadentia — төшенкелек), төрле дәверләрдә яшәгән халыклар мәдәниятендә, әдәбиятында

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынан басылып килә.*

иҗтимагый—сәяси, социаль катаклизмнар, рухи кыйммәтләрне яңадан бәяләү нәтиҗәсендә килеп туган, тарихта кабатланып торган, кризис халәте кичергән күренешләрнең гомуми атамасы. Дөньяны кабул итүнең бер фикри—хисси юнәлеше буларак, яңа тарихи үсешкә, тәрәккыяткә шикләнеп карау, җәмгыятьтән читләшү, яшәештән кнел бизү, мәгънә тапмау, өметсезлеккә, иррационализмга, мистикага, формализмга бирелү хас. Декадентларның этик—эстетик карашлары А.Шопенгауэр, Ф.Ницше, А.Бергсон, И.Кант, В.Соловьёв һ.б. фәлсәфи идеяләренә барып тоташа.

Татар мәдәнияте һәм әдәбиятында декаданс урта гасырларда барлыкка килә. 16 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөзнең 1 нче яртысындагы милли-колониаль изү, Коръәндәге сабырлык фәлсәфәсе һәм суфичылык карашлары б—н аралашып, халыкның иҗтимагый һәм рухи тормышының торгынлыкта, кадимчелектә калуына китерде. Урта гасырлар декадансының бу үзенчәлеге уңай вазифа да үтәде: татар этносын һәм аның ислам мәдәнияте б-н бәйле рухи кыйммәтләрен саклап калырга мөмкинлек бирде.

20 йөзнең 1 нче чирегендәге татар әдәбиятының Европадагы һәм Россиядәге иҗтимагый—фәлсәфи, әдәби—эстетик фикернең төрле модернизм агымнары нәтиҗәсендә Ренессанс гуманизмы һәм антропоцентризм б—н янәшәдә күнел төшенкелеген чагылдырган декаданс та тамыр җәя. Сәнгатьчә фикерләүнең Шәрекънең традицион канунчылыгыннан Европа тибындагы баскычына күчеш күренеше буларак, декадентлык татар әдәбияты тарихында шактый тирән эз калдырды. Билгеле бер дәрәҗәдә символизм, акмеизм, экзистенциализм, экспрессионизм, импрессионизм, «аң ташкыны», футуризм, имажинизм кебек модернистик агымнар йогынтысында булган күп кенә танылган язучылар иҗатында Д. үтә нечкәртелгән сызланулы формалар рәвешендә чагылыш тапты.

1905—07 еллардагы рев—ция җиңелгәннән соң, декадентлыкка тартым халәт С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Ш.Камалларның кайбер әсәрләрендә аеруча калку гәүдәләнде. 1 нче бөтендөнья сугышы елларында аның көчәюе Н.Думави, Г.Газиз, М.Хәнәфи, Ш.Бабич һ.б. иҗатларында күзәтелә. Иҗат иререн декадентларча аңлап, ислам идеологиясен радикаль рәвештә бәяләү, үткәндәге әдәбият—сәнгать казанышларыннан ваз кичү 1920 еллар татар әдәбиятының авангард агымнарга — Һ.Такташның гыйсъянчылык романтизмына, Г.Кутуй футуризмына, К.Нәҗми имажинизмына хас булды.

Кешене илаһилаштыру дәрәҗәсендә олылаган Шәрекъ суфичылыгының пантеистик традицияләре б—н үрелгән, бөтен нәрсәне Ницшечә кире каккан нигилизм, яшәешне мәгънәсезлек дип игълан иткән, шәхеснең чикләнмәгән азатлыгын, индивидуализмын мактаган Д. мотивлары С.Рәмиевнең гыйсъянчылык романтизмында аерата үтемле һәм тәэсирле гәүдәләнде («Алданган», «Мин үләм», «Ямь»).

Символист шагыйрь Дәрдемәнднең фәлсәфи романтизмы да шулай ук Д. мотивлары б—н өретелгән. Аның «Кораб», «Без», «Бузләрем маналмадым», «Өмидләр», «Куанды ил...» кебек шигырьләрендә кеше гомеренең чикләнгәнлеге, язмыштан узмыш булмаудан туган өметсезлек, борчылу—сыкранулар тасвирлана; тарихтагы иҗтимагый—сәяси тетрәүләр аркасында яшәеш чоңгылларына ыргытылган индивидларның гына түгел, аерым халыкларның хыялларының да тормышка ашуы шөбһәле булу турындагы фәлсәфи уйлар, хис—кичерешләр чагылдырыла. Сәнгатьчә фикерләве б—н экспрессионистларга якын торган Н.Думави «Сугыш тәэссораты» шигырендә капитал дөньясының кан коюлы сугышларына, Ницше фәлсәфәсендәгечә «үтә көчле» кешеләрнең «кызганмыйча када штыкны» дип чакыруларына, вөҗдан чикләүләрен белмичә, халыкны талауларына, юлбасарларча эш итүләренә ирониялe ризасызлыгын белдерә һәм күңел төшенкелегенә бирелә. Аның «Алла тигезли» кебек аерым хикәяләрендәге фәлсәфи—эстетик фикерләр А.Шопенгауэрның тумыштан ук кеше табигатенең бозыклыгы турындагы универсаль пессимизмы б—н аваздашлар. Француз философы А.Бергсонның интуитивизм теориясе рухында аңлатылган, кешенең ялгызлыгы, үлем каршында көчсезлеге турындагы Д. мотивлары Н.Думави М.Метерлинктан тәрҗемә ителгән «Чакырылмаган кунак» («Непрошенная») драмасыннан соң язылган әсәрләрендә дә шактый сизелә. Татар әдипләренең Д. рухындагы карашларны һәм алымнарны кабул итүләрендә рус язучысы Л.Андреев иҗатының да билгеле бер йогынтысы бар. Татар әдәби тәнкыйте аны «мәшһүр һәм мәгърүф» (танылган) декадент дип атый. Л.Андреевның «Ачлык патша» («Царь Голод») драмасын укучыга тәкъдим иткән «Шура» (1912) ж—лында һәм «Вакыт» (1913) г—тасында мондый сүзләр язылган: «Ачлык патша». Заманыбыз декадентлык заманыдыр, декадент бина гүзәл, декадент җиһаз могътәбәр, декадент рәсем хуш вә декадент әдәбият назирсыз». Бу рус язучысы иҗатындагы Д. мотивлары, символик образлар б—н аваздашлыкны Ф.Әмирханның «Татар кызы», «Картайдым», «Кадерле минутлар» хикәяләрендә дә табып була. Аның декадanска тартым һәм экспрессионистик алымнарга бай булган «Җиде асылган кеше» («Рассказ о семи повешенных») хикәясен 1909 елда татар теленә тәрҗемә итүе дә Л.Андреев иҗаты б—н кызыксынуы турында сөйли.

Баракларда яшәүчеләрнең декадентларча натуралистик портретлары эротик тасвирлары Г.Исхакыйның «Тормышмы бу?» һәм «Теләнче кызы» романнарында да күренә. Кеше психикасының аңсызлык өлкәсе, геройларның невроз халәте язучының Фрейд өйрәтмәләре — психоанализ йогынтысында иҗат ителгән, «Фамилия сәгадәте» исемле циклга кертелгән «Татар гакылы», «Мәдрәсә йимеше», «Башкорт бәхете», «Көтелгән бикәч», «Шәкерт абый» кебек хикәяләрендә дә күзәтелә.

Яшәешне декадентларча гәүдәләндерү ягыннан үзенә хас урынны тоткан язучы-экзистенциалист М.Хәнәфи, Шопенгауэрның универсаль тәшенкелек фәлсәфәсен уртаклашып, җир тормышын мәгънәсез нәрсә дип исәпли; аныңча «милләтнең үткәне, бүгенгесе, киләчәге — барысы да караңгы һәм өметсез»; кешенең дөнья көтүе дә — бары тик алдагыч иллюзия, төш күрү генә. Ул яшәеш, пантеистик суфилар әйткәнчә, индивид б-н илаһият тәңгәллегенең мәңге кабатланып торуы гына; мәхәббәтнең дә асылы — бер-ни түгел, ул — газаплы экзистенция генә, чын бәхет — үлем сәгате җиткәч, Аллаһе Тәгалә б-н шатланып кушылуда гына; үлем — җирдәге кайгы-хәсрәтләрдән, җәфа-золымнардан котылу, чын мәгънәсендә азатлыкка ирешү дип саный («Сәгадәт турысында», «Сөю — җәллад», «Бер гөл бакчасында», «Мин бер төш күрдем», «Милләтем»). 20 йөзнең 1 нче унъеллыкларында матурлык һәм эротика культын алга сөргән, җитди социаль-әхлакый мәсьәләләрне яктыртудан читләшкән, конфликтлардан азат интим-предметлар дөньясын сурәтләгән, югалган мәхәббәтне сагынып сыктаган, үткән тарихтагы һәм бүгенге чынбарлыктагы вакыйгаларны акмеистларча бик тә гади юмор, янсә шаярулы ирония ярдәмендә чагылдырган, Д. тенденцияләре б-н үрелгән байтак кына әсәрләр язылга (Ф.Әмирханның «Габдельнасыйр гыйшкы», «Куркыныч дошманнар», «Самигулла абзый»; К.Тинчуринның «Гыйшык»; Г.Гобәйдуллинның «Скрипкачы Хөсәен», «Форточкалы кәләпүш», «Бу милләт ничек тәрәккый итсен?», «Ул мактанчык түгел иде» әсәрләре).

Күпгасырлы мөселман мәдәнияте традицияләрен һәм кыйммәтләрен пародия ысулы б-н кире кагу — Ш.Бабичның «Газазил» поэмасының үзәк мотивын тәшкил итә. Мәзәкче автор Алла тарафыннан оҗмахтан куылган Иблис образына һәм шау-шулы тамаша күрсәтү алымына мөрәҗәгать итеп, ислам дине мифологиясендәге риваятьләрдән көлә, якын киләчәктә Ницшенең үтә көчле кешеләрен хәтерләткән, большевиклар токымыннан булган кодрәтле җир аллаларының мәйданга чыгачагы турында яза («Чөнки мин зур, чөнки мин нур, мин галим, / Үз-үземә кечкегә бер алла мин!.. /Дөнья беткәнче җиһанны айкарым.../ Инҗилен, Коръәнәренне таптарым...»).

20 йөзнең 1 нче чирege татар әдәбиятындагы декадансның, Аллага каршы чыгуның, дәһрилекнең, Ницшечә гәүдәләнгән нигилизмның иң югары ноктасы — Һ.Такташның «Җир уллары трагедиясе». Шагыйрь Кабил б-н Әкълимә фаҗигасен сурәтләп, мәхәббәт һәм шәфкать кебек гомумкешелек идеалларыннан яклаудан баш тарткан вәхши Ходайның кирәге калмады; ләгънәтләнгән, залим, хаин Алланы, күкләрне һәм тәхетләрне җимерүче үтә көчле Җир тәңреләре б-н алыштыру заманы килде, дип язды («Кодрәтемнән җимерәләр / Күкләр, тәхетләр, гаршеләр!! / Тез чүгәр алдымда бар көчләр, / Мәләкләр, Аллалар! / Күктә канлы Алла булса, / Җирдә башка алла бар!!»).

Иҗтимагый-сәяси аңның, сәнгатьчә фикерләүнең кризис халәтен гәүдәләндергән Д. иң элек төрле модернистик юнәлешләрдә чагылыш тапты һәм шул ук вакытта ул катлаулы тормыш материалын сурәтләгәндә татар әдәбиятының монархы кулланылышта булмаган тәэсирле чаралар, тасвири алымнар б-н баетты. Еш кына Д. бер үк язучылар иҗатында ренессанс мотивлары б-н тыгыз үрелгән рәвештә дә яшәде.

Марксистик эстетика Д.ны тискәре бәяләде, анда өстен сыйныфларның, буржуаз зыялыларының һәлакәткә дучар ителгән культурасын һәм рухи хәерчелеген күрде. 20 йөз башы татар әдәбияты буенча очеркларда да ана партиянең сыйнфый-социологик күрсәтмәләре күзлегеннән чыгып сәяси бәя бирелде. 20 йөз ахыры — 21 йөз башы татар әдәбияты белеме декадансны реакцион идеологик һәм сәнгати күренеш дип кабул итүдән баш тартты; әдәби процессның аерым чорларында аның калкып чыгуын, кабатланып килүен яшәештәге фаҗигале халәт, «бөек ару», «тарихи авыру» (Ницше), иҗтимагый тәшенкелек, якынлашып килүче афәтләр — этносларның, мәдәниятләрнең һәлакәт һәм инкыйраз алдында торулары б-н аңлатты.

Әд.: XX йөз башында татар әдәбияты. Очерклар. К., 1954; Нуруллин И.З. XX йөз башы татар әдәбияты. К., 1982; Ганиева Р.К. Декадентлык // Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Заһидуллина Д. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. К., 2003.

*Р.К.Ганиева.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Бөрбаш авылы

Бөрбаш авылы Балтач районында, район үзәге Балтач авылыннан 15 чакрымда, Шәмәрдән тимер юл станциясеннән—16, Малмыж пристаненнән 38 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бөрбаш авылы шактый борынгы. Аның Казан ханлыгы чорында ук булуы билгеле.

А. Артемьев мәгълүматларына караганда, авылдагы 123 хуҗалыкта 431 ир-ат һәм 436 хатын-кыз көн иткән.

1877 елда Бөрбаш авылында ислам дине тотучы 449 ир-ат һәм 479 хатын-кыз яшәгән. Ривайәт буенча, Бөрбаш авылын Кече Чурадан килеп бер татар гаиләсе нигезләгән. Елга башланган урында бер генә йорт булганга, елга һәм авыл атамасы да «бер» сүзе белән бәйләнешле булып калган. 1898 елгы хезмәттә Бөрбаш авылында татарлар яшәгәнлеге күрсәтелә. Ун елдан соң Н. К. Берстель Бөрбаш авылында 1188 кеше яшәгәнлеген хәбәр итә.

Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән китабында мондый юллар бар: «Бөре башы авылыннан Ишмән бине Туктаргали бине Көчек бине Тәбеҗ исемле кеше, хайваннары һәм йорт җирләре белән читкә чыгып, башлап утар ясап урнашкан. Бераздан соң ул Бөре башында яшәүче Әшмәкә исемле кеше белән дошманлашып, шул Әшмәкәнең җәбер һәм хурлауларына түзә алмыйча, үз утарыннан бөтенләй күчеп, Мәчкәрәдә урнашкан.

Өлкән бабалары Тәбеж, Бөре суы башында йорт һәм алачык салып, тимерчелек белән кәсеп итеп вафат булган. Хәзергә чаклы ул урыннан күмер, тимер калдыклары, иске дагалар чыга һәм Бөре башы кешеләре аны «Йорт-елга» дип атыйлар. Ләкин ул елга тирәсендә булган агачлар бетеп, суы корыгач, Тәбежнең улы Көчек ул урыннан ярты миль кадәре җиргә—елганың югары агымы тирәсенә килеп йорт салган һәм аның янына кайбер авыллардан кешеләр күчеп килеп, шуннан Бөре башы авылы оешкан. Шуңа күрә ул авыл Россия хөкүмәте документларында әлеге Көчеккә нисбәтән исемләнә. Көчекнең улы Туктаргали, Оренбург һәм Каргалы тирәләрендә сәүдә белән гомер итеп, 1080 (1669) елда вафат була һәм шушы авылның каберлегендә җирләнә. Каберлекнең уртасында, кабере өстендә исемен һәм вафат булу тарихын язган таш бар. Өч улыннан Мәмәт исемлесе Бөре башында калып, авыл халкының күбрәге шул Мәмәт нәселеннән килә. Кече улы Туктаргали дә авылга урнаша. Аның балалары күп булган: Ишмәмәт, Ишмәкә, Ишмән, Ишморад. Алар Бөр елгасы, Үтәмеш елгасы, Утар елгасы тирәләрендә зур-зур терлек утарлары тотканнар. Еллар узу белән авыл зурайган. Бөр елгасының башында урнашканга авылга Бөрбаш дип исем биргәннәр».

Бөр сүзе ни аңлата соң?

Бөр—этноним. Бөр-бөре кавем-кабиләләре күп кенә төрки халыклар, шул исәптән татарлар формалашуда да катнашканнар.

Авыл халкы сөйләшкәндә бер-берсен «бүренекеләр, казныкылар, куяннықылар» дип йөртә. Моны төрки-кыпчакларга мөнәсәбәтле ырудашлык атамаларын куллану дип аңларга кирәк. Авылда һәр нәселнең үз тамгасы бар.

Бөрбаш авылы табигатьнең гүзәл бер почмагына урнашкан. Тирә-ягында калын урманнар, җиләкле аланнар булганга, бабалар ягулыкка һәм печәнгә, җиләк-җимешкә аптырамаганнар. Юкәсеннән чабата, чыпта үргәннәр.

Иң зур урман—Казан урманы. Олылар әйтүенә караганда, бу урман Дәрвиш бистәсе урманнарына барып тоташкан һәм урман аша Казанга туры юл булган.

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

Казанны алганнан соң бу урман казна милке дип игълан ителә һәм шуна күрә Казна урманы дип тә йөртелә, аннан корабльләр төзү өчен имән агачлары кискәннәр. Бу урманда Зарифа почмагы, Мостай болыны һәм Әхмәди ышнасы дигән җирләр бар.

Даулы урманының исеме гаугага килеп тоташа. Салавыч, Алан, Янгул, Салавыч Сәрдегәне бөрбашлылардан бу урманны даулаганнар. Нәтиҗәдә сугыш килеп чыккан. Сугыш бөрбашлылар файдасына тәмамлана, ягъни урман бөрбашлыларныкы булып кала. Урманда Кыржыбай ягы, Сабанай аланы, Апанай буе, Камәй җире, Саралан дигән җирләр бар.

Авылда чишмәләр бик күп. Шуларның иң саф сулысы Бөре елгасы башында урнашкан. Ул изгеләр чишмәсе исемен йөртә. Авылның ир-егетләре сугышка киткән вакытта шул чишмәгә килеп су эчкәннәр һәм үзләре белән бергә чишмә янындагы туфракны алып киткәннәр. Гайни әби чишмәсе, Мәрхаб чишмәсе, Миннемулла чишмәсе, Мәүли чишмәсе, Хәйретдин чишмәсе, Гариф тау асты чишмәсе, Хәдичә чишмәсе—чишмәне караган кешеләр исеме белән аталганнар. Авылда Әптеки чишмәсе дигән чишмә бар. Аны Югары оч хәзрәте Әхмәдулла абзый казыган (кушаматы Әптеки була). Моннан башка авылда тагын Яргыч чишмә, Бөр чишмәсе, Ак балчык үзәне чишмәләре бар.

Авылдагы көмеш сулы 3 чишмәнең һәркайсына улаклар куелган, анда хатын-кызлар кер чайкый, якынрак торган кешеләр чәйгә чишмә суын алып менә.

Авылны урталайга бүлеп Бөре елгасы ага. Аңа бик күп вак елгалар килеп кушыла. Тирән елга, Утар елга, Тәллитүт, Мөәзин елгасы, Үләт елгасы, Норма елгасы, Чишмә башы елгасы, Убыр елгасы, Читәшмәс, Чәмәкәй елгасы, Кирәмәт елгасы, Аракы пешкән елга һ. б. Аракы елгасында, халык сөйләве буенча, элек чирмешләр аракы куып ятканнар. Кирәмәт елгасы бик күп авылларда очрый. Бу елгада куркыныч чоңгыллар бар.

Хәзерге урынга күчеп килгән кешеләр урманнарны төпләп һәм яндырып басу ясаганнар. Иң беренче басу—Олы кыр. Аның бер кырые Эт мазары басуы дип атала. Кыргый этләр кыш көне шунда җыелалар. Утар елга белән Тирән елга арасында Саралан басуы урнашкан. Аракы пешкән елга буенда Киртәлек буе басуы бар. Аның уртасыннан Киртәлек юлы үткән. Урманнан озын киртәлек агачларны шушы юлдан алып кайтканнар. Убыр елгасы белән хәзерге ферма арасында Ләкләк күл буе басуы ята. Элек анда күл булган, ләкин ул күмелгән. Убыр елгасы белән Чишмә башы елгалары арасындагы басуны Убыр басуы дип йөртәләр. Бу басу кырыенда урманнан чыккан су җир астына бөтерелеп кереп китә һәм авыл башында килеп чыгып Бөре елгасына коя. Халык уйлавына караганда, чишмәләр һәм коелар 90 процент күләмендә шушы су белән туеналар. Читәнмәс елгасы кырыенда Читәнмәс басуы бар.

Авыл көрәшчеләр белән дан тота. Ел саен Бөрбаш кешесе Галел Гомәров призына ярышлар уза. Бу кеше беренче комсомолны оештырып йөргән активист булган.

Авылдагы урам исемнәренә игътибар итик. Олы юл уза торган урамны Үзәк урам дип атыйлар. Элек мулла яшәгән урам Мулла урамы дип телгә кергән. Бер генә якта йортлары тезелеп киткән урамны Җөп урам диләр. Зират янында урнашкан урам Әҗәл урамы исемен йөртә. Калку җирдәге урам—Тау башы ягы, ипи пешерә торган пекарняга бара торган урам—Пекарня урамы. Яңа төзелеп килгән, күбесенчә яшьләр яши торган урамны Комгансызлар урамы дип тамгалаганнар.

Авылда элек заманда ук кунакханә булган. Аңа мосафирлар кереп ял итеп киткәннәр. Әгәр дә юлчы-мосафир халыкка ошамаса яки кунакханәдә озаграк ятса, авыл халкы арасыннан шуграклары төнлә килеп кунакханәнең ишеген алып китә торган булганнар. Мосафир моның сәбәбен аңлап, юлын дәвам иткән.

Элек авылда, билгеле инде, мәчет булган. 1865 елда туган Гариф Мөхәммәдиє авылда озак кына мулла булып торган. Шуның өстенә ул оста һөнәрче дә була. Аның урам яктагы өй чарлагы башына куелган зур түгәрәк сәгате, төгәл вакытны күрсәтеп, урамнан узучыларны шаккатырып торган. Бакчасында беседка төзегән, мунча белән өй арасына телефон сузган. Бу мулланың ир туганы Садыйк Мөхәммәдиев абыйсы янында мөәзин булып торган. Ул тимерче һөнәрен яхшы үзләштергән, җил тегермәне тоткан. Боларның өченче туганы Җәлал Мөхәммәдиев икенче мәхәлләдә мулла вазифасын башкара.

1910 елгы исәп алу буенча авылда 269 хуҗалык була. Күбесенең тормышы шактый таза, үз көннәрен үзләре күрерлек көр була. Авыл халкы ярлы кешеләрнең күбесе ялкау, эшкә сәләтсез икәнен белгән һәм андыйларны өнәмәгән, һәр тырыш кеше таза, мул тормышта яшәгән. Укый-яза белүчеләрнең дә саны күп булган.

Халык иген культураларыннан арыш, арпа, солы, бодай белән рәттән борчак, киндер, житен, шалкан, ә соңрак бәрәңге дә иккән. Жир эшләре бетеп торган арада да тик тормаганнар. XX гасыр башына авылда төрле-төрле һөнәр ияләре күп саналган: чабата ясаучылар, итек басучылар, чыпта сугучылар, мич чыгаручылар, пыялачылар, балта осталары, аучылар, терлекчеләр, умартачылар һ. б. Авылда 4 тимерче алачыгы эшләгән. Садыйк Мөхәммәдиев, Мөхәммәт Әхмәтов, Мөхәррәм Мөхәммәтов, Сөләйман Садыйковлар Көчек бабай һөнәрен дәвам иткәннәр.

XX гасыр башында авыл дүрт өлештән торган: Үзәк, Әҗәл як, Тау башы, Әхтәм ягы. Авыл урамнары тау башында урнашкан, тау итәкләреннән челтерәп аккан чишмәләрдән халык оста файдаланган. Ул чишмәләрдә хәтта тирә-як авыллардан килеп бодай юганнар, кояшта киптергәннәр һәм киндерләрне агартканнар.

Авыл уртасындагы мәчет 1823 елда салынган, 1883 елда такта белән тәрелгән, түбәсе яхшы калай белән ябылган. 1938 нче елда манарасын кискәннәр һәм мәчет 1982 елның февраленә кадәр мәдәният йорты булып торган. Ул 1988 елда сүтелгән.

1917 нче елда, күмәк көч белән авылда яна мәчет салалар. Ләкин бу бинага мәчет вазифасын үтәргә насыйп булмый. Советлар хакимияте чорында ул башлангыч мәктәп, ә соңыннан интернат итеп файдаланыла.

Авыл үсә, халкы арта. 1910 елгы исәпкә караганда, авылда 269 крәстиән хуҗалыгы була, аларда 100 ат, 90 лап сыер, 150 баш сарык саналган. Жир эшкәртү өчен 19 тимер, 30 агач сука, 15 тимер сабан, 40 агач тырма исәпкә алынган.

Беренче Бөтендөнья сугышы авылга зур зыян китерә. Авылның әзмәвердәй ир-атлары сугышка чыгып китәләр. Бөтен эш хатын-кыз җилкәсенә төшә. Киткәннәрнең һәрберсе яу кырында ятып кала, исән кайтканнары аз була.

1917 елда революция килеп чыга, тормышлар катлаулана.

1921 елда Идел буенда зур ачлык була. Яз чәчкән ашлык тишелми, көзге арыш көеп бетә. Кешеләр су буйларында үскән сәрдә, кузгалак, кычыткан белән тукланалар. Бу вакытта күп гаиләләр Себер якларына—Новосибирск тирәләренә чыгып китә.

Октябрь революциясеннән соң авылда ярлылар комитеты төзелә. Авыл кешеләреннән Фәхретдин Баһаветдинов, Нәбиулла Хәкимов, Миннемулла Абдуллин һәм Әсма Галиева шул комитетка керә.

Бераздан кулак дип авыл халкын Себергә сөрү башлана. Чынлыкта халык нахакка рәнҗетелә. Байлыкларын үз хәләл көче белән тапканнар тар-мар ителә. Ялкауланып, эшләми ятарга яраткан бәндәләр авылда бар нәрсәгә баш булып алалар.

Мулла-мөәзиннәрнең дә бар мал-мөлкәтен алып чыгып китәләр.

Бер оешып, бер таралып азапланганнан соң, 30 нчы елларда колхоз шактый тернәкләнеп китә. Ана «Кызыл Татарстан» исеме бирәләр. Колхозның беренче житәкчесе итеп укый-яза белмәгән Шакир Закировны утырталар. Белеме булмаса да, аның оештыру сәләте көчле була.

1935 елда беренче трактор кайтарыла. Шул уңайдан авылда демонстрация үткәрелә.

Колхозлар тернәкләнеп китә. Моңа кадәр барлык кыр эшләрен ат һәм кул белән башкарган булсалар, МТСлар оешкач, жирне тракторлар белән эшкәртә башлыйлар. Авыл 6 бригадага бүленә, 3 урында ындыр табаклары төзелә. Ашлык беренче нәүбәттә дәүләткә тапшырыла, шуннан калса, чәчүлек орлык терлекләргә ашату өчен калдырыла һәм хезмәт көненә колхозчыларга бүленә.

1937 елда җәй бик әйбәт килеп, игеннәр нык уңа. Кешеләргә мул итеп ашлык өләшәләр. Яхшы эшләп, хезмәт көне күп булган хуҗалыкларга ашлыкны атларны матур итеп бизәп, дугаларына кыңгырау тагып, алдагы ат дугасына яисә йөккә кызыл флаг кадап өләшеп йөргәннәр.

1940 елга кадәр Бөрбаш авылы Кукмара районына кергән, ә 1940 елда Бөрбаш һәм Бөрбаш Сәрдегәне авыллары Балтач районына күчерелә.

Бер-беренә ярдәм итеп, булганына риза булып матур киләчәккә өметләнеп яшәгәндә бөтен ил өстенә зур афәт килә. 1941 елда сугыш башлана.

Сугыш башлану турындагы хәбәр авылга кичкә генә килеп житә. Сугышка авылдан иң беренче булып китүче ир-егетләрнең кайберләре: Гамбәр Фатыйхов, Зиннәт Зарипов, Ярулла Нурмиев, Кәбир Исрафилов, Кави Нәгыймов һ. б. Сугышның беренче елында авылдан 142 кеше фронтка алына. Иң беренче үлем хәбәре Жаббаров Мөхәммәт турында килә. Ул яшәгән урам аның хөрмәтенә хәзерге көндә Жаббаров исемен йөртә.

Ирләр сугышка киткәч, барлык авырлык хатын-кызлар һәм үсмерләргә кала.

Хәкимова Гөлчирә, Зәйтүнә, Мәдинә апалар тракторчы һөнәрен үзләштереп, механизатор булып эшли башлыйлар. Урман кисү, окоп казу, станциядән орлык ташу, жир эшкәртү һ.б. эшләр барысы да хатын-кызлар тарафыннан эшләнә.

Зарыгып көткән жиңү көннәре дә житә. Бу жиңү шатлыклы һәм кайгылы да була. Чөнки авылдан сугышка киткән 219 кешенең 83 е генә кире әйләнеп кайта. Аларның да күбесе сугыштан алган яраларыннан яшьли вафат була.

Сугыштан соң авыл тиз генә күтәрелеп китә алмый. 1964 елдан алып 1966 елга кадәр Бөрбаш һәм Сәрдегән авыллары Салавыч, Яна Салавыч, Салавыч Сәрдегәне, Биктәш авылларын берләштергән «Кызыл Татарстан» колхозы составында була. 1966 елның 1 нче февраленнән алып «Кызыл Татарстан» колхозының Бөрбаш һәм Бөрбаш Сәрдегәне авылларында урнашкан VI нчы комплекслы бригадасы нигезендә терлек симертү совхозы оештырыла. Аның исемен «Балтач» дип куялар. Совхоз житәкчесе итеп Нормабаш авылыннан югары белемле Гыйрфанов Илгиз билгеләнә. Совхоз оешу нәтижәсендә авыл тормышында шактый үзгәрешләр була. Бу үзгәрешләр иң беренче чиратта төзелештә чагыла. 1962 елда сельпо идарәсе, сельпо кибете, урта мәктәп бинасы салына.

Бүгенге көндә авылда 271 хужалык булып, һәрбер гаиләдә уртача 4 кеше исәпләнә. Авылда урта мәктәпне чама белән ел саен 25 кеше тәмамлый. Югары һәм махсус уку йортларына яшьләр күп керәләр һәм, гадәттә, кире авылга әйләнеп кайталар. Халыкның яртысыннан күбрәге 12 чакрым ераклыктагы район үзәгенә эшкә йөри. Халык мех фабрикасында, типографиядә, кирпеч һәм асфальт заводларында һ. б. урыннарда эшли.

1983 елда ачылган икмәкханә (пекарня) 9 авылны ипи белән тәэмин итеп тора. 1993 елда тегү цехы сафка басты. Бу цех үзе чыгарган продукцияне цех каршындагы кибеттә һәм базарларда сата.

Авыл үсә, алга бара. Соңгы 10 елда 2 яңа урам барлыкка килгән. Авылның үзенә хас традицияләре бар. Шуларның берсе—авыл ир-егетләре милли көрәш белән кызыксыналар. Бүгенге көндә тирә-юньдә дан тоткан көрәшчеләр: Рифкат Хөсәенов, Рафис Шәрифуллин, Фидаил Шакиров (Актанышта яши), Сәит Шакиров (Казанда яши), Васыйл Гарифуллин һ. б.

Авылда яңадан-яңа матур йортлар үсеп чыга. Авыл уртасында матур мәдәният сарае, унберьеллык мәктәп, балалар бакчасы, медпункт, фельдшер-акушерлык пункты һәм зур ике кибет бар.

Мәдәният йорты каршысында сугышта һәлак булганнарга һәйкәл тора. Ул һәйкәлдә сугыштан кайта алмаган 110 авыл кешесенең исем-фамилияләре язылган, һәйкәл ел саен яңартылып тора, янында укучылар чәчәкләр үстерәләр.

Мәктәптә авыл тарихына нисбәтле документлар, төрле экспонатлар тупланган музей эшли.

Мәктәптән азрак түбәндәрәк авылга ямь биреп ике катлы мәчет тора. Мәчетнең аскы катында мәдрәсә эшли. Мәчетнең имам-хатибы Фазлыев Жәмил Васыйл улы. Ул балаларга, хатын-кызларга, бөтен теләгән кешегә дин сабагы бирә. Атна саен мәчеттә жомга намазлары укыла. Гаетләр, дини бәйрәмнәр зурлап үткәрелә. Төрле дини уку йортларында укучы авыл яшьләре мәчеткә практика үтәргә кайталар, һәр жомга саен Жәмил хәзрәт авыл һәм район радиосыннан халыкка вәгазь сөйли.

Мәчеткә йөрүче картлар инициативасы белән ел саен 9 майда зиратны тәртипкә китерү һәм чистарту өмәсе үткәрелә, һәрбер йорттан берәр кеше чыгып бу өмәдә катнаша. Бу көнне зират коймаларының сынганы алыштырыла, чардуганнар буяла.

Йортларда үзәкләштерелгән газ яна, кайбер хужалыкларда мунчага да су кергән, күп хужалыкларның йортына эссе һәм салкын су килә, урамнарда колонкалар эшли. Юлларга асфальт түшәлгән. Халыкның тормышы матур, йортлар таза һәм нык.

Хәзерге Башкортостан республикасының Балтач районында да Бөрбаш авылы бар. Ул авыл халкы бу Бөрбаш авылыннан күчеп киткән.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## Зариф Бәширинең тууына 120 ел

Зариф Шәрәфетдин улы Бәшири 1888 елның 5 маенда элекке Казан губернасының Цивил өязе (хәзерге Татарстанның Кайбыч районы) Чүти авылында мулла гаиләсендә туа. Башта әтисендә, аннары Буа мәдрәсәсендә, соңрак Казанның мәшһүр "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә гыйлем ала. Яшьтән ук шигъри җанлы шәкерт биредәге әдәби даирәгә бик тә табигый кереп китә. Аның шигырьләре бер-бер артлы көндәлек матбугатта чыга башлый. Аның шәкертләр тормышына багышлап язган мәкалә вә хикәяләре дә ул заман татар яшьләре хәл-әхвәлен тәгаен күзалларга ярдәм итә. Шул ук елларда ул, чуаш телен тирәнтен үзләштереп, чуаш халкының тарихы, көнкүреше белән кызыксына. Һәм бу табигый да. Чөнки аның туган авылы Чүти чуаш авыллары белән янәшәдә утыра. 1908 елда Оренбургта вакытта ул "Шура" журналында "Чуашлар" дигән әтрафлы зур мәкаләсен бастыра. Кәримов-Хөсәеновларның матбагасында корректор һәм берникадәр вакыт "Чүкеч" дигән юмор-сатира журналы редакциясендә мөдир булып эшли. 1908-1910 елларда аның төрле нәшриятларда "Язгы кояш", "Тутый тавышы", "Иртәнге азан", "Җуаткыч", "Яз тамчылары", "Хиссият баскычлары" исемле шигырь китаплары дөнья күрә.

Әдипнең чуашлар белән кызыксынуы аның әдәби иҗатында да чагыла. "Чуаш кызы Әнисә" повестен (1910) киң даирә укучылар яратып кабул итә. Бу әсәр матур, тәмле тел белән язылган, аңардан үзенә бертөрле лирик җылылык бөркелеп тора. Аның балалар өчен язылган "Шаян Фәхим", "Ефәк күлмәк" әсәрләре дә бу сүзләргә дәлил.

1910-1917 елларда Зариф Бәшири Пенза һәм Тамбов губерналарында, соңрак Казакъстанның Капал шәһәрендә балалар укыта. Февраль революциясеннән соң исә Алма-Ата шәһәренә күчеп, анда уйгыр газеталарында, татар телендә чыккан "Садат" исемле юмор-сатира журналында эшли. 1918-1918 елларда ул Казакъстанның Жарканат шәһәрендә мәгариф бүлеге мөдире була, соныннан, 1930 елга кадәр, Ташкент шәһәренең мәгариф оешмаларында, газета-журнал редакцияләрендә эшли, Урта Азия дәүләт университеты каршындагы рабфакта үзбәк, уйгыр телләрен һәм әдәбиятын укыта. Нәтиҗәдә, ул "Чуваш әдәбияты" (1928), "Үзбәк әдәбияты" (1929) һәм "Уйгыр әдәбияты" (1931) китапларын дөньяга чыгара.

Репрессияләр афәте аны да аямый. "Иске милли әдәбият вәкиле, мулла малае" дип көннәрдән беркөнне әдипне кулга алалар. Лагерьларда аңа "яңа тормышның" бөтен "ләззәтен" татырга туры килә.

Ирекка чыккач, ул Уфага күченә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр (язучы 1962 елның 21 октябрендә вафат була) шунда яши. Гомеренең соңгы елларында ул башыннан кичергәннәре һәм күренекле замандашлары турында хатирәләр яза. Аның бу хатирәләре "Замандашларым белән очрашулар" исемендә 1968 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күрә.

Ни кызганыч, Зариф Бәшири, шактый гына озын гомер яшәсә дә, әдәбиятта, халык хәтерендә үзенә лаек урынны алмыйча дөньядан кичкән. Озак еллар типкедә, мөһаҗирлектә көн күргән бу фаҗигале язмыш иясенең иҗаты да, тормыш юлы да тиешенчә өйрәнелмәгән, бәяләнмәгән әле.

Укучыларыбызга янә шунысы да мәгълүм булсын: Зариф Бәшири Капал каласында чагында күренекле галим вә әдибебез Миркасыйм Госмановның әнисен мәктәптә укыткан. Ул – талантлы шагыйребез Ркаил Зәйдулланың да әбисе ягыннан якын туганы булып чыга.

## Рәшит Ваһаповның тууына 100 ел

*Илдән-илгә барып җитә*
*Безнең милли, чын көйләр.*
*Алкышлый татар моңнарын*
*Берлин һәм Хельсинкиләр.*

Рәшит Ваһап улы Ваһапов 1908 елны (7 май) Түбән Новгород өлкәсенең Октябрь районы, Актүк авылында туа. Халык телендә бу авылны шигъри исем белән Янапар дип тә йөртәләр. Су буендагы жырлы-биюле кичке уеннар, мең бизәкле ямьле Сабан туйлары, Ураза гаете, Корбан бәйрәме—боларның һәммәсе дә балачакның җуелмас татлы хатирәләре.



Авылның алдынгы карашлы кешеләре Октябрь революциясен кабул итми, яңа тәртипләргә буйсынасы килмичә, Финляндиягә эмиграциягә китә. Алар арасында Ваһаплар нәселеннән дә берничә кеше була. Әлеге күчеп китүләрнең кайтавазы (дөресрәге, кәсафәте) булачак жырчының әтисе Ваһап мулла жилкәсенә зур җәфалар булып ябырыла...

Актүк авылы үзенең гүзәл табигате, урман-суларының муллыгы, сәләтле һөнәр ияләре, нык нигезле хуҗалыклары, икътисады, заманча алдынгы мәгърифәте белән элек-электән тирә-якта дан тоткан. Җөмләдән, Рәшитнең әтисе Ваһап мулла демократик карашлы, алдынгы фикерле дин әһеле булган. Мәдрәсәдә яңача укыту ысуллары өчен көрәшкән. Аның: "Минем мәхәлләдә надан кешеләр булырга тиеш түгел"...—дигән сүзләре генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Фин татарлары белән "хезмәттәшлек"тә гаепләп, мәгълүм органнар Ваһап мулланы сорау алуларга кат-кат чакырып торалар, төрмәгә дә утырталар. Аның берниндн гаепсез-нисез атылуы 1956 елда гына аклана. Әтисенең фажигасе Рәшитнең күнелендә тирән яра эзе калдыра. Моңлы жырчы булуына, халык жырларын тирән моң-сагыш белән башкаруына, үзенең шәхси тойгыларын, эчке уйларын жырга сала белүенә болар да сәбәп булгандыр, күрәсең.

Р. Ваһапов 1922 елда Түбән Новгород татар педагогия техникумына укырга керә. Жыр дәресләре аның яраткан предметы була. Техникумнан соң ул берара укытучы булып эшли. Соңрак Мәскәүдә татар опера студиясендә белем ала. 1941 елдан—Татар дәүләт филармониясе жырчысы. Татарстанның халык артисты (1957). СССРны аркылыга-буйга иңләгән, татар халкының яраткан жырчысына бу дәрәжәле исемне нигәдер әнә шулай соңлап(?!) кына бирәләр...

Аның каруы Ходай Тәгалә татарның бу газиз улына тышкы матурлыкны да, эчке матурлыкны да муллан биргән. Аның сәхнә культурасы менә шушылар нигезендә калыплашкан, билгеле.

"Мораль һәм эстетик яктан Рәшит Ваһапов үрнәк алырлык бер гигант иде. Ул—үзеннән соң килгән жырчыларга юл күрсәтүче". (Илһам Шакиров.)

"Аның тавыш көйләү үзенчәлеге сокландыра. Ул бер аваздан икенче авазга жинел генә күчү осталыгына камил дәрәжәдә ия иде". (Зилә Сөнгатуллина.)

Р. Ваһапов Финляндиягә барырга, андагы татар якташлары алдында чыгыш ясарга хыялланган. Әмма совет чорында хөкем сөргән тәртипләр бу изге теләкне чынга ашырырга мөмкинлек бирми.

## Зөфәр Фәтхетдинов

# ХИКМӘТЛЕ ҖӨМЛӘЛӘР

Теләсә кемне, хәтта үзеңне дә алдарга мөмкин, әмма Вакыт галиҗәнапләрен алдау мөмкин түгел.

***

Ярлы ил—ярлы халык һәм акылга ярлы җитәкчеләр дигән сүз.

***

Безнең борчу-мәшәкатьләр көзге болытларга охшаш: борчуларның берсе китеп барырга да өлгерми, офыкта инде икенчеләре пәйда була.

***

Ирләргә караганда хатын-кызлар өйләнешү мәсьәләсендә күпкә кыюрак була, ләкин беренчеләре аерылу гамәлен тизрәк хәл итүчән.

***

Ирләр эштә—хезмәтче, өйдә—акыл сатучылар, урам һәм стадионда—ачык авызлар, кунакта—тәти егетләр.

***

Яраткан хатын-кызлардан һәрвакыт роза чәчәге исе килеп тора, өнәмәгәннәрдән—әрем исе.

***

Хатын-кыз розага охшаган: хуш исләр тарата, тирә-юньне бизи, ләкин авырттырып чәнчи дә белә.

***

Картая барган хатын-кыз өчен көзге—даими моңсулык чыганагы.

***

Табигатьтә җылы һәм салкын, уңай һәм тискәре корылмалар булган кебек, кеше дә капма-каршылыклардан тора.

***

Чама тойгысын көмәнлек белән чагыштырырга мөмкин: кешедә ул яки бар, яки юк, өченчесе була алмый.

***

Үзең турында дөреслекне әйтү—ихласлылык, башкалар турында сөйләү кешене фаш итү.

***

Бәхәсләшкәндә кайберәүләр өчен хакыйкать түгел, үз фикерен алга сөрү кыйммәт.

***

Дөреслекне ике очракта яраталар: мохтаҗлык яисә файдасы булганда.

***

Югары вазифага күтәрелү—кыюлык, «өстә» кала белү—сәнгать, вакытында китә белү—зирәклек.

*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

Рәйсә
Юсупова

# ТЭТЧЕР МАҖАРАЛАРЫ

### Тоткын

...Юк, өемдә мине Тэтчерым көтми иде шул.

Ә эшемдә... Менә тагын... белдерүемне укыган берәү шалтыратып, мазмаемның Ибраһимов проспектында күпер астына якын гына урында бер эт белән уйнап йөрүе турында хәбәр итте, рәхмәт төшкере. Тик...

Әйе, трубканы кую белән, мин үз-үземә сөйләнеп алдым: "Казанга кайтып җитсә, Ибраһимов урамында тукталып тормый инде ул, туры өйгә чабачак..."

Болгариядән кайтканнан бирле Тэтчерым турындагы һәр хәбәргә колак сала башлаган Роза:

—Бәлки чапканнардыр да. Ишегегез бикле түгелмени?—диде.



—Дөрес әйтәсең, бикле шул. Ирем эштә. Искәндәребез исә өйләнгән көннән хатыны белән үз фатирында яши.

—Төш вакыты бит, һава да сусарбыз; әйдә, карап киләбез,—дип, мине Роза янә гаҗәпләндерде.

...Ярый әле чыкканбыз: карасана, Казаным көзенең бу матурлыгы! Күктән алсу нурларын чәчеп кояш елмая, чәчне, йөзне иркәләп-сыйпап җылы җил искәләп куя.

Мине бу хозурлыкка апчыгучы хезмәттәшемә рәхмәтле карашымны юнәлтәм: синең дә күңелең хушланамы, янәсе. Ул исә Ибраһимов урамының Ямашев проспекты белән кисешкән мәйданны күзәтә.

—Күрәсеңме, ике эт йоклап ята. Барыйк әле яннарына,—ди.

Ун-егерме адымнар үткәч, гаҗәеп манзара алдында мин тукталып калам. Агачлар күләгәсендә, яшькелт, кызгылт, сары яфраклар белән бизәлгән табигатьнең илаһи келәме өстендә йоклап ятучы бу икәүнең берсе... Әйе, әйе, Тэтчерымның "егете"—бик тә чибәр колли иде. Минем мазмаема охшаш "кызы" исә аңа иркәләнеп, башын "егет"нең муенына салган.

Комачауламагыз әле дигәндәй, теләр-теләмәс кенә күзен ача башлаган коллинең карашы миндә тукталды һәм... һәм ул шундук йокысыннан айныды. "Кызы"ның башын "келәм"гә шудырып, торып ук басты һәм яныма килде. Борыны белән аягымның әле берсенә, әле икенчесенә кагылып сәламләгәч, янә күземә текәлде. Мин аны тынычландырырга ашыктым. "Аңлыйм сине,— дидем.—Һәм гаепләмим дә, борчылма. Ир-егетләр табигать тарафыннан

*Дәвамы. Башы журналның 1 санында.*

түземсезрәк итеп яратылган инде ул. Әнә, "кәләшең" дә уянды, аның янына бар".

Тик... тик маэмай кымшанмады да. Ә күзләре, гаепле карашы һаман миңа текәлгән. Иелеп башын сыйпавым да аны урыныннан кузгатмады. Инде мин үзем дә чүгәләп, башын кулларыма алам һәм күзенә тутырып карыйм: "Тәтчерымны яратуың өчен рәхмәт сиңа! Хәзер бар инде, бар; "кызың" борчыла башлады әнә",—дим, һәм китәргә борылам.

—Таныш этеңмени? Бик озак сөйләштегез,—ди Роза.

—Тәтчерым дусларының берсе ул.

—Алай... Ни сөйләде, нәрсәләр диде инде?

—Гафу үтенде. "Ай буе көттем бит. Һаман кайтмый, һаман да юк. Бу "кызый" исә гел артымнан калмый. Ә мин барыбер синең маэмайны гына яратам", диде.

—Син үзең дә нәрсәләрдер әйттең бит?

—Ишетеп тордың ла: аңлыйм сине, ачуланмыйм, дидем...

...Бүлмәбездә телефон дулый. Ашыгудан без бүтән ачкыч тыкканбыз икән; алып кына булмый бит, хәерсез...

Ниһаять, трубканы алырга өлгердем һәм... һәм таныш тавышны ишеттем.

—О-о, Федор Андреевич, хәерле көн! Мин сезгә Болгариядән кайткан теге сишәмбедә үк шалтыраткан идем. Сезне "ерак рейста" диделәр.

—Дөрес әйткәннәр: Новосибирск составын "иярләргә" туры килде бит әле менә. Машинистларына операция булды; хәзер больницада дәвалана. Шуңа күрә сезгә әйтәсе хәбәремнең дә йоны-юне юк диярлек...

Тын алырга да куркып, мин трубканы кыстым. Халәтемне сиздe булса кирәк, машинистым шундук әлеге сүзләренә ачыклык кертте.

—Хафаланырга ашыкмагыз әле: маэмай исән-сау. Бер тапкыр шулай Ижаудан Казанга кайтканда ул минем поездга утырган булган. Вятские Поляныда ике милиционер менгән иде. Алар Кукмарада төшеп калганнар. Үзләре белән маэмайны да әләктергәннәр. Бу хакта мин соңыннан проводниктан белдем. Шушы рейстан соң ук мине менә бу маршрутка күчерделәр. Сезнең үзегезгә Кукмарага барырга туры килә инде. Тулырак мәгълүматны станция башлыгы бирер. Ә минем... дөресрәге, "скорый" дип аталучы бу составның Кукмарада туктап алу хокукы юк.

—Бу хәл... күптән булдымы?

—Новосибирски юлында йөрүемә ярты ай менә.

—Ходаем, ярты ай!..

—Аңламадым. Ни дисез?

—Сезгә рәхмәт әйтмәкче идем, Федор Андреевич. Мин бүген үк юлга чыгам. Хәерле сәфәр теләгез, яме?

...Кукмарага төшүчеләр күп түгел иде. Тиз арада алар да үз юллары белән китеп бардылар. Ә шыксыз, ярым караңгы вокзалда җан әсәре сизелми. Шулай да кашагасына "Касса" дип язылган форточканы кагарга булдым.

—Кем борчый бу вакытта? Ни кирәк?—диде тупасрак хатын-кыз тавышы.

—Мин Казаннан идем...

—Хет җиһаннәмнең үзеннән бул—мине генә борчыма! Күзең чыкмагандыр ич—расписаниене укы! "Биредә Казанга үтүче поездларның бары берсе—иртәнге 5тәгесе генә туктый" диеп алагаем хәрефләр белән язылган белдерүне дә күрерсең. Менә шул: биш тулганда кил!

—Карагыз әле, ханым! Миңа билет кирәкми бит. Башлыгыгызның адресын гына сорамакчы идем.

Форточкада, ниһаять, яңа гына мичтән чыккан күмәч кебек кызарынган чырай күренде. Аның күзләре исә минем күн плащымны, кулымдагы сумка-портфелемне капшап үтте. Аннары "баллы-майлы" сүзләре тезелде:

—Ай, Аллам, сразы башлык! Гозерегезне бәлки үзем генә дә үти алырмын. Йомышыгыз ни иде соң? Төнката башлыкны борчырга да кирәк булмас, бәлкем.

—Төн ката дип... Тугыз да тулмаган бит әле. Мин аларда озаклап утырырга җыенмыйм: тимер юл, станция-вокзал мәйданына беркетелгән милиционерлар турында белешмә генә алмакчы идем.

—Һи, андый гына белешмәне без үзебез дә бирә алабыз аны.—Һәм ул борылып кемгәдер эндәшеп алды.—Шулай бит, Фәһимә? Менә чәй эчә-эчә гәпләшик, алайса. Казан үзе ерак ара булмаса да, юл барыбер арыта ул. Үтегез безнең бүлмәгә. Чәйне кайнарлатып кына алабыз менә...

Чәй табыны янында мин боларга үземнең нинди гозер белән йөрүемне, Федор Андреевичтан ишеткәннәремне сөйләп алдым. "Ревизия-мазар"түгеллегемне белгән ханымнарның йөзләренә елмаю кунды, телләре ачылды. Фәһимә исемлесе кычкырып ук җибәрде:

—Бәй, күрдем бит мин сезнең ул этегезне, билләһи, күрдем. Башлык бүлмәсен җыештырганда милиционер Фәрит килеп кергәч тә мин ул этнең күзләренә игътибар иттем. Тач кеше күзләре инде менә! Шунда әле башлыкның: "Бер наркоманны да тота алмадың инде, ә?"—дип төрттерүенә дә Фәрит: "Аның каравы менә дигән "бер билетсызны" эләктердем,—дип, кочагындагы шул этә күрсәтте.—Плацкарт вагонның ятак-диванын күтәреп җибәрсәм, тәрәзә янындагы почмакта күзләрен мөлдерәтеп утыра бит, әй. Хәзер инде без ул наркотикларны икәүләп эзләячәкбез",—диеп мактанды. Чын инде, чын—этегез Фәритләрдә. Ул аны кочагыннан да төшереп тормады, өенә апкитте.

—Ә өйләре... кайсы тирәдә?

—Якын гына, үзәк урамга чыгучы тыкрык башында. Аны урамның эте дә, бете дә белә. Ләкин бүген сез аларга барып йөрмәгез инде. Фәрит салгаларга ярата; холыксыз да диләр әле үзен. Бүген дә мин аны эчкән килеш күрдем. Иртән сигезләрдә барсагыз, ул чакта әле айнык булыр...

...Кассир ханымның киңәшен тотып, мин иртәнге сигез тулганда кирәкле капканың төймәсенә бастым.Һәм дулкынланып көтә башладым...

Ниһаять, капка яртылаш ачылды һәм каршымда дүрт-биш яшьләр чамасындагы бала пәйда булды. Зурларча кыяфәт, хәтта бер кулы белән биленә таянган. Ә күзләрендә... кызыксынучан күзләрендә сораулар биешә: "кем син?", "кайдан син?", "сиңа ни кирәк?.."

—Мин кунак апа булам. Ә синең исемең ничек?—дим һәм танышырга кулымны сузам.

—Малат.

—Ә әтиең ни атлы?

—Фәлит.

—Малат, Фәлит,—дип, мин дә аны кабатладым.—Чын ир-егетләр исеме икән.

—Үлтәшсәң сүләшмим. Малайлап үлтәшкәнгә бакчага да балмыйм.

Оялуымнан колакларымның да кызаруын тойдым. Үкенү-тәүбәм үзәккә үк үткәндер, мөгаен, инде мин баланың сөйләшүенә матур дефект өстәүче ул "л" хәрефен "р" хәрефе итеп кенә ишетә башладым.

—Гафу ит мине, ачуланма, зинһар! Ялгыш кабатладым бит; ялгыш кына, ышанасыңмы? Ә исемнәрегез ошады, чын менә. Әтиең... ул үзе өйдәме соң?

—Әти дә, әни дә эштә. Ә Венера апа мәктәптә.

—Мәктәпкә йөрерлек апаң да бармыни?

—Беренчедә укый.

—Син мине өегезгә чакырмыйсыңмы соң? Кунакны капка төбендә тоту бер дә килешми инде. Икәүләп Казан чәкчәге белән чәй дә эчәрбез, ә?

—Син Казаннан килдеңме? Минем дәү әнием дә Казанга китте. Дәү апамның җылы өендә кыш чыга.

—Шулаймыни? Сагынгансыңдыр инде?

—Ие...

Бу мизгелдә миңа бик тә якын булып тоелган ошбу бәләкәчне җитәкләп алдым да, капкаларын бикләдем.

—Өегезгә керик. Син миңа дәү әниең турында сөйләрсең, яме?

...Чәй кайнаган арада мин баланың дәү әнисе турында сөйләгәннәрен тыңлый-тыңлый, бүлмәләрне дә, чолан, гараж, сарайларны да карап чыктым. Эт яшәгәнлеге бер генә җирдә дә сизелмәде.

—Әтиең... әллә маэмайны да эшкә үзе белән алып йөри инде?

—Матуркайны әйтәсеңме?

—Матуркай? И-и, бигрәк матур икән исеме дә.

—Мин Матуркай дидем дә, әтием, әнием дә аңа шулай эндәште.
"Эндәште..." Үткән заманга ишарәләүче бу сүз мине өшетеп җибәрде һәм... һәм мин:
—Ә хәзер... хәзер ничек эндәшәләр соң?—диюемне үзем дә сизми калдым.
—Хәзер Матуркай юк бит инде. Әни белән без аны качырдык ла.
—Шулаймыни? Кая качырдыгыз соң?
—Өенә кайтарып җибәрдек.
Күрәм: баланың иреннәре бүсәйде, күзләрен яшь пәрдәсе каплады. Мин аны кочаклап алдым да, үзем дә күңелемнән "Кайтмады бит, кайтмады шул өенә" дия-дия, күз яшьләремә буылдым.
—Ә син нигә елыйсың? Минем Матуркайны әллә беләсеңме?
—Беләм шул, Марат, беләм. Матуркаең—минем маэмаем ул. Исеме Тэтчер аның. Ижаудан, урлаучыларыннан качып үз өенә, Казанга, минем янга, абыйсы янына кайтырга чыккан иде ул. Ике ай буе кайта инде. Тик һаман кайтып кына җитә алмый. Поездга утыра гына, тагын төшерәләр; утыра гына, янә төшерәләр. Менә тагын. Инде кайтып җитәм, инде кайтып җитәм дигәндә генә, әтиең алып төшкән аны.
Гаепле кешедәй малай башын иде. Мин аны тынычландыра торган сүз әйтергә ашыктым.
—Ярый әле кунак иткәч тә кайтарып җибәргәнсең. Рәхмәт инде. Матуркайны әйтәм, синең яннан китәсе дә килмәгәндер әле. Әтиең белдеме соң?
—Жу-ук. Әти белсә, әни белән икебезне дә кыйный. Ә син әйтмәссеңме аңа?
—Әйтмим, билгеле.
—Әти Матуркайны үзе качкан дип уйлады. Матаена атланып өч көн буе эзләде.
—Маэмайның киткәненә өч көн булдымыни инде?
—Әнә, стенадагы календарьга кара! Кызыл түгәрәкне күрәсеңме? Венераның туган көне ул. Менә шул төндә әти исереп кайтты. Ул йокыга киткәч, качырып җибәрдек.
Мин ян стенага борылам һәм кызыл каләм белән боҗрага алынган көн саныннан күземне ала алмыйм: 25 октябрь! Ә бүген... бүген 30ы инде. Шушы биш көн эчендә тагын нинди генә маҗараларга юлыкмагандыр да, нинди генә газаплар күрмәгәндер ул, йә Хода!..
Әйе, ун көнләп биредә, бу бала янәшәсендә яшәгән, димәк. Ничек яшәгән? Ана белән баланың аңа качарга булышулары тагы... Монысын ничек аңларга?..
Ошбу сорауларга җавапны каршымда ук утыручы шушы бәләкәй генә малай белә бит инде. Бәлки әле сөйләп тә бирер. Йөрәгенә ачкыч таба алсам, билгеле...
—Телисеңме, Марат, мин сиңа хәзер Матуркаең турында сөйлим, ә?
—Ие, —ди балакай ышаныр-ышанмас кына, ә үзенең күзләрендә очкыннар йөгерешә.
—Кышның бик тә, бик тә салкын бер көнендә аны, ягъни бәп-бәләкәй генә эт баласын минем улым коридорыбызны җылытып торучы батарея астыннан табып алып керде. Синең бияләй хәтле генә бу көчек әкиятләрдәгечә тиз-тиз генә үсә, минем ни теләгәнне сизә, нәрсә уйлаганны белә, сөйләшкән һәр сүзне аңлый башлады. Мин кухняда аш пешергәндә, мәсәлән, Тэтчер күренми, йоклыйдыр инде дип уйлый гына башлыйм, ул шундук йөгереп килеп җитә. "Йокламыйм, менә ич мин! Сиңа комачауламас өчен генә яныңа килмәдем" диеп, янәдән китеп бара. Ә бермәлне кич, бик соң гына телеграмма китерделәр. Ташкенттагы энебез кунакка кайта икән—самолетны каршылавыбызны үтенгән. Аны каршылау өчен мин иртәнге сәгать 5тә торырга тиешмен. Ничек уянырмын инде, будильник та ватык ичмаса дип уйлап, мин йокларга яттым. Бу юлы да мине Тэтчерым уятты. Стенага күз салсам, сәгать теле нәкъ менә "5"не күрсәтә... Ә гадәттә маэмай мине һәркөн иртән төгәл алтыда уята.
—Чынмы? Ә ничек уята?—ди Марат, көмеш кыңгырау чыңнары чыгарып көлә-көлә.
—Ничек уятамы?.. Йокы бүлмәсенә керә дә, ирен-борыны белән беләгемә

кагыла. Уянырга иренсәм, җәймәмне өстери.

—Ә син торгач, нишли ул?

—Торгач та без әле аның белән узыша-узыша чабып Казансуга су коенырга төшәбез. Мин йөзәргә яратам. Ә маэмай алданрак чыгып, кагына-кагына мине көтә. Комлыкта куыша-куыша уйнап арыгач кына өйгә кайтабыз.Әнә шулай җәй буе без иртә-кичен су коендык. Ә көзен... урладылар үзен.

—Кызык, сәгать алты икәнне каян белә икән Матуркай? Беренче көнне мине дә алтыда уяткан иде ул. Әти икебезгә дә каеш белән сыдырды. Шуннан соң әти эшкә киткәч кенә уята башлады.

—Шулай усалмыни әтиең?

—Усал. Ул Матуркайны наркотик эзләргә өйрәтмәкче булды. Каты характерлы эт тәрбиялим дип котырынды. Әллә нинди папирослар иснәтеп интектерде.

—Ә әниең? Әниең нәрсә ди иде соң?

—Яклаша. Түлке әти әнине тыңламый. Ул безне, мине дә, Матуркайны да, әнине дә яратмый. Күрше кызы Гөлнурны гына ярата.

Мин телсез калдым. Карасана, малайның бәләкәй генә йөрәгенә зурлар да күтәрә алмаслык хәсрәт тулган бит, Ходаем. Ничек юатырга, ни әйтергә дә белмичә:

—И-и, күршеләрне яратырга, алар белән әйбәт сәйләшергә кирәк инде ул,—дигән булдым.

—Белмәдең. Гөлнур безгә гел әни юкта, әти обедка кайткач керә. Аннары үбешәләр.

—Күршене үбү—гаеп саналмый инде ул.

—Гаеп шул. Әнә Матуркай аларны үбештермәде.Урталарына кереп басты да: "Оятсызлар!"—диде.

—Ничегрәк итеп әйтте инде ул аны?

—Бәй, белмисеңмени? Өрми бит Матуркай. Ә ул көнне "һа-у" диде. Аның оятсызлар диюен әти дә, Гөлнур да аңлады. "Абау, күзләреннән оялам бу этеңнең", диеп Гөлнур чыгып качты. Әти каеш белән Матуркайны кыйнады. "Тимә аңа" дигәч, миңа да сукты. "Әниеңә әйтсәң, телеңне кыскартырмын", диде. Матуркайны гаражга бикләп куйды да, ачкычны кесәсенә салды.

—Әйттеңме соң әниеңә?

—Мин әләкче түгел лә.

—Матуркайны уйлыйм, бик-бик гарьләнгәндер инде. Горур бит ул; гаделсезлекне бер дә яратмый. Ун көн буена түзүенә, качмавына да бик гаҗәпләнәм.

—Мине жәлләде ул. Качырган өчен әтинең мине кыйнасын белде. "Тоткын булып ятмасын, өенә кайтып китсен; бар, вокзал янында калдырып кайт үзен", дигән иде әни дә бер көнне. Миңа ияреп кайтты, китмәде ул көнне. "Бик акыллы шул Матуркай. Безне кызгана, авырлык китерәсе килми. Җае чыгар әле, барыбер ярдәм итәрбез үзенә. Әтиең өйдә вакытны качудан баш тартмас ул, мөгаен", дигән иде әни, тәки дөрес булды.

—Бая син, төнлә качырдык, дип әйттең түгелме?..

—Бәй, төнлә булмыйча! Әти эштән төнлә генә кайта ла. Венераның туган көнендә дә төнлә кайтты. Ул йоклаганда әни аның кесәсеннән гаражның ачкычын алды. Матуркайга күп итеп пешкән ит, кыздырылган балык ашаттык. "Бар инде, бар; өеңә кайт!"—дидек. Нык сөенде Матуркай. Әнине дә, мине дә үбеп, рәхмәт әйтте. Ул киткәч, капканы да, гаражны да бикләп куйдык. Әни ачкычны да урынына, әтинең кесәсенә салды...

Күрәм: бала читкә борылды. Һәм мин аның мышык-мышык елаганын ишеттем.

Эчке киеренкелек белән яшәвеннән бушану инде бу дип фаразлап алдым һәм... һәм бик нык ялгыштым.

Ул көчкә-көчкә тыелып:

—Ач бит инде Матуркай. Венераның туган көненә дә әнә әллә ничә көн үтте. Кайтып җитмәгән бит һаман. Һаман юлда да юлда. Ачтан үлмәс микән ул?—диде дә, үксеп тә җибәрде.

—Җә инде, җә, борчылма алай! Үлми ул ачка, үлми—мена күрерсең!..

Һәм мин, бәләкәй дустымны юатырга теләп, Тәтчерым юлда тап булган

мажараларның берсен—ачлык белән бәйлесен сөйләргә булдым.

—...Ул көнне дә маэмай поездга кача-поса гына утыра. Элеккечә үк, вагонның утыргычы астына яшеренеп ята. Менә бермәлне аның борынын бик тә тәмле ризык исе кытыклый башлый. Муенын сузыбрак караса, синең кебек малай белән юан бер хатынның кыздырылган тавык ите ашап утыруларын күрә. Малайның кулында—тавык боты, җитмәсә. Бик тә, бик тә ач маэмай, билгеле инде, түзеп тора алмаган, юан хатынга күренмичә генә, борыны белән малайның аягына төрткән: сыйламыйсыңмы, минем дә ашыйсым бик килә бит—дию инде бу. Акыллы малай шундук аңлап ала, һәм тәмле-тәмле ит калҗаларын яшереп-яшереп кенә маэмайга да суза. Ә бер сузуында... тавык боты шап итеп идәнгә төшә. Утыргыч астына тәгәрәгән әлеге ботны алырга иелгән хатын маэмайны күреп ала һәм... һәм шундук: "Эт вагоны! Балакаем харап булды! Барыгызны да эштән кудырам",—дип чәрелди-чәрелди сөрән сала.

Ә маэмай... ул борынын малайның кулына тидереп рәхмәт әйтә дә, әлеге җәнҗалчы хатынга борылып та карамыйча поездан төшеп кала.

—Каян белдең?

—Шул поездның машинисты сөйләде... Кайтыр юлларында тагын әнә шул малай кебек, синең кебек... әйбәт-әйбәт кешеләр очраса, алар үз ризыкларыннан маэмаебызга да өлеш чыгарырлар, һәм Матуркай исән-сау кайтып җитә алыр, шулай бит?!.

Бала эндәшмәде.

Автобуска ашыгуымны әйтеп, мин аны кочаклап алдым.

...Бикләнгән капка аша малайның бик тә, бик тә моңсу тавышы ишетелде:

—Ә син... Матуркай белән безгә кунакка килмәссеңме?

—Матуркай кайту белән мин сиңа шалтыратырмын. Көт, яме?!.

*Ахыры киләсе санда.*

---

# КУЕН ДӘФТӘРЕНӘ

Мәхәббәт чирен дәвалап булмый.

*А. Пушкин.*

Ихтирамсыз мәхәббәт ераккка бара алмый, биеккә күтәрелә алмый, ул — бер канатлы фәрештә.

*А. Дюма (өлкәне).*

Киртәләрдән курыккан мәхәббәт — мәхәббәт түгел.

*Д. Голсуорси.*

Үзең ихтирам итә алмаган кеше белән беркайчан да дуслашма.

*Ч. Дарвин.*

Беркайчан да газап чикмәгән җан бәхеткә ирешә алмый.

*Ф. Кафка.*

Чын мәхәббәт булган җирдә сүзләргә урын тар.

Мәхәббәт телсез булып калуны өстен саный, чөнки сүзләр артык көчсез һәм артык тупас.

*Ш. Хөсәенов.*

## Равил Сабиров



Равил Сабыр (Равил Рәсим улы Сабиров)—1974 елны Минзәлә районы Тупач авылында туган. 1976 елда Сабировлар гаиләсе шушы ук районның Наратлы Кичү авылына күчеп утыра. Биредә үсеп, мәктәпне тәмамлаганга Равил Тупачны да, Наратлы Кичүне дә туган авылы дип саный.

Максатчан рәвештә язу эшенә Равил 15 яшендә керешә. Аның авыл тормышы жирлегеннән чыгып, ул еллар өчен хас булган проблемаларны ассызыклаган мәкаләләре район газетасында, Чаллыда чыга торган «Таң йолдызы» газетасында, «Татарстан яшьләре»ндә һәм «Социалистик Татарстан» газеталарында еш басыла.

1990 елда Равил Казан дәүләт университетының журналистика, социология һәм психология факультетына укырга керә.

1991 елда «Татарстан хәбәрләре» газетасында аның беренче хикәясе ("Хулиган") басылып чыга.

1992 елдан башлап ул Казан университетында белем алуы белән беррәттән, «Татарстан яшьләре»ндә эшли башлый. Үзе хезмәт куйган газетада, «Идел», «Чаян» журналларында бер-бер артлы хикәяләре басыла.

1995 елда, университетта укуын тәмамлагач, Р. Сабыр Чаллыга китә, шәһәр хакимиятенең матбугат үзәге белгече булып эшли башлый. 1997-1998 елларда ул «Аргамак» журналының баш мөхәррире.

1998 елда аны янә Чаллы шәһәр хакимиятенә эшкә чакыралар һәм матбугат үзәге житәкчесе итеп билгелиләр.

2000 елларда Равил иҗат эше белән ныграк шөгыльләнергә карар кыла. Шул ук вакытта «Вечерние Челны», «Восточный экспресс», «Минем Чаллым» газеталарында эшли. Хәзерге вакытта—«Челнинская неделя» газетасының баш мөхәррир урынбасары.

2004 елда үткәрелгән «Яңа татар пьесасы» бәйгесендә «Земфиракай, сылуым, аппагым!» пьесасы белән катнашып, Равил Сабыр лауреат исеменә лаек булды. Ә 2007 елның октябрендә Чаллы татар дәүләт драма театры аның "Яшел һәм кызыл" пьесасын сәхнәләштереп "Хәят" исемле спектакль премьерасын күрсәтте. Пьеса Фатих Әмирханның "Хәят" әсәре һәм Гаяз Исхакыйның «Татар гакылы» хикәясенә нигезләнеп язылса да, Равил Сабыр яңа мөстәкыйль әсәр тудыра алган, дип яздылар тәнкыйтьчеләр. «Хәят» спектакле күпсанлы тамашачыларның һәм театр белгечләренең игътибарын җәлеп итә алды. Ул бүген дә Чаллы татар дәүләт драма театры сәхнәсендә куела әле. Равил, шулай ук, 2007 елда үткәрелгән "Яңа татар пьесасы" конкурсында җиңүчеләрнең берсе булды.

2008 елның 25 гыйнварында Туфан Миңнуллин, Ркаил Зәйдулла, Вахит Имамов, Ләбиб Лерон тәкъдимнамәләре нигезендә Кабул итү комиссиясе һәм Идарә Равил Сабырны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алу турында карар чыгарды.




*Җиңү көненә багышланган җыелыштан күренеш. Президиумда—сулдан уңга: мөнбәрдә—М. Вәлиев (КПСС өлкә комитеты секретаре), В. Нуруллин, С. Хәким, Г. Ахунов, А. Шамов, Т. Журавлев, Р. Ишморат, Н. Арслан, генерал Ф. Булатов, М. Мусин (КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире). 1981 ел.*



*Уфадан очып дуслар килде. Алгы планда—Мостай Кәрим, арттарак—Нәҗар Нәҗми, Рафаэль Сафин. 1976 ел.*



*Шагыйрь Гадел Кутуй. 1944 ел.*



*Кызык хәл! Сулдан уңга—Әхмәт Исхак, Гариф Ахунов, Фатыйх Хөсни. 1964 ел.*



*Риза Фәхретдин музеена төрле төбәкләрдән килгән бер төркем зыялылар. Әлмәт районы, Кичучат авылы. 2000 ел.*

# Татарстан Республикасы Президенты УКАЗЫ

**2008 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирү турында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комиссиясе тәкъдимнәрен карагач, шулай ук Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә башлауга 50 ел тулу уңаеннан, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комиссиясе (алга таба—Комиссия) тәкъдимен кабул итәргә һәм 2008 елда, искәрмә буларак, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге дүрт Дәүләт премиясен бирергә:

2. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен түбәндәгеләргә бирергә:

**М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының түбәндәге составтагы иҗади төркеменә:** Ахиярова Резедә Зәки кызына (композитор), Агади Әхмәт Эльтифат-Оглына (төп партияне башкаручы), Соболев Виктор Евгеньевичка (дирижер), Панджавидзе Михаил Александровичка (режиссер)—"Шагыйрь мәхәббәте" операсын сәхнәгә куйган өчен;

**Фәтхетдинов Салават Зәки улына**—соңгы еллардагы концерт программалары һәм "Мин яратам сине, Татарстан!" җырын башкаруы өчен, әлеге җыр авторлары—Андреев Роберт Егоровичка һәм Рәкыйпов Роберт Җиһангир улына (үлгәннән соң);

**Гатауллин Рәдиф Кәшфулла улына**—"Газәлләр" ("Мәгариф" нәшрияты, Казан, 2001 ел), "Мәңгелек сусау" ("Рухият" нәшрияты, Казан, 2005 ел) китаплары өчен;

**Аршинов Виктор Петровичка**—"Тукайны укыганда" ("Читая Тукая") һәм М. Җәлилнең "Моабит дәфтәрләре"ндәге шигырьләр буенча эшләнгән "Соңгы җыр" ("Последняя песня") графика серияләре өчен.

3. Әлеге Указ кул куелган көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **М. Ш. ШӘЙМИЕВ**

Казан, Кремль
2008 ел, 25 апрель, № ПУ-167

## ТУКАЙ ПРЕМИЯСЕНӘ 50 ЕЛ

Г. Тукайның әдәби музеенда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә башлауга 50 ел тулуга багышланган «Әйдә, халыкка хезмәткә!..» дигән әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Анда төрле елларда әлеге зур бүләккә ия булган әдәбият-сәнгать эшлеклеләре, аларның иҗатларын хөрмәт итүчеләр җыелган иде.

Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе 1958 елның 10 апрелендә ТАССР Министрлар Советы карары нигезендә гамәлгә кертелә. Әлеге карарда: «Бу премия эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше ягыннан иң яхшы булган әдәбият, рәсем һәм музыка әсәрләренә, театр һәм концерт оешмаларында башкару сәнгате өлкәсендәге зур уңышлар өчен, шулай ук архитектура өлкәсендәге оригиналь һәм экономияле хезмәтләр өчен бирелә»,—дип язылган. 1961—1965 елларда премия бирелү тукталып тора, ә 1975 елда кандидатлар арасында премиягә лаеклар табылмый. Бүгенге көндә бөек шагыйребез исемендәге премиягә 159 шәхес һәм бер коллектив—Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле лаек булды. Лауреатлар арасында—шагыйрьләр, язучылар, галимнәр, җырчылар, композиторлар, рәссамнар, скульпторлар, архитекторлар, режиссерлар һәм театр артистлары бар.

Яңа лауреатларның исемнәре һәр елны бөек шагыйрь туган көн алдыннан ТР Президенты Указы белән игълан ителә. Лауреатларга билге, диплом һәм акчалата бүләкне соңгы елларда Республика көнендә, ягъни 30 августта тапшыру традициягә әйләнде.

## МӘДӘНИЯТ КӨНЕ БӘЙРӘМЕ

Россия Президенты тарафыннан 25 март Мәдәният хезмәткәрләре көне итеп игълан ителде. Быел ул беренче мәртәбә үткәрелде. Шул уңайдан С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында республиканың мәдәният хезмәткәрләре җыелды.

Әлеге бәйрәм белән Премьер-министрның беренче урынбасары Равил Моратов тәбрикләп, бер төркем сәнгать әһелләренә мактаулы исемнәр, «Мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен» медале, Мактау грамоталары тапшырды.

Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева: «Безнең сәнгать коллективлары төрле төбәкләрдә уңышлар яулый. Татарстанның тарихи архитектура һәйкәлләре ел саен күбрәк туристларны җәлеп итә»,—диде. Ул республиканың мәдәният хезмәткәрләренә үзенең котлавын ирештерде. Тантанада китапханә, музей хезмәткәрләре, ветераннар да катнашты. Тәбрикләүләр исә җыр, бию белән үрелеп барды. Зур концертта безнекеләр белән бергә Мәскәүдән килгән мәшһүр җырчылар да чыгыш ясады.

## ТЕАТР ӘҺЕЛЛӘРЕ ХӘТЕР ЯҢАРТТЫ

М. Сәлимҗанов исемендәге Актерлар йортында Татарстан Республикасы Театр әһелләре җәмгыятенең 70 еллыгы һәм Актерлар йортының 40 еллыгы уңаеннан тантана булып узды. Анда Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева катнашты.

Бөтенроссия театр әһелләре җәмгыятенең Татарстан бүлеге 1938 елда оеша. Бу вакытта ул 51 иҗат әһелен берләштерә. Аны төрле елларда татар һәм рус театрларының күренекле артистлары Д. Любин, Х. Әбҗәлилов, Н. Гайнуллин, М. Булатова һ. б. житәкли. Театрыбыз тарихын өйрәнү, Идел буе, Урал, Урта Азия театрлары белән элемтәләр урнаштыру, Россия күләмендә конференцияләр уздырып, Россия иҗатчыларының игътибарын татар театрына юнәлтүдә Театр әһелләре берлегенең роле бик зур. Әлбәттә, эшчәнлекне киңрәк җәелдерү өчен сәнгатькярләргә үзләренә аерым йорт кирәк була.

Һәм бу көннәрдә Актерлар йорты төзелүгә дә 40 ел тулды. 1988 елның 24 октябрендә элеккеге оешма нигезендә Татарстан Театр әһелләре берлеге барлыкка килә. Шул ук елда идарә рәисе вазыйфаларын ару-талуны белми башкарып килгән актриса Р. Җиһаншинаны Г. Камал театрының күренекле актеры Р. Тажетдинов алыштыра. Ул бүген дә рәис вазыйфаларын уңышлы башкарып килә. Моннан 6 ел элек Актерлар йортына мәшһүр режиссер М. Сәлимҗанов исеме бирелде. Ә бу юбилей көннәрендә йорт диварына М. Сәлимҗановка истәлек тактасы куелды. З. Вәлиева театр әһелләренә Президент М. Шәймиевнең юбилей уңаеннан котлавын да укып ирештерде.

## ЙОМГАК ЯСАЛДЫ

27 мартта—Халыкара театр көнендә бишенче тапкыр үткәрелгән «Яңа татар пьесасы» бәйгесенә йомгак ясалды. Жюри бәйгегә килгән 39 пьеса арасыннан иң яхшы 10 драма әсәрен сайлап алган. Алар арасыннан драматурглар Хәбир Ибраһим һәм Рәдиф Сәгъди бергәләп иҗат иткән «Кияү абый» пьесасы, Нурания Җамали һәм Халисә Ширмәннен «Мәхәббәтнең соңгы көне» пьесасы, Эльвира Ибраһимованың «Адашкан язмышлар» әсәре кызыксындыру бүләкләренә лаек дип табылды. Язучы, драматург Эсфир Яһудин берьюлы ике бүләккә—«Тәхет» әсәренең матур тел белән язылуы һәм «Былтыр кыз» әсәре өчен—3-4 яшьлек балаларга атап язылган әсәрләргә «Җыен» мәдәниятне үстерү фонды тарафыннан тәгаенләнгән бүләккә ия булды. Өченче премия «Тимерчыбык мажаралары» пьесасын язган Йолдыз Миңнуллина һәм Сөмбел Гаффаровага бирелде. Икенче премияне «Теләк» дип

исемләнгән әсәре өчен Равил Сабыр алды. 35 яшькә кадәрге яшьләр өчен күренекле драматург Туфан Миңнуллин тарафыннан тәгаенләнгән махсус бүләккә «Бәби» әсәре өчен Илгиз Зәйниев лаек булды. Илгизгә бәхет ике мәртәбә елмайды. Ул «Люстра» пьесасы өчен Мәдәният министрлыгының махсус бүләген дә алды. Беренче бүләкне жюри «Мылтык» пьесасын язган драматург Зөлфәт Хәкимгә бирде.

Жюри рәисе, академик Миркасыйм Госманов әлеге бәйгедә әсәрләрнең сыйфат ягы үсүен, темаларның киңәюен билгеләп үтте. Балалар өчен әсәрләр иҗат ителә башлавы җәһәтеннән сөенүен әйтте. Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева «Яңа татар пьесасы—2007» бәйгесендә психологик, социаль-лирик пландагы әсәрләрнең күренә башлавын уңай күренеш дип бәяләп үтте.

Алга таба үткәреләчәк «Яңа татар пьесасы» бәйгесендә 1, 2, 3 нче премияләр күләмен 200, 150, 100 мең сумга кадәр күтәрү күздә тотыла.

## ХЕЗМӘТТӘШЛЕК КИҢӘЕР

Татарстан Республикасы Премьер-министры Рөстәм Миннеханов ТР Министрлар Кабинетында Иран Ислам Республикасы дәүләт телевидение һәм радиосы рәисе Сәед Эзаталла Заргами белән очрашу үткәрде.

Очрашуда мәдәният, кино һәм телевидение өлкәсендә хезмәттәшлек перспективалары турында фикер алышынды.

Очрашу кысаларында Иран Ислам Республикасының дәүләт телевидение һәм радиосы белән «Яңа Гасыр» ТРК арасында хезмәттәшлек турында килешү төзелде.

## КИНО БЕЛГЕЧЛӘРЕ БЕЗДӘ ҮСӘЧӘК

Агымдагы елдан Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты базасында эшләүче Театр, кино һәм телевидение институтында кино һәм видеосәнгать бүлегенә студентлар кабул ителәчәк. Әлеге бүлектә 5 ел укып чыккан студентлар кино һәм видеоиҗат студиясенең житәкчесе, укытучы белгечлеге алачак. Булачак кино хезмәткәрләрен танылган белгечләр укытыр дип планлаштырыла. Бүлекнең җитәкчесе итеп Министрлар Кабинетының мәдәният һәм ТР халыклары телләрен үстерү бүлеге башлыгы, Татарстанның халык артисты Рамил Төхфәтуллин билгеләнгән. Абитуриентлардан гаризалар кабул итү 15 июньнән башланачак.

## КҮРГӘЗМӘДӘН БАЕП КАЙТТЫЛАР

Мәскәүдә XI милли «Россия китаплары» күргәзмә-ярминкәсе булып узды. Анда катнашкан 600 нәшрият һәм полиграфия фирмасы арасында Казаннан «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы да бар иде. Быелгы форум «Россия китаплары—Гаилә елына!» шигаре астында үтте. Татарстан полиграфчылары экспозициясе зур кызыксыну уятты, бигрәк тә «Тыюлыклар», «Татарстанның спорт казанышлары», «Жир хартиясе», «Чаллы энциклопедиясе» кебек басмалар күпләрнең игътибарын җәлеп итте. «Идел-Пресс» коллективына хас һөнәрмәндлек, югары сыйфат, оперативлык казанлыларга «Дрофа», «Карапуз», «Глобус», «Поколение», «Дашков и Ко» кебек абруйлы нәшриятлар белән файдалы килешүләр төзергә мөмкинлек бирде. Якынча нәтиҗәләр буенча, «Идел-Пресс»ның заказлар портфеле 130 миллион сумга баеды, әлеге акчага 600 мең данәдән артыграк китап бастырылачак.

## ҖИҢҮ ЯУЛАДЫ

Мәскәүдә ундүртенче мәртәбә уза торган «Алтын битлек» конкурсына Россиянең төрле төбәкләреннән 52 спектакль тәкъдим ителгән иде. Анда композитор Резедә Ахиярова тарафыннан язылган «Шагыйрь мәхәббәте» операсында Тукай партиясен башкарган өчен Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Әхмәт Агади «Операда иң яхшы ирләр роле» дигән төрдә җиңү яулады.

Әсәрнең премьерасы моннан ике ел элек М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында булган иде.

## ТУКАЙГА ЧӘЧӘКЛӘР

Быел бөек шагыйребез Габдулла Тукайның вафат булуына 95 ел тулды. Күркәм гадәт буенча, Казанның Яңа татар бистәсе зиратында быел да хәтер яңарту мәрасиме үткәрелде. Анда әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, мәдәният хезмәткәрләре, дин әһелләре һәм шигырь сөючеләр катнашты. Хәтер җыенында катнашучылар алдында Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, шагыйрь Ш. Галиев Тукай җәмгыяте рәисе, профессор Х. Миңнегулов, язучы М. Маликова, артистлар Э. Җәләлетдинов, И. Әхмәтҗан һ. б. лар чыгыш ясады. Тукай каберенә чәчәкләр куелды. "Хәтер" мәчетенең имам-хатыйбы Харис хәзрәт Салихҗан шагыйрь рухына дога багышлады. Хөрмәтләү мәрасимен Татарстанның халык шагыйре Р. Фәйзуллин алып барды.

## "МИНЕ ӘСӘРЛӘРЕМНӘН ЭЗЛӘГЕЗ"

24 март көнне Г. Камал театры бинасында Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге ТР Дәүләт премиясе лауреаты Аяз Гыйлажевнең 80 еллыгына багышланган "Йөгез, бер дога" дип исемләнгән кичә булды. Аяз Гыйлажев—XX

гасырның икенче яртысындагы татар әдәбиятының иң колоритлы, язмышы һәм иҗаты белән гаять гыйбрәтле һәм үзенчәлекле әдипләрнең берсе. Әдипкә багышланган кичә дә эчтәлекле һәм сәхнә бизәлеше ягыннан үзенчәлекле иде. Репрессия елларында башлап язучы студент егеттән сорау алу күренешләре, сонрак—житлеккән әдипнең кешелеккә—яңа буыннарга куйган сораулары тамашачыларны тирән уйлануларга тартты. Сәхнәдә А. Гыйлаҗев әсәрләре буенча куелган "Яра", "Өч аршин җир", "Җомга көн кич белән" дигән спектакльләрдән Г. Камал, Әлмәт, Чаллы театры артистлары тарафыннан өзекләр күрсәтелде. Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, әдипнең Зәй һәм Сарман якларыннан килгән якташлары, Аяз Гыйлаҗевнең хатыны Нәкыя ханымга да үзләренең рәхмәтләрен ирештерде. Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева ана Президентның Рәхмәт хатын укыды. Язучының якын дусларыннан берсе булган академик Миркасыйм Госманов үзенең хатирәләре белән уртаклашты. "Мине әсәрләремнән эзләгез" дигән әлеге кичәнең сценарий авторы Ркаил Зәйдулла һәм шагыйрь Газинур Морат Аяз Гыйлаҗевка багышланган шигырьләрен яңгыратты.

## ӘДИПНЕ ИСКӘ АЛУ

20 мартта Актерлар йортында язучытәрҗемәче, мөхәррир-текстолог, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт, Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премияләре лауреаты Рәис Даутовның тууына 80 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе булып узды. "Яшәү яме" дип исемләнгән бу кичә үзенең эчтәлеге һәм самимилеге белән күпләрнең күңелендә калырлык итеп оештырылган иде. Әдипнең тормышы һәм иҗат эшчәнлеге турында аның замандаш дуслары, хезмәттәшләре, шәкертләре чыгыш ясады: М. Госманов, Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ, Л. Хәмидуллин, Р. Рахман, Л. Лерон... Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, Татарстан китап нәшрияты директоры Д. Шакиров, "Мәгариф" нәшрияты директоры М. Вәлиев, Г. Камал театры директоры Ш. Закиров... Кичәдә популяр җырчылар халык җырларын, атаклы композиторларыбыз әсәрләрен башкардылар. Сәхнәдән Р. Даутовның хатыны, классик драматург Г. Камал оныгы Диләрә ханым Даутованың да чыгышы яңгырады. Кичәне Татарстанның халык язучысы Р. Батулла алып барды.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬ

Шагыйрь һәм драматург Равил Бохараев, Англиядә яшәсә дә, Татар дәүләт «Әкият» курчак театры белән нык элемтәдә тора. Биредә аның «Су аты» (Водяной конь) дигән пьесасы буенча эшләнгән спектакль куелды. Драматург аны шотланд халык мифларына таянып иҗат иткән. Спектакль премьерасын күрү өчен автор үзе дә Казанга кайтты. Тәэсирләре белән уртаклашып ул болай диде: «Минем шушы күркәм театрда дүртенче спектаклем куела. Балалар өчен бик теләп һәм яратып иҗат итәм. Чөнки иң чиста, пакь күңел—балаларда».

Театр директоры Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Роза Җаббарова, кыскача язучы хакында сөйләп, аның элекке спектакльләрен искә алды.

Әсәрне сәхнәгә Татарстанның һәм Россиянең атказанган артисты И. Зиннуров куйган.

## СЕБЕРГӘ СӘФӘР

Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова Себердә озак вакытлы сәфәрдә булып кайтты. Ул Төмән, Омск, Новосибирск, Курган өлкәләрендә яшәүче милләттәшләребез белән очрашты, архивларда татар халкына кагылышлы эзләнүләр алып барды, мәктәп-китапханәләргә үзенең китапларын бүләк итте. Ул шулай ук Тубыл, Тара шәһәрләрендә халык белән очрашулар уздырды, үзенең "Күчем хан" дип аталган китабын һәм күренекле мәгърифәтче Габдрәшит Ибраһимовның "Дәүре галәм" әсәрен тәкъдим итү кичәләрендә катнашты. Ф. Бәйрәмованың Себергә бу сәфәрен оештыруда Бөтендөнья татар конгрессы ярдәм күрсәтте.

## КИТАПХАНӘЛӘРГӘ ЗУР БҮЛӘК

Апрель аенда Татарстан район китапханәләре өчен бик тә сөенечле вакыйга булды. Татар авторларының дүрт меңнән артык яңа китабы Зәй, Тукай, Сарман, Түбән Кама, Актаныш, Нурлат һәм Аксубай районнарында яшәүче китап сөючеләр карамагына тапшырылды.

Бу—Татарстан Дәүләт Советы депутаты, "Татэнерго" ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Илшат Фәрдиевнең китап укучыларга бүләге. Әлеге акция белән энергетик холдинг, Татарстан агросәнәгать өлкәсенә эре инвестицияләр кертүче генә түгел, әдәбиятсәнгать, гомумән, рухи үсешебез өчен дә зур иганәләр өләшергә сәләтле мәрхәмәтле оешма икәнлеген янә бер мәртәбә расла-ды. Әлеге китап байлыгын беренче чиратта "Агрокөч-Төркем" җәмгыяте эшли торган районнарның китапханәләре кабул итеп алды.

Бу вакыйгага багышланган тантана Зәйнең Сәббух Рафиков исемендәге үзәк китапханәсендә узды.

### ЯШЬЛЕГЕ КАЗАНГА БӘЙЛЕ

Светлана Коновалованың «Максим Горькийның эчке дөньясы. Язучы тормышында Казан шәһәре» дип исемләнгән китабын тәкъдир итү кичәсе булды.

Автор үз вакытында Горький музеенда эшләгән. Горький темасы буенча кандидатлык диссертациясен яклаган. Хәзерге вакытта ул Толстой музее директоры.

Китапта Горькийның Казанда яшәгән вакыттагы тормышын өйрәнүгә зур игътибар бирелгән. Анда XIX гасыр ахырындагы Казан шәһәре турында кызыклы гына мәгълүматлар тупланган. Бу вакытта А. Пешков университетлар юлын гына үтеп калмый, ә шәхес буларак формалаша. Язучы дөньяның төрле почмакларында булуга карамастан, Казан шәһәре аның язмышында мөһим урынны алып тора. «Мин Түбән Новгородта тудым, әмма рухи яктан Казанда чыныктым. Казан «университетларым» арасында иң яратканы»,—дип әйтә торган була. Горькийның Казанга багышлап язылган әсәрләре дә бар.

### БИГИЧЕВ ПРЕМИЯСЕ

ТР Мәдәният министрлыгы яшь вокалистлар өчен Хәйдәр Бигичев премиясен булдырырга карар итте. Татарстан Республикасының халык артисты, Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәйдәр Бигичевның истәлеген мәңгеләштерүче, академик һәм халык җырларын үстерү максатын күздә тоткан бу премия ел саен 15-30 яшьлек җырчыларыбызга тапшырылачак. Быел бу премия конкурсының жюри составына Зилә Сөнгатуллина, Мөнир Якупов һәм, әлбәттә, Зөһрә Сәхәбиева кертелгән.

### ИМАНЛЫ ЯШЬЛӘР ЯРЫШЫ

27-28 мартта башкалабыздагы Россия Ислам университетында ислам уку йортлары арасында гарәп теле һәм ислам дине нигезләре буенча беренче Бөтенроссия олимпиадасы уздырылды.

Татарстандагы уку йортларыннан тыш, анда Мәскәү Ислам университеты, Түбән Новгород Ислам институты, Уфадагы Россия Ислам университеты, М. Солтанов исемендәге мәдрәсә, Чечня, Кабардин-Балкар, Дагыстан Ислам институтлары шәкертләре катнашты. Ярышлар барышында Татарстан һәм Дагстан шәкертләренең аеруча яхшы әзерлекле икәнлеге ачыкланды. Нәтиҗәдә гарәп телен иң яхшы белүче итеп РИУ шәкерте Алмаз Сафин, дин нигезләрен иң әйбәт үзләштерүче дип Махачкаладагы Теология һәм дин белеме институты шәкерте Әхмәт Гаирбәкев танылды. Ярышта катнашкан бердәнбер кыз—"Мөхәммәдия" мәдрәсәсе шәкерте Галия Мөхәррәмова да егетләрдән ким түгел икәнен күрсәтеп, гарәп теле белүе буенча икенче урынны яулады.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Полиграфия һәм матбугат өлкәсендәге казанышлары, Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле һәм намуслы хезмәте өчен "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексы" ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Әхмәтҗанов Ислам Галиәхмәт улы** "Фидакарь хезмәт өчен" медале белән бүләкләнде.

### ЮГАЛТУЛАР

2008 елның 25 мартында күренекле педагог һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстан ФА академигы, журналыбызның элеккеге редколлегия әгъзасы һәм даими авторы **Мәхмүтов Мирза Исмаил улы** вафат булды.

2008 елның 13 апрелендә 80 яшендә танылган шагыйрь һәм прозаик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Кави Латыйп** (Кави Таһир улы Латыйпов) вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан тимер юл вокзалы.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Габдулла Галиев**.

# Яңа китаплар




**Даутов Р. Н.** Балачак әдипләре: Биобиблиографик белешмәлек. Дүртенче китап—Писатели нашего детства: Биобиблиографический справочник. Книга четвертая.—Казан: «Мәгариф», 2008.—255 б. Тиражы—2000 данә.


«Балачак әдипләре» сериясенең дүртенче китабында утызлап хәзерге заман татар язучысының тәрҗемәи хәлләре, иҗат эшчәнлекләре, әсәрләре турында мәгълүматлар, бала чагы белән бәйле хатирә язмалары татар һәм рус телләрендә бирелә. Китап-белешмәлек мәктәп укучыларына, укытучыларга, балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләргә һәм, гомумән, әдәбият белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.




**Шамил Маннапов.** Тормыш сиратлары: шигырьләр, поэмалар, җырлар.—Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2008.—239 б. Тиражы—2000 данә.

“Тормыш сиратлары”—күренекле шагыйрь һәм прозаик Шамил Маннаповның сайланма басмасы. Китап әдипнең 70 еллык юбилее уңае белән чыгарылган. “Тормыш сиратларын кичкәндә”, “Янган саен өмет янара...”, “Энә белән дәвалау” һәм “Шигъри багышлаулар” дигән бүлекләрдән торган бу китапка авторның төрле елларда язылган һәм аның иҗади йөзен билгеләүче әсәрләре сайлап бирелгән.

Китапта автор турында белешмә, аның әлегәчә нәшер ителгән китаплары исемлеге дә бирелгән.



Габдулла Галиев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZANUTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)